ISSN 0206-4189
Индекс 73210

# Казан утлары

1.2011





**Фатих Әмирхан**
**(1886—1926)**

# Казан утлары
# Qazan utları

2011

**1**
**(1059)**

**ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:**
*Татарстан хөкүмәте,*
*Татарстан Язучылар берлеге,*
*Редакциянең хезмәт коллективы*

**НАШИРЕ:**
*«ТАТМЕДИА» ачык акционерлык җәмгыяте*
*Казан, Академия ур.; 2*

татмедиа

*БАШ МӨХӘРРИР*

**Равил Габдрахман улы**
**Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*

**Рабит Батулла**
**Зилә Вәлиева**
**Разил Вәлиев**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Тәлгат Галиуллин**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркәтип)*
**Илфак Ибраһимов**
**Дамир Исхаков**
**Туфан Миңнуллин**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Гәрәй Рәхим**
**Розалина Шаһиева**
**Рәфикъ Юныс**
*(баш мөхәррир урынбасары)*

---

*Мөхәррирләр:* **Гөлзадә Бәйрәмова, Мансур Вәли, Рәдиф Гаташ, Рөстәм Галиуллин, Марат Закир, Камил Кәримов, Алмаз Хәмзин.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Радик Вәлиев, Лилия Гатауллина, Элеонора Җамалиева, Флера Сабирова.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Гөлнара Галиева** (баш бухгалтер), **Эльвира Камалова.**

---

✉: *420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.*
☎☎: *Баш мөхәррир—562-10-62.*
*Баш мөхәррир урынбасары—292-93-16.*
*Җаваплы сәркәтип, компьютер үзәге—562-11-28.*
*Шигърият, публицистика, фән һәм сәнгать бүлеге—292-39-63.*
*Чәчмә әсәрләр һәм әдәби тәнкыйть бүлеге—292-39-63.*
*Гамәли хезмәткәрләр—562-11-28.*
*Исәп-хисап бүлеге—222-09-80. kazanutlari@yandex.ru*
**Факс**—*(843) 562-11-28.*
**E-mail:** *kazanutlari@telebit.ru.*

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ–НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ–СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

Бу санда

**БАШ МӨХӘРРИР СҮЗЕ**

Равил ФӘЙЗУЛЛИН. Сыналабыз, әмма сынмабыз. 5

**ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР**

Әсгать САЛАХ. Үрләргә менгән чаклар. *Бораулаучы истәлекләре*. 6
Зиннур МАНСУРОВ. Тамыр буйлап ага хәтер... *Шигырьләр*. 42
Әхәт МУШИНСКИЙ. Һаваларда—ак күгәрчен... *Роман*. 50
Илдус ГЫЙЛӘҖЕВ. Онытмасагыз иде. *Шигырьләр*. 79
Рөстәм ГАЛИУЛЛИН. Өч хикәя. 84
Ханәфи БӘДИГЫЙ. И татарлар! *Шигырьләр*. 102
Мөнир ВАФИН. Дөньялар серле, серле... *Шигырьләр* 105

**ГОРУРЛЫК**

Польшада татарга һәйкәл куелды. *Польша президенты Бронислав Коморовскийның һәйкәл ачу тантанасындагы чыгышы*. 108

**Г. ТУКАЙНЫҢ 125 ЕЛЛЫГЫН КАРШЫЛАП**

Бөеклек баскычлары. 120

**САТИРИК ӘСӘРЛӘР КОНКУРСЫ**

Рөстәм ЗАРИПОВ. Яңартылган мәкальләр, әйтемнәр. 126

**ФӘН**

Раиф МӘРДӘНОВ. Мансур Хәлляҗ кыйссасы. 128
Фирдәвес ГАРИПОВА. Авылларыбыз тарихы. 141

**БЕЗНЕҢ МУЗЕЙЛАР**

Тарих калка гасыр түреннән... 145
Рашат НИЗАМИЕВ. Гасырлар белән күзгә-күз. 148

**ХӘТЕР**

Фәнис ЯРУЛЛИН. Хәтер төпләрендә утлы күмер. *Көндәлекләр*. 111
Азат ЗЫЯТДИНОВ. Такташ иленә ике сәяхәт. *(Һади Такташның тууына 110 ел)* 151
Тәлгат ГАЛИУЛЛИН. Шигърияткә багышланган гомер.*(Нил Юзиевның тууына 80 ел)* 166

**АК ҖИЛКӘН**

Рабит БАТУЛЛА. Бәләкәй Батулла. 169

**КИТАП КҮЗӘТҮ**

Хатыйп МИҢНЕГУЛОВ. «Татар кызы»—«Хәят юлында». 181

Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. 189

# В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

«Слово главного редактора»: «Испытания нас лишь закаляют».
«Проза и поэзия»: роман А. МУШИНСКОГО «Шейх и звездочет» (прод.); воспоминания А. САЛАХА «Будни бурильщика»; рассказы Р. ГАЛИУЛЛИНА;
стихи З. МАНСУРОВА, И. ГИЛЯЗОВА, Х. БАДИГИ, М. ВАФИНА.
«К 125-летию Г. Тукая»: хронология жизни поэта.
Выступление президента Республики Польша Бронислава Коморовского на торжестве открытия памятника татарину Республики Польша.
«К 80-летию Н. Юзиева»: Т. ГАЛИУЛЛИН. «Жизнь, посвященная поэзии».
«Наука»: Р. МАРДАНОВ. «Сказание о Мансуре ХАЛЛАДЖЕ»;
Ф. ГАРИПОВА. «История наших деревень» (прод.).
Страницы из «Татарской энциклопедии».
«Память»: дневниковые записи Ф. ЯРУЛЛИНА; эссе А. ЗИЯТДИНОВА «На Родине Такташа».
«Наши музеи»: Р. НИЗАМИ. «С глазу на глаз с прошлым».
«Белый парус»: Р. БАТУЛЛА. «Маленький Батулла»; рассказики К. ЮЛДАША;
К. ШАКИРОВ. «Озорной физик».
«Книжное обозрение»: Х. Миннегулов «Татарка»–«В пути жизни».
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: Памятник татарину в Республике Польша;
писатель Халиса ШИРМАН.

# IN THIS ISSUE:

«Editor's word»: «We harden just at testing».
«Prose and Poetry»: Novel by A. MUSHINSKY «Sheikh and astrologer»; memories by A. SALAH «Driller's routine»; stories by R. GALIULLIN;
poems by Z. MANSUROV, I. GILAZOV, H. BADIGI, M. VAFIN.
«To 125th anniversary of Tukai»: Chronology of poet's life.
Speech by President of Republic of Poland Bronislaw Komorowski at the ceremony of unveiling of monument for Tatar of Republic of Poland.
«To 80th anniversary of N. Yuzeev»: T. GALIULLIN. «Life dedicated to poetry».
«Science»: R. MARDANOV. 'Legend about Mansur Hallaj; F. GARIPOVA. «History of our villages» (continuation).
Pages from Tatar Encyclopedia.
«Memory»: diaries by F. YARULLIN; essay by A. ZIYATDINOV «On Taktash's Homeland».
«Our museums»: R. NIZAMI «Face to face with past».
«White Sail»: R. BATULLA. «Little Batulla»; story by K. YULDASH;
K. SHAKIROV «Mischievous physicist».
Diary of social-cultural life.
On our covers: Monument for Tatar in Republic of Poland; writer Halisa SHIRMAN.

*The magazine edits monthly*

★ Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★ Редакциягә килгән кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★ Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 30.12.2010, график буенча 30.12.2010.
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70Х108 1/16.
Нәшер-хисап табагы 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ О–1849. Тираж 4516.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләрне күзәтү буенча Федераль хезмәтнең Татарстан буенча идарәсендә, 2010 елның 1 апрелендә теркәлде.
Теркәлү таныклыгы ПИ №ТУ 16-00337
Индекс 73210 (физик затлар өчен), 16262 (юридик затлар өчен). Бәясе ирекле.

«ПИК «Идел-Пресс» ААҖ «ТАТМЕДИА» филиалы типографиясендә басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2010 ел.

*Баш мөхәррир сүзе*

# СЫНАЛАБЫЗ, ӘММА СЫНМАБЫЗ

Әле кайчан гына дулкынланулы хисләр белән «Казан утлары»ның 1000нче санын әзерләп мәш килеп йөргән идек. Сез яңа гына кулыгызга алган бу журналның тәртип саны инде 1059га җиткән! 5 елга якын гомер җил кебек үткән дә киткән... Дөрес, күңелләргә гел бәлзәм генә салып китмәде бу еллар. Казанышлар белән беррәттән татар мәдәниятендә (хәер, бер бездә генә дә түгел), бигрәк тә көндәлек матбугат һәм китап дөньясында әллә никадәр сәер үзгәреш-метаморфозалар, кемнәрдер әйткәнчә, реформалар булды. Нәшрият һәм газета-журналлар даирәсендә бигрәк тә ачык чагылды бу хәл. Оптимизация шаукымында, кушылулар (нәшриятларны әйтүем), күченүләр, кыскартулар дисеңме... Шуна өстәп, язганына каләмхак түләмәү, шул сәбәпле талантлы кешенең иҗатка дәрте сүрелүе... Илдә эзлекле милли сәясәт булмау, булса да, аның шовинистик юнәлештә булуы... Санасаң, күп инде хәлләр. Кыскасы, мәдәни иҗат эшендәге зыялыларның хәле мактанырлык түгел хәзер. Матди байлык рухи байлыкны тезләндерүен дәвам итә. Илдә кыргый капитализм үр алды. Гражданлык җәмгыяте хыялда гына кала бирә.

Шундый вәзгыятьтә эшләргә һәм иҗат итәргә туры килә. Яшәү девизыбыз бер: үзебезгә ышанырга, халыкка таянырга. Әмма халыкны уятырга, канатландырып торырга да кирәк әле. Бу җәһәттән «Казан утлары»н тылыбыз—телебез сагында торган эре калибрлы рухи корал дип саныйм мин. Әйе, замана тегермәннәрендә тартылабыз, бәргәләнәбез, хәтәр җилләрдә сыналабыз, асылда, чыныгабыз. Әйе, сыналабыз, әмма сынмыйбыз. Чөнки, тоткан мәсләгебез, барыр юлыбыз дөрес. Киләчәккә өмет-ышаныч яшәтә безне, иманлы максат көч-куәт бирә. Моны безнең «Казан утлары» мисалында да күреп була. Язучы авторларыбыз, шөкер, актив иҗат итә. Алар тудырган әсәрләр арасында тарихта калырлык хөр фикерлеләре, тирән мәгънәлеләре дә байтак. Журналга тәкъдим ителгән кульязмаларның күплеге—сайлап алып бастыру мөмкинлеге тудыра. Гасыр башында яңа яшь исемнәр ешрак күренә башлады. Бу да куандыра. Тиражыбыз да кимемәде әлегә. «Казан утлары» һәр яктан—эчтәлеге, тышкы кыяфәте, таралышы ягыннан әдәби журналлар арасында ил күләмендә беренчеләрдән санала. Болар безне, әлбәттә, сөендерә, иҗади дәрт бирә, горурлык уята. Мисал өчен Мәскәүдә чыга торган федераль журналларның тиражын карыйк: «Москва»—3400, «Октябрь»—2500, «Нева»—2300, «Молодая гвардия»—2000, «Дружба народов»—2000...

Соңгы чорда газета-журналлар нык үрчеде, әмма иҗтимагый бәяләре очсызланды. Күп басмалар, заманына җайлашып, әллә ничә мәртәбә маяк-ориентирларын алыштырып, әллә нинди төсләргә кереп беттеләр... Бу яктан, шөкер, безнең «Казан утлары» халыкның рухи көзгесе булып, һаман да шул юлдан баруын дәвам итә. Тотрыклылык зур нәрсә. Бәлки шуңадыр да Ватан сугышы елларында СССРда бөтен әдәби журналлар бөтенләй диярлек ябылып торганда да, безнең басма чыгудан туктамаган.

«Казан утлары»—энциклопедик характердагы журнал. Анда бүгенге татар әдәбиятының өр-яңа әсәрләре белән беррәттән, фәнгә, тарихка, сәнгатькә, спортка, гомумән җәмгыять тормышының төрле өлкәләренә кагылышлы аналитик хезмәтләр дә дөнья күрә. Шулай да, ул иң әүвәл язучылар журналы. Язучыларсыз аны күз алдына китерү кыен. Бәхетебездән, бүгенге көндә мең дигән оста каләм ияләре бар. Минемчә, тарихта калырлык классик әсәрләр тудырырга сәләтле бернечә дистә язучыларыбыз, шагыйрьләребез, драматургларыбыз бар. Бу зур байлык. Заманалар никадәр генә катлаулы булмасын, язучыларыбыз туктаусыз иҗат итеп килә. Хезмәтеңнең тормыш алып барырлык әҗере булмаслыгын белә торып та иҗат итә алу—фидакарьлек ул. Әйткәнемчә, һәрберебез өчен иң кыйммәт хәзинәбез—туган телнең, әдәби телнең сагында торучылар бит алар. Әгәр талант калерсез икән, димәк, җәмгыять үзе сансыз. Шулай да оптимист булыйк: рухың какшамаслык нык икән, аны җиңәр көч юк ул. Шикләнмим, юлыбыз дөрес, эшебез хак, уңышлар безгә юлдаш булыр. Хәерле Яңа еллар һәммәбезгә!

**Равил ФӘЙЗУЛЛИН**

*Татарстанның халык шагыйре,*
*«Казан утлары» журналының баш мөхәррире.*



Әсгать
Салах

# ҮРЛӘРГӘ МЕНГӘН ЧАКЛАР

БОРАУЛАУЧЫ ИСТӘЛЕКЛӘРЕ

**Бигәш «академиясе»**

Буровойларның тылсымлы көче бар. Миңа яшьлегемдә шулай тоелды.

...Илле икенче елның җылы, яшел хәтфәгә, чәчәкләргә күмелгән май ае. Без, бер төркем Елховой авылы егетләре, Лашман авылыннан (Чирмешән районы) җәяү кайтып киләбез. Машиналар юк, аларны көненә берне дә очрата алмаган еллар иде ул. Өч ел шул авыл урта мәктәбендә укыдык, алда чыгарылыш имтиханнары гына. Сират күперен ничек үтәрбез? Күбебезнең кайгысы шул. Укуда таләп зур булды, алкы-салкы йөрүне белмәдек, шулай да...

—Юкка баш ватмыйк әле, егетләр! Имтиханнарны уңышлы бирәбез,—диде арабызда иң олыбыз Мәхмүт Гыйззәтуллин, безне өметләндереп.

—Бирә алмасак, әнә, Бәркәтә янында разведка буровое көн-төн җир кимерә, шунда китәбез эшкә,—диде Мөхәррәм.

Бу хәбәр күбебез өчен яңалык иде. Мин, һәрвакыт күпне белергә тырышып, һәрнәрсә белән кызыксынып яшәгән егет, юл уңаенда шул буровойга кагылырга тәкъдим ясадым һәм без, Кара Чишмә авылына кергәнче, юлыбызны уңга, Бәркәтә авылы ягына каердык.

Ә буровой Шушма елгасының текә ярыннан өстәрәк, калкурак урынга урнашкан иде. Дүрт аяклы, мәһабәт биек тимер манара-вышка—үзе бер соклангыч. Мондый гаҗәп нәрсәне безнең әлегә кадәр күргәнебез юк. Эче тулы зур-зур механизмнар, җиһазлар. Алар янында майланып каткан киемле берничә кеше эшләп йөри. Буровой тирәли биниһая күп металл торбалар аунап ята—ике эшче аларны ломнар белән тәгәрәтеп рәткә сала. Читтә—ике тәрәзәле, бер ишекле такта будка. Тирәндә, җирнең әллә кайсы бер серле почмагында яшеренеп яткан «нефть» дигән хәзинәгә әнә шул буровой юл ача икән бит. Ягъни шул буровойда эшләүчеләр. Бораулаучылар дип атыйлар икән аларны...

Имтиханнарны, шөкер, уңышлы тапшырдык, кулыбызга таныклык

Әсгать САЛАХ (1935) — *язучы, публицист; «Аккан сулар», «Балыкчы малайлар» һ.б. китаплар авторы. Әлмәттә яши.*

та алдык. Күбебезнең кая да булса укырга китәргә иде хыялы, ләкин кереме булмаган ярлы авыл баласының кесәсендә жилләр уйный—чыгып китеп була торган түгел. Мәхмүтне очучылар хәрби училищесына алып киттеләр, Сәгадәт Минабетдиновның да яше житкән—аны армиягә алдылар. Калганнарыбыз кышны авылда үткәрде. Яз килде. Шунда гына, бераз уйланып йөрдек тә, тәвәккәлләп Әлмәткә, бораулаучылар әзерләүче мәктәпкә укырга китеп бардык. Әнә шулай, дүрт авылдаш һәм сыйныфташ—Әлфрит Гыйззәтуллин, Мөхәррәм Фәйрушин, Наил Мостафин һәм мин Бигәш «академиясе» курсантлары булып киттек. Безнең өчен бу бик кулай нәрсә иде: барлыгы ике ай укыйсы да ике ай күнегү (практика!) үтәсе. Мәктәпнең тулай торагы бар, күрше ашханәдә көненә өч тапкыр бушлай ашаталар (талон белән). Кыскасы, ашау байдан, үлем Ходайдан. Безнең ише ярлы-ябагайга тагын ни кирәк?

Татар балаларына ШБКда русча уку жинел булмаса да, акрынлап авырлыкларга, аларны жинәргә өйрәндек.

Ләкин минем башка, һич уйламаганда, кайгы килеп төште. Бер жылы май кичендә, дәресләрдән һәм кичке аштан соң, спорт мәйданында бик бирелеп волейбол уйнадык. Яшь чак, гайрәтле чак—шау килдек. Арып-талып бүлмәләргә таралыштык. Яту белән йокыга да талганбыз. Төн урталарында чылтырап безнең бүлмә тәрәзәсе ватылганга сискәнешеп торып утырдык. Нәрсә булды бу? Тәрәзәне кем ватты? Киң тәрәзәнең нәкъ минем карават башындагы өлгесе челпәрәмә килгән. Ул да булмады, мин шул өлге кырыендагы кысада кадакка элеп куйган пинжәгем, күлмәк белән майкам һәм кипкемнең юклыгына игътибар иттем. Алардан жилләр искән. Ә пинжәк кесәсендә минем барлык документлар, заемнар, яна алган стипендия, ашханәдә туклану өчен бирелгән талоннар, хәтта тәүге шигырьләрем тупланмасы—блокнот та бар иде. Димәк, аларның берсе дә юк хәзер. Кызганыч, иң соңыннан яткан иптәшебез—авылдашыбыз Исхак абзый Зиннуров утны сүндермичә ауган урынына. Ә каракка шул гына кирәк тә: бүлмә эче күренеп тора, кулына перчатка кигән килеш тәрәзәне ваткан да, шул мизгелдә киемнәрне дә тартып алган...

Иртән вакыйганы директорга житкердек. Аннары каршыдагы Бигәш зиратын урап кайттык, тик бернәрсә дә тапмадык. Директор миңа кабат талоннар бирдерде—ашамыйча торып булмый ич. Әлфрит, рәхмәт үзенә, Нил абыйсының кителен бирде, чөнки өскә киярgә әйбер калмаган иде. Наил кемнендер ашханәдә онытылып калган кипкесен миңа алып кайтты. Ярый әле чалбарны ике матрац арасына «үтүкләргә» салып йоклый торган гадәтем бар иде—анысыннан коры калмадым. Хәзер документларны табасы калды. Директорыбыз Афанасий Романовичның тәжрибәсе бар иде, ахры, ул: «Подождем несколько дней»,—дигән киңәшен бирде. Хак, бер өч көннән соң мине Бигәш авыл Советына чакыртып алдылар һәм паспорт, комсомол билеты һәм хәрби комиссариатка теркәү таныклыгымны кулыма тоттырдылар—аларны, әйтүләренчә, почта әржәсенә салып калдырганнар икән. Минем өчен иң үкенечлесе—шигырьләрем белән тулы блокнотның югалуы булды.

Әлеге вакыйга безнең барыбызны да: «Уяу йөрегез!»—дип кисәтте. Ургып нефть чыга башлаган Әлмәт төбәге барлык эшкуарларны, акча сөючеләрне һәм шул исәптән кыек куллы хәшәрәтләрне дә магнит кебек үзенә тартып китергән. Ул еллардагы сугыш-кырылыш, бер гөнаһсызларны аз-маз акча өчен үтереп ташлау—болар турында без гел ишетеп яшәдек. Ә минем киемнәрне урлап киткән карак белән юллар кисеште дә бугай әле. Яшь чак бит, гел буровой мәктәбе кысаларында гына яшисе килми, акрынлап кичләрен якындагы Бигәш авылы клубы мәйданына төшеп

йөри башладык. Ә анда кичке сәгатьләрдә шул ук нефть тартып китергән йөзләгән татар егетләре-кызлары җыела. Аларның күпчелеге төрле авыллардан, төбәкләрдән килеп, бигәшлеләрдә фатирда торып, кем кайда булдыра ала эшләп йөрүчеләр. Мәйданда гармун тавышы тынмый. Яшьләр, түгәрәкләнеп, «әлләрия-ләрия»гә биешәр, җырлыйлар. Мин дә шунда Әнисә атлы бер Бигәш кызы белән таныштым. Очраша башладык.

Бер кичне мин аны өенә чаклы озата бардым. Турыларында сөйләшеп торганда, ул еллар өчен әле бик сирәк очрый торган өч тәгәрмәчле мотоцикл килеп туктады. Анда ерык авызлы өч егет. Алар, миңа һич игътибар итмичә, «Әйдә, утырып әйләнәбез»,—дип, Әнисәне алып та киттеләр. Иң гаҗәбе, Әнисә бу егетләр белән күптән таныш һәм «утырып әйләнүгә» дә күнеккән иде булса кирәк—бер каршылыксыз риза булды аларның тәкъдименә. Аптырап калдым. Әһә, имәндә икән чикләвек! Үзен һәм очрашып йөргән егетен хөрмәт иткән пакь кыз бер төркем әрсез алабай белән китмәс иде. Мин үпкә катыш ачу белән тулай торакка юнәлдем.

Икенче кичне Әнисә кырына бармадым, ул үзе килеп сарылды: «Нишләп кайтып киттең, мине бит тиз кайтарып куйдылар»,—ди бу.

—Безнең авылда мондый хәлнең булганы да, буласы да юк. Кызларыбыз да үз егетләрен санга сугалар, башкаларга ияреп китмиләр,—дидем. Шул сөйләшүдән соң Әнисә белән ара өзелде, гәрчә ул моның белән килешмәсә дә. Кыскасы, минем өчен бу уенның кызыгы бетте. Теләсә нинди егеткә ияреп чапкан кызның ышанычы буламыни?

Шул ук кичне теге әрсез алабайларның берсе минем янга килеп басты. Миннән шактый калку, нык бәдәнле, олы башлы, озын кара чәчле.

—Әйдә танышыйк. Мин—Руслан,—ди бу.

Таныштык.

—Синең әйберләрне урлаганнар икән. Милициягә җиткердеңме соң?—ди бу, мине гаҗәпләндереп.

Каян белгән? Димәк, Әнисәгә сөйләгәннәрем боларга да барып ирешкән. Менә сиңа «сөйгән» кыз! Бу—шулар эше түгелме соң?

—Милиция таба дип уйлыйсыңмы? Аларга эшең төшмәсен. Аны гына беләбез инде,—дидем мин, эчтән барысы турында да үземчә фикер йөртеп.

Кыска гына аралашу көннәрендә бу озын чәчле шикле бәндәнең чын исеме Рөстәм икәнлеген дә ачыкладым.

Алга китеп әлеге Руслан-Рөстәм белән тагын очрашуымны да әйтеп узу урынлы булыр. Бусы инде бер ел узгач—Баулыда, Акбуа бистәсендәге хәл. Соң гына эштән кайттым да, ашханә ябылганчы дип шунда чаптым. Ашханә ул чакта Энгельс урамында тезелешеп утырган баракларның берсендә иде. Кичке ашка килүчеләр аз түгел—чират. Минем арттан да берәү чират алды. Сизәм, теге минем пинжәкнең уң кесәсенә кулын тыгып маташа. Мин яшен тизлеге белән аны эләктереп алдым. Борылсам, теге Руслан бит...

—Әй, Әсгать малай, син икәнне белмәдем. Ачуланма инде. Акча беткән иде, миңа да ашарга ал әле. Иртәгә үк китереп бирермен,—ди бу. Күзен дә йоммый. Әллә нинди халәттә калдым. Шулай да кесәгә кергән каракның ашарына алдым—бик йомшак, җәлләтеп сөйләшә бит. Ашап туйгач, миңа рәхмәт әйтте һәм кайсы тулай торакта яшәгәнемне сорады.

Иртән вахта автовокзалында: төнлә төзүчеләр кибетен басканнар дигән хәбәр таралды. Күңелгә: «Шул Руслан-Рөстәм өере түгелдер бит?»—дигән уй килде. Кичен мин эштән кайткан җиргә тулай торакта кизү торучы апа: «Бер егет сиңа калдырып китте»,—дип миңа акча сузды. Икенче көнне исә шул ук автовокзалда кибет басучыларны тотканнар дигән сүз ишеттек. Башкача мин ул Руслан-Рөстәмне очратмадым-күрмәдем. Шикләнүем

хак булды, ахры. Гүзәл яшьлеген караклыкка багышлаган тап-таза, чибәр егетнең язмышы төрмәгә килеп төртелде булса кирәк. Ә төрмәләрнең кешене Кеше иткәне юк бугай әле...

Гомер агышымда миңа михнәтне күп чигәргә туры килде. Ачлыкны да, ялангачлыкны да җитәрлек татыдым. Ләкин урлашу, алдашу, кеше өлешенә керү, кемне дә булса рәнҗетү кебек гөнаһ эшкә бару булмады. Мәрхүмә әниебез бик саф күнелле, намус, пакьлек дигән күркәм сыйфатларга ия кеше иде. Безне дә чит-ят кеше әйберенә тимәскә өйрәтеп үстерде. Ә менә легендар Рөстәм исемен йөрткән татар егете, шундый тәрбияне алмый үскәнгәдер, көенечле язмышка дучар ителде.

Шөкер, шуннан соң хәвеф-хәтәр булмады. Сиздерми генә ике ай үтеп китте. Безне практикага җибәрү вакыты җитте.

Практикага төрлебезне төрле якка юлладылар, чөнки бу вакытта Баулыда да, Писмәндә дә, Азнакай һәм Әлмәтнең үзендә дә буровойлар гөрелтесе еракларга янгырый иде инде. Наил Писмәнгә язылды—анда аның туганнары яши икән. Ә мин кая барырга кирәклеге турында алдан ук уйлап куйган идем: Баулыга! Бу теләгем болай туды. Ул вакытта мин «Яшь сталинчы» (хәзер «Татарстан яшьләре») газетасын ала һәм бик яратып укып бара, үземнең мәкаләләр һәм шигырьләрне дә шунда җибәрә торган идем. Шул газетаның бер санында Баулы төбәгендә иң алдынгылардан саналган бораулау остасы Мөгаллим Гыймазов җитәкләгән бригаданың чиксез уңышлары турында язылган мәкаләне укыдым. Анда мастерның рәсеме дә бар иде. Менә шуннан соң миндә Баулы якларына барып чыгу хыялы туды. Ул елларда мин Баулыны кайдадыр Казан якларында итеп күз алдына китерә идем, ә ул, соңыннан белгәнемчә, бөтенләй кире якта—республикабызның көньяк-көнчыгышында, Башкортстан белән Оренбург өлкәсе чигендә икән.

Баулыга дигәч, Әлфрит тә минем белән китәргә булды, чөнки ул миндә ышанычлы иптәш күрә иде. Аның белән юллама алып, ишек төбенә чыксак, Мөхәррәм сөмсерен коеп утыра:

—Мине ялгызымны калдырасызмыни?—ди бу, еламсырап.

Өчәүләшеп яңадан дирекциягә кереп киттек һәм, Баулыга урын беткән булса да, бик үтенеп сорагач, Мөхәррәмгә дә юлламаны шунда алдык.

Бәхетебез бар икән: Әлфрит белән Мөхәррәмне практика үтәргә әлеге дә баягы мин газетадан укып белгән Мөгаллим Гыймазов бригадасына билгеләделәр. Ул бригадага эләкмәвемә мин бераз кимсенеп тә куйдым, ләкин миңа да яхшы бригада—Баулы җирендә тагын да танылганрак, күкрәгендә Ленин ордены йөрткән, әле Башкортстан нефтен күтәрешкән оста Газим Гайфуллин бригадасына эләгү насыйп булды.

Буровойда уртача буйлы, кырык-кырык өч яшьләрдәге ачык йөзле мастер мине өлкән бораулаучы Василий Кожанов вахтасына билгеләде. Кожановның да Гайфуллин кебек артыгын сөйләшми торган эш кешесе икәнен хәтерлим. Ул каяндыр Грозный тирәсеннән иде. Гомумән, күпчелек бораулаучылар Татарстан нефтен үзләштерергә Баку, Грозный, Краснодар, Башкортстан, Краснокамск һәм башка төбәкләрдән килгән кешеләр иде.

Тәүге вахта. Минем эшкә өйрәнә башлаган беренче көнем... Кулда нык тоткалы, киң һәм тирән «совковый» көрәк: «бери больше, кидай дальше»... Газим Гайфуллин коллективының чираттагы скважинаны бораулый башлаган көннәре. Борау, җир җимертеп, аска таба хәрәкәт итә, дүрт аяклы тимер вышка шар-шор килеп калтырый, шыгырдый, насос моторлары ярсып эшли, югары басым астында скважинага куылган су үзе белән борауланган токым—шламны өскә чыгара, аны такта улак буенча су чокырына агыза. Ләкин токым авыр, ул улакка утыра да, су улак өстеннән

як-якка агып китә. Без, вахтадагы иң түбән разрядлы эшче Закир абзый Подмарев белән мин, җан-тиргә батып шул улакларны тазартабыз, тик өлгерә генә алмыйбыз. Закир абзый урта яшьтә,бишенче дистәсе белән бара, гәүдәгә дә зур түгел—көче чамалы. Ә мин яшь һәм тәҗрибәсез. Шулай да тырышабыз.

Ике-өч көн шулай бергә маташтык. Һәм шул көннәрнең берсендә Закир абзый үзенең ялга китәргә җыенуын әйтте.

—Энем, мастер сине алыштырырга кешем юк, дип мине ялга җибәрми. Кал әле минем урынга. Эшкә өйрәнерсең, акчасы да булыр...

Закир абзый—Ульян мишәре. Тормышы җиңел түгел—олы гаилә, хатыны эшләми, өчме-дүртме кызлары үсә. Буровойда эшләп йөрүенең дә сәбәбе шул бугай.

Мине аның фамилиясе кызыксындыра: нигә Подмарёв? Урысныкы бит бу, татарныкы түгел.

—Минем бабай Подмарёв дигән урыс алпавыты крестьяны булган. Шул урыс барлык крестьяннарына да үзенең фамилиясен тага торган булган,—диде абзый.

Минем ике уйларлыгым юк: Закир абзый урынында эшләсәм, акчалы булачакмын, чөнки практикага чыгып киткән көнне алган стипендиядән кесәдә санаулы сумнар гына калды. Аннары ач утырачакмын.

—Сиңа ничә яшь?

—Унсигез.

—Эшли алырсыңмы соң, энем? Буровой эше бик авыр бит ул,—диде Газим абый, Закир абзый мине аның янына алып кергәч.

—Тырышырмын. Барыбер эшкә өйрәнәсе бар бит.

—Анысы да дөрес. Давай, алай булса, иртәгә вахтага чык!

Әнә шулай, практикага килгән егетләр арасында беренче булып мин вахтага бастым. Һәм, әлбәттә, буровойда эшләүнең ничек авыр булуын миңа ун гына түгел, йөз тапкыр татырга туры килде. Ләкин бу минем өчен мәктәп иде. Тәвәккәллек, ирлек, батырлык мәктәбе!..

Һәм мине эшкә өйрәтүче агайларга да рәхмәт. Бурильщик Кожанов бораулау торбаларын күтәреп-төшерү вакытында, ротор янында өйрәнчек егет эшләгәнен искә алып, «элеватор» дигән корал өстендәге колоннаны роторга акрын гына китереп утырта һәм стропларны азат итә. Без Мансур Сәмиков белән стропларны икенче элеватор колагына кидерәбез һәм ул өскә, чираттагы «шәм» артыннан менеп китә. Беркем миңа кычкырмый, хәтта катырак эндәшүче дә юк. Кожанов әледән-әле: «Осторожно, осторожно, ребята, не спешите»,—дип әйтеп тора. Роторның икенче—миңа каршы ягында бурильщик ярдәмчесе Мансур Сәмиков та тыныч. Ул да әйтәсен киңәш итеп кенә әйтә: «Ашыкма».

Мансур миннән алты-җиде яшькә олы. Буйга минем чамада гына, ләкин киң, нык бәдәнле, кул һәм күкрәк мускулларына җитәрлек көч җыйган. Эшен белеп, ышанычлы, җиңел башкара. Сабыр холыклы, уйлап кына сөйләшә.

Ул елларда гади бораулаучыларның ялы кыска—барлыгы 18 көн иде. Закир абзый да:

—Рәтләп ял да итеп булмады,—дип озакламый эшкә чыкты. Ә мине шул ук «төшемле» шөгыль Мөнәвир Фәттахов вахтасында көтә иде. Мөнәвир кара туткыллы, дулкынланып торган кара чәчле, чибәр, егерме сигез-утыз яшьләрдәге таза гәүдәле бораулаучы. Ул да буровойга гади эшче булып килгән һәм менә бүген ул өлкән бораулаучы. Фронтовик. Эшен дә чатнатып эшли, сүзен дә оста сөйли, шаяртып та ала. Бораулаучылар арасында аңа бәйле бер мәзәк тә йөри иде әле. Мөнәвир төшке ашка һәр көн ипи белән

бер шешә сөт алып килә икән. Сөт ачымасын дип, аны пешкәккә агып торган су астына куя. Бер көнне сөтне алырга килсә, аннан җилләр искән, бөкесе ачык шешәгә су агып тора. Икенче көнне дә шул хәл кабатлана. Өченче көнне исә Мөнәвир үзе хәйләгә керешә: сөтенә касторка салып куя. Карак тиз тотыла, ул—верховой Минәхмәт икән. Касторкалы сөт эчкән егет эче китеп көне буе куаклар арасында утыра...

Фәттахов вахтасында эшләгән атналар минем өчен тагын да авыррак булды, чөнки геологик-техник наряд буенча без инде нык ишелә торган поддоманник һәм девон катламнарын үтеп, скважинаны тәмамларга җыенган идек. Моның өчен су белән бораулаудан туктап, балчык измәсенә күчәргә тиеш идек. Ә балчык измәсен ул елларда бригада эшчеләре үзләре әзерлиләр, зур-зур носилкалар белән тиргә батып махсус яшел балчык, сода һәм торфны измә болгаткычка ташыйлар иде.

Беркөнне измә ясаганда көчле яңгыр явып үтте, аяк асты тайгак, болгаткыч өстендә эшләве куркынычка әйләнде. Мөнәвир безне будкага алып кереп китте. Утырып ял иттек, үзе белән ризыгы булганнар ашарга керешге. Ә минем андый нигъмәт юк, авызны чөйгә элеп утырам. Моны күреп, Мөнәвир миңа да өлеш чыгарды. Стипендия бетеп, хезмәт хакы алырга вакыт җитмәгән көннәр иде болар. Кичен Закир абзыйларга бурычка акча сорарга киттем. Йөзгә бик матурдан булмаса да, күңеле якты иде аның—елмаеп каршы алды. Хәлемне аңлап, ашаттылар-эчерттеләр, сораганча акча да биреп җибәрделәр, рәхмәт төшкерләре. Шул көннән башлап Акбуа эшчеләр бистәсендә минем өчен Ульян мишәре Закир абзыйдан да якынрак кешем булмагандыр.

Мөхәррәм белән Әлфриткә практика вакытында минем кебек эшләү насыйп булмады, еш кына авылга кайтып китеп, вакытны үз гаиләләрендә үткәрделәр. Практика вакыты бетәр алдыннан гына килделәр дә, белешмә алып, бергә Әлмәткә кайтып киттек. Имтиханнардан соң Баулыга Мөхәррәм белән икәү генә юнәлдек. Ә Әлфрит шул ук «Бигәш академиясе»нә электриклар курсына укырга кереп калды. Буровойда эшләү өчен нык сәламәт булу кирәк, аның исә бөсере бар иде.

### Тәүге вахталар

Укып килгәч безне буровойларга җибәрерләр дип өметләнгән идек, булмады. Башта безгә шактый гына труббазада чиләнергә язган икән.

Монда эшнең очы-кырые юк: буровойларга торбалар, «обсадка»лар, турбобурлар һәм бораулар ташыйбыз, заводтан килгән торбаларны эстакадага тезәбез, нечкә насос-компрессор торбаларын шаблон белән тикшерәбез. Әйе, эш күп, ә төшем юк—хезмәт хакы ашарга да җитәрлек түгел икән, без моны беренче «получка»да ук белдек. Иң яхшы юл—тизрәк буровойга ычкынырга. Ләкин ничек?

***

Тулай торакта Федя исемле егет белән бер бүлмәдә яшәдек. Ул безнең бораулау конторасында танылган оста Василий Чердаков бригадасында эшли иде. Акчасы бар, кайгысы юк. Киемдә зәвык дигән төшенчәне әлләни белмәсә дә, матур киенергә тырыша. Ял көннәрендә күбрәк сыра мичкәсе тирәсендә әйләнә-тулгана. Кәефләнеп бүлмәгә кайтып керде исә, патефонын эшкә җигә. Бу музыка коралы аның иң зур байлыгы һәм горурлыгы иде. Патефон бар, ә менә тәлинкәсе бер генә—шул чорның мәшһүр җырчысы Людмила Русланова җырлары. Ачы тавыш белән Русланова сузып-сузып:

—У-у-ро-о-ди-и-ла-ся я-а-а,
Как бы- лин-ка в по-ле;
Ни-кто-о за-муж не бе-рет
Дев-чон-ку-ку-у за-а э-э-это-о..,

—дип җырлый.

Федя аны канәгатьләнү белән тыңлап утыра-утыра да, тәлинкә ахырына якынлаша башлауга патефон энәсен күчереп куя һәм тагын:

«Уродилася я...» башлана.

Мин яңа гына эштән арып-талып кайттым. Өзелеп ашыйсым килә, тик ашханәгә барырга рәт юк—кесәдә җилләр уйный. Руслbuilt «уродилася я»... дигәнен ишетеп, елап җибәрүдән көчкә тыелып утырам. Хәзер булса, Федядан ашарга сорар идем, ә ул елларда, сугыштан соңгы ачлыкны кичергәнгәме, кешедән сорап алырга кыюлыгым житмәгән, күрәмсең. Ничек, нәрсә кылырга? Тукта әле, «спецовка» кесәсендә бирәр нәрсә калмадымы икән? Ашыгып кесәләрне актарам. Йа Ходa, буровой керенә баткан брезент чалбар кесәсеннән нәкъ бер кирпеч кара ипилек акча килеп чыкмасынмы. Шатлыктан кычкырып җибәрә яздым: нинди табыш, нинди байлык! Тиздән кибеткә чаптым. Һәм, бәхет кошы эләктергәндәй, кара, ләкин искиткеч туклыклы (кара ипи генә шулай туклыклы була ала) бер ипи алып кайттым. Шул ипи белән мин һич кайгысыз тагын ике көн яшәдем. Бер телем кисеп алам да, аңа тоз сибеп, кайнаган су белән валчыгын да калдырмый ашап бетерәм. Иртән дә эшкә шулай бер кисәк ипи ашап китәм. Кичен кайткач тагын бер кисәк. Тоз сибеп, кайнаган су белән...

Ипи! Сугыштан соңгы үтә ачлык елларда безгә ипи ашау бәхете тәтемәде. Бәрәңге, кабак, чөгендер, шалкан... Ә ипи булмады. Озын бер ел буена бер-ике кисәк ипи эләктеме икән? Юк бугай. Бәрәңгене исә ашаганчы да ашыйсы килә, ашагач та озакламый тагын ашыйсы килә башлый. Ә ипи ашагач ашыйсы килү басыла. Әйе, ипи—ипи инде ул. Иң туклыклы, иң ышанычлы тормыш чыганагы ул—ипи. Шуңа бит инде безнең буын кешеләре өчен ипидән дә кадерлерәк, анардан да туклыклырак ризык юк. Валчыгына кадәр кадерле ул бүген дә. Әлбәттә, ипи кадерен белгән кешегә!

Шулай да бәхет бар икән. Бер иртәне труббаза директоры, сугыш инвалиды (бер кулы юк иде) Хәертдинов абзый йортта тыз-быз килә. Мөгаллим Гыймазов бригадасына яңа турбобур илтергә кирәк икән, ә тракторчы эштә күренми.

—Кайсыгыз трактор йөртә белә?—ди бу.

—Мин,—дидем. Буровойларга трактор белән төрле йөк ташу атналарында мин дә, Мөхәррәм дә тракторны йөртергә өйрәнгән идек инде.

—Әйдә, күрсәт һөнәреңне!

Мин С-80 тракторын тырылдатып кабызып җибәрдем дә, аны бер урында зырылдатып әйләндереп алдым. Хәертдинов абзый сыңар кулын гына селтәде: бар!

Трос белән турбобурны тракторга тактым да, юл аркылы чыгып, Баулыдан күп дигәндә чакрым чамасы урман өстеннән вышкасы калкып торган буровойга юнәлдем.

Трактор тавышына мастер үзе каршы чыкты. Чандыр гәүдәле, очлы борынлы, зәңгәр күзле, өстенә шактый таушалган кожан, аягына кирза итекләр кигән гади генә бер кеше икән танылган бораулау остасы. «Мондарак, мондарак»,—дигән мәгънәдә ул миңа турбобурны күпергә якынрак китерергә изәде. Аннары үзе үк турбобурны таккан тросны ычкындырырга булышты.

—Син яңа трактористмы әллә? Күргәнем юк,—диде ул миңа.

—Юк, Мөгаллим абый, мин ШБКда укып килгән бораулаучы, практика вакытында Гайфуллин бригадасында идем. Кожанов белән Фәттахов вахталарында эшләдем. Хәзер труббазада чиләнәм.

—Вәт бит, ә! Мин ике атна хәзер подвахтага кеше сорыйм, ә алар юк диләр. Фамилияң ничек?

—Салахов.

—Иртәгә труббазага үзем киләм сине алырга. Ишеттеңме?

Ишетмәгән кайда! Мин канатланып кайтып киттем труббазага, тик Гыймазов белән сөйләшкәнне беркемгә дә әйтмәдем.

Төнлә һава үзгәрде. Кичтән җылы иде әле, ә төнлә туңдырып җибәрде һәм кар ява башлады. Әйе, илле өченче ноябрь башы иде инде тышта.

Гыймазов—әйткән сүзен үти торган кеше икән, чыннан да үзе килде мине алырга. Хәертдинов абзый аның минем арттан килгәнен белгәч, еламсырап:

—Ә миңа кем белән эшләргә соң?—диде Гыймазовка.

—Анысы синең кайгы, абзый. Ул бит труббаза эшчесе түгел, ә бораулаучыга укыган. Ызначит, урыны да буровойда булырга тиеш...

Аннары миңа борылды да:

—Бар, атлый тор! Мин әле конторга керәм,—диде.

Тиз бораулау буенча инде берничә рекорд куйган һәм танылган бригада җитәкчесе Мөгаллим Гыймазовның абруйлы кеше икәнлегенә мин шул көнне төшендем. Мине иң түбән хезмәт хакына эшләтүче Хәертдинов абзыйны урынына утыртты. «Әллә син мине ачка үтерергә җыенасыңмы?»—дип, мин дә берничә сүз катарга җыенган идем дә, сугыш утын кичеп, кулын калдырып кайткан олы кеше белән әрләшмим инде дип, эндәшмәдем.

Урман аланындагы 359нчы буровойда мине көтәләр иде инде. Каршыга кара туткыллы, елмаюлы йөзле, утыз яшьләрдәге бер бораулаучы чыгып:

—К нам что ли?—дип сорады. Аннары мине буровойга алып кереп китте—анда барыбызны да эш көтә иде. Катлаулы эш, чөнки бирегә, инде өч айдан артык, авария иде—«инструментны» җир кыскан. Бу хәл илле өченең җәй айларында 417нче буровойда тизлек буенча 2011 метр җир бораулап рекорд куйганнан соң булган икән. Ялан-ялан майлы ботка булмый шул! Скважина бораулау эше гел шома гына бармый, һәркемгә уяу булу кирәк.

Миңа, бригададагы яңа кешегә, тагын бер нәрсә мәгълүм булды. Дүрт кешедән торган безнең вахта ике бригадага—Гыймазовка һәм Җәмил Каюмовка хезмәт күрсәтә икән бит: өч эш көнен бер бригадада, тагын өч эш көнен икенче бригадада үткәрә. Аннары бер көн ял итә. Шулай чиратлап ике бригадада эшли.

Ул елларда илдә сигез сәгатьлек эш көне иде һәм буровойларда «подвахта» дигән нәрсә кулланыла иде. Мин нәкъ шул «подвахта»га эләккән булып чыктым. Ә бераздан шул ук Гыймазов бригадасына килгән дустым һәм авылдашым Мөхәррәм Фәйрушин төп бригадада, Иван Шеремет вахтасында эшли башлады.

Хрущев абзый хезмәт халкын җиде сәгатьлек эш көненә күчергәч кенә бер бораулау бригадасында дүрт вахта оештырылды, «подвахта» дигән төшенчә бетте.

Әлеге «подвахта»да исә бораулаучы булып Краснокамскидан килгән урыс Алексей Михайлович Логунов, Чуашстан егете, аның ярдәмчесе Владимир Андреевич Мудюков һәм верховой, Бөгелмә районының Димескәй авылы татары Рәшит Кәримов иде.

Бу язмамда мин җаныма якын бу кешеләр турында аерым тукталам. Әгәр

ул чор кешеләре гомумән кешелекле, шәфкатьле, игътибарлы, ярдәмчел иде дип әйтсәм, аз булыр. Ә Алексей Михайлович (яше кырыктан узган иде инде), Володя һәм Рәшит минем өчен әүлиядай иде. Барысы да тырыш хезмәт кешеләре. Һәммәсенә дә кинәшеп, аңлашып, ярдәмләшеп эшләү, күңел күтәренкелеге, шаянлык-шуклык, юморны, көлкене аңлау хас. Логунов өчен без, татар егетләре, барыбыз да «Петрович»лар идек. Рәшит Кәримов—Карим Петрович. Ярый ла аңа инде 25 яшь. Ә миңа бит әле 18 генә, ләкин мине дә, килү белән «Асхат Петрович» дип «олылый» башладылар. Үпкәләсәң—үпкәлә, үпкәләмәсәң—юк. Ләкин бер-беребезгә булган мөнәсәбәт—иң җылылардан иде. Ротор янында бергә эшләгәч, минем өчен иң якыны Володя булгандыр. Аңа 27 яшь. Унсигездә сугыш утына барып кергән—Бөек Ватан сугышы яугире. Егерме ике яшендә армиядән кайтып, озак та тормый Азага өйләнгән. Аннары олы кызлары Галя, икенчесе—Оля туган. Мин аның ачыктан-ачык, киң күңелле, кунакчыл Азасы, бәләкәй кызлары белән беренче атнада ук таныштым. Сугыш кичкән кеше тоя, сизә бит ул яңа гына тормыш юлына чыгып килгән буйдак, булышчысыз егетнең хәлен. Чакырыйм әле, килсен, күрсен, ашап-эчеп, игътибарга тиенеп китәр, дип уйлагандыр. Ләкин беренче, икенче чакырулардан соң мин инде ирексездән гаилә дустына әверелдем. Володя белән шахмат уйныйбыз. Аннары күршеләр керә дә, лото уйный башлыйбыз. Мин килгән саен бәләкәй кызлар миңа елышалар, чөнки мин дә хәзер буш кул белән кермим. Володя да, Аза да бик аралашучаннар. Володя дуслары белән өч телдә—чуаш, урыс һәм татар телләрендә иркен аралаша. Ә бит андыйлар безнең тормышта сирәк әле.

Гайфуллин бригадасында эшләп алу миңа яхшы мәктәп булды. Логунов кул астында, Володя һәм Рәшит белән вахтада тору миңа ышаныч китерде. Кыскасы, яраттылар, һич югында ошаттылар мине яңа иптәшләрем. Зур гәүдәле, таза, миннән җиде яшькә олы Рәшит исә мине «үз кеше»—татар булганга якын итә иде бугай. Икәү генә калганда гел үз телебездә сөйләшәбез һәм бу Рәшиткә бик ошый иде.

Ул мине биредә эшли башлавымның беренче көннәрендә үк яклады. Бер кичне төнге вахтага өчәү генә чыктык—Володя суык тидергән икән. «Шәм»нәрне өскә күтәрә башладык. Мин, яңа килгән эшче, ротор артында берүзем маташам. Барысы да килеп тә чыкмагандыр инде—Логунов кычкырынырга тотынды. Минем дә ачуым чыкты:

—Чего ты, абзый, кричишь? Забыл, что я один работаю за двоих? Или ты не знаешь правила техники безопасности? Это ведь не мешки таскать...

Киттем кызып, киттем. Логунов аңлады минем хаклы булуымны-чыгырның двигателен сүндерде дә, башын өскә күтәреп Рәшиткә кычкырды:

—Слезай, Карим Петрович, пойдем, отдохнем...

Аска төшкәч, Рәшит тә Логуновка минем хаклы булуымны әйтте:

—А если, не дай бог, угробим парня? Он ведь только начинает, опыта нет...

Әлбәттә, кызу көннәрдә вахтада өчәү эшләгән вакытлар аз булмады. Бер-береңә булышкан, ярдәм иткән очраклар да. Бигрәк тә бораулау буенча тизлек, рекорд өчен көрәшкәндә.

Теге кичне булган хәлне барыбыз да тиз оныттык. Алексей Михайлович та миңа аталарча игътибарын арттырды. Володя гына түгел, бераздан Логунов үзе дә мине кич утырырга чакыра башлады. Аның инде җитеп килә торган улы—Толя бар. Урта мәктәптә укый. Ул да, атасы да шахмат уйныйлар. Мин килгән кичләрне без чиратлашып көч сынашабыз.

Алексей Михайловичның бер кайгысы бар—ашказаны белән интегә. Аракы эчү, тәмәке тарту—тыелган. Күбрәк сөт-катык, дарулар эчә. Ләкин эштә батыр иде үзе.

## Минем тәүге рекордым

Гаҗәп хәл: минем хәтер төбендә күпчелек Гыймазов бригадасында эшләгән мизгелләр саклана. Ә Каюмов? Ул инде иллене тутырган булгандыр, озакламый аның урынына яшь, талантлы мастер Әхмәт Вәлиевне куйдылар. Мин Җәмил абый белән аралашырга да өлгерә алмый калдым, аны яна бораулап тәмамланган скважиналарны үзләштерүче бригадаларның берсен җитәкләргә җибәрделәр. Шундый хикмәт: илле яшен тутырган осталарның бик сирәге генә буровойда тоткарлана иде. Җитәкчеләр өчен Җәмил абый Каюмов та «тычкан тотмый башлаган карт песи» булгандыр. Ә озын буйлы, 23 яшьлек, махсус осталар мәктәбен тәмамлап килгән кыю, уңган, күп нәрсәне белә, сүзен кистереп сөйли торган, хәтта бераз «блатной» да Әхмәт Вәлиев мастерлар арасында аерылып тора иде. Ул килгән көнне безнең «подвахта» аның буровоенда эшләде. Ноябрь башы жылы торганга, яна буровойга су линиясен җир өстеннән генә сузганнар. Көннәр суытып җибәрү белән, ул линиядәге су урыны-урыны белән бозланып каткан. Ә сусыз бораулап булмый.

Буровой янындагы мичкәдән ягулык (солярка) алып килеп, чүпрәк-чапракны шуңа манчып, ут кабызабыз да, торбалар буйлап жылытып йөрибез. Су йөрешен барлыкка китерү өчен торбаны корыч тишкеч—бородок белән тишәбез. Су торбасының бер башыннан икенче башына йөгерәбез—мәш киләбез. Шулай, бик катлаулы һәм күп көч таләп итә торган эш булса да, бурычны үтәдек. Ярый әле көндез бераз жылытып та җибәрде. Мастер үзе дә безнең белән беррәттән җир җимертеп эшләде. Без дә сер бирмәдек—тырыштык. Безнең бу танышу бер үк вакытта бер-беребезне сынау да булды: ул—безне, без—аны. Шунда, минемчә, бер-беребезгә хөрмәт тә туды. «Әһә, моның белән эш кылырга була»,—дип сөйләштек без—Логунов, Мудюков, Кәримов һәм мин.

Кыш килде. Карлы-буранлы кышкы айлар артык ярсымыйча гына эшли торган вакыт ул буровойда. Ишеп яуган кары да, котырынган бураны да, чатнама суыклар да киерелеп эшләргә бирми. Мастерларның да еш әйтә торган «күрсәтмәләре» шуңа кайтып кала: манифольдны туңдырмагыз, насосны еш эшләтегез!

***

Ниһаять, 1954 елның язгы ягында Гыймазов бригадасы авариядәге скважинаны көч-хәл белән тәмамлауга иреште. Без, әле күптән түгел генә килгән яшь бораулаучылар (мин биредә үземне һәм Мөхәррәмне истә тотам), ул вакытта бу хәлләргә әһәмият тә биреп бетермәгәнбездер. Яңа гына авариядән чыккан остазыбыз Мөгаллим Гыймазов исә артка түгел, алга карап яшәгән икән. Ул гына да түгел. 307нче буровойга күчеп, беренче метрны бораулый гына башлаган идек, ул вакытта Бөгелмәдә урнашкан «Татнефть» берләшмәсе җитәкчесе Алексей Тихонович Шмарев, үзенең тугрылыклы урынбасарлары һәм ярдәмчеләре белән, безгә килеп житте. Будкабыз зур булса да, жыелган халык көчкә сыйды. Шмаревның өстендә тау инженерлары формасы—зәңгәр петлицалар белән озын, кара шинель-пальто, киң зәңгәр лампаслар белән шундый ук кара төстәге чалбар, башындагы бүреге дә тау инженерларыныкы. Тышкы кыяфәте белән гел генерал инде. Үзе таза, уртачадан шактый калку гәүдәле. Аның турында

бораулаучылар чегән нәселеннән икән дип сөйлиләр иде.

Күкрәгеннән гөрләп чыккан тавыш белән:

—Ну что, товарищи буровики, пойдем на скорость? На аварии посидели, отдохнули. Давайте реабилитироваться, очередной раз показать, на что вы способны,—диде барыбызга да. Сөйләшү уңаенда без аңладык: «Татнефть»тә һәм «Баулынефть» трестында безнең мастер белән күптән сөйләшенгән. Бусы—яңа җиңүгә хәер-дога бирү икән.

Шул көннән башлап 307нче буровой яңа ритм, яңа режим белән эшли башлады. Ике-өч көн саен буровойга Шмарев үзе, йә булмаса «Баулынефть» тресты управляющие Рәфгать Мингәрәев килеп йөриләр. Мөгаллим Гыймазовның исә өенә кайтканы да юк, бөтен тормышы буровойда, хәтта төн уртасында да бораулаучылар янына чыгып баса. Буровойдагы хәл—аның җанында. Болай да аз сүзле, хәзер исә ул тагын да җыенганрак, гел үз уйлары белән мәшгуль. Буровойны җибәрү конференциясендә коллектив алдына тизлек буенча яңа биеклек куелды—3000 метр! Алты ай авариядә утырганнан соң танылган бораулау остасы алдына-артына карабрак, исәпләбрәк, уйлабрак эшләү кирәклегенә төшенгәндер. Шул ук вакытта аңа һәрвакыт алга, яңага, элек ирешкәннәрдән югарырак биеклекләргә ирешү омтылышы да тынгылык бирмидер. Әлегә кадәр булдырдылар бит, тагын да булдырырлар...

Урамда—май. Җылы, рәхәт. Вахталар бер-бер артлы алышынып тора. Барысы да тырыша. Күрсәткечләр өметле, тоткарлык юк. Коллективның барлык эшчеләре дә олы җаваплылык хисе тоеп башкаралар үз вазифаларын. Әйтерсең лә барысы да бер механизм. Яхшы күрсәткечкә ирешү—бригада өчен дан булса, һәрбер аерым бораулаучы өчен—яхшы хезмәт хакы, премия, шул ук вакытта үзеңне дә күрсәтү. «Каждый солдат мечтает стать генералом»,—ди урыс. Бораулаучылар да үсү турында уйламыйлар түгел. Гади эшче—верховой, ә верховой—бораулаучы (бурильщик) ярдәмчесе булу турында уйласа, бурильщик үзе—оста, ягъни мастер булу турында хыяллана. Алдынгы бригадада эш күрсәткән бораулаучы һәрвакыт күз уңында—аңа үсү юлы ачык. Атаклы Гыймазов бригадасында ныгыган, тәҗрибә туплаган, скважина бораулауның серенә тулысынча төшенгән егетләр аз булмады. Шуларның берсе—минем яшьлек дустым, сыйныфташым Мөхәррәм Миндар улы Фәйрушин булды. Бораулаучы баскычларын бер-бер артлы үтеп, танылган оста—мастер булып, өч ел Сүриядә командировкада йөреп кайткач та озак еллар бораулау бригадасын җитәкләгән, Татарстанның атказанган нефтьчесе, СССР нефть сәнәгате отличнигы исемнәренә лаек булган, тәүге бүләк—нефть сәнәгате министры Н.Байбаковның Мактау кәгазен әле верховой булып эшләгәндә үк алган егет.

Гыймазов мәктәбен үткән чуаш егете Петр Якимов та остазы кебек мастер дәрәҗәсенә күтәрелде, саллы күрсәткечләргә иреште.

Болары соңыннан, әлбәттә. Ә хәзер Мөхәррәм дә, мин дә, Петя да гади эшчеләр генә әле. Ләкин барыбыз да бер кимәлдә тырышабыз: тизлек өчен, рекорд өчен көрәш бара!

***

Девон катламына якынайган саен буровойда киеренкелек арта бара. Әнә, труббазадан «обсадка»ларны да китерә башладылар. Үзбушаткычлар каяндыр, Акташ тирәсеннән, махсус яшел төстәге балчык ташый. Измә өчен! Токымы ишелә торган катламнарны фәкать шул балчыктан ясаган измә белән генә бораулап үтәргә мөмкин, су белән борсаң—эшләрең харап: көт тә тор—авариягә юлыгасың. Шөкер, ул катламнарны да «чыпы»сыз гына бораулап үттек. Ниһаять, девон! Ашыгыч рәвештә скважинаны ныгыту

өчен колонна төшерәбез. Мондый киеренке вакытта бригаданың барлык вахталары да эшкә чыга. Ротор янында икешәр вахта егетләре эшли. Бу вакытта калган икесе ял итә. Чиратлашып мәш киләбез. Тик гел җай белән генә бармый шул эш. Бер торба муфтасына икенче торбаны утыртканда таза гәүдәле, мыеклы украин егете Иван Бондаренко бер ялгышты, ике, өч ялгышты һәм оста, бик нык ачуланып, Иванны ротор яныннан куып җибәрде. Бер яклап өч торба юкка чыкты, икенче яклап, иң мөһиме, күпмедер вакыт югалды. Мөгаллим абый, көтмәгәндә, күпер башында чираттагы торбаны әзерләп торган җирдән мине чакырып алды да, ротор артына бастырды. Кыскасы, иң гади эшчене—иң җаваплы җиргә. Ләкин сер бирмәдем. Торбаны муфтага утырткач та аның үзәккә килгән мизгелен көтәм һәм бораулаучыга кул белән «Әйдә!» дигән әмер бирәм. Ул исә шул ук мизгелдә бер башы чыгырның әйләнеп торган муфтасына, икенче башы торбага чорналган сүстән ишелгән арканны тартып, торбаның сырын сырга кертеп җибәрде.

Колонна төшеп беткәнче мин ротор артыннан китмәдем һәм бер генә мәртәбә дә ялгышлык җибәрмәдем.

Бораулаучылар арасында төрлесе була. Эшең барып чыкмаса, берәүләр сиңа иптәшләрчә, киңәш иткәндәй генә әйтә, ә икенчеләр кычкырына, сине кимсетә башлый. Кайсыдыр вахтада верховой булып эшләүче Җәмил Мөхәммәтгалиев (Сары Җәмил) ярата иде безнең ише «уңмаганны» өйрәтергә. Колонна төшергәндә мастер миңа җаваплы эш кушып, аны намус белән үтәгәннән соң, Сары Җәмил генә түгел, кайбер башка аның сымаграклар да миңа хөрмәт белән карый башладылар. Хәтта: «Оста сине ярата»,—дигән көнчелек сүзен әйтүчеләр дә булды. Анысы инде Бөгелмәдә чыгучы «Нефтяник» журналы хәбәрчесе Мәхмүт Хәсәновның безнең бригада уңышлары турында чыгарган бәләкәй, юка китабын укыганнан соң булгандыр, чөнки уңганнар арасында минем исем дә бар иде.

Әйе, шул—булачак татар язучысы Мәхмүт Хәсәнов. Олы гәүдәле, тузгып торган ярым бөдрә, саргылт чәчле, күзлекле. Аның безгә, бораулаучыларга, игътибары зур—гел тегесе-бусы турында сораша һәм без сөйләгәннәрне блокнотына язып бара. Әңгәмә, әлбәттә, эш арасында гына була, чөнки җәелеп сөйләшергә вакыт тар. Шуңа күрә Мәхмүт абый күбрәк культбудкада, оста янында утыра. Ләкин останың да эше җитәрлек.

Мәхмүт Хәсәнов әңгәмә барышында үзе турында да сөйләп алгалый иде. Сугыш елларында унбиш яшьлек үсмер ФЗӨ мәктәбен тәмалап, Казанда хәрби заводта эшләгән, шунда чиксез авырлыкларны күргән икән. Ачлык-ялангачлык, 16-18 сәгатькә сузылган хәлдән тайдыргыч эш. Шуның өстенә ул комсомол оешмасы җитәкчесе дә.

—Тулай торакка кайтып йөрү юк—ерак, юлда вакытны уздырмас өчен хәтта кышкы салкыннарда да завод чарлагына менеп юан-юан җылыткыч торбалар арасында йоклый идек. Чөнки таң белән эшкә тотынасы бар,—дип сөйләгәне истә.

Аның тагын бер гыйбрәтле вакыйганы искә алганы хәтердә. Ачка киселгән олы яшьтәге бер завод эшчесе станогы янында егылып үлә. Аны җирләүне комсомол оешмасына йөклиләр. Урамда чатнама суык. Мәхмүт берничә үсмерне кабер казырга җибәрә, үзе мәрхүмне зиратка илтергә тиеш була. Профсоюз оешмасыннан өч метр марля алып, мәрхүмнәрне соңгы юлга әзерләүче дорфа гәүдәле, йомыкый маржага кертеп бирә, үзенең аңа булышырга әзер икәнен әйтә. Маржа:

—Иди, иди, я сама,—дип, Мәхмүтне куып чыгара.

Табутны чанага салып, Мәхмүт Арча кырына юнәлә. Кышкы юл чалулы. Түбәнгә төшкәндә арык ат ирексездән юырта башлый. Шулчак чана чалулап

китә һәм Мәхмүт бер якка, табут икенче якка тәгәрәп төшеп калалар.

—Торсам, табут бер жирдә, капкачы икенче жирдә, ә мәрхүмнең шәрә жәсәде ике арада ята—теге дуамал, нәфселе маржа аны мин алып килгән кәфенгә төрмәгән, тар гына марля кисәге белән аскы ияген генә тарттырып бәйләгән дә, эш беткән,—диде Мәхмүт абый көрсенеп.—Көч-хәл белән жыеп, зиратка илттем. Әнә шул шәрә килеш жирләдек инде мескенне...

Мәхмүт Хәсәновнын бу кыйссасы минем хәтергә мәңгегә сеңеп калды. Соныннан анын белән дуслашып киттек. Азнакайда яшәгәндә ул Татарстан язучыларынын Әлмәт бүлегенә еш килә, мин дә вакыт булган саен шунда керә торган идем. Ә аның белән очрашу, аралашу—үзе бер гомер, күнел яме иде.

...Колоннаны төшереп бетергәндә автомашина белән кабат «Татнефть» житәкчесе А.Т.Шмарев, бер төркем анын якын хезмәттәшләре, шулай ук кайсыдыр бер ашханә хезмәткәрләре килеп төштеләр. Генералны хәтерләткән зур, таза гәүдәле Шмарев:

—Ну, ребята, от души поздравляю—вы установили новый рекорд,—дип безнен барыбыз белән дә кул биреп күрешеп, тәбрикләп чыкты. Аннары жину яулаган бораулау бригадасында кыска гына митинг булды. Алексей Тихонович командасы кызыл әләм алып килергә дә онытмаган икән, ул: «Дайте сюда флаг»,—диюгә, ана сораганын китереп тоттырдылар.

—Ну, кто заслужил установить флаг победы на кронблоке?—диде ул гөрелтек тавыш белән.

—Алексей Тихоныч, это, я думаю, надо поручить молодым,—диде Григорий Яковлевич Поляков, Мөхәррәм белән миңа ымлап.

—Правильно, правильно,—диештеләр башка бораулаучылар да.

—На, Мугалим, сам вручай флаг своим ребятам,—дип, Шмарев әләмне Гыймазовка бирергә теләгән иде, безнең мастер риза булмады:

—Когда сам Шмарев здесь, нам остается лишь наблюдать,—дип көлеп куйды. Шмарев әләмне Мөхәррәм кулына тоттырды да, икебезгә дә:

—Ну, орлы, вперед,—дип, вышка башына менә торган баскычка күрсәтте.

Ике-өч минуттан кызыл әләм—жину әләме вышка башында жилферди иде инде. Аста, буровой янында жыелган халык «ура» кычкырды.

Шул арада «Татнефть»тән килгән икътисадчылар 307нче скважинаны нәкъ ике мәртәбә иртәрәк—25 тәүлектә тәмамлап, тиз бораулау буенча яна рекорд куюыбыз турында әйттеләр. Тизлек—әлегә кадәр күрелмәгән, шаккатыргыч иде: 3023 метр! Союзда иң яхшы күрсәткеч...

Бәйрәм хакына буровой янында ачык, жылы, ләкин жиләс һавада табын әзерләнде. Беренче тостны әлеге дә баягы «Татнефть» житәкчесе, олы гәүдәле, ләкин безнең өчен үтә гади, бик кешелекле, кайгыртучан Алексей Тихонович Шмарев әйтте. Башкаларны белмим, әмма Мөхәррәм белән минем өчен бу—тәүге тапкыр аракы эчү булгандыр, чөнки күпмедер вакыттан соң аракы сөремендә йоклап киткәнбез. Без уянганда халык таралышкан иде инде. Без, ике дус, кочаклаштык та: «Ай-ли баулылар, һәр эштә мактаулылар»,—дип жырлый-жырлый тулай торакка кайтып киттек.

Чираттагы скважинада да рекорд кую теләге бар иде бригаданың. Ләкин аз гына килеп чыкмады. Капкан саен калжа булмый диләр бит безнен халыкта. Шулай да тизлек тагын 3000 метрга якын иде.

***

Ә безнең «подвахта» эшләгән икенче—Әхмәт Вәлиев бригадасы шул көннәрнең берсендә геологик-техник наряд буенча 1100-1150 метр тирәнлектәге ташкүмерле катлам—«угленоска»га кадәр бораулау бурычы

алды. Әхмәт зирәк егет иде, бу мөмкинлекне үзен таныту өчен файдаланып калуны хуп күргәндер. Бораулаучыларны җыеп:

—Наша задача—установить рекорд по коммерческой скорости. Соберемся?—диде ул баскан килеш. Гәүдәгә ул мин искә алган Шмарев, «дядя Гриша» Поляков, Рәшит Кәримовлардан да калку иде.

Җәмил Каюмовтан калган бу бригада халкы бик ялкынлы күренмәсә дә, Әхмәт үзе бик ялкынлы булганга, берничә бораулаучы:

—Давайте, попробуем,—диештеләр.

Аның бит вакыты да искиткеч—июнь ае. Ә ташкүмерле катламга тәҗрибәле бораулаучылар беренче сулу алуда төшеп җитәләр иде ул елларда. Әхмәт Вәлиев тә бораулаучы булып эшләгән кеше. Яхшы бораулаучы, чөнки начарын мастерга укырга җибәрмиләр. Ул да исәп тота белгәндер.

Еллар үткәч, бу рекорд барлык нечкәлекләре белән минем хәтердә калмаган. Әмма проекттагы тирәнлеккә егерме өч көн урынына җиде көндә төшеп җитеп, 11 мең метрдан артык тизлек белән үзенә бер аерым рекорд куйганыбыз хәтердә. Дөрес, бу рекордны девонга ясаган рекорд белән тиңләштерергә ярамый. Девон—девон инде. Шулай да бу вакыйгадан соң газета-журналлар Әхмәт Вәлиев һәм аның бригадасы турында шаулап алдылар. Яшь останың абруе шактый күтәрелде ул чакта.

Бергә туң су линиясен «җылытып» йөргән көннән алып мастер Әхмәт Вәлиев белән гади эшче Әсгать Салахов арасында үзем дә дөресен генә әйтеп бирә алмаган бер җылы мөнәсәбәт урнашты. Бәлки, яшь мастерның бригадага күбрәк яшьләрне җыеп, удар көч тупларга булгандыр исәбе?

Кайсыдыр бер буровойда эшләгәндә көннәр бик кызу китте—чыдап торгысыз. Аптырагач, кипкене суга манчып киябез—ул вакытта башны саклаучы махсус каскалар киюне без белми идек әле. Аннары мин, бораy забойда булудан файдаланып, буровойны бераз чылатып алу исәбеннән суны ачтым. Су линиясендә басым көчле икән—шланг кулдан ычкынды да, буровой күперенә килеп кергән Вәлиевне су белән коендырды. Мин: «Нечаянно»,—дип акланырга тотындым. Ә Әхмәт:

—За нечаянно бьют отчаянно,—дип, минем кулдан шлангны алды да, мине су белән коендырырга тотынды. Ә су шундый җылы, чөнки су линиясе җир өстеннән килә, ул кояшта җылынып ята. Бер рәхәт! Әхмәт шлангны миңа бирергә өлгермәде, мин дә тегене коендырырга тотындым. Шулай көлешә-көлешә, бер ямь, рәхәт табып бер-беребезне коендырыштык та, аннары өсләрне салып, сөйләшә-сөйләшә киемнәрне кибәргә элеп куйдык. Бу хәл дә безне, гаҗәпләнмәгез, шактый якынайтты бугай.

Ләкин буровойда күңелле мизгелләр сирәк була. Икенче көнне без эшкә килгән җиргә «сюрприз» ясап куйганнар иде—«шәм»нәрне төшергәндә яшь бораулаучы ташкүмерле катламда саклык чараларын күрергә онытткан да, инструмент колоннасы скважинадагы чыгынтыга барып терәлгән һәм, «элеватор» ачылып китеп, колонна аска дөбердәп төшеп киткән. Без килгәндә өстә калган «шәм»нәрне төшереп, колоннаны элэктергәннәр, тик аны өстән коелган токым кыскан, тартып чыгара алмый азапланалар иде. Бораулау конторасыннан яшь инженер Авдошин да килеп җиткән—ул буровойларда авариядән котылу чаралары оештыру эше белән шөгыльләнә иде.

—Давайте, попробуем вытащить,—диде ул Алексей Михайлович Логуновка.

—А где Баушин?—дип сорады Логунов.

—Он приболел,—диде инженер.

Безнең конторада Баушинны белмәгән кеше юк иде. Үз вакытында тәҗрибәле оста булган, девон нефтенә күп мәртәбә юл ачкан. Хәзер исә

ул безнең конторада авария мастеры иде. Тик менә авырып киткән бит әле...

Башка чара юк. Алексей Михайлович, ашказаны белән интексә дә, батыр, тәвәккәл кеше иде—үз урынына килеп басты һәм колоннаны тартып карады. Индикатордагы авырлык үлчәме угы соңгы чиккә терәлде.

—Будем работать под давлением, включайте насосы,—диде Логунов. Аның хәзер авария эшләре белән шөгыльләнә башлавын сизеп, верховой (Рәшитне Поляков вахтасына алгач, безгә икенче верховой килгән иде): «Избавьте меня от этой рискованной затеи, у меня дети»,—дип буровойдан чыгып ук китте. Әйе, ул хаклы иде: авария эшләре вакытында бораулаучының эш урынында фәкать авария мастеры гына калырга тиеш, башка бораулаучыларга буровойга керергә рөхсәт ителми. Володя Мудюков та читкә китеп басты. Ләкин насослар янында, штурвалда кемдер булырга тиеш бит. Алексей Михайлович миңа эндәште:

—Мы с тобой вдвоем остались, Асхат Петрович. Давай к штурвалу!

Мин икеләнеп тормадым—насослар сараена кереп киттем. Яшь идем шул әле, тәвәккәл булганмын, куркуны белмәгәнмен, чөнки жир астында кысылган «шәм»нәр колоннасын өскә тартканда һәм котырып насослар эшләгәндә линиядәге су басымы 140-150 атмосферага чаклы күтәрелә. Басым астында су торбасы үзе дә шартларга мөмкин—Алла сакласын! Мин басымны штурвал ярдәмендә көйли башладым. Ачык задвижкадан су агымы пулеметтан атылып чыккан пулялар кебек атыла. Вакыт-вакыт үземне дә шик ала. Шулай маташканда бер-бер артлы ике мәртәбә су линиясендәге диафрагма шартлап, су фонтаны вышкадан да югарырак өскә атылды. Янда гына бомба шартлаган кебек булды. Икенче кат бәреп чыккач, диафрагманы бераз «калынайтырга» туры килде. Ике сәгатьләп азапланганнан соң, Логунов белән икебезнең тырышлык бушка китмәде—скважинада кысылып калган «шәм»нәр колоннасы, акрын гына кузгалып, өскә таба үрмәли башлады. Безнең эштә бу хәл күбесе өчен чын батырлык иде.

***

1954 елның августы. Баулы бораулау конторасына яңа—Павловка нефть мәйданында скважиналар бораулау бурычы куелды. Берничә бригаданы ашыгыч рәвештә ул вакытта Бөгелмә, хәзер исә Азнакай районына кергән Актүбә эшчеләр бистәсенә күчерергә булдылар. Актүбә авылының көнчыгышында, кыр уртасында, әзер «щит»лардан вакытлыча диеп төзелеп килгән бер катлы барак-фатирлар, ике катлы сигез фатирлы йортлар, ашханә һәм башка социаль корылмалар аякка баса. Актүбәнең бу өлешенә инде «бистә» исеме дә бирелгән.

Баулы бораулаучылары арасында бу турыда әле сүз генә бара. Кайсы бригада китә, кайсысы Баулыда кала? Безнең «подвахта» эшләп йөргән Әхмәт Вәлиев бригадасы да китә икән. Балалар йортында тәрбияләнеп, шунда үскән, татарчаны рәтләп белмәгән, гел русча гына сөйләшкән оста бер иртәне:

—Ты со мной поедешь. Верховым! Собирайся, завтра едем,—диде миңа.

Нишләргә: минем ике житәкче, кайсында калырга, кем белән булырга? Гыймазов бу турыда сүз әйтмәде әле, ә Вәлиев турыдан-туры: «Со мной поедешь»,—диде әмер биргән кебек. «Верховым»,—дип тә өстәде. Минем өчен бер баскычка үсү бит әле бу. Димәк, киләчәк өметле минем өчен. Әйдә, Әсгать, ни булса—шул булыр, киттек Вәлиев белән яна жиргә!

Актүбәдә безне вакытлыча булачак фатирларга урнаштырдылар. Монда буйдак та буйдак, өйләнгәннәр, бала-чагалылар да буйдак, чөнки әлегә

аларга фатир бирү юк.

Бер атна мин Вәлиев бригадасында бораулаучы, әзәрбайжан Жамал Гусейнов вахтасында верховой булып эшләдем. Бу чорга безнең бораулау конторасы да «янарган» булып чыкты. Ул «Татбурнефть» трестының (Лениногорскида) 2нче бораулау конторасы дип атала икән.

Бер көнне безнең буровойга, минем янга Әлфрит килеп керде. Электриклар курсын тәмамлаган, электр эшләре буенча ниндидер бер оешмада эшләп йөрүе икән, юл уңаенда мине эзләп тапкан. Бераз сөйләшеп тордык. Ул да:

—Комиссиядә булдым, армиягә алып китәрләр ахры,—дип куйды.

—Китәрбез инде, аңа мин дә әзер,—дидем мин саубуллашканда.

Ләкин минем Актүбәдәге «карьера» кинәт кенә өзелеп куйды. Төнге вахтадан соң рәхәтләнеп йоклап ятам. Колакка:

—Где тут Салахов, где Асхат?—дигән сүзләр ишетелә.

—А он со мной живет. После ночной вахты спит,—ди мукшы егете Кирилл Канайкин. Күземне ачып жибәрсәм, каршымда Мөгаллим абый басып тора.

—Син нишләп миннән сорамыйча китеп бардың?—ди бу.

—Әхмәт чакырды да киттем. Мин бит «подвахта»да, сезнең бригада өчен кирәгем калмады дип уйладым...

—Әйдә, жыен! Баулыга кайтабыз...

Кирәгем бар икән бит! Иске, кыршылып беткән чемоданга барлы-юклы киемнәрне ташладым да Гыймазовның министр Байбаков бүләк иткән «Победа»сына чыгып утырдым. Ул вакытта киң кулланышка кереп барган, илдә иң кәттә жиңел автомашина иде «Победа». Аның белән мастер үзе якын иткән бораулаучы егетләрне ял көннәрендә сыра эчәргә Бөгелмәгә, йә булмаса Октябрьскийга алып китә. Безнең өчен андый сәфәрләр үзенә күрә бер кызыклы чара була иде. Иң мөһиме—аралашу, тормышка өйрәнү, кеше арасында булу, сине кешегә санап, үз итеп чакыру, сине әллә кайларга алып бару ләззәтен тату.

Мөгаллим абый аз сүзле булса да, игътибары житәрлек, күзе очлы иде. Кем көчен куеп, тырышып эшли, кем хәйләлек белән үтәргә чамалый, кем ялкау яисә булдыксыз—барысын да күреп тора. Һәм үзенә ошамаганнардан да тиз арына. Алар урынына эшчән егетләрне сайларга тырыша. Логунов «подвахта»сы да үзенә күрә төп бригаданы ныгыту чыганагы иде бугай. Мин эшләп йөргән чорда верховой Рәшит Кәримовны бездән бригаданың иң тырыш һәм булдыклы бурильщигы Григорий Поляков вахтасына күчерде мастер, чөнки Рәшит тә Поляков кебек эшкә батыр иде. Озакламый ул вахтага Иван Шереметта эшләгән Мөхәррәм Фәйрушинны да верховой иттереп күчерделәр. Мине исә Мөхәррәм урынына, Шеремет вахтасына алып кайтуы икән Гыймазовның. Әнә шулай бригаданы эшчән егетләр белән ныгыта иде безнең остаз. Һәм ул гына түгел, башка бригада житәкчеләре дә шулай эшлиләр, чөнки башкача алар уңышка ирешә алмыйлар иде.

Совет, партия елларында «Кадры решают все!» дигән канатлы сүз булганын һәркем белә. Ә бит ул бүген дә шулай.

***

Акбуага әни килеп төште. Кемдер аркылы мин аны чакырткан идем. Кесәдә акча күп. Болай мин булышмый тормадым, һәрвакыт акча жибәрә идем. Ләкин алда—уку елы, сеңлем Мөзәянә белән энем Әгъдәскә мәктәпкә киенеп барырга кирәк. Баулы белән Акбуа кибетләрен үтеп, бер капчык кием-салым жыйдык. Акча да бирдем әнигә. Аннары Бөгелмә юлына озата чыктым. Ул вакытларда да, соңрак та әле маршрут автобуслары йөрүне

белмәдек без. Яхшы юллар һәм автобуслар булмаганга йөрми иде алар.

Менә бер йөк машинасы килеп туктады. Әнигә әрҗәгә менәргә булыштым да капчыкны аңа суздым. Әни:

—Рәхмәт, улым, зур рәхмәт!—дип китеп барды. Безнең әни олы улына нилектәндер кырысрак булды. Шулай да аның миңа рәхмәт әйтүе йөрәккә май булып ятты.

***

Гыймазовның мине Актүбәдән Акбуага «дөбердәтеп» алып кайтуына карамастан, Иван Шеремет вахтасында озак эшләргә язмаган икән. Күп дигәндә ай ярым эшләдем бугай, аннан мине армиягә алып киттеләр. Ләкин шул кыска вакыт та яңа кешеләр белән танышу, аларның холык-фигылен белү өчен җитәрлек була икән. Украинадан килеп татар арасында адашкан Иван Ширәмәт (без аны үзебезчә шулай атый идек, чөнки бу исемнең төрки-татарныкы икәнлеген белдек) каршылыклы бәндәләрнең берсе иде. Эшен тырышып башкара—бу яклап безнең останың идеалы. Ләкин башка унай якларын хәтерләмим. Беренчедән, саранның сараны. Бер-бер артлы ике-өч папиросны кабызып тарткан Иванның кесәсендә бер кап түгел, бер данә папирос та булмый, кешенекен пыскыта. Моның өстенә Иван абзыебыз эшкә ашарга да алып йөрми, анысы да безнең өстән. Һәм ул бу хәлне шулай булырга тиеш дип саный иде бугай. Ширәмәтнең шул гадәтләре генә дә бригадада аңа карата җирәнгеч тойгы уята иде. Иң күп акча алып эшләүче бурильщикларның берсе үзен шулай түбән тотсын инде...

Тагын бер кимчелеге—Иван борауны забойда кирәгенчә ашалганчы тотарга курка, янәсе «шарошкалары» төшеп кала. Бу яклап аның осталыгы да, тәҗрибәсе дә җитми иде. Ярдәмчесе генә булса да Баязит Сәлимов исә, киресенчә, бораунын забойда ашалу дәрәҗәсен соңгы метрга чаклы тоя торган егет иде. Ләкин Иван аны тыңламый, курку хисе аңа Баязитны тыңларга бирми:

—Хватит, хватит, подъем, а то шарошки оставим,—ди дә насосларны туктатып, «инструмент»ны күтәрә башлый. Яртылашы да ашалмаган бораy скважинадан килеп чыккач, үпкәле Баязит Иванга:

—Ват, пасматри, чту ты дилаеш, пасматри!—дип ярсырга тотына. Ә Иван аның ярсуын исенә дә алмый, чөнки бу аның файдасына түгел. Шулай тынычлап бораулау урынына «вира-майна» куа, бездән дә кудыра.

Әнә, дядя Гришаның боравы забойда соңгы мөмкинлегенә кадәр токым кимерә. Һәм без аның вахтасындагы егетләргә ак көнчелек белән карый идек: бәхетлеләр дә инде, ашыкмыйлар, кабаланмыйлар, рәхәтләнеп эшлиләр һәм күрсәткечләре дә иң югары...

***

Башкортстан авылларының берсеннән килгән Баязит Сәлимовның русчасы бик шәп булмаса да, үзе бик шәп кеше иде. Армас-талмас, искиткеч эшлекле, тынгысыз, гадел һәм хәйләсез. Ширәмәтне күралмый, ә мине энесен яраткан кебек ярата, чөнки авыр эш халәтендә янында сине аңлаган, сиңа булышкан, һич югында фикереңне уртаклашкан кешең булу кирәк.

—Китәм мин, башка бригадага китәм. Туйдым бу Иваннан, шуның өчен китәм...

—Юкны сөйләмә әле, бажа,—дим мин аның яраткан сүзен кулланып.—Синсез бригада нишләр? Мин, Мөхәррәм нишләрбез? Сине бит бөтен кеше ярата. Озакламый син үзең бурильщик булырсың, менә шунда Иваннан котылырсың.

—Ә син?

—Мине армиягә алалар...

Анының үзе белән эшләп йөргән һәркемгә «бажа» дип эндәшә торган кызык гадәте бар иде. Хәтта безнең ише өйләнмәгәннәргә дә. Гәрчә кайвакыт «бажа» дип эндәшкәнне мыскыл итү дип аңлаган кайберәүләр белән четерекле хәл туса да. Без исә моңа күнгән: «бажа» дип әйтү ул дустым, якын күргән кешем дип әйтү кебек. Әле бу мәсьәләдә берни аңламаган урыс яки Иван кебек тун хохоллар да аңа «базя, базя» дип эндәшәләр. Янәсе «Баязит»ның кыскартылган рәвеше ул—«базя».

Аны яратмый, хөрмәт итми мөмкин түгел иде: эше уртак, ашы уртак, сүзе уртак. Үзе кызыклы. Әйтик, буровойга кертер өчен эстакададан лом белән торба тәгәрәтә. Ә без, яшьләр, онытылып нәрсә турындадыр сөйләшәбез. Шулчак Баязитның төртмәле сүзе безне сискәндереп җибәрә: «Малайлар таза!..» Янәсе, малайлар таза тазалыкка, тик Баязит абзаларының үзенә генә туры килә эшләргә, ә таза малайлар карап торуны гына беләләр. Һәм без дә ломга тотынабыз...

«Малайлар таза»... Бу искиткеч кинаяле ике сүзне тәүге тапкыр ишетүемә ярты гасырдан артык инде. Ә истән һич чыкмый, гел күңелдә. Картаймыш көнемдә бакчада ялгызым маташкан вакытта: «Малайлар таза» дип үз-үземне юатам да күңелем булып китә, тырышыбрак эшли башлыйм кебек. Аннары көлеп куям. Минем өчен тылсымы бар бу сүзләрнең. Аларны әйтеп калдырганың өчен мен рәхмәт сиңа, Баязит дустым!..

Баязит, барлык бораулаучыларны шаккатырып, ул чорда иң танылган Иж-49 мотоциклы алды. Зур бәягә! Бүген «Мерседес» алган кешеләр дә Баязит чаклы шатланмыйлардыр. Ә ул шатланды. Һәм ничек кенә әле! Беренче көннән үк безне буровойга утыртып йөри башлады. Бергә китәбез, бергә кайтабыз. Рөхсәт (права) дигән нәрсәне белми идек әле ул елларда. Атаклы Гыймазов бригадасының унган егете Сәлимовны милиция дә туктата алмый—шикләнә тоткарларга. Әйе, шулай иде ул чакларда. Гыймазовның исеме бөтен илне шаулатканга шулай иде.

Еш кына мотоциклның арткы урындыгына Мөхәррәм белән икәү менеп кунаклыйбыз. Бажа яңа асфальт юлдан 120 чакрым тизлек белән элдертә, безгә каршы «чапкан» җил бөтен тәнне өшетә. Яшьлек һәрвакыт тиле инде ул. Ничек бәрелеп бетмәгәнбездер? Әнә, Гыймазовта дан казанган бораулаучы Ахун Арысланов, шулай ук мотоциклда бәрелеп, төбеннән үк бер аяксыз калды. Ул турыда беләбез бит югыйсә...

Авыл кызларының иң юашы булган Сәхипҗамал да бер сүз әйтми безгә. Яраткан иренең дусларына ничек сүз әйтсен? Анының моңа вакыты да тими—эш аты—ир турында кайгыртасы, бер-бер артлы туган балаларны карыйсы бар. Акчаны көрәп алып кайтып торган Баязиты гына исән-имин булсын. Хәерче дәрәҗәсендәге ярлы авылда төшкә дә кермәгән хезмәт хакы алып эшли бит ул, рәхмәт төшкере! Бәхете булды инде Сәхипҗамалның. Шуңа кинәнеп яши дә...

## «Күңел дәфтәре»...

Сентябрь бетте, октябрьгә кердек. Егетләрне армиягә алып китә башладылар. Хәрби комиссариатта үземнең нинди төр гаскәрләрдә хезмәт итәсемне белдем. Авиация! Ә анда иң соңгы «набор» икән, тиз генә китмибез әле, октябрь ахырында гына.

Бер кичне Мудюковларга бардым. Мине югалтканнар—күптән кергән юк иде. Вакыт булмады. Ул елны мин, яз айларыннан башлап ук, Акбуада яңа төзелеп тәмамланган «Нефтяник» клубында драма түгәрәгенә йөри башлаган идем. Володя, Аза, балалар белән утырып чәй эчтек, сөйләштек, шаярдык, көлдек.

Артист булу хыялы мине балачактан озатып килә. Әле үзебезнең авылның башлангыч мәктәбендә дүртенче сыйныфта укыган чакта ук укытучылар һәм авыл яшьләре җыелып Тажи Гыйззәтнең «Чаткылар» драмасын клуб сәхнәсендә куйганда, андагы кыяр урларга җыенып йөрүче ике малайның берсен—Сәләхине уйнадым. Әсәрдә малайларның роле—ут төртүче Мочтакны фаш итү. Инде җидееллык мәктәпнең алтынчы сыйныфында укыганда Түбән Абдул авылы клубында тагын бер малай ролендә уйнарга туры килде. Аннары Елховой һәм без өч ел укыган Лашман авылы клубларында шул ук «Чаткылар»да Тимай карт һәм Әтүтән Дәүли рольләрен, Мирсәй Әмирнең «Көннекче Әхмәт» комедиясендә Мәзин ролен башкарган идем. Болар турында алдагы хатирәләремнең берсендә язып та үттем.

Акбуаның яңа клуб мөдире Казаннан килгән Нури абый Аппакаев иде. Озынрак буйлы, чандыр, кара туткыллы, авызындагы алгы тешләре алтыннан, өсте чиста-пөхтә, үзен тотышы буенча гел татар зыялысы. Театрны яхшы белә. Соңыннан ачыкланды—Нури абый үзе дә Галиәсгар Камал исемендәге татар дәүләт академия таетрында эшләгән кеше икән. Язгы айларның берсендә клубта драма түгәрәге оешкач та, мине аның тәкъдиме белән түгәрәкнең совет рәисе итеп сайладылар. Репетицияне Гамир Насрыйның «Күңел дәфтәре» дигән пьесасын әзерләү белән башлап җибәрдек. Миңа төп ир-егет ролен башкару йөкләнде, ә төп кыз ролендә Акбуаның үз кызы Сәкинә (фамилиясе хәтердә калмаган) иде.

Аһ, ул еллар! Халык татар театрын үлеп ярата иде. Бәлки шуңадыр да, безнең драма түгәрәгенә иллеләп кеше язылды. Тиккә генә йөрмәсеннәр өчен бер үк вакытта клуб мөдире дә, бер үк вакытта художество җитәкчесе дә булган Нури абый җиде-сигез рольдән торган пьесаның һәр ролен икешәр-өчәр кешегә өйрәнә торырга бирде, янәсе, дөнья хәлен белеп булмый; зур театрларда әнә шулай эшлиләр.

Ә драма түгәрәгенә йөри торган кызлар арасында шундыйлары бар—һушыңны алырлык! Уналты, унҗиде яшьлекләр... Күзләре гел драма түгәрәгенә йөри торган егетләрдә. «Болар бит түгәрәккә генә түгел, бер үк вакытта егетләр белән дә танышырга-кавышырга килгәннәр»,—дигән уй туа күзәтебрәк йөргән кеше башында. Илле кешенең кимендә утызлабы—шул яшь кызлар. Араларында бик чаялары да бар, аларга егетләр янына килеп сөйләшү-танышу берни тормый. Тик егетләр генә аз йөри түгәрәккә...

Чыгышым авылдан булгангадыр, мин әсәрләр укып, мәхәббәтне идеаллаштырып үскән егет. Минем ул вакыттагы карашымча, мәхәббәт булса, бер һәм берәгәй, әдәби әсәрләрдәге, классикада тасвирланган хис-тойгылар, ялкын, мәңге онытылмаслык садә мизгелләр белән булсын. Моның өчен кызларның теләсә ниндие түгел, ә шәхескә тин—гүзәл, югары зәвыклы, ләкин тыйнак, эчке, рухи дөньясы бай булганнары гына игътибарга лаек. Ә андыйлар йөзгә бер генә булалар. Бәлки шуңадыр, драма түгәрәгенә йөргән гүзәл затлар арасында югары зәвыклы кешене мин очрата алмадым.

«Күңел дәфтәре»нә репетиция ясап йөргән чорда Нури абый Аппакаев Казаннан спектакльгә декорацияләр ясау өчен күренекле рәссамнарны чакырып китерде. Үзе яхшы белә торган кешеләр икән. Алар килү белән сәхнәдә зур эш башладылар. Мин мөмкин кадәр үземнең эш сәгатьләреннән соң яки ял көннәрне шул рәссамнар янында кайнашырга тырыша идем, чөнки рәсем сәнгате белән яшьлегемдә мин дә яратып шөгыльләндем, карандаш белән генә булса да Г.Тукай, К.Насыйри, А.С.Пушкин, М.Ю.Лермонтов, М.Әмир («Агыйдел» повестен яратып укыгангадыр инде) рәсемнәрен ясап, диварга элеп куйган идем. Ә бу рәссамнарның иҗаты чагыштыргысыз. Мин аларның декорацияләренә сокланып карыйм, еш

кына үзләренә дә булышам, чөнки Нури абый аларга булышырга әйтте. Ә бит олы рәссамнар булган икән алар: Петр Тихонович Сперанский—Нәҗип Җиһановның «Алтынчәч» операсына, Нәкый Исәнбәтнең «Хуҗа Насретдин» һәм башка бик күп спектакльләргә декорацияләр ясаган, Россия Федерациясенең атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстанның халык рәссамы; Эрнст Брунович Гельмс—Россиянең атказанган, Татарстанның халык рәссамы. Ул да Казандагы театрларга күп төрле декорацияләр ясаган. Сперанскийга ул вакытта алтмыш, ә Гельмска кырык ике яшь иде.

Спектакльне куяр алдыннан гына Казаннан Акбуага Г.Камал исемендәге татар дәүләт академия театрыннан ул чорның мәшһүр артистларының берсе Делюс Ильясов килеп төште. Бу Нури абый Аппакаев чакыруы буенча булгандыр. Йомры, елмаеп торган ачык йөзле Делюс абый безнең драма түгәрәге әгъзалары, аның белән очрашуга килгән башка бик күп театр сөючеләр белән ике сәгатьләп әңгәмә үткәрде—халкыбызның театр сәнгате тарихы, күренекле театр әһелләре, театр тормышыннан булган кызыклы вакыйгалар турында сөйләде, сорауларга җавап бирде. Бу очрашу минем күңелдә бүген дә аерым бер истәлекле сәхифә булып саклана.

Профессиональ театрлардагыча, без рольләрне суфлерсыз уйнарлык итеп яттан өйрәндек. Һәм шул кадәрле зур әзерлек белән куелган спектакль Баулы театр сөючеләре тарафыннан олы уңыш, зур тантана буларак кабул ителде. Чын театрларда гына була торган атмосфера, артистларның килешле уйнавы, геройларның оста җырлавы, музыка һәм профессиональ рәссамнар тарафыннан ясалган искиткеч сәнгати декорация тамашачыны таң калдырды.

—Сөям дигән ихлас сүзең белән
Ашкындырдың мине бүген дә;
Татлы сүзләреңне түгел, үзеңне дә
Саклыйм, иркәм, йөрәк түремдә...

—дип, пьесадагы «Иркәмә» җырын мин башкардым.

Шушы кичтә без үзебезне чын артистлар итеп тойдык, тәүге тапкыр тамашачыларның артистларны сәхнәдән җибәрмичә өзлексез алкышлавын күрдек. Безнең өчен бу көтелмәгән казаныш иде. Әле соңыннан да таныш һәм бөтенләй таныш булмаган кешеләр сәхнә артына менеп безне котладылар—кочакладылар, үптеләр, берсеннән-берсе җылырак мактау сүзләре әйттеләр.

Һәм китте, китте. «Күңел дәфтәре» белән без, декорацияләрне төяп, күрше Кызылъяр, Шалты, тагын кайсыдыр бер авылга барып спектакльләр куйдык. Анда да уңыш казандык.

—Әсгать энем, сиңа артист булырга кирәк. Талантың бар, аны тулысы белән театр сәнгатенә багышларга иде. Син киләчәктә зур дәрәҗәдәге артист булачаксың, әгәр шул юлны сайласаң,—диде шул вакытта Нури абый. Ләкин аның сүзләренә колак салырга, ул турыда чынлап уйларга минем вакытым юк—кесәмдә армиягә чакыру ята иде.

***

Октябрь ахыры. Мөхәррәм белән икәүләшеп авылга кайтып киттек. «Армиядән кайчан кайта алабыз әле, кайчан тагын туганнар белән очрашырбыз? Кайтыйк әле...»

Мөхәррәм авылдан 26 октябрьдә (1954 ел) чыгып китте. Ә икенче көнне, 27 октябрьдә, кичен Елховой күген куе зәңгәр болыт каплап алды да, төне буе ишеп яшенле яңгыр яуды. Октябрь ахыры... һәм яшенле,

жылы яңгыр—мин моны гомер буе хәтеремдә саклыйм, чөнки иртән мин дә әлеге яңгырдан соң изрәгән авыл юлы белән, лыч-лыч атлап, Баулыга чыгып киттем.

Ә иртән, 29 октябрьдә, мин Баулыда, армиягә озатыласы егетләр арасында идем инде.

Бер сәгатьтән автобус безне Бөгелмә тимер юл вокзалына алып килде. Ә монда мине гадәттән тыш моңсу да, шатлыклы да вакыйга көтә икән. Автобустан төшүем булды, яныма балачак һәм яшьлек дусларым—Бөгелмәдә тимер-бетон заводында эшләүче Җәмил Гыйльманов (авылыбыздан чыккан язучы Ләбиб Гыйльминең абыйсы Әхмәтнең улы) һәм Әлмәттән Әлфрит Гыйззәтуллин килеп бастылар. Озатырга беркем дә килмәс инде дип уйлаган идем. Поездга вакыт бар иде әле. Егетләр тиз генә шешә табыштырдылар—саубуллашу уңаеннан бераз гына каптык та. Үгет-нәсыйхәт, соңгы сүзләр, кочаклашып аерылышулар... Һич онытырлык түгел бит мондый озатуларны!

Кузгалып китәргә берничә минут калгач, перронда энем Тәлгать тә күренде—аңа минем артык киемнәр белән төенчек бирәсем бар иде.

Безнең эшелон башта Казанга, аннан көнчыгышка китеп барды. Алда безне берничә елга сузылган армия хезмәте көтә иде.

Без китәбез инде, сез каласыз,
Без китәбез ерак җирләргә...

## Безне көткәннәр

Нәкъ өч ел да бер ай авиациядә хезмәт итеп, 1957 елның 29 ноябрендә мин авылга кайтып төштем. Көннәр суык—утыз градус. Авылда армиядән кайткан дисталәгән яшьтәшләр кангырап йөри: кая китәргә, кайда көн күрә башларга? Колхоз әле ул елларда да кешене кинәндерми иде—ни эше, ни ашы. Рәтле тормышта яшим дисәң, төшемле урын табарга кирәк. Паспорт алуы да авыр—колхоз рәисе кирәкле кәгазьләрне бирми. Без армиягә киткәндә паспортларны военкоматта алып калганнар иде. Алып калу бар, ә кайтарып бирү юк.

Мөхәррәм дә, Германиядә ике ел хезмәт итеп, карт һәм ялгыз анасының үтенеч язуы буенча кайтып килгән. Очраштык, киңәш итештек. Әлбәттә, кабат үзебезнең бораулау конторасына китәргә.

Армиядән тоттырып җибәргән пакетны алып, мин башта Баулыга киттем: хәрби учетка керергә, билет һәм паспорт алырга. Ярый әле тукталырга кешем бар—Мудюковлар. Гаилә ишәйгән—Аза тагын ике кыз тапкан: Лена һәм Таня. Таняга әле ике-өч кенә ай. Аза мине әлеге бәләкәчнең «крестный»ы итеп атады. Мин риза—дуслар өчен ни генә кыланмыйсың. Володя «Баулынефть»тә калган бердәнбер бораулау бригадасында бораулаучы булып эшли. Өй каршында бәләкәй генә сарае бар, шунда куяннар асрый. Көн саен бер куян суябыз—армиядән кайткан дуска ярамаган тагын куян ите...

Хәрби комиссариатта өч көн тоткарландым. Билет алдым, ә паспорт юк, «прописка» сорыйлар. Мондый тинтәклек, булса да, шул безнең илдә генә булыр. Аптырагач, райкомның беренче секретаре Кәримов янына барып кердем. Кайсыдыр мине тоткарлап маташты, ләкин бик ярсу идем—этеп җибәрдем дә, кереп киттем. «Беренче» мине тынлап торды да, паспорт өстәленә шалтыратты: «Хәзер үк бирегез!». Ун минутта паспорт алдым да, Мудюковлар белән саубуллашып кайтып та киттем.

***

Илле сигезнең башы белән мин Актүбәдә идем инде. Тулай торакта яшәргә урын бирделәр, вакытлыча скважиналар үзләштерү бригадасына эшкә билгеләделәр.

Әле Актүбәгә килгәндә үк без Әлмәттә танылган бораулау остасы Михаил Белоглазовның буровойда һәлак булу фаҗигасен ишеттек. Армиядә булганга, без аның исемен дә ишетми яшәгәнбез. Ә ул яңадан-яңа рекордлар куйган бригаданы җитәкләгән икән. Безнең Мөгаллим Гыймазов бригадасы куйган 3023 метрлы рекорд соңгысы булмаган. Михаил Белоглазов бригадасы башта скважинаны 14 тәүлектә тәмамлап 3326, аннары 12 тәүлектә бораулап рекордны 3799 метрга җиткергән. Алда 4000 метрлы чик. Ләкин Белоглазов ялда чагында Азнакайга Мәскәү нефть институтыннан практикага килгән яшь студент Николай Македонов, мастерсыз калган бригаданы кабул итеп, скважинаны 11 тәүлектә тәмамлый һәм тизлекне 4569 метрга җиткерә. Бу искиткеч хәл була. Әле институтта укып кына йөргән студент, кайбер зур тәҗрибәле осталарның борынына чиртеп, һич көтмәгән биеклеккә ирешә.

Ләкин Михаил Белоглазов та йоклап ятмый. Ялдан чыгу белән аның бригадасы чираттагы скважинаны 10 тәүлектә бораулап, фантастик рекорд куя—5011 метр.

Кызганыч ки, бу рекорд Белоглазов өчен, аккош җыры кебек, соңгысы була... Хәзер Әлмәтнең бик зур бер урамы аның исемен йөртә.

Аннан соң да тиз бораулау буенча рекорд берничә тапкыр янара.Әле күп кешегә бөтенләй таныш булмаган Василий Ермаков, Виктор Гурьяновлар бер-бер артлы Белоглазов куйган чикне узып китсәләр, алда мин искә алган талантлы мастерларның берсе Әхмәт Вәлиев бригадасы рекордны 5517 метрга җиткерә.

Болар турында без кабат эшкә чыккач кына ишеттек.

Скважиналарны үзләштерү бригадасында безне күнегә торсыннар дип эшләттеләр бугай. Труббазадагы кебек, монда да хезмәт хакын аз түлиләр иде. Безнең өчен бигрәк тә беренче атналар авыр булды, чөнки ашарга, яшәргә кирәк, ә кесә буш. Ярый әле безгә Мөхәррәмнең иң олы туганы Срурия апа булышты. Ул Әлмәттә ТЗБда (торгово-закупочная база) эшли иде. Ач утыра башласак, Мөхәррәм Әлмәткә китә һәм мендәр чаклы төенчекләр белән язгы кояш кебек елмаеп кайтып керә. Анда колбаса да, балык та, макарон һәм ярма, май һәм башка ризыклар да була. Шуның өчен Срурия апага без бүген дә бик рәхмәтле. Ул хәзер 85 яшьтә, үз авылы—Түбән Абдулда исән-имин яшәп ята. Аяклары-куллары сызлаусыз, гомере озын булсын!..

Шөкер, бу бригадада без озын-озак эшләмәдек. Павловка нефть мәйданындагы скважиналарның яңа бораулана торганнары да, үзләштереләселәре дә бер үк тирәдә—шахмат тактасындагы фигуралар кебек тезелеп киткәннәр.

Бер көнне мин иптәшләрдән Мөгаллим Гыймазов бригадасы турында кызыксындым.

—Менә бит алар,—дип миңа якындагы буровойны күрсәттеләр. Вакыт табып, шунда киттем. Культбудкада Мөгаллим абый нәрәт тутырып утыра иде. Мине күргәч:

—Кайттыңмыни? Ә нишләп күренмисең, нигә килмисең?—дип миңа үпкәле сүзләр яудырды.

—«Освоение»дә эшләп йөрибез, вакыт тимәде,—дип акландым.— Мөхәррәм дә кайтты.

—Тапканнар кайда эшләргә! Ике-өч көннән бригадага чыгарсың.

Мөхәррәмгә дә әйт—ул да әзерләнсен...

Әнә шулай без икебез дә үзебезнең данлыклы бригадага кайттык. Икебез дә верховой булып—мин Михаил Клишин, Мөхәррәм кабат «дядя Гриша» Поляков вахтасына. Кыскасы, безнең икебезне дә көткәннәр булып чыкты. Алдынгы бригада ышанычын аклый торган егетләр идек шул.

Клишин минем өчен яңа кеше иде, ләкин Баязит Сәлимов—үз кеше, дуслар. Ул да безне сагынган. Мәгәр Михаил белән дә тиз уртак тел таптык, чөнки минем турыда ишетеп белә икән. Иң мөһиме—үз эшеңне җиренә җиткереп, тырышып эшләү, осталык, кыюлык. Бу—верховойга кирәкле иң төп сыйфатлар. Михаил исә тиз эшләргә, минем «шәм»нәрне элеватор верховой бишеге яныннан тиз үткәндә дә шапылдатып эләктергәнне ярата.

Без кайткан чорга рекордлар кую чире узган, хәзер бригадалар алдына еллык бораулау буенча иң күп скважина, «метр бирү» бурычы куела башлаган, барлык бригадалар да шул ярышта катнашалар иде. Безнең бригада монда да сер бирмәде. Берничә ел рәттән үзебезнең конторада алдынгы булдык: иң тиз һәм иң күп скважина, иң күп метр тау токымы борауладык.

Әйе, эшебез әйбәт бара, кулга акча да мул төшә. Сугышка китеп югалган әти салып калдырган өй искергән иде—авылда яңа өй сала башладык. Минем булышу бик вакытлы килеп чыкты.

Ләкин күңел тыныч түгел. Һаман олыгая барам, ә укуны дәвам итеп булмый. Әлмәттә Мәскәү нефть институтының кичке филиалы ачылган икән, Актүбә урта мәктәбендә оештырылган әзерлек курсларына йөри башладым. Ләкин Мәскәүдән килгән укытучы марҗа апалар бик таләпчән булып чыктылар—армиядән кайткан, алдынгы бригадада җир җимертеп эшләп йөргән мишәр егетен өченче имтиханда мәтәлчек аттырдылар. Язмыш белән килешеп, буровойда тагын да тырышыбрак эшләргә туры килде. Бүген шул турыда уйлыйм да, үземне сүгеп ташлыйм. Югыйсә, шул институтка барып керү минем өчен берни дә тормаган, тресттан алдынгы бригадада эшләвем турында характеристика һәм юллама гына аласы булган. Дөбердәтеп барып керәсе идем институтларына...

## Танышу

Илле тугызның ноябрь ахырлары. Актүбә читендә генә яңа скважина бораулый башладык. Вахта машинасына утырып, кырык-илле чакрымдагы буровойларга чыгып чапкан вакытлар булды, ә монда... Тулай торактан өч-дүрт минутлык җирдә эшлибез. Тик менә көннәр суык тора, төньяк җиле үзәкләргә үтә. Ноябрь ахырлары елның-елында чатнама суыклар алып килә безнең якларга.

Буровойны тәмамлап киләбез—алда соңгы метрлар. Эшне бүләбез дә, балчык измәсе ясыйбыз. Көтмәгәндә без йөри торган урман сукмагыннан буровойга ике ир якынлашты. Үзебезнең бистә кешеләре түгел—ятлар, безгә таныш түгелләр. Чатнама суыкта икесе дә язгы-көзге пәлтәдән, шуның өстенә берсе генә башына сарык мехыннан тегелгән ыспай кара бүрек кигән, ә олырак яшьтәгесе кипкедән. Армиядән кайтканнан соң мин дә кыш буе кипке киеп йөрдем, ә солдат бүреген эшкә кия идем. Хәзер исә минем башта да сарык мехыннан тегелгән кара бүрек. Ә менә абзыйның башында...

Икесе тиң килеп безнең белән кул биреп күрештеләр.

—Без—язучылар,—диде кара бүреклесе.—Менә бу абыегыз—күренекле татар шагыйре Хәсән ага Туфан, ә мин—язучы Гариф Ахунов. Сезнең бригаданың чиксез унышлары турында ишетеп, танышырга килдек әле...

Минем гаҗәпләнүемнең чиге-чамасы булмады шул мизгелдә. Тәүге тапкыр тере язучылар белән очрашу иде бу. Менә алар каршыбызда гына, тыйнак кына елмаеп, безнең янда басып торалар.

Кунакларны каршы алырга культбудкадан Мөгаллим абый да чыкты—ул аларның килүе турында хәбәрдар икән. Барыбыз да, суыктан качып, тизрәк җылы культбудкага кереп утырдык. Кайнар электр пиче өстендәге табада колбаса кыздыра башладык, үзебез белән алып килгән башка ризык-нигъмәтләрне чыгардык, чәй кайнарладык һәм күнелле итеп сөйләшә-сөйләшә кунаклар белән ашап-эчеп алдык. Ундүрт яшьтән район газетасында мәкаләләр бастыра башлаган, сонрак шигырьләр дә язгалаган кеше булгангадыр, мин һәрвакыт әдәбият белән кызыксынып, язгалап-сызгалап яшәдем. Һәм шул халәтем кунаклар белән очрашканда да үзен сиздерде булса кирәк, Гариф абый Ахунов:

—Син, малай, үзең дә язгалыйсың, ахры,—ди.

Без кабат измә ясарга чыктык, ә язучылар остабыз белән сөйләшә калдылар. Соңыннан алар вышка башына менеп төштеләр. Киткәндә мин аларның кайда урнашуларын сораштым.

—Кер, әйдә, кер, Әсгать. Сөйләшеп утырырбыз,—диде Хәсән ага. Аның белән Гариф абый да килеште.

Эш ахырында мин, верховой сәндерәсенә менеп, армиядә бүләк ителгән көмеш портсигарымны алдым. Тартуны сирәгәйткән, ташларга йөргән чак. Портсигар эченә минем санаулы «Север» папирослары янына Хәсән ага өч данә «Любительские» папирослары куеп калдырган булып чыкты. Ул гел шул сыйфатлы, затлы папиросны гына тарта торган иде.

Кич белән мин, күчтәнәчләр тотып, алар янына кердем. Актүбәдә ике тулай торак кына бар, кунакханә исә юк иде. Ир-атлар тулай торагы янындагы ике катлы «щитовой» йортның икенче катындагы бер фатир кунакханә ролен үти иде—Хәсән Туфан һәм Гариф Ахунов нәкъ әнә шунда өч көн яшәп, Актүбә бистәсе халкы, бораулаучылар, нефть чыгаручылар һәм төзүчеләр белән «Буровик» клубында, укучылар белән бердәнбер урта мәктәптә очрашулар үткәреп йөрделәр. Чыгышлар ясау, шигырьләрен уку, үзе турында сөйләү Хәсән ага өлешенә тиде, чөнки ул утызынчы елларда котырынган репрессия корбаны, бер гаепсез килеш «халык дошманы» буларак атарга хөкем ителгән, «всесоюзный староста» Михаил Калининга язган үтенеч хатыннан соң гына исән кала алган, 17 ел утырып, ниһаять, акланган һәм 1956 елда сөргеннән азат ителгән шагыйрьне халык белән очраштыру-таныштыру кирәк иде, һәм бу вазифа әле оешып кына килгән Әлмәт язучылар оешмасы житәкчесе, яшь прозаик Гариф Ахуновка йөкләнгән.

Бәхеткә каршы, ул көннәрдә безнең вахта көндез эшләде һәм өч кичне дә мин Актүбәнең олы кунаклары янында булуга ирештем. Язучылар аракы эчми торганнардыр дип, беренче керүемдә шампан шәрабе белән генә сыйланган идек. Соңыннан минем караш үзгәрде. Беренче кичне үк Гариф абый белән без күбрәк Хәсән аганы тыңладык. Аның сөйләгәннәре йөрәк өзгеч иде. Тикшерүдә яткан чорда аның хәләл җефете—Луиза Салиаскарова һәркөн ашарга алып килә. Бу вакытта танылган актрисаның үзен дә «халык дошманы» хатыны дип эштән куган булалар.

—Каян акча табасың соң син бу тәмле пәрәмәчләрне пешерер өчен?—дип сорый шагыйрь.

—Сорама, табам инде,—ди хатыны. Баксаң, ул кан тапшыра икән, шул акчага тоткын ире өчен ризык хәстәрли.

Актүбәдән киткән иртәне кунакларны бораулаучы дустым Фәрәсәт Әсхапов белән үзебезнең конторга чаклы озата бардык. Көнне сындырган,

жил тынган һәм һавада уйнаклап әкрен генә кар ява. Урман аша кышкы тар сукмактан үрдәк бәбкәләре кебек беребез артыннан икенчебез тезелешеп, сөйләшә-сөйләшә чыктык. Шунда Хәсән ага:

—Синең, Әсгать, өйләнер вакытың да җитеп киләдер инде. Кызың бармы соң?—дип сорап куйды.

—Бер кыз белән дуслашып йөрибез болай,—дидем.

—Татармы?

Әлегә бер ниятсез дуслашып йөргән кызның безнең милләт кешесе булмавын әйткән идем, Хәсән ага, бик пошынып:

—И-и, Әсгать, зинһар, башка милләт кызына өйләнә күрмә, үкенерсең,—дип тулы бер үгетләү сүзе сөйләп ташлады.—Менә без—язучылар, шагыйрьләр—бергә җыелабыз да, үз ана телебездә әдәбияттагы хәлләр турында сөйләшә башлыйбыз. Шунда кайбер әдипләрнең чит милләттән булган хатыннары, оятсыз рәвештә: «Хватит вам на своем болтать, говорите на человеческом языке!»—дип тенкәләргә тияләр. Син дә әдәбият кешесе булырга җыенасың бугай, ялгыша күрмә!


*Сулдан уңга: Ә. Салах, Х. Туфан һәм Г. Ахунов. 1959 ел.*

Аннары Хәсән ага белән Гариф абый ул вакытта әле исән-сау, хатыннары марҗа булган кайбер әдипләрнең исемнәрен атадылар.

—Ә син беләсеңме: марҗа белән яшәгәнгә, уртак тел таба алмаганга аларның күбесе бүген үкенеп туя алмый,—дип өстәде гакыл иясе Туфан.—Аңладыңмы?

—Аңламаган кая, Хәсән ага, әлбәттә...—дидем.—Мин бит марҗага өйләнергә җыенмыйм...

Туфан, күнеле булып, монсу гына елмаеп куйды.

—Әгәр теләсәң, мин сине бер кыз белән таныштырам. Бик әйбәт кыз. Матур-матур шигырьләр яза, чын шагыйрә.

—Кайдан соң ул, Хәсән ага? Казан кызымы?

—Юк, Әлмәттә яши.

—Мин аны беләм бугай...—дидем мин кинәт ул кызның исемен атап. Хәсән ага белән Гариф абый бер-берсенә серле генә карашып алдылар.

—Ә син аны каян беләсең?

—Әлмәттә минем туганнар яши, еш кына аларга барам. Шунда ул кыз турында ишеттем, бик талантлы дип әйттеләр,—дидем. Чынлыкта ул кыз турында күбрәген дә ишетеп белә идем, тик кунакларга артыгын сөйләү урынлы түгел иде.

—Әсгатькә өйләнергә соң түгел, Хәсән ага, аңа башта югары уку йортына кереп укырга кирәк. Менә мин, Әсгать, сиңа киләсе елга Казан университетына керергә киңәш итәм,—диде Гариф абый.—Быел анда тәүге тапкыр журналистика бүлеге ачылды. Татар журналистикасы. Уку—читтән торып. Мәкаләләр, шигырьләр, башкасын язасың икән—димәк, синең өчен иң кулай факультет. Дөрес әйтәмме мин, Хәсән ага?

—Бик дөрес. Мин дә хуплыйм моны...

Кунакларны озатырга бораулау конторасыннан автобус бирделәр.

Фәрәсәт фотоаппаратын да алган иде—безне фотога төшерде. Ул сурәт бүген дә минем альбомда саклана.

Китәр алдыннан Хәсән ага:

—Казанга килеп чыксаң, безгә дә керерсең,—дип адресын язып калдырды. Аның үрнәгендә Гариф абый да адресын бирде.

Тагын бер ай үттеме-юкмы, минем чыннан да Казанга барасым килеп китте. Гариф абый әйткән журналистика бүлеге дә, олуг шагыйрь Хәсән ага Туфан да шунда ич. Кесәмдә адрес та бар...

Дөрес, башта мин Казан университетының юридик факультетын тәмамлап килгән туганнан туганым Әнвәр янында тукталдым. Ул Кызыл Позиция урамындагы университет тулай торакларының берсендә яши иде.

Аннары Хәсән аганы эзләп киттем. Ул вакытта олуг шагыйрь кызы Гөлгенә белән Маяковский урамындагы күп катлы кирпеч йортта ике бүлмәле фатирда яши иде.

Ишекне кызы ачты. Мин үземнең кем булуымны әйттем. Шул вакытта зәңгәрсу буй-буй пижама кигән Хәсән ага да үз бүлмәсеннән чыкты һәм җылы елмаеп, «якташ мишәр канәт»ен каршы алды.

Бераздан без Хәсән ага бүлмәсендә кызы пешергән хуш исле пәрәмәчләр, мин алып килгән күчтәнәчләр белән сыйланып, рәхәтләнеп сөйләшеп утырдык.

Һәм бу очрашуда, ни гаҗәп, Әлмәттә яшәүче шагыйрә кыз белән алтмышын тутырып килгән, ләкин әле һаман тирән хис-тойгы белән яшәгән, яшьләр кебек ялкынлы йөрәкле шагыйрь арасында романтик мөнәсәбәт кабынуы турында белеп кайттым. Моңа, бәлки, шагыйрә кызның Казанга килеп университетка укырга керүе сәбәпче булгандыр, чөнки ана якынайгач очрашулар ешая, тәэсирләр һәм бер-береңә тартылу көчәя.

Мин әлеге вакыйганың күпмедер дәрәҗәдә шаһиты булган кеше һәм биредә исәбем укучыга шәхси фикеремне җиткерү, чөнки теге елларда бу хәл төрле даирәдә төрлечә бәяләнде. Берәүләр Овидий Назон кебек аяусыз тоткынлык кичергән, ләкин саф күңелен саклап кала алган, яшьлегендәгечә романтик ялкын, кайнар хис белән яшәгән шагыйрьгә сокланып карадылар, битәрләргә кыймадылар; икенчеләр исә аның мәхәббәтен хупламадылар. Шул исәптән, Хәсән аганың бердәнбер якыны—кызы Гөлгенә дә.

Хәсән ага кызына «Гуля» дип эндәшә иде. Төрле хатирә-истәлекләрдә аның исемен төрлечә язалар: Гөлгенә, Гөлсинә. Габдрахман Минскийның икенче хатыны Сәлимә ханым үз истәлекләрендә Туфан кызының исемен Гөлсинә дип яза.

Университет тулай торагында студентларның Яңа ел бал-маскарадында да катнашу бәхете тәтеде. Һәм шунда миңа әлеге дә баягы шагыйрә кыз белән очрашырга, хәтта вальс биергә дә язган булып чыкты. Актүбәдән озатканда Хәсән аганың: «Бер кыз белән таныштырыйммы?»—дип әйткәне хәтердән чыкмаса да, кызны күргәч, турысын әйтим, егылып китмәдем. Ә менә аның олуг шагыйрь белән булган мөнәсәбәтенә уңай карадым, чөнки ике ялгыз, ниһаять, бер-берсен тапканнар, дип уйладым. Икесенең дә хисләре бер кимәлдә тулып ташкан сыман иде. Ләкин алай булмады, ахры. Ташкын хисләр фәкать шагыйрь йөрәгендә генә кайнады бугай...

Шуңа карамастан, Туфанның ул чорда йөрәгеннән ташып чыккан мәхәббәт поэзиясе тиңе булмаган классик әсәрләр тезмәсенә әверелде. Ул шигырьләргә иң күренекле, иң талантлы композиторлар берсеннән икенчесе тәэсирләнеп, халык йөрәген тиз арада яулап алырдай, аны уйландырган-моңландырган җырлар яздылар.

Әйткән идең: « Әгәр сөя калсаң
Миннән башка берәр бүтәнне,
Сөй, ләкин сөй миннән яхшыракны,
Сөймә бары миннән түбәнне».

Очрадым мин быел бер чәчкәгә,
Көтмәгәндә, уйламаганда
Нәкъ синдәйгә, синең шикеллегә,
Әйтерсең лә синең дәвамга.

Тормышымның синнән соңгысында
Сөймәм диган идем һичкемне.
Нишләргә соң миңа, нишләргә соң:
Ул һәр яктан синең шикелле...

Күңелгә бәгырьләрне телгәли торган бер моңлы җыр булып кереп калган бу юллар шагыйрьнең шул чактагы йөрәк авазы икәнен һәркем аңлый булыр.

Казаннан кайткач, озакламый республика җәмәгатьчелеге, Татарстан Язучылар союзы Хәсән Туфанга 60 яшь тулуны билгеләп үтте. Шагыйрьне тәбрикләп Актүбә бораулаучылары исеменнән телеграмма җибәрдек. Ул телеграмманы юбилей тантанасы президиумыннан укулары турында Хәсән ага соңыннан бик сөенеп искә алды.

Алтмышынчы елның башында «Казан утлары» журналында Гариф Ахуновның безнең оста Мөгаллим Гыймазов турында язган очерк-хикәясе басылып чыкты. Ул «Картина» дип аталган иде.

Әлмәт—Казан түгел, ул миңа якын, кырык кына чакрымда, анда туганнар да яши һәм җае туры килгәндә мин еш кына барып та чыгам. Инде бер танышкан-дуслашкан, минем күңелгә һәр яклап хуш килгән, ачык йөзле, гади, җылы күңелле Гариф абый Ахунов янына да барып йөри башладым.

Алтмышынчы елның көзе. Мин, әрсезләнеп, тагын аларга барып кердем. Гариф абый, киенеп, каядыр барырга җыенган иде.

—Иҗатташ дустым Фазыл безне—Әдип белән мине—кич утырырга чакырды. Әйдә, син дә артык булмассың, яңа әдәбият әһелләре белән танышырсың. Аннары безгә кайтырбыз,—дип, мине дә ияртте. Ахуновлар яшәгән Радищев урамыннан Әлмәтнең Ленин урамына төштек тә, «Россия» кинотеатры каршында безне көтеп торган, безнең кебек үк урта буйлы, Гариф абыйдан берничә яшькә олырак, аның кебек үк сөйкемле йөзле кеше янына килеп туктадык. Бу—Әлмәткә әле 1955 елда ук «Яшь сталинчы» (хәзер «Татарстан яшьләре») газетасының нефть төбәге буенча үз хәбәрчесе итеп җибәрелгән шагыйрь Әдип Маликов булып чыкты. Ул бер үк вакытта бу төбәктә каләм тибрәткән эшче яшьләрне туплап, яшь язучылар берләшмәсен оештырган һәм бүген шуны җитәкли икән. Алда безне көткән очрашуга да әнә шул яшь язучылар җыеласы икән.

Безгә ерак барасы булмады: шул Ленин урамындагы өч катлы йортның икенче катына күтәрелдек. Ни гаҗәп: биредә мине тагын бер очрашу көтә икән. Гариф абыйның «иҗатташ дустым» дигәне минем авылдаш, ул вакытта «Кызыл Татарстан» (бүген «Ватаным Татарстан») газетасының Әлмәттәге үз хәбәрчесе Фазыл абый Мостафин булып чыкты. Фазыл абый сугыш кичкән һәм Елховойга исән-имин әйләнеп кайткан санаулы авылдашларымның берсе иде. Таза гәүдәле, түгәрәк йөзле, бөдрәләнеп торган карасу-соргылт чәчле, дөньяны танып-белгән, югары белем алган, җор телле, язарга сәләтле.

Фазыл абыйның хәләл җефете Суфия апа да югары белемле, бик акыллы икән—мин аларда аз гына булу арасында шуңа инандым. Ул гына да түгел, Суфия апа пианинода да бик әйбәт уйный икән. Алар хозурында сыйланып, күңелле генә сөйләшеп утырганнан соң, Суфия апа пианино артына утырды һәм, бераз клавишаларга баскалады да, әкрен генә барыбызга да күптән таныш «Тәфтиләү»не уйнап җибәрде. Шаулап сөйләшүдән тынып калган өйгә чиксез дулкынландыргыч борынгы, һәрвакыт тансык көй яңгырады, моңлы җыр барыбызның да яралы җанын телгәләде:

И мөкатдәс, моңлы сазым! Уйнадың син ник бик аз?
Син сынасың, мин сүнәмен, аерылабыз, ахрысы!
Очты дөнья читлегеннән тарсынып күңелем кошы,
Шат яратса да, җиһанга ят яраткан раббысы...

Халкыбызның бөек улы Тукай сүзләренә язылган бу көй безнең җанны кузгатты, хисләндерде, уйландырды, бәгырьләргә тиде. Хис-тойгыга тагын да тоемлырак Фазыл абый исә ул минутларда хәтта яшьләнеп тә алды.

Соңгы елларда минем күбрәк буровой шавыннан, моторлар гүләвеннән каткан күңел, ниһаять, йомшарып китте. Хуҗалар, Гариф һәм Әдип абыйлар белән саубуллашып, туганнарга бару юлында үсмер чакта үлеп яраткан, хәтта урамда җырлап йөргән моңлы «Тәфтиләү»не кабат көйләп алдым.

Мин гомерем буе Тукай һәм Такташ иҗатларына сокланып, шигырьләрен яттан укып яшәдем. Алар минем бүген дә яраткан шагыйрьләрем. Язмыш мине һич көтмәгәндә-уйламаганда Такташның иң якын һәм тугрылыклы дусты Хәсән Туфан һәм ул вакытта әле иҗаты ачылып кына килгән язучы Гариф Ахунов белән очраштырды. Бу вакыйга минем тормышымны үзгәртеп җибәрде, гүя алар миңа тылсымлы канат бирделәр. Мин күтәренке күңел, үзгә максат һәм илһам белән яши башладым. Алар киңәше белән 1960 ел августында Казан дәүләт университетының журналистика бүлегенә читтән торып укырга барып кердем. Имтиханнарны «бишле» һәм «дүртле» билгеләренә генә бирдем. Буровойда рекорд өчен көрәшкән чактагы ялкын белән яшәгән көннәр иде ул. Университетка керәм бит. Университетка! Күптән хыялымда яшәгән югары уку йортында белем, гыйлем алу өчен тырышуым мине шулай ялкынландыргандыр. Абитуриентлар арасында мин иң күп балл җыеп, керүчеләр исемлеге башында булып чыктым. Шатлыгымны уртаклашыр өчен Маяковский урамына, Хәсән ага янына йөгердем. Тик ул өйдә булмады.

—«Аккош күле»ндә ял итә ул, ике-өч атнасыз кайтмас әле,—диде Гуля-Гөлгенә. Аңа мин үземнең укырга керүем турында әйттем. Гуля мине мактап алды, тәбрикләде.

—Хәсән агага әйтегез: буровойда эшләүче якташ мишәр егете сезнең киңәшне тоткан—укырга кергән, диегез. Зур рәхмәт аңа! Миннән кайнар сәлам тапшырыгыз. Мин аңа саулык-сәламәтлек, иҗатында чиксез уңышлар телим,—дидем дә, Гуля белән саубуллаштым.

***

Читтән торып укучының имтиханнар биргәндә вакыты тар була. Мин, бернигә карамый, Хәсән ага янына кереп чыгарга тырыша идем. Аның тоңык, талгын тавыш белән: «Укулар ничек, канәт?»—дип соравы әле дә колак төбендә.

Туфанның бүлмәсе зур түгел, ләкин ул аннан бик канәгать иде: якты, җылы, тыныч. Пөхтә итеп җыештырылган.

—Минем өчен менә дигән бүлмә,—дип әйтә торган иде. Шунда сөйләшеп,

аның әле яңа гына иҗат ителгән шигырьләрен укуын тынлап, уйлы-моңлы мизгелләр кичереп утырулар онытыла торган түгел. Әсәрләрен ак кәгазьгә яшел кара белән элеккечә гарәп графикасында язганын хәтерлим.

—Шулай күнегелгән инде. Балачактан ук. Тегендә дә шулай яза идем...

«Тегендә» дигәне—ялгыз камерада яткан чорда түгел әлбәттә, Ата Җәллад үлгәннән соң, киеренкелек бетә башлагач, сәяси тоткыннарны камералардан сөргенгә чыгаргач, язарга мөмкинлек тугач.

Сөргендә Хәсән аганың бер совхозда яз башыннан ук көтүче булып йөргәнен сөйләгәне хәтердә. Шулай бер көнне шагыйрь далада ботарлап ташланган бер киек казга тап була.

—Аккош иде,—диде ул.—Ботарланган, бичара, ике канаты гына калган. Төлке-мазар эше булгандыр инде. Кызгандым кошларның кошын, күңелем тулып, күзләрдән яшьләр бәреп чыкты, йөрәгем сулкылдады. Бу тетрәнгеч хәлне үземнең язмышым кебек кабул иттем. Шунда кабат хатыным, кызым искә төштеләр—сагышымның тулып ташыган чоры иде. Ике ак канат мине әллә нинди моңсу уйларга этәрде. Шул ук кичтә елый-елый шигырь яздым:

Көзге төндә аккош моңая,
Кемгәдер ул эндәшә бугай,
Төннәр буе моңаеп шулай
Эндәшми тик һичбер кем аңа,
Көзге төндә
Ялгыз моңая.

Ята кырда ике ак канат,
Алар күккә
Җилкенми инде;
Төлке тагын иснәнә җилне,
Мыегындагы каннарны ялап...
Ята җирдә
Ике ак канат...
............
Күз алдымда тора әле дә:
Киткәндәге моңсу күзләре,
Йөзендәге тамчы эзләре...
Онытa алмам, ахры, мәңгегә,
Күз алдымда тора әле дә...

Бу юлларны укыганда чиксез күп ачы хәсрәт, төрмә, лагерь газапларын кичергән, әмма күңеле катмаган, аның йомшаклыгын, башка күркәм сыйфатларын саклап кала алган Хәсән аганың үзенең йөзендә дә тамчы эзләре пәйда булды...

***

Ульянов-Ленин исемен йөрткән Казан университетына укырга керүем тормышымны нык үзгәртте. Миндә үзгә халәт барлыкка килде. Эчтә шатлык, күтәренке күңел, яшәү яме, киләчәккә матур уй, ният. Алда максат—югары белем алу, еллар буе баштан китмәгән, йөрәктә янган уй-теләкләрне тормышка ашыру—Кеше булу, калган гомерне иҗатка багышлау...

Актүбәдә минем яңалыкны дуслар котлап каршы алды. Мөгаллим абый гына:

—Мин сине бораулау остасы булырсын, киләчәктә мине алыштырырсың

дип уйлаган идем. Ярар инде, хәерле булсын. Шуны әйтим: мин синен булдыруына ышанам. Университет хәтле университетка барып керүен—үзе мона зур дәлил. Маладис!—диде. Аннары:

—Эшли торгансыңдыр бит әле, китмисеңдер?—дип сорады.

—Эшлим әле, эшлим. Калганын киләчәк күрсәтер,—дидем мин.

Әйе, эшләми кая китәсен? Авылда әни дә, туганнар да авыз шапылдатып миннән ярдәм көтеп торалар. Тагын елдан артык мин үз бригадамда верховой һәм бораулаучы ярдәмчесе булып эшләдем. Көне-көне белән бурильщикны да алыштыргаларга туры килә иде.

Ләкин бераздан мин буровойда эшләү белән бергә читтән торып вузда укуның гаять дәрәҗәдә катлаулы, авыр икәнлегенә төшендем. Үзеннән-үзе җинелрәк эшкә күчү теләге туды. «Их, эш урының якында гына һәм өстәл янында булса икән»,—дип хыялланган көннәр күп иде. Җәһәннәмдәге буровойларга барып-кайту, бигрәк тә көзге-язгы юл өзеге айларында, кышкы кар-бураннарда интегүләр, вахта сәгатьләренә тиң өстәмә вакыт югалтулар... Мондый шартларда ничек укымак кирәк?!

***

Ләкин яңа эшкә күчә алу минем өйләнүдән башланды. Алтмыш икенче ел башында миңа 27 яшь тулды. Ул елларда туган көннәрне «билгеләү» юк иде әле. Мин аны үземчә билгеләдем—икенче көнне ике генә ай элек танышкан, күрер күзгә өметле генә күренгән кызны җитәкләп ЗАГСка киттек. Актүбә ипи заводында мастер булып эшли иде ул. Казанда бер еллык кондитерлар курсын тәмамлаганнан соң җибәрелгән Актүбәгә. Үзе Әлмәттән. Минем өчен дә Әлмәт үз: шунда бораулаучыга укыдым, шунда минем якын туганнарым яши, киләчәктә дә шунда кайтып төпләнү хыялы бар.

Өйләнү турында уйлап йөргән көннәрдә миңа бер бүлмәле квартир да бирделәр, ләкин Актүбәдә түгел, Азнакайда, чөнки ул чорда Актүбәдә, ни сәбәпледер, торак төзелеше туктатылган, төзелеш Азнакайда гына бара иде. Мин инде моңа да бик риза идем.

Язылышасы көнне иртән сөйгән яр яшәгән завод тулай торагы сымаграк өч бүлмәдән торган фатирга кереп киттем. Кәләшем яңа гына төнге сменадан кайтып кергән—арыган, талчыккан, йокларга ятарга җыена. Ә мин—өйләнергә...

—Соң, нәрсә, барабызмы, әллә юкмы?

Бу катгый сораудан йокысы качты, ахры, тиз генә киенде дә:

—Әйдә, киттек,—диде.

Гыйнвар бураннарыннан соң Актүбә урамнары кар көртләре астында калган—без шул карны ерып бистә Советы йортына юнәлдек. Ярый әле аякта киез итек. Икәүдән-икәү, озатучылар юк һәм без аларга мохтаҗ да түгел—өйләнешүне икебез генә хәл иттек. Төрледән-төрле тасмалар таккан, берсеннән икенчесе кәттәрәк чит ил автомашиналарыннан торган туй колонналары озата бүген өйләнешүчеләрне. Кая инде ул безгә? Атлы чана да юк. Юк һәм кирәге дә юк, чөнки бистә йорты бездән илле генә адымда.

Өстәге, киез итекләрдәге карларны кагып, бистә Советы бинасының икенче катына күтәрелдек—язылышу бүлмәсе шунда икән.

Ярты сәгатьтән без юлда очраган үзбушаткыч (самосвал) белән Әлмәткә китеп бардык. Бер атнадан шул ук Әлмәттә, хатыны ягында туебыз булды. Әнә шулай тормышыбызда яңа чор башланды.

Азнакайда яши башлагач, хатын шундагы ипи заводына күчерелде. Бергә тормыш итүнең унынчы аенда беренче улыбыз туды. Шатлыгыбыз белән бергә мәшәкатьләребез дә тигез артты, чөнки бер айдан хатын кабат эшкә чыкты—ул елларда, бүгенге кебек, бала тапкач та анага озакка сузылган

түләүле ял бирү юк иде. Шөкер, бер ел да өч айдан соң ике бүлмәле квартир алдык. Озак та тормый, аны бер бүлмәлегә алыштырып, Әлмәткә кайттык. Әйе, Әлмәт—безне чолгап алган мәшәкатьләрдән котылу юлы иде. Биредә хатынымның ата-анасы, туганнары яши. Бәләкәй улыбызның әбисе, рәхмәт төшкере, аны карау вазифасын үз җилкәсенә алды. Мин дә, ниһаять, укуымны уңышлы дәвам иттерү мөмкинлеге таптым—якты һәм җылы бүлмәдә, өстәл артында гына утырып эшли торган, Әлмәттә әле май аенда гына оештырылган «Татнефтестрой» комбинатына урнаштым. Әнә шулай олы хыялым тормышка ашты. Бу—1963 елның сентябре иде.

Әлмәткә күчеп кайткач, Гариф абый белән матур гына аралашып яшәргә насыйп булды, чөнки «Хәзинә» һәм «Хуҗалар» романнарын язган чорда аңа нефть сәнәгатен, буровой эшләрен белгән кешеләр кинәше, аларның фикерләре, уйлары бик кадерле, кирәкле иде. Ул сорауларын Гариф абый кайчак телефоннан гына бирә, кайчак кичен урамга һава суларга чакыра...

Аның белән шулай аралашып яшәү үзе бер рәхәт иде.

Үземнең ул вакыттагы беркатлылыгым белән: геройлар чынбарлыктагы кешеләрме соң, дип сораганым да хәтердә. Ул тегеннән-моннан тартып чыгарып әсәрнең әзер бүлекләрен укый башлый. Менә буровойда авария, бораулау остасы Кәрим Тимбиковның һәлак булу вакыйгасы...

—Бу—Михаил Белоглазов түгелдер бит?—дим, Гариф абыйны бүлдереп.

—Әйе, аның холкындагы кайбер сыйфатларны Тимбиковка бирдем. Синең остазың Мөгаллим Гыймазовтан да бераз алдым. Син дә, бораулаучы иптәшләрең дә бар әсәрдә,—диде ул, мине шаккатырып, тик мин китапта үземне дә, иптәшләремне дә таба алмадым. Гомумиләштерелгән образларда үзеңне табып буламыни?

—Ә менә Арслан Гобәйдуллин образына кергән прототипларның берсе—Үзбәк Саттаров. Син аны беләсеңме?

Юк, ул чакта мин Саттаровны белми идем әле. Ләкин Әлмәткә килеп «Знамя труда» газетасында сәнәгать бүлеге мөдире булып эшли башлагач, Миңлебай газ эшкәртү заводының баш инженеры Үзбәк Газиз улы Саттаров белән якыннан танышып кына калмадык, дуслашып та киттек, чөнки янадан-яңа объектлары төзелеп килгән бу завод, аның хезмәткәрләре, төзүче-монтажчылар турында миңа даими язып тору насыйп булды.

Үзбәк абый—сугыш ветераны, Әлмәтнең төп үз кешесе, абруйлы, мәшһүр җитәкче. Озак та үтми, аны «Татнефтегаз» идарәсенең баш инженеры, аннан соң «Татнефть» берләшмәсе генераль директоры урынбасары итеп күтәрделәр. Мәскәүдәге министрлыклар да аны эшкә чакырдылар, тик ул: «Әлмәтем—җәннәтем, Мәскәвегез үзегезгә булсын!»—дип шаяртты да, урыныннан кузгалмады. Һәм, минемчә, бик дөрес эшләде.

Ул бик шаян-шук, тапкыр телле, кирәк чакта усал да була алган нык ихтыярлы, үз-үзенә ышанып эш кылучы иде. Беренче хатыны аңа балалар бүләк итә алмады. Бер-берсенә хөрмәт саклаган килеш, сөйләшеп-аңлашып аерылыштылар. Икенчесе, Извилия ханым, бер-бер артлы ике матур кыз тапты. И-и, яратты инде Үзбәк абый кызларын—авызыннан өзми шулар турында, алар белән булган кызыклы хәлләр турында куанып сөйли торган иде. Һәм, ни гаҗәп, шул дулкында аның язучылык таланты ачылды: кызлары өчен дип кенә соклангыч хикәяләр иҗат итте, ике китап чыгарды, Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы булды.

Гариф абый белән Үзбәк абый якын дуслар иде. Иҗади дуслар. Һәм Үзбәк абыйның язучылык белән «җенләнеп» китүе дә Гариф абый фатихасы белән булганын беләм. Ахуновны Казанга чакырып алгач, Үзбәк абый язган

хикәяләрне уку, аларга төзәтмәләр кертү, авторга киңәш бирү минем өлешкә төште. Кайчак эш сәгате бетәр алдыннан телефон шалтырый. Трубкада таныш тавыш:

—Синең бүген ничек—вакытың буламы? Нәрсә әзерләтим—чәйме, кофемы?..

Кич буе аның бәләкәй, ләкин кызыклы, балалар өчен исә хәтта серле дә хикәяләрен укыйбыз, кирәк дип санаган җирләренә төзәтмәләр кертәбез.

Үзбәк абыйның ул хикәяләре 1980 елда китап булып чыкты. Тик шау килеп эшләп, иҗат итеп торган җиреннән ул алтмыш яшендә һич уйламаганда, якты дөньядан китеп барды. Мин аны бүген дә әрнүле сагыш белән искә алам.

Әйе, хәтердә никадәр якты истәлекләр бар. Болары язылганнары, ә күпме язылмаганнары?

Күз алдыма еш кына университет еллары, шул чорда бергә укып йөргән Абдулла Сәләхетдинов килә. Шагыйрь һәм журналист буларак шактый танылган, кеше буларак гаҗәп гади һәм аралашучан, сөйләгән сүзләре дә йөрәккә сары май булып ята. Ул да, мин дә Такташ иҗатына мөкиббән булуыбыз белән уртак тел таптык бугай, сөйләгәндә дә гел Такташтан мисал китерә иде.

Шактый еллар үткәч, «Казан утлары» журналы хезмәткәре Абдулла Әлмәткә килеп төште. Журналга яздыру мәшәкатьләре белән йөри икән. Мин шул ук урыс газетасында партия бүлеге мөдире, укучыга ике тиенгә дә кирәк булмаган партия тормышы турында язарга мәҗбүр булып яшәгән чор. Бу эштән җан азыгы табалмавыма Абдуллага да зарландым.

—Тукта әле, Әсгать малай. Юкка яна синең йөрәк. Без бит икебез дә чабаталы мишәр малайлары,—диде ул тагын Такташ сүзләре белән.—Син нефтьчеләр башкаласында редактор урынбасары, мин Татарстан язучыларының мәшһүр журналында әдәби хезмәткәр. Безгә шөкерана кылып яшәргә кирәк...

Ул әнә шулай юатырга оста иде. Төшке ашны буфетта бергә ашадык, аннары тагын озаклап сөйләшеп утырдык. Киләчәктә дә очрашып торырырга сөйләшкән идек. Булмады, Абдулла дустым фаҗигагә юлыкты... Урыны оҗмахта булсын!

***

Миндә Гариф абыйның автограф белән язып үз кулы белән бүләк иткән китаплары саклана. 1974 елда басылган «Хәзинә»сенә ул: «Әсгать дустыма—бәхетнең зурысы, хезмәтнең олысы. Дусларча: Гариф Ахунов. 19.09.75» дип язган. Гомумән, янадан Казанга кайтып киткәч, Гариф абый очрашкан вакытта минем буровой эшчесеннән журналист, мөхәррир булып җитешүем, язучы булып китүем турында әңгәмәдәшләренә сөенеп сөйли торган иде. Ә андый садә мизгелләр хәтердән һич җуелмый.

Халкыбызның күренекле шагыйре Хәсән Туфан белән якыннан танышып, дуслашып йөрү елларын исә мин тормышымның илаһи сәхифәсе итеп саныйм. Бәхеткә каршы, 1969 елның ноябрендә Әлмәттә уздырылган язучылар семинарыннан соң Хәсән ага һәм аның белән бергә танылган әдип, тәнкыйтьче, университет укытучысы, остазым Гази Кашшаф, Туфан кебек үк репрессия корбаны, язучы Сөббух Рафиков һәм минем Азнакайда яшәгән чорда ук якын дустыма әверелгән, шагыйрь, язучы Рахмай Хисмәтуллин бездә кич утырып, кунак булып киттеләр. Безнең өч бүлмәле квартир Әлмәтнең үзәк урамнарының берсе—Гагаринда, дүртенче катта иде. Сөйләшә-сөйләшә әкрен генә менә-менүгә Хәсән ага кинәт хәлсезләнеп китте, ава башлады. Ярый әле тотып калдык.

—Йөрәк,—диде ул. Кергәч тә аны урын җәеп диван-караватка салдык. Гази ага аңа бер таблетка валидол бирде—ул беркайчан да валидолсыз йөрми, студентлар белән дәрестә утырганда да еш кына валидол алып каба торган иде. Озакламый Хәсән ага игә килде, торып утырды.

Ул кичтә сүзнең күбрәк Татарстан делегациясенең Каракалпак АССРда кунакта булуы, аннан алып кайткан тәэсирләр турында барганы хәтердә. Игътибар үзәгендә, әлбәттә, Хәсән ага, аның сөйләгәннәре булды. Гази ага да сүзсез утырмады. Ә менә Сөббух абый күбрәк тыңлады гына. Ул кичтә утыз биш яшьтәге, башында уй-фикер, үзендә дәрт кайнап торган Рахмай да, һич аңа хас булмаганча, олы әдипләрнең сөйләгәннәрен дикъкать белән тыңлап, тын һәм тыйнак кына утырды. Әйе, нинди генә кайнар, шаулы булмасын, Рахмай дустымның олыларны олы итә, аларга итагатьлелек күрсәтә торган күркәм сыйфаты бар иде.

Бездә кич утырып киткәннән соң өч айлап үттеме-юкмы, Зәйдә яшәп иҗат иткән Сөббух Рафиковның кинәт вафат булуын белдек. Бу аянычлы хәбәрне мин әрнү белән кичердем. Һич шулай тиз арада дөнья белән хушлашыр дип уйларлык түгел: чиста-пөхтә, карап торырга да сәламәт кебек иде. Гулаг афәтен кичермәсә, талантлы әдип шулай иртә гүр иясе булмас иде, дип уйладым мин.

Тагын биш елдан соң Муса Җәлилнең иң якын дусты, олуг галим, күренекле әдәбиятчы, журналист, педагог, Казан университеты журналистика факультеты студентларының аталары кебек якын кешесе, остазлары Гази ага Кашшафның да гомере өзелде (1975 елның 9 декабрендә).

Бүген исә ул кичтә әңгәмә корып утырган, әле тагын күпме еллар яшәү өмете, матур хыяллар белән, алларына изге максат-ниятләр куеп, ашкынып яшәгән, иҗат иткән олуг затларның берсе дә калмады, хәтта үземнән өч айга гына олы Рахмай дустым да.

Уку чорында газеталарда төрле жанрда материаллар язарга тиеш идек. Азнакайда ул чорда чыгучы «Коммуна» газетасы редакциясендә хатлар бүлеге мөдире Рахмай Хисмәтуллин белән таныштык һәм дуслашып та киттек. Һәр мәкалә, очерк, башка язмалары тирән мәгънәле, оста тел-сурәтләүләр белән языла, укучыны уйландыра, аларда төрле фикер уята. Шулай ук бер-бер артлы шигырьләре дә басылып тора. Кыскасы, Рахмай Хисмәтуллин Азнакай төбәге укучыларынын игътибар үзәгендә иде. Безнең бер бүлмәле квартир исә яшь каләм ияләренең штабына әверелде. Рахмай, «Азнакайнефть» идарәсенең комсомол комитеты секретаре Мисхәт Мөхәммәтшин өчен ишек һәрвакыт ачык. Мисхәттә дә язу сәләте бар. Аның хатыны Рәхимә ипи заводында баш технолог. Минем хәләл дә шунда мастер булып эшли, Рәхимә белән дускынайлар. Рахмай да өйләнү турында уйлап йөри, сайлана, тик үзенә бик ошаган кызлар гына күренми. Һәр очрашып сөйләшү, фикер алышу—үзе бер гомер. Рахмай һәм Мисхәт миннән Тakташны сөйләтәләр.

Алтмыш икенең февраль-март айлары идеме икән, Рахмай безгә Марс Шабаевны ияртеп килде. Марс белән минем тәүге очрашу бу. Ул, «Яшь Ленинчы» газетасы хезмәткәре, Баулы районының Кызылъяр авылында, армиядән гарипләнеп кайткан егет янында булган. Бик оста шигырьләр яза икән. Аларны ул үзе белән алган, кайберләрен безгә дә укып күрсәтте. Шабаев үзе дә шигырьләр яза икән, аларны да укыды.

Игътибарлы укучыларның зиһененә барып ирешкәндер: Шабаевның Фәнис Яруллин яныннан кайтып килгән көне иде. Әйе, ул әнә нәкъ М.Шабаев ярдәме белән шагыйрь һәм язучы булып танылды. Моны Фәнис Яруллин үзе дә инкарь итми, Марс Садри улы рухына рәхмәт-догаларын җиткереп тора.

Марсның шатлыклы көннәре—аның тәүге китабы дөнья күргән вакыт.

Беренче китап, беренче поэма—«Яңа җыр». «Әсгать дускай! Яңа җырлар менә шушылай башлана икән инде ул. Синең дә китабыңны көтеп—М. Шабаев. 29.01.63. Казан».—Бу аның әнә шул китабындагы кул тамгасы.

Рахмай дустым исә тәүге китабын Марс китабыннан соң ике елдан чыгарды. «Салават күпере»—китап өчен матур исем. Романтик Рахмайның Казанга китеп «Оргсинтез» заводы төзелешендә эшләгәндә язган очерклары җыентыгы. «Казанга Әсгать килгәнен ишетсәм, күңелдә әллә нинди бер матур шатлык туа. Әллә бу синең үзең тудырган шатлык, әллә инде яшьлекнең иң матур көннәрен бергә үткәргән истәлекләрнең янадан уянуыннан туган куаныч...

Ни булса да, синең исем миндә яшәргә теләк, иҗатта дәрт уята, күгемдәге болытларны куа, беләгемдә көч арттыра. Әдәбият мәйданында кулга-кул тотынып бергәләп атласак иде, дустым. Сүндермә, сүндермә романтик хыялларыңны. Алар сүнсә, тормыш та кирәкми. Дустың Рахмай. 25.01.1965». Әнә шундый автограф ул китапта. Минем әле һаман укып, тормышымның киләчәге ачыкланмаган, эч пошып йөргән чак булганга, Рахмай миңа тынычландыру сүзләрен юллагандыр...

Күз алдыма да еш кына Актүбә эшчеләр бистәсе янындагы урман эчендә шау-гөр килеп эшләп торган буровой, урман сукмагында шул буровойга таба килүче ике кеше—Хәсән ага Туфан һәм Гариф Ахунов...

Минем өчен аяклары төкле булды бу ике олуг шәхеснең. Язмыш мине соңыннан берсе икенчесеннән талантлырак бик күп мәшһүр әдипләр белән очраштырды, таныштырды, аралаштырды һәм хәтта дуслаштырды да. Шул бәрәкәтле дулкында үземә дә язучы булып китәргә язган икән, гәрчә бу уңышым миңа шактый соңлап килсә дә. Гамил Афзал, Әдип Маликов, Сажидә Сөләйманова, Әзһәр Габиди, Клара Булатова, Миргазиян Юныс, Равил Фәйзуллин, Флүс Латыйфи... Мин аларга мәңге рәхмәтле.

Үзгәртеп кору еллары татар дөньясы өчен хәерхаһлы да, башкача да булды. Шул елларда Совет чорында урыс исеме белән тулган Әлмәт урамнарына, ниһаять, үзебезнең бөек шәхесләребез исемнәрен бирү мөмкинлеге туды. Хакимият каршындагы мәдәният һәм географик атамалар комиссиясе әгъзасы буларак, без—берничә Әлмәт язучы-шагыйрьләре калабыз яки төбәгебездә яшәп иҗат иткән әдипләребезнең исемнәрен мәңгеләштерүгә ирештек. Бу игелекле эшебезне бүген дә дәвам итәбез. Хәзер Әлмәттә Муса Җәлил, Гаяз Исхакый, Һади Атласый, Афзал Таһиров, Ләбиб Гыйльми, Һади Такташ, Кави Нәҗми урамнарына Хәсән Туфан, Гомәр Бәширов, Гариф Ахунов, Юныс Әминов, Гамил Афзал, Сажидә Сөләйманова, Рафаил Төхфәтуллин, Шамил Бикчурин, Җәмит Рәхимов, Үзбәк Саттаров, Изаил Зарипов, Фәрит Гыйльметдинов урамнары өстәлде. Иншалла, мәрхүм, каләмдәшләремнең рухы моңа шаттыр.

## Еллар аша

Миннән кайвакыт: «Буровойда эшләп йөргән елларың өчен үкенмисеңме?»—дип сорыйлар. «Юк»,—дип җавап бирәм. Өч елдан артык армиядә хезмәт итүем—сарыф, ләкин ул да тормыш мәктәбе булды. Буровой исә—мәктәп тә мәктәп!

Һәм никадәр якты истәлекләр! Алар мине гомерем буе озата киләләр. Шул ук Мөгаллим абый Гыйммазов. Мактауга саран, ләкин үзенә ошаган тырыш егетләргә җылысын бирә белгән үзенчәлекле шәхес. Без, аның бригадасында үз-үзебезне аямыйча эшләгән кешеләр, аңа Социалистик Хезмәт Герое исеме бирелү белән бүген дә горурланып яшибез. Гәрчә үзебезгә бораулау конторасының Мактау кәгазеннән башка бернәрсә дә тәтемәсә дә. Шул ук «дядя Гриша»—Поляков. Аны Ленин орденына тәкъдим иткәннәр һәм ул моңа лаек иде. Сугыш вакытында Власов саткан армиядән

дошман әсирлегенә төшкән Григорий Яковлевичка Хезмәт Кызыл Байрагы ордены гына эләкте. Без инде моңа да шатландык. Ләкин орденсыз һәм медальсез калган, лаеклы игътибарга тиенә алмый вакытыннан алда гүр иясе булган батыр бораулаучы дусларым Баязит Сәлимов, Рәшит Кәримов, Зәки Гафиятуллин, Җәмил Мөхәммәтгалиев (Сары Җәмил), электрик Әхъяр Абдуллин һәм башкалар рухы нишли икән?

Буровойда эшләп йөргән елларның мин күбрәк уңай, бәрәкәтле һәм тантаналы вакыйгаларын гына искә алдым. Ә бит безнең тирәдә генә фаҗигале хәлләр дә җитәрлек булды. Белоглазов фаҗигасен искә алдык. 1961 елның язы. Карабашны узып Бөгелмәгә китү юлында сул якта бер-бер артлы, 3—4 метр ара калдырып, ике скважина борауладык. Беренчесен бораулаганда Юрий Гагарин космоска очты. Моңа бөтен дөнья сөенде. Советлар иле исә тантана итте, чиксез горурланды. Һәм нәкъ шул көннәрдә Белоножкин бригадасында эшләүче яшь мукшы егете Юрий Майоров вертлюгтан егылып төшеп һәлак булды. Ике язмыш: майор Юрий Гагарин һәм... Юрий Майоров. Якты елмаюлы, яшь, өйләнеп, яңа гына кызы туган, көзен генә Лениногорск нефть техникумына читтән торып укырга кергән, киләчәге турында кайгыртып, шуңа куанып яшәгән әйбәт егет. Аның белән бер автобуста вахтага йөри-йөри, аралаша-сөйләшә тәмам дуслашып киткән идек.

Мин Гайфуллин бригадасында практика үткәндә Мөнәвир Фәттахов вахтасында армиядән кайтып эшли башлаган Гөргери Федотов белән аралаштым. «Каеннар юлы» әсәрендәге Сандра язмышы турында әнә шул гади, җинел аралашучан керәшен егете сөйләгән иде. Мин армиядә чакта Гөргери дустым, «подсвечник» җимерелеп «шәм»нәр арасында кысылып калган һәм җан биргән... Шулар искә төшә дә, йөрәк сулкылдап куя.

Безнең илдә кеше кадере юк һәм булмады да—бу турыда мин бер генә язмадым. Кабат рекордлар атасы Мөгаллим Гыймазовка кайтыйк. Герой, СССР Югары Советы депутаты, сугыш ветераны. Ул 1982 елда Актүбәдә алтмыш яшендә бронхиаль астмадан үлеп китте. Берничә ай кала мин остазымның хәлен белергә барып кайттым. И-и, шатланды инде минем килүгә! Мөсаллия апа чәй куеп җибәрде. Сөйләшә-сөйләшә күчтәнәчләр белән чәй эчтек. Мөгаллим абый урамга чыкмый икән, анда үзгә һава, тыны кысыла. Мөсаллия апа гомер-гомергә чая, әйтәсен ярып әйтә торган хатын, ире өчен борчылып, бораулау конторасы, трест җитәкчеләрен орышып ташлады: Геройның хәлен белергә дә килмиләр, кая инде ул аның сәламәтлеге турында кайгырту. Аңа хәтта союз күләмендәге персональ пенсия юллау турында да уйламыйлар икән...

Мөгаллим абый белән кочаклашып аерылыштык. Бу безнең соңгы күрешү, соңгы аерылышу булды. Озак та үтмәде, республика газеталары аның вафат булуын хәбәр иттеләр...

Истәлекләремнең башында язган яшьлек дусларымнан Әлфрит Гыйззәтуллин да, Наил Мостафин да юк хәзер. Атом-төш коралы әзерләүче «Арзамас-16» дигән каһәрле җирдә хезмәт иткән Әлфрит тә иртә китте. Хәзер без Мөхәррәм белән икәү генә калдык. Хәтта аның берләнбер мәхәббәте—хәләл җефете Һаҗәр дә күптән түгел фанидан бакыйга күчте. Шуннан соң Мөхәррәм Түбән Абдулга, ялгызы яшәгән Срурия апасы янына кайтты. Шөкер, аның белән очрашкалыйбыз.

Герой бригадасында рекордлар куйган, бүген дә исән-имин яшәгән егетләрне санар өчен бер кул бармаклары да җитә икән. Таза гәүдәле, гел елмаеп торган Шәмсетдин Сиражетдинов соңрак уңган бораулаучы булып җитешкән. Хәзер ялда, Актүбәдә яши. Бригаданың алыштыргысыз слесаре, шулай ук гаять уңган, искиткеч тыйнак, әүлиядай тәртипле, намуслы Зәкәрия Газизуллин да гаиләсенең игътибар үзәгендә—Актүбәдә

яши. Әйе, яши, ләкин, кызганычка каршы, күзләре күрми. Мәрхүм Җәмил Мөхәммәтгалиев та соңгы елларын сукырлыкта үткәргән. Бу инде буровойдагы күкертле мохит нәтиҗәсе. Бригадага әле Акбуадан ук килгән Хәлим Харрасов та Гөлнәзирәсе белән Актүбәдә калдылар, шунда яшиләр. Хәлимнең кайгысы—аяклары авырта. Һәм Баулыда калган гыймазовчы дустым Владимир Андреевич Мудюков. Очраша торабыз. Владимир Андреевичка да, бергә яратышып гомер кичергән хатыны Азага да сиксәннең өсте. Икесе тиң ветераннар хорында катнашалар, концертлар белән хәтта Әлмәткә дә килеп чыккалыйлар. Ә очрашулар һәрвакыт көтеп алына. Аларның мине якын күрүләренең, үз итүләренең чиге юк. Минем өчен дә алар бик кадерле. Михаил Клишин да исәндер дип уйлыйм. Ул гаиләсен алып Белоруссиягә киткән иде.

Актүбәдә яшәгән елларда Мөгаллим абый белән Мөсаллия апа фатиры безнең туган йорт кебек була иде. Аларга кереп кич утырулар, Мөсаллия апа пешергән тәмле бәлешләр белән сыйланулар безнең өчен гадәти хәл иде. Аерып әйтәм—барысы өчен дә түгел, фәкать остазыбызның үз иткәннәре өчен генә. Шөкер, кунакчыл Мөсаллия апабыз бүген дә исән-сау, тугызынчы дистәсен тутырып килә. Шуны да әйтим, уллары Фәнис һәм Фәрит тә бораулаучылар, Мөхәррәм Фәйрушин бригадасында икесе тиң бораулаучы булып эшләгән егетләр. Хәзер алар Себердә. «Долг платежом красен», диләр бит урыслар. Гыймазовта эшләп мастер дәрәҗәсенә күтәрелгән Мөхәррәм үзе дә аның улларын кеше иткән. Моны ничек мактамыйсың инде?..

Татарстанның нефть тарихына алтын хәрефләр белән язарлык рекордлар куйган дусларымның язмышы әнә шундый. Берәүләр күптән юк, ләкин һаман истә, хәтердә. Икенчеләр онытылган, тартып-сузып көн күрәләр. Ләкин нишлисең—без мәгънәсез, шәфкатьсез-мәрхәмәтсез, кеше кадерен белмәгән, аны санга сукмаган, байлыгы арткан саен хәерчелек упкыны тирәнәя барган илдә яшибез. Безнең өчен бердәнбер шатлык—яшәү!

Шуңа күрә бүген, бернинди күңел төшенкелегенә дә бирелмичә, булган сәламәтлекне саклап, дуслар белән мөмкин кадәр аралашырга тырышып, хатирәләр яңартып яшәргә дә яшәргә кирәк.

Ошбу истәлекләремдәге соңгы сүзем итеп гыймазовчыларга гына түгел, башка бик күп бораулаучыларга да токым катылыгыдай ныклы сәламәтлек, бәхет-сәгадәт, бәрәкәтле һәм тыныч тормыш телим. Яшик әле, дуслар, яшик!..



Зиннур
Мансуров

# ТАМЫР БУЙЛАП АГА ХӘТЕР...

## Тәрҗемәи хәлемә кереш

**Аллаһ ирке белән яшәп ятса
янәшәдә тагын бер дөнья,
шунда кабат гомер кичәр идем,
ап-ак биттән башлап барын да.**

**Әмма белмим җаның өргән мәлдә
Күкнең нинди ният кыласын.
Бирми калмас бит Ул янә сынау
сораганга насыйп кол хакын.**

**Ярты төшкә дәвам уйлап тапкан
фалчы халәтенә иш хәлем.
Мине анда көтеп тора кебек
гомер җитми калган эшләрем.**

**Тиздән һиҗрәт итәр инсан төсле,
моңсу карап алам артка да...
Дәхи туа калсам, беркем үзен
җайсыз тоймас минем аркада.**

**Әнкәемә тулгак тоттырмыйча,
кендегемне үзем кисәрмен.
Кабатланыр өчен бакыйлыкта
сизәм канда үҗәт көч барын.**

**Шигырь итеп, бәлки, түкмәс идем
мәҗрух күңелдәге бар гамьне,—
җитмәгәнме гамәл дәфтәремә
мәләкләрнең язып барганы?!.**

Зиннур МАНСУРОВ (1949)—*шагыйрь, публицист; «Кул бирәм», «Ваем», «Күңел сәфәре», «Җәрәхәтле йөрәк җылырак», «Күңелдә фидаи яшәсә» һ.б. китаплар авторы. Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты. Казанда яши.*

Соңга калып килде минем язлар,
йөрәк вакътым аз-маз кичекте.
Ярый әле, салмак фигыль белән
яшьли ал бирмәскә көч җитте.

Кызыл йоккан аңга озак сеңә:
телгә—ана, илгә—ир терәк.
Кешелеккә татар икәнемне
игълан итәр идем иртәрәк.

Җитди аслың илдә кемгә кирәк,
шамакайлар яши җайлырак.
Инде бераз шаян булу лазем—
миннән арганнарга ял кирәк.

Сабыр төбе бигрәк тирән икән,
әллә ничә тапкыр баш ярдым.
Ихлас кылган савап эшем өчен
байтак кына кыен ашадым...

Менә шулар искә төшкән саен
маңгаемнан салкын тир ага.
Әгәр мине яңа дөнья дәшсә,
кат-кат басмам бер үк тырмага.

Анда гомер үзгә шартта үтәр,
үзгәрмичә калмам үзем дә.
Канча еллар яшреп сөйгән ярны
яратырмын халык күзендә.

Аллаһ ирке белән яшәп ятса
янәшәдә тагын бер дөнья,
юлны башлар идем, истә тотып
алган сабакларның барын да...

Чормавыклы хәтер чоңгылында
мең югалып, мең кат табылам.
Кайчак чит-ят якта йөргән чакта
үтә таныш хәлгә тап булам.

Әллә җирдә шушы рәвеш белән
мин... икенче тапкыр яшимме?
...Сорау аша күккә баккан мәлдә
кальбем тулук ачы яшь иде...

## Тәкъдиргә язылмаган үкенеч

*«...Күрше агаемыздан бер алтатар*
*сорарга кичтән ният итеп яттым».*
Габдулла Тукай

Әйдә әле, бераз гына фараз кылып ал, татар:
теге агай шагыйреңә биргән булса алтатар...

Ул бит күпме фасикъ затка багышлаган чын ясин,
шуннан инде үзең аңланиләр килеп чыгасын.

Хәер, кат-кат уйлангандыр шулай ният иткәндә,
читен халәт—дошманнарың артып китсә эттән дә.

Әйтер патша охранкасы: «Кушаматы—«Биик усал»;
якасыннан гына тотма, кулларына богау сал!»

Бәгыréндә бәргәләнсә дәверләрне гизгән гамь,
чыпчыклар[1]ны атып йөрмәс капиталга кизәнгән...

Утлы корал табу уе килгән аңа Арчада,
ярар Ишми ишеләрне куркыткалап алса да.

Бәлки, үчле Карәхмәтнең йодрыгына тап булыр,
тора-бара татар канлы Дантеслар да табылыр...

Милләтчеләр аһәң белән кисеп әйтер: «Ул аткан!
Күккә атып, безне гафләт йокысыннан уяткан!..»

Кодрәт чәчеп торган каләм бармас мондый гарь эшкә,
ләгънәтләнгән Нәмруд угы булып очмас гарешкә.

Үкенечкә салыр иде ул сөекле халкын да,
ярый әле, кала белгән туры Тукай хәлендә.

Менә шулай бераз гына фараз кылып ал, татар:
теге агай шагыйреңә биргән булса алтатар...

## Коръән-хафиз

Бисмилләәәһир-рахмәәәнир-рахииим.

Коръән ятлый угыл ялгыз гына,
ризалыгы өчен Алланың;
түгелгәндәй була күңеленнән
әллә шатлык хисе, әллә моң.

Ниятләгән сүрә аятьләрен
хәтеренә бикләп барганда,
әллә ничек истән чыгып тора
фани дөньядагы бар гамь дә.

Җаны өчен җайсыз рәвеш алган
манарасы килә зир-зөбәр.
Зиһнен ачып кергән һәрбер сүздә
хикмәт нуры сеңгән энҗе бар...

Япь-яшь башы кинәт чатнап куя,
дәррәү чәнчегән күк мең инә,—
бөтен галәм агып керә төсле
йодрык кадәр генә миенә.

Аслын аңлап ятлый откыр угыл,
сокландырып сыный Хак юлы.
Мөкатдәслек тулы могҗизаны
сыйдырырмы адәм гакылы?!.

[1] Чыпчык авылы тирәсендәге урман аркылы үткәндә юлчыларга бәйләнүчән кораллы каракларга ишарә. Алар Габдулла Тукайны да шөбһәләнергә мәҗбүр иткән.

**Бәгырь өнен якты моңга төреп,**
**үзалдына хәтем кылганда,**
**тагын пакьлек аша үтә кебек**
**ана сөте белән кергән дә.**

**Укып киткән һәрбер хәреф саен**
**насыйп итәр аңа ун әҗер.**
**Талибанә күккә таянганның**
**исәп тоткан эше уңадыр.**

**Ул кальбенә уйгач әл-Китабның**
**ахыргача утыз парәсен,**
**килеп басар мең дә утыз сөаль:**
**дөнья кая таба бара соң?..**

**Гарше әгъля күрми сабак аша**
**фашлап күрсәтәдер барсын да;**
**Җиргә вәхи булып иңгән хөкем**
**кайнап тора ябь-яшь башында.**

**Коръән ятлый угыл ялгыз гына...**

## Күчемле фигыль

**Кардәшлекнең һәрбер кайтавазы**
**алысларга китә кан аша,—**
**бабалары әлүн тәгамләсә,**
**оныкларның теше камаша.**

**Тамыр буйлап аккан ачы суттай,**
**күчә бара хәтер—барсы хак.**
**Әлгәрләре кыен ашаганга,**
**варислары шулай басымчак.**

**Иман белән пакьләп күпме юма,**
**юк, барыбер эчтә кер кала.**
**Аталары шәраб уртлаганда**
**улларының теле көрмәлә.**

**Татар башын татар ашый икән,**
**милләт җаны күккә ашачак!..**
**...Инде тәшвиш килми торсын бераз—**
**авыз ачар вакыт[2]—ахшам чак.**

## Җен куу

**Газап чигеп яшәү ай-яй читен—**
**бәгыремә кемдер үч күмгән.**
**Куштаннары, көн-төн туктамыйча,**
**җенне кумакчылар эчемнән.**

**Уттай өтеп алган зәһәр үттә**
**миңа тагын күпме кайныйсы?..**
**Гаҗәп түгел, йөрәк тетрәп торса—**
**тамыр куптарылу—кан эше.**

2 Бу шигырь Рамазан аенда язылды.

Аң-зиһенне юа әгъвалары,
әфсеннәре җанны өшетә.
Әллә дөнья гамен җуеп барам—
кулдан иң кадерле эш китә...

Үзгәртмәкче алар үзләренчә
Күктән иңдерелгән хөкемне.
Ярар, сынап карыйк—ахыр чиктә
яклавына алыр Хак кемне?..

Бүген хәлем менә шундый әле:
бәгыремә кемдер үч күмгән,—
миңа насыйп кыйлган... Шигырь җенен
куып чыгармакчы эчемнән.

Хәерлегә булсын...

## Allegro

*Ошбу шигырьдә үзен танып алачак*
*көйязар ханымга*

Яшен ташы кебек тота-каба
иңде икән сиңа кем җаны?!
Инде хәзер гомер итә бирче,
ашыктырып фани дөньяны.

Әмма тәкъдир сүзе шундый саллы—
килеп бетмәс синең көеңә.
Илаһ җаен хаклап таңнар ата
һәм моң гына сүнеп көн иңә...

Күпләребез бии кубызыңа,
уйнак кулың җитә бар җиргә!
Фәрештәләр кылган гамәлеңне
өлгералмый язып барырга.

Эчең поша хәтта матәм маршын
гел-гел шулай акрын уйнауга.
Насыйп җенең өстәп торган дәртне,
бүлсәң, җитәр иде ун җанга...

Көнем бетәр диеп хафа чикмә,
фигылеңә мәңге тугры син,—
олуг нәби сурга өргән чакта
нота битен ачып торырсың.

## Әкияти юллар кисешү

*(Сәйяр вагантларга ияреп)*

Болын буйлап июль туе узган—
хозурлыкка ничек түз монда!
Әллә ничә истән биһуш булып,
Алып ята кибән төбендә.

Уйный рәшә сихри көзге кебек,
(әгъвалавы бетәр өч көннән).

Кызыл башлык кигән җиту кызый
чыгып килә урман эченнән.

Көйли батыр (мондый җырны аңа
кемдер биреп торган бурычка):
«Билең нечкә, җанкач, чыдар микән
язмыш бүләк иткән бер кичкә?!»

Мәгърур таудай торып баса егет,
«Алып!» дип ул әйтә атын да.
Чая кызның җавап сүзе әзер:
«Тычкан үлми кибән астында...»

Болын буйлап июль туе узган,
сихри исләр калмас өч көннән.
Әллә кемнәр килеп чыгар төсле
могҗизалы рәшә эченнән.

## Ишарәт

Күбәләк канаты кагылып киттеме,
тетрәтеп үттеме бибекнең өн-моңы,—
ишелде кинәттән... кып-кызыл күбәдәй,
чирәмдә утырган багалма өеме.

Аптырап көндезге тәгамгә ашыктым,
янәдән гаҗәпкә калдырды өй мине:
бернинди сәбәпсез ишелде табында
телемләп киселгән ипекәй өеме.

...Сентябрь яңгыры. Кыйблага караган
тәрәзәм ничәнче мәртәбә юылды.
Аңыштым, ниһаять—мин газиз әнкәмне
төшемдә күптәннән күргәнем юк иде.

## Агыш

Бормаланып чишмә ага әрәмәдән,
тирә-юньгә җофар исе бөркелә.
Яргаланган җиде улак эргәсендә
бер карт белән ике малай гөр килә.

Бабалары, кабат-кабат бисмиллалап,
багалмалар тәгәрәтә иң өстән.
Өметләнеп аста тора оныклары:
«Коры калмыйк безгә тиеш өлештән!»

Ә дәүәти, инде зекер әйтә-әйтә,
торыннары хозурында ант кыла.
Тегеләре тәкатьсездәй тәкрарлыйлар:
«Улак буйлап алма озак акты ла...»

Агымсулар соңгы вакыт аксакалның
төшләренә гелән кереп йөдәтте;
күрсенгәндәй кабатлады күңеленнән:
«Балачакның алмалары тиз акты,
аһ, шулкадәр тиз акты!..»




*Гомәр Бәширов Арча кантонында юстиция оешмаларында эшләгән чорда. 20нче еллар.*



*Г. Бәширов Яңа сала авылындагы туган нигезендә китапханә ачылу уңае белән туганнары һәм авылдашлары арасында. 1983 ел.*



*Әдип Украина язучылары съезды кунаклары белән (сулдан уңга): А.Калган(Чувашия), Г.Бәширов, Г.Әмири (Башкортстан), Крученюк (Молдавия), Н.Золотарев(Якутия) һәм Р.Нигъмәти (Башкортстан). Киев. 1949 ел.*



*Аккош күле урманында. 1973 ел.*



*Гомәр Бәшировның хатыны Кәримәгә 70 яшь тулу уңае белән бергә төшкән фоторәсеме. Казан. 1972 ел.*



*Татарстан язучыларының VIII съездында. Сулдан уңга: Сибгат Хәким, Илдар Юзеев, Гариф Ахунов, Гомәр Бәширов. Казан. 1974 ел.*

Әхәт
Мушинский

# ҺАВАЛАРДА—АК КҮГӘРЧЕН...

РОМАН

### Кайчак тормышны акка күчереп язасы килә

Шәех гадәттә футбол бәрелешләреннән читләшә иде. Менә хәзер Титенко аны капкада торырга чакырды, чөнки яхшы уенчыны һич тә капкачы итеп бастырып булмый.

Шәех көтмәгәндә риза булды. Ул, эшлекле рәвештә кемнең кайсы командада икәне белән кызыксынды да, аягыннан салып, чалбар балакларын сызганып куйды, учларына төкереп алды. Бу вакытта уенчылар каршы як капкасы тирәсендә мәш киләләр иде. Ул шәһәр беренчелегенә барган ярышларда Пичуга (без Саша Пичугинны үзара шулай дип йөри идек) шикелле «Хезмәт резервлары»н яклаган тугызынчы класс укучысы Алик Насыйбуллин командасына эләкте.

Мин, булдыксыз капкачыдан көләргә дә һәм аның өчен җанатарга да әзерләнеп, капка артындагы бүрәнәгә килеп кунакладым.

Пичуга безгә каршы уйный, Жбан белән Киләле дә аның командасында. Жбан, укуындагы шикелле, авыр уйный, ә Киләле аннан җиңелрәк хәрәкәтләнә. Тик барыбер икесе дә сакчы буларак, карачкы сыман, һаман Пичуга артында йөриләр.

—Исәп нинди?—дип кызыксынды Шәех.

—Бишкә-биш,—диделәр аңа.

«Димәк, Алик бирешми»,—дип уйлап алдым мин. Көрәш асылда һәрвакыт икесе—Алик белән Пичуга арасында бара, ә калганнары болай гына йөгереп йөрүчеләр, фон гына дияргә була. Бу турыда уйлап та өлгермәдем, шунда Шәехнең башы Пичуганың бик көчле типкән тубын кире кайтарды. Ул әле селкенергә дә өлгермәде шикелле иде, ә туп инде кире очып китте...

—Булдырдың син!—дип мактап алдым мин аны.—Кабагың ярылмадымы?

Ләкин ул мине ишетмәде. Аның колагы тонган, ул ориентациясен югалткан һәм аның иң беренче адымнары шундый удардан соң тигезлеген саклап калырга юнәлтелгән иде.

—Б-рр!..—диде ул, бары тик башын гына селкеп.

Аның каруы кырның теге башында Алик, Пичугадан аермалы буларак, ялгышмады. Ниндидер гади генә хәйлә белән Жбанны тезләндереп һәм аны үзенең артында калдырып, ул бик тиз итеп капканың аркылы борысы астына таба тибеп җибәрде. Туп, ертык ятьмә аша үтеп, койма өстеннән

*Дәвамы. Башы узган елның 12нче санында*

бакчага ук очып китте. Кайберәүләр, туп ятьмәгә кермәде, читләтеп үтте, дип бәхәсләшергә маташты.

—Уйнарга кирәк, ачык авызлар!—дип акырды Пичуга, һәм ачык авызлылар шундук тынып калды.

Тупны алып килделәр дә уен тагын дәвам итте.

Пичуга базардан сатып алган сары грушасын чәйни-чәйни туп белән капкага таба якынлашты. Ул бу мизгелдә менә дигән слаломчыны, ә безнен сакчылар чангычы җәһәт кенә әле бер, әле икенче яктан әйләнеп узган флагчыкларны хәтерләтәләр иде. Бер «флагчык» егылды, икенчесе чак кына егылмыйча мәтәлмәде... Шулай итеп, аның алдында бер генә, анда да җинел каршылык—җиденче «А» классыннан килбәтсез капкачы Шәех кенә калган иде. Пичуга аңа күз ташлап алды да эченнән: «Көзге чебеш!»—дип куйды һәм якыная башлады. Ул аны да читләтеп үтәргә һәм тупны буш капкага бик матур итеп, алай бик кертергә дә теләмәгән шикеллерәк кенә, үкчәсе яисә хәтта чүгәләп, арты белән кертергә теләде. Тик моның өчен, ничектер алдап, Шәехне капкасыннан чыгарга мәҗбүр итәргә кирәк...

Шәех үзен озак көттермәде. Чылбырдан ычкынган шикелле атылып чыкты да, тупка каршы ыргылырга җыенды. Пичуга шунда хәлнең шаярырлык түгел икәнен аңлап алды. Һәм тупны буш калган почмакка төртеп кертергә уйлады. Ләкин соң иде инде. Шәех, үзен аямыйча, «дошман»ның аягы астына ташланды. Нинди дер мизгел эчендә Пичуга, житез голкипер аша очып, шап итеп капка янына килеп төште. Янәшәсендә, тузанда груша кимерерге аунап ята иде.

Икенче атака тагын да ярсурак булды. Пичуга тагын алга узды. Ул кырыс йөзле, игътибарын бер ноктага төйнәгән, уңайлырак булсын өчен тупны тиз генә уң аягы ягына күчерде, янәсе, тибәргә икән, берәгәйле итеп тибәргә! Бу мизгелдә ул Пичуга да түгел иде бугай. Мыек астыннан елмаюы да, ваемсыз булып кылануы да юкка чыккан. Авызы ачылмаслык булып ябылган һәм ничектер кыекланып кысылган, борын тишекләре фиништагы чабышкы атныкы шикелле зур итеп ачылган, күзләре, йомшак җирен эзләп, капка буенча йөгеренә, әйтерсең менә хәзер алар ятьмәгә туптан да алдан атып җибәрергә җыеналар.Әй, күпме көчен салды ул шушы тибүгә! Бу очракта—капкадан биш метрда!—кирәгеннән дә артык каты типте. Хәтта крокодил тиресеннән тегелгән туфлие аягыннан ычкынып китте. Шәех нәкъ шуны тотып алды да инде. Ә туп исә, штангага эләгеп, янадан кырга, футболчылар өеренә килеп төште.

Пичуга Шәех кулыннан туфлясын тартып алды:

—Иштең ишәк чумарын!..—диде ул, ачу белән.

Ләкин ул аны аягына киеп тормады, киресенчә, икенче туфлиен дә салып атты да оекбашларын сыерып төшерде, тар балакларын сызганып, тупны яланаяк килеш тибә-тибә, яңа атакага ташланырга җай эзләп китте.

Бу юлы, ничек кенә гаҗәп тоелмасын, капка янына Жбан үтеп керде.

Бер класста икенче елын утыручы Анатолий Жбанов холкы, сәләте буенча һәм тышкы кием-салымы белән дә бик үзенчәлекле егет иде. Аның кыска, безнең балкон култыкса баганачыгы—текмә шикелле балтырлы аякларына иңбашына калкып торган яңаклы башы утырган, цирк көрәшчесенеке кебек беләкле, тәмам олы ир-атныкына охшаган гәүдәсен күтәреп йөртергә туры килә. Солдат итеген чистарта торган яхшы сыйфатлы щетканы күз алдына китерегез. Бу башта маңгаеның аскы өлешеннән үк үсә башлаган чәчләр дә шундый ук кара, каты иде. Аның портретын ләм белән капланган сыман катып калган, һаман ни турындадыр сораган, һаман нәрсәнедер аңлап җиткермәгән шикелле күзләр төгәлли.

Ул инде Шәех белән бергә-бер килеп чыккан иде, шулчак аның артыннан

нииндидер ялан маңгайлы ташбаш һич калышмады. Аны этеп җибәреп, Жбан тизлеген арттырды, ләкин аның кыска аяклары адым хәрәкәтләренең ешлыгын туктатып кала алмады һәм ул, гөрселдәп, авыр гәүдәсе белән тапталып беткән капкачы мәйданы алдындагы тузанга килеп төште.

Тавыш күтәрде, янәсе, аяк чалу булды, пенальти тибелергә тиеш! Беркем бәхәсләшмәде дә. Гаепсездән гаепле булган малай да бер сүз дәшми. Аның каруы: «Бернинди тәртип бозу булмады, ул үзе егылды»,—дип Шәех каты торды.

—Минме? Үземме?..—дип йөгереп килде аның янына Жбан.

Капка артында махнушка уйныйлар иде.

—Йөз дә ике, йөз дә өч, йөз дә дүрт...—Эченә кургашын кисәге беркетеп куелган йон йомрысы кәкре аяклы виртуозның күкрәк тирәсендә сикереп йөри. Сугышчан аягының «яңагы» белән ул дөнья рекорды куеп маташа. Ләкин аны күрмиләр дә иде, ишегалдындагылар барысы да Шәех капкасы янына җыелды.

—Мин үземме?—дип кабатлады Жбан.

—Үзең... Бернинди аяк чалу булмады.

Шунда Киләле дә килеп җитте. Болай да кысык булган күзен тагын да кыса төшеп:

—Мин күрдем бит... Чиста аяк чалу иде. Бас капкага!—диде ул.

—Бас!—дип кабатлады Киләле артыннан Жбан. Кабатламады, ә боерды. Тупны кулына алды да унбер адымны санап китте.

—Булмады тәртип бозу,—диде Шәех һәм капка баганасына сөялде.

—Бас урыныңа!—дип акырды Жбан. Ул Шәех янына килеп, аны капка уртасына таба тартты.

Шәех талпынып куйды:

—Баскан ди. Кирәк иде!

Аның бу сүзләре капылт һәм тәкәббер килеп чыкты. Һәм шунда ул бөтенләй ишегалдыннан китәргә дип җыенган гына иде, ләкин Жбан Шәехнең вельвет курткасы җиңенә чат ябышты...

—Бас!

—Мин әйттем бит инде...

—Ә мин әйтәм—бас!

Шәех башын селкеп куйды. Борыны югары чөелгән, карашы койма артында чәчәк аткан алмагачлар ябалдашы ягына юнәлгән—аның башка сөйләшер сүзе юк.

—Соңгы мәртәбә кабатлыйм,—дип кысып чыгарды Жбан теше арасыннан.

—Ярар инде, ярар,—дип хихылдап куйды Киләле.—Ташла әле шул киреләнүеңне. Менә бит син бүген юлбарыс шикелле, арыслан шикелле, хе-хе... Нәкъ Яшин! Хе-хе...—Киләле чамасыз күп сөйләүчән һәм хахылдаучан, юк, дөресен генә әйткәндә, хахылдаучан түгел, ә хехетләүчән егет.—Йә, бассаң ни була инде?!

Шәех җавап кайтармады.

—Кара аны, Шәех, синең эш, хе-хе,—дип Киләле иңбашларын җыерып куйды һәм, хушлашкан сыман, кулын бирде. Шәех аңа үзенең сул кулын (уңын һаман Жбан тотып тора иде) сузды. Әмма Киләлегә башка нәрсә кирәк икән. Ул үҗәтнең атсыз бармагын җитез генә эләктереп алды да бора башлады.

Шәех авыртудан сыгылып төште, ә Киләле җәзасын дәвам итте:

—Басасыңмы?

Шәехнең күзеннән яшь тәгәрәп чыкты, ләкин ул дәшмәде. Киләле сүгенеп куйды һәм буйсынмас капка сакчысын этеп җибәрде. Хәтта тегесе

чак кына егылмый калды, барысы да көлешеп алдылар. Алай да Шәех егылмады, тигезлеген саклап калу өчен бары тик куллары белән әллә ниткән хәрәкәтләр генә ясап алды һәм шунда Жбаннан да ычкынды.

Киләле усал гына хехелдәп:

—Олак монннан!—дип куйды.

Кара тутлы, кошныкына охшаган борынлы бу Киләле хәйләкәр, чамасыз кызу канлы, ләкин, Жбаннан аермалы буларак, ачуы тиз басылучан. Аның кушаматы «кил» һәм «әле» дигән ике сүздән ясалган. Аны Жбанга колларча бирелгәнлеге өчен шулай дип атыйлар. Малай чактагы кушаматлар бик ябышып калучан була, кайчак, маңгайдагы тамга шикелле, гомер ахырына тикле ияреп бара. Ә аның чын исеме, хәтерем ялгышмаса,—Равил. Әйе, Равил Гарипов.

—Ташла сана шуны, Толик,—диде ул Жбанга.

Әмма Анатолий Жбанда «ташлау» халәте түгел, ул һаман нәрсәнедер аңлап житкерми иде бугай әле. Ул үзенә менә монда, ишегалдында каршылык күрсәтүгә ияләнмәгән. Аның сазлык шикелле төссез күзләре кулларына караганда да ныграк ябыша торган иде. Менә хәзер Шәехне дә шулар жибәрми тора иде бугай.

—Димәк, уйнамыйсың?

—...

—Димәк, сөйләшергә дә теләмисең?

Ул Шәехне кабат эләктереп алырга теләгән иде дә, тегесе ваемсыз гына читкә тайпылды.

Шунда Жбан аңа китереп сукты. Кизәнеп, сул ягына. Шәехнең иреннәре кысылган авызыннан төкерекләр чәчрәп чыкты. Шундук, бер аягыннан икенчесенә дә авышып тормыйча, Жбан уң кулы белән тагын берне китереп сылады. Йодрыгы Шәехнең яңак сөягенә килеп төште, борынын жимерде.

Авар дип көткән Шәех егылмады, бары тик чайкалып кына куйды. Бәлки, Жбанны нәкъ менә шул тагын да ярсыта төшкәндер. Ул, инде яшермичә, бөтенләй боксерларча булмаган яңа ударга әзерләнде—йодрыгын астан, боты тирәсеннән үк күтәрде. Мин аның Шәех кебек сугышчыларны гына түгел, аннан күпкә көчлерәкләрне дә аяктан ега, астан ияккә бирә торган бу апперкотын белә идем. Хәер, Шәех нинди сугышчы булсын ди инде?! Ул читкә тайпылырга да омтылмады, канаган борынын сөртеп, үзен кыерсытучыга салкын карашын төбәп, тик басып торды.

Күпме халык бар иде шунда! Ләкин ул төркем, әкренләп эри барып, бер сүз дә дәшмәде.

Шунда мин Жбанның кулыннан эләктереп алдым. Ул аптырап миңа карап куйды да көч белән күкрәгемә төртте.

—Син дә мондамыни әле, Әһли!

Аның төртүе шулкадәр көчле булдымы, әллә мин шулхәтле зәгыйфь идемме, бездә әйтергә яратканча, кәтүктән очып төштем һәм, капка янында жиргә килеп мәтәлгәч, баш чүмечем белән бәрелеп, аның баганасын селкеттем. Алар металл торбалардан эретеп ябыштырылган иде. Шул торбалар чыңлап куйды. Һәм минем башым да...

Ярсып ук китеп, Жбан тагын кизәнде...

Миңа аякка басарга кирәк иде, тик мин басмадым. Хәзер уйлавымча, башым чыңлаганга гына түгел, мин аңымны җуймадым бит, исемдә...

Жбанны Пичуга суытты. Музыкаль бармаклары белән жинелчә генә аның иңенә кагылып алды да:

—Житәр сиңа, артыгын кызып киттең,—диде.

Инде аягына туфлиләрен киеп алган Пичуга бу хәлне ялкау гына читтән

карап торган, тик тиздән аны Жбанның психлыгын күзәтеп тору туйдырган. Кыза, йодрыкларын селки, кан чыгара, йә моннан кемгә нинди файда?

—Йә, кемгә әйттем?!

Жбан бераз вакыт шул тирәдә бөтерелде, Шәехне тагын куркытып алды. Алай да Сашаның сүзен тыңламыйча булдыра алмады. Аның өчен Пичуга югары инстанция булып санала иде. Жиденче классның үзенчәлекле холыклы, таш башлы малае булган Жбан аңа нәрсәгә сатылган соң? Пичуга аңа киеп торыр өчен биргән кием-салым өчен генә түгелдер бит? (Жбан кыш буе диярлек аның ул чакта бик модада булган «олимпийка»сын—ачык зәңгәр төстәге спорт фуфайкасын киеп йөрде). Мин моның сәбәбен соңрак кына белдем...

Жбан, мин чак кына башымны ярмаган багана төбенә кече йомышын үтәп алды да, теше аша төкереп куйды:

—Ярар, Багдад шәехе, тагын килерсең әле монда!

Шәех аны ишетмәде дә бугай. Аякларына ботинкаларын киеп алды да, өскә чөелгән борынын ике бармагы белән кысып, кайтып китте.

Гүя аны кыйнамадылар, киресенчә, ул барысы белән дә исәп-хисабын өзгән дә, менә хәзер шул җиңүне горур рәвештә өенә алып кайтып бара дип уйларга мөмкин иде.

## 2 БҮЛЕК

### Николай Сергеевич Новиков

Кухняда, ягъни кухняга әйләндерелгән безнең гомуми коридорда, кульюгыч янында басып торабыз. Шәех тас өстенә иелгән, астында сыек-кызыл «мыегы» һаман бетми торган борынын сөртә. Мин аңа нәрсәдер әйтәм, ул миңа нәрсәдер җавап бирә, кулы белән әледән-әле кульюгыч таягына кагылып-кагылып, янадан битенә тидерү өчен аннан уч төбенә су агызып ала.

Бу картина, һаман-һаман кереп аптыраткан төш шикелле, мине гомер буе эзәрлекләде. Ул кульюгыч тавышын бүген дә ишетәм кебек мин: тук-тук-тук...

Ниндидер материя белән хан заманында ук тышланган булып, инде хәзер аның тышлык диярлеге дә калмаган, тетелеп беткән өйалдыннан кухняга чыга торган ишек шыгырдап ачыла да, бусагада һәрвакыт ыгы-зыгы килгән безнең тынгысыз галим күршебез Николай Сергеевич Новиков пәйда була. Озын буйлы, аз гына бөкрәя төшкән, зур борынлы һәм Бетховенныкы сыман мул чәчле, ул билгесез токымнан булган кабарынган зур кошны хәтерләтә. Аның бер култык астында—портфель, икенчесендә—гомуми почта әрҗәсеннән алынган газета һәм журналлар, кулларында—хуҗалык челтәрләре. Алардан, диңгез миналарының чәнечкеләре шикелле макароннар, сосискалар һәм тагын әллә нәрсәләр тырпаеп тора, ә авызында беркайчан да үзгәрми торган: «У-ту-ту!» Ул шулай поезд яисә пароход сыман сүзсез, көйсез, гади генә әйткәндә, кешеләрне үзенең килүе, үткәндәгеләрнең барысы да әйбәт, ә алда әле җан сөйгән әллә нихәтле эш көтә, дип белдерүе иде бугай.

—Исәнмесез, исәнмесез!—дип сәламли ул безне.—У-ту-ту! Сезгә, балалар, нибары ике газета гына, калганнары—миңа. Дөресен әйтергә кирәк, бүгенге почта бай түгел.

Газета һәм журналларны ул берүзенә бөтен Алмалы яздырганнан да күбрәк ала иде бугай.

—Әйдә булышыйм, Николай Сергеевич,—дип, мин аның кулыннан идәнгә куйсаң таралып китәргә торган челтәрләрен алам да аның почта

әржәләрен бикли торган кечкенә генә йозак белән бикләнгән авыр, борынгы ишегенең йозагын ачканын көтәм һәм әйберләрен бүлмәгә алып керергә булышам.

—Николай Сергеевич, ярты сәгатькә генә «Вокруг света»ны алып торырга мөмкинме?

—Рәхим ит, рәхим ит! Мин укуын укымадым әле, ләкин анда Тунгусс метеориты турында гаҗәеп кызыклы мәкалә бар.

Мин журналны, безнең яшьләр газеталарын элэктереп алам да чыгып китәм. Минем арттан Николай Сергеевич атлый:

—Ә Шәех һаман юынамыни әле?—ди ул.

Шәехнең борыныннан кан килү туктады. Ул әледән-әле, кан табы белән пычранмыймы дип карый-карый, сөлгене сак кына кабарган борынына тидереп-тидереп ала—корыта иде. Шунда ул үзенең тырышып башкарган бу шөгыленнән аерылмыйча гына:

—Ә нәрсә, Николай Сергеевич?—дип сорый.

—Мин әйтеп тормаган идем, бушагач дип уйладым... Анда, аста, ишегалдында синең белән кызыксыналар...—Николай Сергеевич Шәех «портреты»ндагы үзгәрешне сизми.

Шунда мин:

—Икәү—носилка, берәү балта белән,—дип шаяртып куйдым.

Шәех минем сүзләрне колагына да элмәде.

—Кем?

—Дөресрәге, ул синең белән түгел, ә синең күгәрченнәрең белән кызыксына. Ир кеше...

Николай Сергеевич чүмеч белән ишек янындагы чиләктән су ала да, чайкалдырып аның шактый өлешен идәнгә түккәннән соң: «У-ту-ту»,—дип мыгырданып куя, монысы инде аның: «Әй, нинди булдыксыз кеше мин!»—дигәнне белдерә. Ул гадәттә бер дә кухняда пешерми, анда аның бары тик бер өстәле һәм шуның өстендә Шәех белән без гел тулы килеш тотарга тырышкан бер чиләге генә тора.

Шәех иңнәрен сикертеп куя:

—Кемгә кирәгем чыкты икән?

## Кыям абый

Ишегалдында башына челтәрле эшләпә кигән һәм янтыгына офицер планшеты таккан олы яшьтәге, ләкин пөхтә киенгән, кылыч сыман туры сын-гәүдәле ир-ат йөренә иде.

—Эта вы хазяин галубятни?—дип сорады ул, «а» хәрефенә көчле басым ясап. Ачыклаганнан соң әдәпле генә исәнләште:

—Здравствуем!

—Исәнмесез,—дип җавап кайтарды Шәех, сагая төшеп.

Таныш булмаган кеше, туган телендә сөйләшергә мөмкин икәнлегеннән канәгать калып, ашыкмыйча гына аңлатырга кереште:

—Мин рәсемнәр ясыйм. Үзем өчен генә, үз өемдә. Күптән түгел генә бер картина ясамакчы булган идем. Исеме... Хәер, хикмәт аның ничек дип аталуында түгел. Ничек икәнен үзем дә белмим әлегә. Мөһиме—анда күгәрченнәр булырга тиеш. Аклар. Әйе, матур ак күгәрченнәр. Ә аларны кайдан аласың ди? Гадәтиләреннән күчереп ясап булмый ич. Аңлыйсыңмы? Ә синең... Карале, исемең ничек синең? Шәех? Матур исем. Ә синең күгәрченнәр, Шәех,—күз алдында, менә алар, очалар! Карап туймаслык! Минем тәрәзәдән яхшы күренә алар. Без дүртенче катта яшибез. Сары кирпеч йортны беләсеңме?

—Бригантинамы?

—Менә, менә, ни өчендер аны Бригантина дип йөртәләр. Аның бер башында күмәч кибете, икенчесендә—гастроном. Ә синең нинди токымнар?—дип таныш булмаган кеше күгәрченнәр кетәгенә таба ымлады.

—Төрлесе бар.

—Ә шундыйлары... аяклары каурыйлылары бармы?

—Йонлачлармы?

—Бәлки, йон-лач-лар-дыр да,—дип сузды ир-ат үзенә таныш булмаган сүзне.—Кем белгән аларны.—Ул эшләпәсе астыннан чәчен рәтләп алды. Аның чәче карасу каштан төсендә, куе һәм бөдрә иде.

—Хәзер куып чыгарам мин аларны, шунда карарсыз,—диде Шәех һәм сарайга сөяп куйган баскычка таба атлады.

Кошлар гөрләшә-гөрләшә һәм канатларын кага-кага кетәк янындагы лаваны тотыргач, аста калган таныш булмаган кеше, планшетыннан альбом-блокнотын чыгарды да, бите буенча карандашын тиз-тиз йөртә башлады.

—Син аларның кайсы ата, кайсы ана икәнен ничек аерасың?

—Тотам да томшыгыннан тартып карыйм. Әгәр ычкына икән—ата, әгәр юк икән—ана.—Шәех зур гына чуар бер турманны кулына алды да томшыгыннан тартты. Теге башын кире тартып алды. Шәех аның өстеннән сыпырды да өскә чөйде, ләкин турман лавадан югары очып китмәде.

—Ялкау икән!—диде рәссам.

Шәех каршы төште:

—Юк, картайган гына ул.

—Картка охшамаган шикелле.

—Шикеллесен шикелле дә, ә инде акылын җуя бара. Хәзер аңа кайда яшәсә дә барыбер, тик ашатсыннар гына, очуын да үз теләге белән генә оча, лавадан куып җибәреп булмый. Күренеп тора: борынында—гөмбәләр, күзләрендә—кутыр.

—Ә-йе,—дип көрсенде рәссам,—картлыкта күгәрченнәр дә коточкыч сөйкемсез булып калалар икән шул.

—Авыр да сулыйлар, мышныйлар...

Кунак тагын көрсенеп куйды һәм бераз дәшми торганнан соң:

—Мине Кыям Әхмәт улы дип йөртәләр, Мөхәммәтшин,—диде.—Ишеткәнең бармы?

—Юк,—дип җавап бирде Шәех, уңайсызлана төшеп.

—Ул чагында Кыям абый дип дәш.

Барысыннан да озак очкан соңгы пар почта токымлы күгәрченнәрнең ничек салмак кына түбәнәя баруларын һәм нindидер тавыш чыгарып лавага килеп төшүләрен күзәтеп тордылар.

—Кырыйдагысы бик яшь әле,—диде Шәех, аңа күрсәтеп.—Күптән түгел генә кошлар базарында Бөгелмәдән килгән күгәрчен асраучыдан катун токымлыга алыштырып алдым. Бетте, кире әйләнеп кайтмый инде бу дип уйлаган идем. Алай да үзем өметләнәм, ышанам. Шуннан соң бер атна үтте, ике атна... Бер мәртәбә гвардияне куып чыгардым да ишегалдында нидер эшләп йөрим, лавага карасам,—бә-й!—әйтерсең очып та китмәгән! Үзе сөйгәненә елыша, әйе, әйе, әнә тегенә, үзе шатлыгыннан бүксәсен киергән, койрыгы—идән буенча сөйрәлә, тавис дип белерсең. Тегесе дә шат—канатларын җәйгән, муенын аккош сыман бөккән, гөрли, иркәләнә—янәсе, егете тугрылыклы булып чыккан бит. Мин аны Тугрылыклы дип атадым да.

—Мәхәббәт, яшьлек... Сөю дигән нәрсә аларда да бар диген, ә!

Кыям абый альбомының яңа битен ачты да, рухланып, күгәрченнәрне

ясый башлаган гына иде, шулчак карандашының үткен итеп очланган очы сынды.

—Әй, шайтан алгыры!—дип куйды ул.

—Ни булды?—дип сорады Шәех өстән.—Ә-ә, карандаш... Хәзер төшәм дә очлыйбыз аны.

Сарайга керделәр. Шәех лезвие яисә пычак эзләргә keреште, Кыям абый исә тирә-якка күз йөртте. Аңа монда бар нәрсә дә кызык иде.

—Карале, чын радиорубка! Монысы нәрсә? Сарайга телефон кертелгән мәллә?! Кайдандыр революциягә кадәрге аппарат та тапкансың...

—Болай гына, уенчык ул... Дустымның өенә үткәрдем, сөйләшкәләп торабыз.

—Күгәрчен кетәгенә шушыннан күтәреләсеме?

—Шушыннан.

—Монда йоклыйсың дамы әллә?

—Әйе...

—Минем «Балтика» радиоалгычым бар. Эшләми, иске инде. Ташларга кызганыч. Бәлки, рәткә кертеп булыр? Тикшереп карамассыңмы икән?

—Карарга мөмкин.

Ниһаять, карандашны очлар нәрсә—ясалма саплы финка иде ул—табылды, юкса кунак аның нигә кергән дә онытып өлгергән иде инде. Ул сарайның барлык почмакларын да тикшереп чыкты. Утын әрдәнәсе артын да карады, күгәрчен кетәгенә менә торган «авыз»га да башын тыкты. Әгәр күзенә Шәех былтыргы җәйдә Уйсулык чүплегеннән өстерәп кайткан метр ярымлы кызыл төстәге бер табак калай чалынмаса, кем белгән, ул сарайда әле тагын күпме вакыт карап йөргән булыр иде.

—Сиңа нәрсәгә бу?—дип катып калды Кыям абый аның янында.—Сат әле аны миңа!

—Кирәксә, болай гына бирәм. Ә сезгә нәрсәгә соң ул?

—Күп белсәң, тиз картаерсың. О-о, авыр икән бу! Алып кайтырга булыш әле!

## Алар абыйлы-сеңелле икән бит!

Шәех подъездның алтмыш алтынчы басмасында үзенең йөген төшергәч, Кыям абый аны кызганып куйды:

—Тының беттеме? Әйттем бит мин сиңа, булышыйм, дип.

Ишекне Кыям абыйга искиткеч охшаган сөйкемле хатын-кыз ачты. Һәм шундук кулларын җәеп җибәрде:

—Тагын өстерәп кайткан!

—Йә, йә, шаулама,—диде аңа Кыям абый,—кеше белән таныш башта. Бу—Шәех. Теге күгәрченнәр хуҗасы.

—Узыгыз әйдә!—диде хатын-кыз.

Кыям абый Шәехтән калайны алырга теләгән иде дә, тик ул бирмәде һәм аны кая куярга кирәклеген күрсәтергә дип алдан атлаган хуҗа артыннан иярде.

Шәехнең ишектән керүе булды, ул шаккатып авызын ачты. Бу фатир түгел, ә чын мәгънәсендә музей иде. Ишек янындагыннан алып, стеналарда йә лак белән капланган имән, йә алтынланган рамнарда майлы буяулар белән язылган төрле зурлыктагы картиналар тезелешеп торалар. Кунакчыл натюрмортлар—пейзажлар, пейзажлар исә төрлечә сурәтләнгән һәм шул ук вакытта нәрсәләре беләндер бер-берсенә охшаш та булган кешеләр портретлары белән алышына. Бер бүлмә аша үткәндә Шәех башын югары күтәрде дә, кулындагы йөген онытып, туктап калды. Бизәк төшерелгән түшәм

буенча тоташ яфраклар, җимешләр белән чупләмләп чигелгән һәм ишек яңаклары буенча идәнгә кадәр төшеп торган һәм керешмә белән бизәлгән гипс коелмасы сузылган. Обойдан буш стеналарда җәннәт кошларының ясалган койрык шлейфлары ялтырап тора, шарлавыклар ага һәм искиткеч гөлләр чәчәк атып утыра. Аны катып калган хәленнән хуҗаның:

—Монда кер, монда,—дигән тавышы чыгарды һәм Шәех зур булмаган бүлмәгә үтте.

—Менә шушында яшәп ятам инде мин,—диде Кыям абый, суыктан кергән шикелле, кулларын уып.—Менә бирегә куй.

Балконга чыгышлы бу бүлмәгә дә керешмә белән бизәлгән гипс коелмасы ябыштырылган, шулай ук рәсемнәр төшерелгән, ләкин картиналар стеналарда түгел, ә төркем-төркем булып почмакларга сыенганнар. Бераз иялнеп алгач, Шәех чыныктырылган агачлардан сырлап эшләнгән, Каюм Насыйри, Габдулла Тукай, Һади Такташ, Муса Җәлил китаплары күренеп торган китап киштәләрен дә һәм кырыйларына миниатюралар ясалган бик иркен язу өстәлен дә карады. Бүлмәнең икенче башында ниндидер эретмәле шешәләр, каләмкыллы банкалар каралып күренеп тора.

Шәех киштәдән бер китапны алды да берничә битен актаргалап карады. Бу Гадел Кутуйның «Тапшырылмаган хатлар»ы иде.

—Татарча укыйсынмы син?—дип сорады Кыям абый.

—Алай бик тиз түгел, ләкин укыйм.

—Э-хе-хе... Ә минем оныклар... Ә минем оныклар әниләре телен белмиләр.

Шәех тышлык артында бүләк итеп язылган култамганы күреп алды.

—Бүләкме? Авторның үзеннәнмени бу?—дип сорады.

—Сугышка кадәр дуслашып йөргән идек,—дип аңлатты Кыям абый.—Хатыннарыбыз да дуслар иде. Шуннан соң Иделдән күпме су акты инде! Сугыш, яралану... Менә мин исән калдым. Ә ул... Һәм ул да ...яши—китабы яши бит. Сугыш башланыр алдыннан Гаделша миңа үзенең язу рәвешләрен аңлаткан блокнотын бүләк иткән иде. Үзе төзегән. Кызыклы нәрсә, кешенең ничек язуы бар нәрсәне дә аңлатып бирә икән, хәтта аның холкы ничеклеген дә. Ләкин бәла шунда: саклый гына алмадым. Зурлыгы буенча кечкенә, уч төбе хәтле генә, ләкин калын блокнотчык иде ул.

—Кайбер аңлатмаларын хәтерлисезме соң?

—Кайберсен генә... Мәсәлән, язганда кемнең кәгазьдәге юлы югарыга таба менеп китүчән булса, ул энергияле, дөньяда ник яшәгәнен белә торган кеше икән. Болай гына әйткәндә, Гаделша үзе нәкъ менә шулай—ашкынулы һәм югарыга таба яза иде.

—Ә кемнең язуы аска таба китә торган булса?

—Кемнең аска таба...—Кыям абый сүз эзләп туктап калды.

—Аңлашылды. Ә тагын?

—Кем фамилиясе алдыннан исем инициалын да чыгара икән, димәк, ул шөһрәт сөючән кеше. Фамилиясенең башы бөдрәләнгән хәрефле булса да—шулай ук. Тагын нәрсә? Кем имзасыннан соң нокта куя—власть сөючән. Кем сулга авыштырып яза—үҗәт. Салмак, түгәрәк-йомры язылган хәрефләр—йомшак күңеллелек билгесе, ә аерым-аерым язылганнары—уйлап эш итүчән кешенеке.

—Тулы бер фән икән бу!

—Шаярулы.

—Барыбер кызык бит,—дип Шәех урындык кырыена килеп утырды.—Карыйм, сезнең монда—кабинет та, остаханә дә, йокы бүлмәсе дә.

—Билгеле бер дәрәҗәдә шулай шул,—дип килеште Кыям абый.—Ә синең үзеңнең сараең күпьяклырак.

—Кая инде!—диде Шәех, тагын бер мәртәбә карашы белән түшәмне, картиналарны, авыр-авыр рамнарны күздән кичереп.—Боларның барысын да үзегез ясадыгызмы?

Кыям абый җавап бирмәде, ләкин күренеп тора, ул кунакның тиз төшенүчәнлегеннән канәгать иде. Бары тик кулларын гына җәеп җибәрде: янәсе, ни булганы—алдында, гаеп итмә.

—Сез рәссаммы, Кыям абый?

—Юк, пенсионер.

—Ә болар?

—Бу... э-э... болар үзешчән сәнгать.

—Ярыйсы үзешчән сәнгать!

—Бу нәрсә әле... Ә менә минем оныкамда—чын талант. Менә кара!—дип Кыям абый, күзләрен күтәреп, стенада эленеп торган, сырлап ясалган җиңел рамдагы бердәнбер кечкенә генә пейзажга таба күрсәтте.

—Казансумы бу?—дип сорады Шәех.

—Ул.

—Мин бу урынны беләм—Зәңгәр күлдән ерак түгел генә ул.

—Ә бит уйнап кына ясаган иде. Махсус мәҗбүриләп ясаттырып кара, ясамый,—дип Кыям абый көрсенеп куйды,—ялкау кыз. Хәер, берәр нәрсәм килеп чыкмаган чакта мин аны чакырам. Көлеп-көлеп куя да булыша аннары. Шундук түгел, ялкаулыгы кими төшкәннән соң гына. Мин аңа, синдә—талант, сиңа сәнгать буенча укырга кирәк, дим. Ә ул кулын гына селти. Мәскәүгә, Питерга барырга кирәк, дим. Көлә генә. Киләчәк турында уйламый, бер дә уйламый. «Хи-хи» дә «ха-ха». Әллә хәзер бөтен кызлар шундый инде?! Белмим! Безнең... минем икенче төрле булды. Укыйсым килде, бик килде, ләкин язмыш миннән теләгемне сорап тормады. Беләсеңме, беренче мәртәбә аның рәсем ясаганын күргәч ничек гаҗәпләндем! Аңа нибары ун яшь чамасы гына иде әле ул чакта. Аның сызгалау-бозгалавына мин күнеккән идем инде. Ә монда ничектер минем кылкаләмнәремне, буяуларымны алды да... Мин Айвазовскийдан күчермә ясый идем. Котырынган диңгез, дулкын корабльне куа... Ә ул аяк астымда бөтерелә, хәтта мин аңа: «Йә, комачаулап йөрмә әле, Юлия!»—дип кычкырдым. Һәм шунда очраклы рәвештә генә аның альбомына күзем төште. Атакай гынам! Хәтта тыным кысылып куйды. Аның рәсеме минекенә караганда яхшырак чыккан иде. Диңгезе тере сыман. Сулый. Менә сиңа Юлия! Шуннан бирле мин аның бөтен рәсемнәрен дә җыеп бара башладым. «Казансу»ын һәм тагын кайбер нәрсәләрен рамга куйдым. Беләсеңме, шундый биш картинасын ул үзенең элек маймыч вакытында йөгереп йөргән балалар бакчасына илтеп бирде. Көчкә-көчкә генә «Казансу» ны алып калдым.

—Сезнең ул оныкагызга ничә яшь соң?

—Синең шикелле ул. Ә аның диңгез һәм корабльле альбомын сакладым. Телисеңме, күрсәтәм?—Кыям абый барып бер шкафны ачты.—Кая соң әле ул?

—Сез пенсиягә хәтле кем булып эшләдегез?—дип сорады Шәех.

—Фокусчы булып.

—Юк, чынлап та?

—Чыннан шулай... Фокусчы-иллюзиончы идем мин. Циркта, ә аннары филармониядә. Мин, кадерлем... әтиең исеме буенча ничек дип йөртәләр сине?

—Исмәгыйль улы.

—Кадерле, Шәех Исмәгыйль улы, мин безнең республикада бу жанрга нигез салучы булдым дияргә мөмкин.

Шәех ышанмыйча көлемсерәп куйды.

—Ышанмыйсынмы?

Шәех иңбашларын җыерды.

Кыям абый, шкаф ишеген ябып, берничә секундка туктап калды, аннан соң өстәлдән бер зәңгәр тәлинкәне эләктереп алды да: «Уща-мараха!»—дигән тавыш белән аны идәнгә тотып бәрде. (Аннары белүенчә, бу сүз «бетте, очты-китте» дигәнне аңлата икән.) Өйдә тукылган борынгы келәм коткара алмады, тәлинкә челпәрәмә килде. Фокусчы аның ватыкларын җыеп алды да чүп-чар тартмасына салды.

—Нигә инде сез? Мин сезне рәнҗеттемме?—дип сорады Шәех.

Кыям абый бер сүз дә дәшмичә, әйтерсең берни дә булмады, пинҗәк куенына тыгылды да аннан исән, ватылмаган зәңгәр тәлинкәне тартып чыгарды. Шәех чүп савытына карады. Анда берни дә юк иде.

—Ләкин мин монда кыйпылчыклар ташланганын күреп тордым бит...—диде ул, гаҗәпләнеп.

Жанрга нигез салучының йөзе балаларныкы сыман балкып китте.

—Тагын мөмкинме? Зинһар, кабат күрсәтегез әле!

—Профессионаллар бер үк номерны ике тапкыр күрсәтмиләр.

—Ул чагында нинди дә булса башканы. Шәт, сезнең репертуар байдыр бит?

—Шулай булмыйча! Теләсәң—манеж өчен, теләсәң—сәхнә өчен. Тар даирә өчен дә мөмкин.—Фокусчы Кыям абый, үрелеп, ике бармагы белән китап шүрлегендәге тартмадан бер шар алды. Куе алсу төскә буялган гадәти теннис шары иде ул. Аны халыкка күрсәткән сыман, куллары белән табигый булмаган ниндидер хәрәкәтләр, ишарәләр ясап алды һәм—башланды! Бармаклары аерылган иллюзияче кулындагы шар, бәлки, әсирләнгән Шәех күз алдында гынадыр, ишәйде, төсен үзгәртте. Илһамланып киткән тылсымчы ул шарларны йота барды, күзләрен акайтты, аны очкылык тотты... Һәм аннары авызыннан һаман төрле төстәге яңа шарлар чыга торды. Иллюзияче Шәехнең үз кесәсеннән дә дүрт шар чыгаргач, ул бөтенләй аптырап калды.

Сине циркта юләрсетүләре аңлашыла. Анда фокусчы синнән ерак тора. Ләкин менә хәзер артист кул сузымында гына басып тора. Шар булмау аркасында инде ярты ел теннис уйнамаган кешенең үз кесәсеннән аны учлап алалар икән, монда инде, кем әйтмешли, гафу итәсез!..

Кыям абый тәмам мавыгып китте. Ул пинҗәген салып куйды, ике фарфор чынаяк, үзенең челтәрле эшләпәсен алды... Тик шулчак ишек шыгырдап куйды һәм анда хуҗабикә күренде.

—Ашарга әйдәгез!—диде ул.

Артист эшләпәсен төшереп җибәрде.

—Менә! Берәр нәрсә эшләргә генә тотынасың, сине шундук туктаталар, бүлдерәләр, ниндидер көн тәртибенә буйсындыралар! Әйтерсең бу көн тәртибе кеше өчен түгел, ә кешедән өстен, кешедән мөһимрәк.

—Син тагын, әти!?—диде хуҗабикә кырыс тавыш белән.—Табиб тыйды бит сине...катгый рәвештә...—Һәм чыгып киткәндә өстәп куйды:—Батыраеп киткән... Ә төнлә тагын «Ашыгыч» чакырыргамы аннары?

Кыям абый бик тиз суынды, йомшарды.

—Бернишләп булмый, ашарга икән—ашарга!—диде ул һәм чынаягын урынына куйды да җиңел, гадәтләнгән хәрәкәт белән кара бөдрә чәчләрен рәтләп алды.—Минем кызым бик әйбәт әзерли.

—Шулай дип уйлаган идем.

—Нәрсә уйлаган идең?

—Бу сезнең кызыгыз дип.

—Мин сезне таныштырмадыммыни? Аh, әйе! Нишләтәсең, склероз. Роза исемле ул, Роза Кыям кызы. Шулаймы, әйт, боерырга яратучы! Еллар үткән саен, дускай, балалар әти-әниләренә әйләнә, ә әти-әниләре—балаларына. Әйдә!

—Рәхмәт.—Шәех борынына, кабарган иренәнә кагылып алды, монда ул алар турында тәмам оныткан иде.—Өйгә кайтырга вакыт инде миңа.

—Бернинди каршылыксыз, кадерлем!—дип Кыям абый Шәехнең терсәгеннән тотты.—Бернинди каршылыксыз!

Аны әле бер сәгать элек кенә ул аерыла алмыйча карый-карый аркылы үтеп чыккан бүлмәдәге өстәл янына утырттылар. Өстәл бик зур һәм кырыена хәтле ризыклар белән тулган иде. Мондый нәрсәне Шәехнең зур бәйрәмнәрдә генә күргәне бардыр. Хәер, мондый да, бөтенләй үк мондый да түгел. Әнисе бәлешләр пешерә, алар беренче, икенче ашка гына түгел, ә киләсе атнага да кала, әле тагын күршеләрен сыйларга да житә. Кеше чаманы белеп бетерми. Аның каруы гадәти көннәрдә авызны чөйгә эләргә туры килә. Чөнки ишегалды себерүче хатынның хезмәт хакына бик кылана алмыйсың. Ә монда исә өстәлдә—беренче, икенче, өченче ашлар, төрле соуслар, аш тәмләткечләр, салатлар, казылыклар, ыслаган кисәкле итләр! Телеңне йотарсың! Һәм тагын әллә нәрсәләр бар әле монда, аларның исемнәрен дә белеп бетерерлек түгел.

Роза апа кунакны сыйлый һәм үзе сораштыра: кайсы йортта яшисең, ничек укыйсың, әти-әниеңнәр кемнәр?

—Ә йөзенә ни булды, сугыштыңмы әллә?

Кыям абый, түзеп-түзеп торды да, чыдый алмады:

—Бәйләндең егеткә!—диде.

Һәм сүзне икенчегә борып җибәрде. Аның белән сөйләшүе җинел, чөнки Кыям абыйсы белән сүз бөтенләй башка, Шәех белән бәйле булмаган темаларга барды.

Кинәт ул кемнеңдер үзенә текәлеп карап торганын сизгәндәй булды. Кыям абый да, Роза апа да түгел иде бу... Шунда Шәех карашын өскә күтәрде. Бер картинадан аңа ике күкбаш чәчәген хәтерләткән зәңгәр күзләре белән аксыл чәчләренә күкбаш чәчәкләреннән үргән такыя кигән бер кыз карап тора иде. Әйтерсең ике күкбаш чәчәге кайдандыр өзелеп төшкән дә кашларының кара чатыры белән ябынган. Аксыл чәчләр һәм кара кашлар...

—Ошыймы?—дип сорады Кыям абый.

—Әйе,—диде Шәех.—Ул миңа... кемнедер хәтерләтә кебек...

—Ул аның оныкасы ,—дип елмайды Роза апа.

—Аның кызы ул,—дип аңлатты Кыям абый.

—Нигәдер сезгә бик аз охшаган,—диде Шәех, кызның әнисенә карап.

—Аз гына түгел, гомумән, тамчы да охшамаган,—дип куйды иллюзияче.—Бөтенләй әтисе! Бары тик тышкы кыяфәте белән генә. Ә ул хәзер кайтырга тиеш.

Шунда, аның сүзләрен раслагандай, ишек ягында кыңгырау чылтырады. Хуҗабикә урыныннан кутәрелде.

Тик ул портреттагы кыз түгел, ә Александр Пичугин иде.

—Таныш булыгыз,—диде аңа Роза апа.

—Ә без танышлар инде, әни,—дип Александр өстәл янына үтте.—Ашарга тәмлерәк нәрсә бар?

Роза апа аш чүмече белән савытка тыгылды.

—Иртәрәк син бүген, улым.

—Соң кайтсам да ошамый, иртә кайтсам да ярамый сезгә,—диде ул, елмаеп һәм кунакка карап алды.—Йә, хәлләр ничек соң?

—Ярыйсы,—дип Шәех, бармаклары белән борынын һәм иренен каплап, ияген учына куйды.

—Син нәрсә, Саша, кешегә картлар соравы бирәсеңме?—дип кызыксынды Роза апа. Ләкин шулчак тагын кыңгырау тавышы яңгырады.

Шәех өенә җыена башлады.

—Озатам мин сине,—дип урыныннан күтәрелде Кыям абый.—Бераз йөреп тә кайтырмын.

—Менә безнең Юлия дә кайтты!—дип белдерде Роза апа.

Чыннан да бүлмәгә, очынып, Юлия килеп керде:

—Исәмсез!

...—Портрет менә кемнән ясалган булган бит!—дип, миңа кичәге көн вакыйгалары турында сөйләп утырган Шәех тезенә сугып куйды.—Кыям абый белән алардан чыкканда минем—ышанасыңмы, юкмы?—хәтта башым буталды: Пичуга-Пичугин, Юлия, картиналар, тавислар, фокуслар... Ә аларның әтиләре... Әйе, кияүләре, Кыям абыйның кияве профессор икән бит! Пичугин Семён Васильевич. Ә Юлия белән Саша-Александр... Син аларның абыйлы-сеңелле икәнен белә идеңме? Ниче-е-ек? Ә нигә миңа әйтмәдең соң син моны?

## Их, ул иртәдә нинди яз иде!

Шәехнең ярсуы җинел аңлатыла, ул Юлиягә гашыйк иде. Хәер, аңа безнең бөтен малайлар да гашыйклар иде. Шул исәптән мин үзем дә.

Горизонтта ул моннан берничә генә ай элек, өченче чиректә укыганда, көзен бабасы белән яңа фатирга күчеп килгән Пичугадан шактый соңрак пәйда булды.

Пичугиннарның әллә ничә бүлмәле—аларның ничә икәнен әле хәзер дә бутыйм—зур профессор фатирына, Алмалыдагы бердәнбер биш катлы, Бригантина дип йөртелгән йортка күчеп килүләре бик тә сәер, ничектер чират буенча килеп чыкты. Башта бабалары пәйда булды. Ул шундук төзекләндерү, фатирны «музей» итеп үзгәртү эшенә кереште. Соңыннан үзенең чиктән тыш бай китапханәсе белән профессор Пичугин, аның артыннан аның малае һәм соңгы булып Юлия белән Роза апа күченеп килде.

Хуҗабикәнең күчеп килүе белән гаилә тормышы үзенең гадәти эзенә төште: вакытында иртәнге, төшке, кичке ашлар өлгерде һәм йокы алдыннан барысы өчен дә мәҗбүри булган, өстендә ак май сипкелләре йөзеп йөргән кайнар сөт эчелде. Роза апа—күренекле математика профессорының хатыны, ул эшләми, аның бердәнбер кайгырту объекты гаилә иде. Ул гел нәрсәдер кыздырды, аш-су пешерде, балалар белән дәресләр әзерләде, мәктәп җыелышларына һәм ата-аналар комитеты утырышларына йөрде... Иренең вакыты бик кысан иде. Кечкенә буйлы (хатыныннан бер башка тәбәнәк иде ул), аз гына аркасы чыккан, ә кайчак бөкре шикелле дә күренгән, ләкин яр буендагы йомры таш сыман нык гәүдәле, ачык зәңгәр күзле һәм кардай ак беретка охшаган чаларган чәчле профессор тәүлекләр, ә күп вакытта атналар буена конференцияләрдә, симпозиумнарда, семинарларда, төрле «көн»нәр, «кичә»ләр, «атна»ларда югалып тора... Ул кайнап торган табигатьле, мавыгучан, үзенчәлекле фикерле, еш кына үзенең һөнәре чигеннән башка өлкәләргә дә чыгып, күпчелек карашына капма-каршы килүчән масштаблы уйлый торган кеше. Сынлы сәнгать, атлар чабышы белән кызыксына, открыткалар, маркалар җыю белән мавыга, «Пушкин поэтикасы» (ул Пушкин буенча һөнәри белгеч дип санала иде) дигән китап чыгарды, аны университетта яисә педагогика институтында «Шигырьгә математик

анализ» дигән темага лекция укыган чакта күрергә мөмкин иде. Ул аны һәрвакыт Маркснын: «Фән бары тик математика белән файдаланганда гына камиллеккә ирешә ала»,—дигән сүзләре белән башлап җибәрә. Шулай ук аны шәһәр әдәби берләшмәләрендә үзенең берниндди матанализга бирешми торган, формасы буенча да, эчтәлеге белән дә кыю шигырьләрен ( җирле нәшриятта аның бер кечкенә китабы да басылып чыккан иде) укыганда да очратырга була иде. Кыскача гына әйткәндә, профессор, фән докторы, фәнни-тикшеренү институты директоры, кайчандыр паровоз машинисты булып эшләгән кешенең малае, үзләре белән шөгыльләнергә һич тә вакыт таба алмаган сөйкемле һәм ягымлы балалар булган Александр һәм Юлиянең әтисе иде Семен Васильевич Пичугин. Ул гаиләсен матди яктан муллыкта яшәтте. Тәрбия мәсьәләсендә аны каенатасы Кыям Әхмәт улы алыштыра иде.

Семен Васильевич ике мәртәбә өйләнгән кеше. Икенче тапкыр өйләнүе, зарлану гөнаһ булыр, уңышлы булган. Сәламәт һәм—тфү, тфү, тфү, күз тимәсен!—нык гаилә килеп чыккан.

Шәех менә шушы тыныч, гаугасыз гаилә белән аралаша башлады.

Профессор малае Саша Пичугин белән ул инде ишегалдындагы сугышуга хәтле үк таныш иде, тик ул очраклы, тегенди-мондый гына танышлык иде.

Юлия—бөтенләй икенче эш...

Их, ул иртәдә нинди яз иде! Әйе, без аның белән танышкан иртәдә. Хәер, параллель класста укый башлаган бу яңа кыз турында без элек тә белә идек. Мин аның Пичуга сеңлесе икәнен дә белдем. Бу барысына да билгеле иде. Гаҗәп, моны Шәех кенә ничек ишетми калган соң?

Күктә кояш балкып тора һәм малайлар Алмалы елгасының язгы су кергән бер тармагы буенча кәгазь кораблар җибәреп мәш килә. Шәех белән без иртән үк өй күләгәсендә яткан һәм инде яртылаш судан торган карны тараттык. Кышның соңгы байлыгы соскыч сыман көрәкләрдән күңелле генә юлга, машиналар тәгәрмәче астына оча. Йөк машиналарынын шул кар өемнәрен ничек изеп китүләрен күзәтеп тору кызык иде. Алар, катер шикелле, тирә-якка юеш кар һәм сулар чәчрәтеп үтеп китә. Шунда тыкрыктан кулларына портфельләр тоткан ике кыз күренде һәм алар, күлләвекләр аша сикерә-сикерә, урамның икенче ягына чыктылар. Менә шунда аларны бер «үгез» (радиаторына никель йөгертелгән үгез фигурасы беркетелгән үзбушаткычларны шулай дип атый идек) карлы-сулы ботка белән коендырып китте. Берсенә, аксыл чәчлесенә, бигрәк тә күп әләкте, аны аягыннан башына кадәр коендырды, хәтта ул кулыннан портфелен дә төшереп җибәрде. Ә портфеле исә шап итеп аның аягы астына килеп төште дә ачылып китте, аннан дәреслекләр, дәфтәрләр һәм кечкенә генә «Альпинист» радиоалгычы туп-туры күлләвек өстенә чәчелде.

Зыянга тарган бу кыз Юлия иде.

Ул, нишләргә дә белмичә, баскан урынында катып калды. Курыккан иптәшенең авызы да бияләй сыман салынып төште. Беренче булып мин искә килдем. Таратып ташланган кар өеме аша аларга таба атладым. Килеп, башта чәнчә бармагым белән кызның портфелен әләктереп алдым, аннары радиоалгычны күтәрдем дә сөйләтеп карадым—тынлык иде.

—Әзер бу!—дип абруйлы нәтиҗә ясадым мин.—Хәзер бу бары тик запчастьларга гына ярый инде.

Шәех килеп җитте.

—Бир әле, карыйм,—диде ул.

Юлия уфылдамады, ахылдамады, сүзсез генә дәфтәрләрен җыеп алды да, алардан юеш кар бөртекләрен сыпырып төшерергә, кыңгырауга охшаш

пальтосын кагарга кереште, бары тик аксыл маңгай чәче астындагы кашлары гына бер-беренә елышып куйды.

—Хәер, нигә запчастьларга?—Шунда мин җиденче «Г» классының сокландыргыч бу кызы белән танышу өчен башка мондый уңайлы очрак туры килмәячәген аңлап алдым.—Сезнең транзистор, мадемуазель,—алтын кулларда, без аны айн моментта төзәтәбез.

—Айнмы, айн түгелме, ләкин ничектер рәтләргә мөмкиндер, мөгаен,—дип фаразлады Шәех, аны карап.

—Борчылмагыз,—дидем мин кыю гына,—барысы да менә дигән булыр... Һәм тагын, тагын да берничә ниндидер буш, барабан каккан сыман яңгыравыклы сүзләр әйтеп ташладым. Шәехнең аны һичшиксез төзәтәчәген белә идем, чөнки мондыйларга гына җан кертмәде инде ул!

Шәехнең җәйге резиденциясе үз сезонын ачмаган иде әле, шуңа күрә без күңелсезлеккә тарган бу чибәр кызларны аның өенә алып киттек, чөнки әти өйдә иде, ә аның өендә беркем дә юк, әнисе туганнарына киткән. Ул туганнарына еш барып йөри.

Әнисе белән Шәех тыйнак кына яшиләр. Өйләрендә борынгы каминнан башка (аңлашыладыр, аны үзләре ясамаган) башка күз төшәрлек нәрсәләре юк иде. Игътибарны төрле радио чүп-чарлары белән тулган камин артындагы почмак җәлеп итсә генә инде. Ләкин анда кызлар күзе нигә төшсен? Ә каминнары исә—менә дигән! Курай тоткан көтүче малай һәм аның тирәсендә әвәрә килгән кәҗәләр төшерелгән барельефлы зәбәрҗәт плиткалар белән тышланган бу камин аны күргән кешеләрнең барысында да яхшы тәэсир калдыра иде. Безнең класс җитәкчесе Тамара Алексеевна нинди каты күңелле кеше инде, алай да, бер мәртәбә аларга Шәехне әнисе алдында ачуланмакчы булып килгәч, ул да, кубызлы көтүче малайга күз кырые белән генә караштыргалап, сәер рәвештә тынып калган.

Кызлар каминны бармаклары белән капшап-капшап карадылар.

—Нинди матур!—дип сокландылар.

—Нәфис тә инде! Ә эшлиме соң?

—Юк, хәзергә менә монысы белән файдаланабыз,—дип җавап бирдем мин Шәех урынына, кулга йога торган ак известь белән буялган гап-гади мич кырыена суккалап.

Юлия комод өстендәге кышкы иртәләрдә Шәех шыгырдаткалый торган гармунны күреп алды. Минем дусымның шундый үзенчәлеге бар: ул үзенең биш планкасы мехын бары тик кыш көне һәм анда да иртәнге сәгатьләрдә генә сузгалый иде. Юлиянең сүзсез соравына каршы мин баш кактым, әйе, янәсе, Шәехнеке ул.

Ул арада Шәех үзенең радиопочмагында аның «Альпинист»ын сүтеп тә аткан иде инде. Без дә эшкә керештек: кызлар щетка белән Юлиянең пальтосын чистартырга тотынды, ә мин аның суда мәлҗерәгән дәфтәрләрен үтүкләдем.

Яшен һич тә көтмәгәндә, аяз көн уртасында яшьнәде: кинәт кичкә хәтле торам дип киткән Рәшидә апа кайтып керде.

—Менә ышан син аңа!—дип мыгырданды ул, бүлмә буенча әрле-бирле йөренеп. Әле кухняга чыгып китте, аннары тагын бүлмәгә килеп керде һәм аннары башын комод тартмасына иде ул.—Мин аны кар тарата, боз вата дип торам, ә ул...—Һәм ул, кызларга карап-карап алды да, кулларын селкеде:—Кая киткән соң алар?

—Кем?—дип сорады Шәех.

—Кем, кем... лотерейкалар!

Күрше хатынның күп санлы сәерлекләренең берсе—зур лотерея отышына булган какшамас ышанычы иде. Ул, бер бәхетле билет бөтен тотылган

чыгымнарын һәм очсыз-кырыйсыз булган бурычларын каплый дип ышана-ышана, тыйнак гаилә («үзенең» димим, «гаилә» дим, чөнки Шәехкә ул ире өчен пенсия ала иде) бюджетыннан шактый акча туздырып бара. Ләкин ана бәхет һаман елмаймады, көткән билеты кулына һич тә килеп кермәде.

—Егерме биш лотерейка... Кайда икән соң алар?

Ин куркыныча—ул боларны барыбызга да аңлашыла торган рус телендә әйтте.

Кызлар, карашларын аска төбәп, өйләренә җыена башлады. Мин жир тишегенә кереп китәрдәй булдым. Ә Шәех? Белмим. Карап торырга болай тыныч шикелле күренде. Рәшидә апа аны менә шушылай кешеләр алдында беренче мәртәбә генә хурламый инде. Моңа, әлбәттә, күнегеп булмый, ләкин нишләмәк кирәк, әнисе бит. Ул шөрепборгыч белән радиоалгычта казына бирде, тик кашлары арасындагы тирән, аның яшенә хас булмаган сырлар гына мина күп нәрсә турында сөйли иде. Бары тик кырыс кына:

—Беркем дә алмады аларны синнән. Кемгә кирәк алар?!—дип куйды.

—Кирәк булмас! Үтеп-сүтеп йөрелмәле ишегалды ясагансың монда!—диде әнисе үз сүзләре белән үзен-үзе кыздыра барып. Тиздән инде ул кайный, кемдер әйтмешли, былт-былт итә үк башлады. Баскычтан без аның күпмилләтле кара тиргәше эзәрлекләгән тизлек белән төшеп киттек.

Бер сәбәпсез ямьсез сүзләр белән әрләнгән, бер гаебебез дә булмаган без дүртәү, ни әйтергә дә белмичә, саф һавада аптырап карашып торабыз. Шушының белән безнең танышлык та бетә инде, дип уйлап алдым мин.

Безнең камин шикелле зур, авыр һәм салкын тынлыкны Юлия бозды. Ул, яланбашындагы аксыл чәч учмаларын өскә чөйдереп, чыдый алмыйча, тыныч, борчулысыз көлү белән көлеп җибәрде. Без, хәйран калып, хәтта ничектер куркынып, аның сөт сыман ак колакларына, маңгаена, мәктәп формасының якасы челтәреннән сузылган аккошныкына охшаган озын муенына карап алдык һәм, нииндидер ярамас эш эшләгәндәй, үзебезне чит кешенең ачык тәрәзәсеннән күзәтеп торган шикелле хис итеп, күзләребезне шундук читкә бордык. Ул елларда бар кызлар да толымнар, чәч үремчекләре йөртә иде, ә аның,—чыннан да аның гына бугай,—чәче киселгән иде. Бу исә Юлиянең кыяфәтенә сизелмәс мөлаемлык, нәфислек өсти сыман. «Ул һәръяклап үзенә карап тора: аның көндәшләре юк, дуслары юк. Аның балкышында безнең гүзәлләрнең төссез түгәрәге югалып кала»,—дигән аның турында шагыйрь ул туганчы йөз ел элек үк. Ә ул чәчен рәтләп һәм пальтосының чабуын каплап:

—Нигә күңелсезләнеп калдыгыз әле?—диде.—Ана әрли—акыл кертә. Карагыз, кояш нинди бүген! Яз, апрель! Ә сез...

—Әйе,—дип баш артын кашып куйдым мин,—уңайсыз килеп чыкты.

—Күңелегезгә якын алмагыз, без үпкәләмибез. Дөресме, Галя?—диде Юлия.

Галя—Юлиянең дусты, «аның балкышында югалып кала» торган «төссез түгәрәк»нең берсе. Ләкин алай да ул—һәрвакыт аның янында булган, ана тугры калган һәм аның белән бар нәрсәдә дә тынычландырырга килешкән дусты, бу хәл белән риза булырга ашыкты:

—Дөрес, дөрес! Сез безгә булышырга теләдегез бит,—диде Галя.—Балалар әти-әниләре өчен җавап бирми.

—Галя!—дип Юлия аның җиңеннән тартты. Ә тегесе, ни ычкындырганын абайламыйча, иңбашларын җыерып куйды:

—Мин дә шулай дим ич...

Күзләре белән безнең ике арада адашып, ул башка берни дә әйтмәде.

Шәех ачулы һәм сүзсез иде. Аны мәгънәсез хуҗабикә һәм килеп чыккан ул хәлне менә хәзер бераз йомшартырга тырышкан (нәрсәне йомшартырга,

кыз күзләргә килмәдегез лә!) бәхетсез кунаклар арасындагы киеренкелек тәмам алжыткан иде бугай.

—Радиоалгычны төзәтәм мин, борчылмагыз,—дип йөткеренеп алды ул,—аннары мәктәпкә алып килермен.

—Ә без борчылмыйбыз да,—диде Юлия. Аның күтәренке кәефе үзгәрде, ул тонудан бөрешеп калды, пальтосының бар төймәләрен дә каптырып куйды.—Киттек, Галя.

Язмыш тарафыннан җибәрелгән мөмкинлекне кулдан ычкындырырга ярамый иде, һәм мин телемне икеләтә энергия белән эшкә җиктем. Әле безнең кайсыбызга бәхет күбрәк елмаячагын белмәгән килеш, үзем өчен дә, таш кебек катып калган Шәех өчен дә.

—Сез кая? Шундый рәхәт, матур вакытта?.. Үзегез бит: апрель, тамчылар... Ә үзегез...—дидем мин.

—Өйгә,—диде Юлия салкын гына.

—Әгәр мөмкин булса, без сезне бераз гына озатабыз, шулай бит, Шәех?

Ул сүзсез генә буйсынды.

Юлиянең йөреше балеринаныкы шикелле—җиңел, очынган сыман.

Әгәр дә лирикасыз гына әйтсәк, үкчәләре—бергә, аяк очлары аерылган, ә әгәр дә бераз чәнчүлерәк итеп әйтсәк, Чарли Чаплинныкы кебек иде.

—Сез бер йортта яшисезме? Ә пальто болай ярыйсы гына чистарган...—дип тыкылдадым мин.

Бригантина янында аерылыштык.

Шәех белән без, өстебезгә аның әнисе өйгән уңайсыз, аптырашлы хәлне бөкшәеп калган иңнәребезгә салып, кайтып киттек. Яңа танышлар белән әдәпле генә саубуллаштык, хәтта эчкерсез дә бугай әле, ләкин барыбер күңелдә сиңа битараф булмаган кеше белән очрашканнан соң, синең гаебең аркасында булмаса да, аңа карата ниндидер уңайсызлык эшләнгән сыман ямьсез тойгы калды.

Баш өстендә балкып торган апрель кояшын да, аяк астындагы күңелле күлләвекләрне дә күрәсе килми иде.

Алай да инде рәттән ничәнчедер йорт тәрәзәләренең җәй көнендәгечә ачык булуларына игътибар иттем. Урамның каршы ягындагы балконнан бер малай, ниндидер ишарәләр ясый-ясый, шул ук вакытта күккә төртеп күрсәтә-күрсәтә, безгә нәрсәдер аңлатмакчы булды. Ни әйтүе? Күк йөзе ачык зәңгәр, хәер, ул инде берничә көн шулай иде.

Кинәт Шәех туктады һәм мәгънәле итеп бармагын югары күтәрде дә:

—Левитан!—диде.

Икенче катның якындагы тәрәзәсеннән безнең колакларга атаклы дикторның тантаналы тавышы ишетелде.

—Әйе, ул!—дип җөпләп куйдым мин.—Ниндидер мөһим хәбәр әйтә, ахрысы! Киттек тизрәк.

Өйалдында безне дулкынланган Николай Сергеевич каршы алды:

—Шәех, Ренат, сез кайда йөрисез? Кеше—космоста!—диде ул.

Өйалды ишеге дә, аның бүлмәсенеке дә шар ачык, аннан Левитанның күк күкрәгәндәй тавышы ишетелә:

—ТАСС бел-де-рү-е. Мең дә тугыз йөз алтмыш беренче елның уникенче апрелендә Советлар Союзында Җир әйләнәсендәге орбитага бортында ке-е-ше булган дөньяда беренче космик корабль-иярчен «Восток» җибәрелде. «Восток» корабль-иярчененең пилот-космонавты Социалистик Советлар Союзы Республикасы очучысы майор Га-га-а-рин Ю-урий Алексе-е-евич!

—Инде әллә ничәнче мәртәбә тапшыралар!—дип пышылдады Николай

Сергеевич, безне радиоалгыч янына утыртып.—Башланды, башланды! Бөек Вакыт башланды! Тиздән Ерак Космоска да барып җитәрбез һәм акыл буенча туганнарыбызны да кочарбыз.

Төшке аштан соң без мәктәпкә дәресләргә киттек. Анда ни булганын күрсәң! Ачык тәрәзәләрдән кәгазь самолетлар болыты оча. Җиденче «А» да икенче смена көчкә-көчкә генә рус теленнән башланып китте. Хәл фигылен кулланып язарга планлаштырылган инша «Кеше космоска оча» дигән сочинение белән алыштырылды.

Шәех белән безнең сочинениеләр иң озын һәм, минем карашымча, иң яхшылар иде. Ләкин аларда ялгышлар да барысыннан да күбрәк булып чыкты. Безгә икеле куйдылар. Ләкин бу турыда без берничә көннән соң гына белдек һәм, хәтерлим, моңа бер дә борчылмадык та.

Ул көнне мәктәптән соң без озак кына вакыт күгәрченнәр очырдык. Рәшидә апа безгә ягымлы гына итеп үзенең лотерея билетларын табуы турында хәбәр итте.

## Дөрес, картинаны ашап булмый

Шулай итеп, нәрсәдә туктап калдык әле без? Әйе, Роза апа:

—Менә Юлия дә кайтты!—диде.

Чыннан да бүлмәгә очынып Юлия килеп керде. Туры мәгънәсендә—үзе.

—Исәмсез!

—Таныш бул, кызым,—диде аңа әнисе,—бабаңның яңа дусы—Шәех.

—Ә без таныш инде, әни,—дип елмайды Юлия.

—Карале, нәрсә соң бу, үз балаларымның иптәшләрен дә белмим!

—М-да ,—диде бабасы һәм кул чабып куйды.—Ярый, Шәех, чәй эчеп алыйк!

Үзенең мескен башына бәла булып чыккан бу төшке аш вакытында Шәех үзен бик начар хис итте. Ул кайчан чәйнәргә, кайчан җавап кайтарырга кирәк, кайчан тыңларга икәнен белми аптырады. Нәрсәдер чәйни-чәйни тыңласаң—уңайсыз, авызга бөтенләй берни дә алмасаң—килешми, чөнки ул, ни әйтсәң дә, төшке аш өстәле янында утыра. Юлия кайтып кергәннән соң аның хәле тагын да кыенлаша төште. Кыз оятсыз рәвештә һаман аны күзәтә, сөйләшүдә катнашмый, ләкин, аның күзләрендәге тере, хәйләкәр рәвештә ачылып-йомылып торган күкчәчәге буенча, аның өстәл янында барган хәлләргә судья, күзе бәйләүсез һәм кулы үлчәүсез Фемида икәнлеге күренеп тора иде.

Ә монда, җитмәсә, Шәехнең борыны шешенгән, ирене кабарган...

Аның өчен дөнья ахыры Роза апа Шәехкә чираттагы соравын биргәч һәм аның җавабын көтеп барысы да алларындагы тәлинкә-кәндиләреннән башларын күтәргәч җитте. Ул бу вакытта бик кыстап тәкъдим ителгән гөбәдияне алып ята иде, тик бу гамәле уңышсыз чыкты: алган кисәге, кинәт сынып, аның тезенә килеп төште һәм эчендәге йөзем, дөгеләр келәмгә чәчелде. Иелеп өстәл астына керүдән башка чара калмады.

—Үзем, үзем җыеп алам,—дип каударланды Роза апа. Ул бу мизгелдә кунак өчен өстәл астында мең мәртәбә яхшырак икәнен исенә дә китермәде. Әгәр дә аны тартып чыгармасалар, ул анда төнгә хәтле утырыр иде.

—Нәрсә инде син, йа, Алла!—диде Кыям абый.—Идәнгә төшкән дөге—уңышка ул. Яхшыга, димәк, икенче мәртәбә безнең өстәл тагын да мулрак булачак. Таптың борчылыр нәрсә! Э-хе-хе. Ә нигә көләсең син, Юлия? Синең килеп керүең белән, Юлия, безнең сөйләшү язды юлдан. (Монда бабасы сүзләр уйнатты: «Юлия»—«юлдан». Шушылай шаярткаларга ярата

иде ул.) Без бит синең турыда сөйләшә идек.

—Кызык!

—Синең турыда түгел, ә синең картинаң турында,—дип ачыклап куйды Роза апа.

—Ә-ә, анлашылды, барыбер гайбәт саткансыздыр инде.

—Юк, Шәехкә бабаңның эше ошады.

—Бабайның эшеме, әллә эшенең объектымы?—дип елмайды Пичуга.

—Анысы да, монысы да.—Роза апа шаян гына итеп малаенның баш түбәсенә кагылып алды.

—Мин белгеч түгел, ләкин, валлаһи...—Бераз тынычланып алган Шәех Кыям абыйның картинасына карата үзенең карашын белдерү өчен сүзләр сайлады.—Валлаһи, яхшы.

—Тирән һәм җентекле нәтиҗә,—диде Пичуга.

—Мин бигрәк ни... кинәт кенә авыр... Ләкин миңа Кыям абый Юлиядәге иң мөһим нәрсәне—аның кәефен һәм... һәм, эчке дөньясын дип әйтимме, тотып ала белгән.

—Шулаймыни-и?—дип сузды Юлия һәм, кызыксынып, аның портретын менә хәзер генә алдына элгән шикелле, үзенең сурәтенә карап бакты.

Картинага Роза апа да игътибар белән карады. Башын кырын салып, рәссам да күзләрен аңа таба күтәрде.

Бары тик Пичуга гына ваемсыз калды. Йомшак, елмаюлы кыяфәте генә аның монда утыручы дилетантлардан өстен булуы турында сөйли иде.

—Мөмкин, мөмкин,—диде ул, тәлинкәсен читкә этәреп.—Мөмкин, монда нәрсәдер бирелгәндер дә, тик Юлия үзенә бик аз охшаган. Бу—ул, димәсәләр, аның чыннан да ул икәнен белеп тә булмый.

—Рәссам ничек күрә, шулай ясый да,—дип каршы төште Шәех.—Кайбер бөек рәссамнар ясаган кешеләр дә үзләренә охшап бетмиләр.

—Аларның берәрсенә үз портретыңны ясарга заказ бирүенә шикләнәм.

—Әй, Саша,—дип көрсенде Роза апа,—син һәрвакыт бар нәрсәне дә тәнкыйтьлисең.

—Тәнкыйтьләмимм, ә моназара кылам. Бабайның портретлары, анда ясалган кешеләргә караганда, күбрәк бер-берсенә охшаганнар.

—Үз иҗади рәвеше!—дип нәтиҗә ясады Юлия.

—Рә-ве-ше... Ул кырык беренчедә кылыч белән ясаган, менә мин моны аңлыйм, бу рәвеш булган.

Кыям абый, кисәк кенә муенын тартып куйды да, чынаяк чокырын тәлинкәсенә каплады.

—Соң, мин бит кылыч белән менә шушы бөтен нәрсә хакына селтәндем, мин бөтен гомерем буе шуның турында хыялландым... Әгәр аңа тиешенчә өйрәнә алмаганмын икән, тормыш мине кече яшьтән үк башкага өйрәтте. Ул минем планнарымны һәрвакыт эзлекле рәвештә җимереп килде.

Бабасының реакциясе Пичуганы гаҗәпкә калдырды, чөнки аңа һәрвакыт бар нәрсә дә рөхсәт ителә. Элек моның ишене генә ычкындырмый иде әле, ә бу юлы... Ләкин Пичуга каушап калмады.

—Мин аны күздә тотмаган идем,—диде ул.—Инде минем, сәнгатькә болай гына карыйм, дип күпме әйткәнем бар... Сәнгатьнең бар төре дә, әгәр төшенә калсаң, шайтаннан килә, вакыт артыктан һәм сәламәт булмаган шөһрәт сөюдән. Тик бу сиңа кагылмый, бабай. Ә син, Шәех, алай-болай шагыйрь түгелсеңдер бит?

Шәех авызындагы пирог кисәген йотарга өлгермәде, ә Александр инде дәвам итте:

—Күрәм, түгел. Мин дә. Лирикадан камыр җәеп булмый. Бу киндер

тукымаларны, сүз уңаенда әйтүем, ашап булмый, менә шушы су белән дә...—Пичуга стенаның өстеннән астына хәтле булган шарламага ишарә ясады,—эчеп җибәрә алмыйсың. Бүгенге көндә прогрессны фәнни-техник революция—эф-тэ-эр билгели! Ә болар,—ул чәнечкесе белән бүлмәне айкап алды,—әлбәттә, болар барысы да яхшы. Сугыш ветераны өчен менә дигән шөгыль, ләкин аның асылы түгел. Безнең бабай барыннан да элек—Бөек Ватан сугышы ветераны, кылычы, әйе, әйе, кылычы белән баштанаяк коралланган фрицларны кырган данлы Доватор кавалерия дивизиясе сугышчысы.

Пичуга бабасына ясалма горурлык белән карап алды, ләкин тегесе оныгының бу сүзләреннән артык рухланып китмәде.

—Әйе, картинаны ашап булмый.—Бабасының тавышы тоныкчыкты.—Ашый алмыйсың... Ләкин аннан башка кеше уща-мараха. Картиналар... Картиналар мине инвалид арбасыннан күтәрде.—Ул авызына ашъяулыктан җыйган ипи валчыкларын капты да тынып калды.

—Бу минем тәрбия булдымы инде?!—дип Роза апа малаена шелтәле караш ташлады.—Бу безнең республиканың беренче иллюзиячесе... нигез салучысы оныгымы соң?!

—Син минем нәселдән килгән фокусчы булуымны телисеңме әллә?

—Мин синең яхшы кеше булуыңны телим.

—Ә мин?..

—Син борыныңны күтәрәсең.—Китапларны күп укыйсың, тик, белмим, алардан ни генә аласыңдыр?!

—Мәгълүмат!—диде Пичуга һәм бармагы белән һавага төртеп алды.—Алай да әдәбиятта ул азмы-күпме бар. Ә менә натюрмортларда... Бәлки, алар күңелгә ни дә булса бирә дә торгандыр, ә акылга... бернинди азык та бирмиләр.

—Ә синең яраткан футболың ничек соң?—дип кызыксынды Юлия.

—Футболмы? О-о, футбол—ул югары математика! Анда бүтән нәрсәгә караганда да баш кирәк. Команданың уены буенча мин андагы кешеләрнең нинди икәнлекләрен, тренерның нинди кеше икәнен шундук әйтеп бирә алам. Алай гына да түгел... Хәтта мин сезгә ул команданың кайсы илнеке икәнен һәм ул илдә нинди сәяси строй хөкем сөргәнен дә әйтеп бирәм. Менә нәрсә ул футбол! Дәүләтнең аркылы кисеме ул, интеллектуаль шөгыль.

—Яхшы,—диде Юлия, бәйләнүен дәвам итеп,—ә ул чагында синең архитектурага булган ялкынлы теләгең белән ничек килеп чыга инде?

—Барысы да логика чикләрендә. Архитектура—тагын шул ук мәгълүмат ул. Аннары аңа математиклардан кем ваемсыз карый ала? Архитектура бөтенләй геометрия белән сугарылган. Һәм киресенчә, Евклид, Менелай, Декарт, Лобачевскийларны бөек архитекторлар димичә кем дисен?.. Николай Иванович Лобачевский безнең университетны таштан берәмтекләп җыйган. Ул бинаның соңгы планнарын күрсәгез икән сез! Гаҗәпләнәм, нишләп аның исеме архитектор Пятницкий исеме белән янәшә куелмый икән? Лобачевский шундый ук автор, юк, баш автор, җитәкчесе, төзүчесе, тәэминатчысы, әйдәп баручысы, хуҗасы булган...

Пичуга илһамланып китте.

—Математика... Тормышның үзенә дә математик анализ ясарга кирәк. Аның чын авторы була белергә кирәк. Менә мин үземнекен илле елга алдан планлаштырып куйдым. Син, Шәех, бер атнадан соң сәгать җиде дә утызда ни эшләргә җыенасың? Белмисеңме? Шулай шул менә. Ә мин беләм. Мин, мәсәлән, утыз өчтә өйләнәсемне дә беләм. Кемгә дип уйлыйсың? Скрипкада уйнаучы кызга. Инде кандидатура да бар. Быел балалар бакчасыннан соң музыка мәктәбенә бара. Хәзергә әле толымчыклар, бантиклар... Сөйкемлекәй!

Аны тиешле яшькә җиткерәм дә кирәкле юнәлештә тәрбиялим... Ә инде консерваториядән соң рәсми тәкъдим ясыйм...

—Әй, Саша, әй, Саша!—дип Роза апа үзенең карашын улыннан әтисенә күчерде.

Кыям абыйның куе чәче буялган икәнен Шәех шунда гына сизде. «Бөтенләй чаларгандыр, мөгаен»,—дип уйлап алды ул. Бу эчкерсез карт ошады аңа, аның картиналары да ошады. Баксаң, язмышы да гади генә түгел икән. Аны Пичуганың йөгәнсез ачыклыгы тайчандырды. Аның сүз җаенда гына ташланган кебек тоелган уйлары (шулай гына булса иде дә кана!) акыл тарафыннан кире кагылмады, көтелмәгән раслау тапты. Чыннан да аның портретлары—ә бу бүлмәдә асылда алар гына эленеп тора—гаҗәеп рәвештә бер-берсенә охшашлар иде. Шул ук яссы йөзләр, бер үк кыяфәт (бил тинентен, ярым борылган килеш, тамашачыдан каядыр читкә юнәлгән караш белән), алар бөекләрдән кемнеңдер манерасын хәтерләтә дә кебек, шул ук вакытта беркемне дә, хәтта анда сурәтләнгән кешеләрне дә ачык хәтерләтми. Ул стенадан Юлия белән янәшә ясалган Пичуганы, Роза апаны да тиз генә таный алмады, аксыл чәчле, зәңгәр күзле, күкчәчәкле такыя кигән кыз да аның өчен карауга ук Юлия булып чыкмады. Шәех бу минутта үзенә Пичуганың бабасына карата тыйнаксызлыгы (хаклы икәнсең, ярар, ләкин ник тупаслык күрсәтергә?) өчен генә түгел, тагын анда Шәех үзен күргән кыек көзге шикелле тотуы өчен дә ошамаганын абайлап алды. Ул да бит, Пичуга сыман, тик алай ук кистереп түгел, өстәлдәге бәрәңге белән ипине картиналарга караганда яхшырак дип саный һәм аны китап битләре буйлап, барыннан да элек, кызыксыну йөртә, һәм ул үзе дә, тик бераз икенче төрлерәк, ләкин—монысы инде бернинди сүзсез!—ФТРның тантана итәчәгенә ышана. Билгеле инде, андагы фәнни фантастикага мәхәббәт һәм киләчәккә чабучы машинага үз шөребен борып кую теләге әнә шуннан килә. Алай да сәнгатьне, шигъриятне бары тик кирәк булган чакта аларны ипигә ягып булмый, ашап булмый, борып һәм тегеп булмый дигән сәбәп белән генә чабып ташлау, һәрхәлдә бик гаҗәп. Сүз белән артык мавыгып китте бугай бу Пичугин. Кизәнде, кизәнде дә бер яктан сәнгатькә чабып җибәрде һәм шундук икенче ягына килеп ябышып калды. Архитектура бит ул, ни әйтсәң дә, барыннан да элек—сәнгать, ә инде аннан соң гына математика. Тормышны матанализлауга килгәндә исә, ул, Шәех тә, нәрсәдер планлаштыра. Утыз яшьтә яшь скрипкачы кызга өйләнүне түгел, әлбәттә...

Шәех Кыям абыйның әсәрләренә тагын бер мәртәбә карап алды. Ни әйтсәң дә, Пичуга хаклы: аның рәсем ясау рәвеше—осталык җитмәүдәндер. Шуңа күрә дә портретлардагы йөзләрне тиз генә танып булмый. Ләкин аларны бераз вакыт карап торганнан соң гына тануда да, чынбарлыкның андагы үзгәрешендә дә Шәех шундук сизеп алган үзенчәлеге, тәме бар иде, тик ул аны башта чит кеше фикеренә ияргәнгә күрә генә үз-үзенә аңлатып бирә алмады. Бу, мөгаен, кешеләр «үзләренең тамырларына» бөтен гомерләре аша килгән шикелле, күп кенә рәссамнар да тәҗрибә һәм осталык аша килә торган бик катлаулы булмаган шул үзенчәлек иде бугай.

Кыям абый сүзсез озак тормады. Оныгы аны тагын сөйләштереп җибәрде. Ул аны нәрсә белән алырга икәнен белә иде. Бабай туган теленең чисталыгын һәм әйләнешен чын күңеленнән кайгырта һәм азчылык булган милли телләрнең тора-бара күпчелек милләт телендә эрүе турындагы фаразларны җаны сөйми иде. Пичуга сүзен дәвам итте:

—Телләрнең үзара йогынтысы—табигый процесс,—диде ул.—Ничек кенә әйләндермә, ахырда җир йөзендә аларның кайсыдыр берсе... бердәнбере генә калачак. Беренче Интернационалның бер резолюциясендә, гомуми тел гомуми игелек булыр һәм халыкларның үзара якынаюына бик көчле булышыр

иде, дип язылган булган. Кешеләр моны күптән аңлады. Күз алдыгызга китерегез, моннан егерме биш гасыр элек санскрит—гомумһиндстан теле барлыкка килгән һәм ул милләтләр мичкәдәге сельдь шикелле булган бу илдә бүген дә файдаланыла. Ә бит славяннар өчен Кирилл белән Мефодий дә якынча шуны ук эшләгән. Ә унсигезенче гасырда нindидер сукбай һәм авантюрачы Псалманазаром беренче иреклe, башыннан ахырына хәтле ясалма булган тел уйлап чыгарган. Әлифбасын да, сүзлеген дә бармагыннан суырып алган. Ә кая барасың, ул бит үзен әле яңа гына бик-бик еракта, җәһәннәм астында ачылган җир, дөресрәге, су, утраулар кешесе дип игълан иткән булган. Ул үзе француз булган, имеш. Күрәсең, бабакай, телләр интеграциясенең зарурлыгы бик борынгы заманнарда ук барлыкка килгән. «Тайванныкы»ннан соң сукбай ул үз телен «тайван» теле дип атаган. Нинди генә төрләре булмаган аның: «сабир», «бич-ла-мар», «воляпюк», «эсперанто»... Аңлашыла, алар—берсеннән-берсе ясалма телләр. Әйтик, Гавай утравының беренче короле малае туу уңаеннан яңа тел уйлап чыгарган һәм боерыгы белән үз вассалларын шул телдә сөйләшергә мәҗбүр иткән. Шуннан нәрсә килеп чыга? Баланы агулыйлар да, нәтиҗәдә бу яңалык бик тиз онытыла.

—Ә-һә!—дип Кыям абый бармакларын шартлатып куйды.

—Нәрсә ә-һә? Мин дә суррогат яклы түгел. Алай да кайсыдыр тере телнең башкаларын үзенә тулысынча суырып алачагы һәм өстенлекле, ә аннан соң бердәнбер тел булып калачагы—бәхәссез.

—Синең бар нәрсә дә нигезләнгән,—дип көрсенде бабасы.—Хәтта анаң телендә сөйләшә белмәвең дә! Әйт, үзенең бишек җырлары телен белү кемгә комачаулый икән?

—Ә-ә, бабакай!—дип Пичуга кулындагы чәй кашыгын хәрәкәтләндереп алды.—Мин инглизчәне белгән кадәр сезнең берегез дә белми. Әллә Шәех—ду ю спик инглиш?

—Инглиш буенча дуетмы ул, юкмы, анысын белмим, ләкин ул үзенең туган телен белә...

—Камил дәрәҗәдә үкме?

—Ничек «камил дәрәҗәдә үкме»?—дип каушап калды Шәех.—Сөйләшәм...

—Укый да,—дип өстәде Кыям абый.

—Гафу итәсез, дуслар! Бездә инглизчә бөтен класс укый. Шулай да аны беркем дә рәтләп белми. Ә чын белем бик гади тикшерелә—җыр белән. Әйдәле, Шәех, раслап күрсәт!

—Мин җырчы түгел,—дип кырт кисте Шәех.

—Сезнең белән барысы да ачык. Менә шулай, бабакай, бишек җырын да хәтерләргә мөмкин булыр иде. Ә бит мин интернациональ гаилә әгъзасы. Әтием минем, барыгызга да мәгълүм булганча, рус кешесе, һәм мин рус бишек җырларын беләм. Өстәвенә бер инглизчәне дә. Ә синең әтиең кем, Шәех? Әй, юк бит ул синең...

—Бар,—дип Шәех башын түбән иде,—тик үлде ул...

—Ә син җырла, Шәех,—диде Роза апа.

—Җырла,—диде кыска гына итеп Кыям абый, аның булдырасын белгән шикелле.

Шәех башын аска ия төште дә кинәт калын тавыш белән сузып җырлап җибәрде:

Ай яктысы бигрәк якты
Утырып күнел ачарга...
Әлли-бәлли, йокла, улым,
Өлгерерсең тел ачарга.

Тәмам җырны җырлап бетергәнче ул шулай бөкрәеп, паркет чыршысына карап утырды. Керфеген дә какмады. Иреннәре дә селкенми шикелле, ә сагышлы, ягымлы җыр агылды да агылды.

—Бишек җырымы бу?—дип сорады Юлия, ул тынып калгач.

—Әйе,—диде Шәех.

—Мондыйны ишеткәнем юк,—дип уйга калды Роза апа.

—Бер төрле үк әйтелешләр: бу бишек җырындагы «бәлли» сүзе бездә—«баю», инглизчә—«бай»,—дип куйды Пичуга.

—Әйдә тагын, Шәех!—дип кочаклап алды кунакны дулкынланган Кыям абый.—Күптән күңелдә болай җылы булганы юк иде!

—Җырга бугаз төене комачауламый,—дип елмайды Шәех.

Һәм җырлап җибәрде. Бу юлы ул тыңлаучының йә ачуын китерә, йә бик соклandыра торган, күңелле, «һайт!» дип кычкырулы күтәренкелек белән сугарылган гамьсез-ваемсыз, күңелгә тия торган җыр иде. Аның югары нотасында үсмерлек карлыгуы югалып калды, тавышы чиста һәм яңгырашлы чыкты. Шәехнең кыяфәте дә үзгәрде: бишек җырын җырлаганда һаман урынында торган кашлары арасындагы тирән эз юкка чыкты, куллары җанланып китте... Икенче кушымта вакытында ул куллары белән үзенең тезләренә сугып алды да бүлмә буенча китте. Башы югары күтәрелгән, куллары—артында, ә аяклары эштә—әле аяк очлары, әле үкчәләре белән тыпырдатып ала, артист дип белерсең!

Кояш нуры, ачып куелган мәктәп тәрәзәсеннән чагылып, бүлмәне зур энә белән тишеп алды. Шәех чагылган күзен йомды, ләкин туктап калмады. Аның күзен менә шулай каты итеп чагылдырган башка бер көн, икенче төрле кояш чагылышы исенә төште. Ул вакытта аңа өч-дүрт яшь иде һәм бу аның үз тормышыннан хәтерләгән беренче хатирәсе иде бугай... Әтисе эштән кайтып керде, аны үзенең җылы кытыршы зур куллары белән эләктереп, үзенең кызыл погоннарыннан да югары күтәрде, аннары түшәмгә чөйде, бүлмә буенча әйләндереп йөрде. Менә хәзер дә күзләрне шундый ук кояш нуры чагылдыра, бөтен тирә-як та шулай әйләнә сыман...

Соңгы мәртәбә ул әтисен зиратта күрде. Аның каны качкан, сүрелгән йөзен тирән итеп казылган, аста махсус уем-ләхет алынган кабергә төшерер алдыннан салкын кояшка ачканнар иде. Шәехне әтисенең баш очына китерделәр дә шунда күндәм рәвештә аңа карап басып торды. Ул аның әтисе дә кебек, ләкин инде әтисе дә түгел иде. Кечкенә күкрәгендәге биш яшьлек йөрәге кысылып куйды һәм калтырый башлады. Чөнки әнә шул мизгелдә йөрәге, әле балалар акылы чыкмаган үзеннән аермалы буларак, аңа иң якын булган кешесенең үлүен бөтен ачыклыгы белән аңлап алды. Кабер кисемендә куе бәс җемелди, көмеш сыман ялтырый иде. «Юк, юк,—дип типте йөрәк,—аңа анда һич тә әйбәт һәм җылы булмас». Ябышкак караш белән катып калган күзләренә кайнар булып китте, ләкин Шәех еламады. Моннан соң ул гомумән беркайчан да еламады.

... Шәех үзенең житез биюен кинәт кенә туктатты да урынына килеп утырды. Шунда аның аңына Кыям абыйның:

—Әһә-ә, менә бу безнеңчә!—дигән тавышы килеп житте.—Булдырдын, Шәех! Ә-ә, Пичугин әфәнде?!

—Бик яхшы, бик шәп,—дип җавап бирде Пичуга.—Алай да...—Отылу, жиңелү дигән нәрсә аңа хас түгел иде, тик шунда Юлия баш күтәрде.

Ул бераз вакыт уйланып калган иде: аны Шәехнең җырлары дулкынландырды. Аның икенчесен радиодан ишеткәне бар иде инде. Ләкин аны чагыштырып буламыни! Ярар, радиода профессионаллар да һәм тере оркестрлар да булсын, ләкин монда—тере тавыш бит! Синең янында гап-гади кеше дә, хәер, нинди кеше?—малай, синең яшьтәшең дә шундый

нәрсә тудыра алыр икән...

Жаны уйнаклавыннан соң Шәех ничектер катып калгандай булды. Ул йөзенә үк чыккан бердәнбер, ничек кайтып китәргә диган уйлы караңгы чырай белән утыра бирде.

Юлия аңа карап алды да карашын бабасы белән абыйсына күчерде.

—Житәр, ә? Кунак турында оныттыгыз. Бабай, бу синең дустың бит. Аның белән безне шулай дип таныштырдылар бугай?

Кыям абый нәрсәдер әйтергә жыенган иде, ярты сүзендә бүленеп калды, челт-челт итеп күзләрен йомгалап алды.

—Әмма,—диде Юлия, толымчыгын селкеп,—сез дәвам итә аласыз... Ә без Шәех белән язмалар тыңларга киттек.

«Язмалар» сүзе бүген бик тә гадәти яңгырый. Ә ул елларда, магнитофоннар әле яңа гына кулланышка кергән һәм муллык билгесе дип саналган, әле бик тә сирәк булган ул чакта, бу сүз могжиза сыман яңгырады. Пластинкалар түгел, ә яз-ма-лар!

Юлиянең якты, бик пөхтә бүлмәсе бабасыныкы белән янәшә иде. Стеналарында бернинди үзешчән рәсем сәнгате юк—һәрберсе «Огонек» журналыннан булган репродукцияләр. Өстәлендә—китаплар, альбомнар, һәм килеп керүгә үк бөтен көченә жибәрелгән «Гинтарас» магнитофоны. Көче, әлбәттә, бүгенге «маг»ларныкы кебек үк түгел түгелен, ләкин этажеркалардагы вазалар барыбер калтыраналар кебек иде. «Рок, рок, рок-н-рол!» дип бөтен көченә акыра иде анда кайсыдыр инглиз. Юлия, музыка тактына тапочкаларын селеккәләп, кечкенә генә кәнәфигә урнашты. Шәех магнитофон янындагы урындык кырыена килеп утырды. Аның кыяфәте форточкадан ялгыш килеп кергән кошныкын хәтерләтә иде. Ул Юлиядән әле һаман төзәтә алмаган «Альпинист»ы өчен шелтәләвен көтте. Ләкин кыз бер генә сүз дә катмады, әйтерсең бернинди апрель дә, бернинди котырган «үгез» дә һәм бәлале язгы көлләвекләр дә булмады. Аның «ә без танышлар, әни»дән башка берние дә жылытмый иде. Әле аның анысы да: «Бабай, бу синең дустың бит...» диган сүзләре белән суытылды. Калганы, шул исәптән рок-н-ролл да, эч пошканнан һәм ачудан гына туган «әлли-бәлли»е иде. Кирәк бит шулай, аңа жырла әле, дип әйтүләре булды, ә ул шундук—баш өсте!

—Транзисторны, һичшиксез, төзәтәм мин,—дип сытып чыгарды Шәех жырлар аралыгында,—бер диод кына таба алмыйм әлегә...

—Ярар ла ,—диде Юлия һәм «инглиз»не әкренәйтә төште.—Син рәссаммы әллә?

—Юк...

—Минем бабай белән ничек таныштыгыз соң?

—Ә-ә , күгәрченнәр очыручы мин, күгәрченнәр очырам, ә аңа аларны рәсемгә төшерергә кирәк булган, менә шулай танышып киттек.

Юлия Шәехнең өендә картиналарның исе дә булмавын хәтерләп алды. Канифоль белән кургашын—әйе, бар, ә картиналар...

—Минем бабай тынгысыз кеше.

Шәех елмаеп куйды:

—Кызыклы кеше.

—Без аның белән бик дуслар.

—Ә Саша нигә шулай икән?

—Ничек?

—Агрессив ул ничектер.

—Алар гел шулай... Бүген берсе кайнарлана, иртәгә икенчесе. Нәкъ балалар шикелле. Тик син әллә нәрсә уйлама, абыем карап торырга гына шулай ул... Дөресрәге, шулай булып күренергә тырыша, уйный, ә болай

күңеле чиста аның. Әдәбиятны да ярата ул, рәсем сәнгатен дә, музыканы да... Балалар бит кемне яратарак төшә, шуны күбрәк талкый-борчый. Ә ул әле бала гына, зур бала.

—Сәер.

—Нәрсәсе сәер?

—Һич тә уйламаган нәрсә турында сүз куертуы.

—Әйтеп торам бит: уйный ул, уй-ны-ый. Аның белеме ничеклеген үзең ишеттең ич. Менә бит ничек...

Өстәл кырыендарак инде Шәех күптән игътибар иткән калын гына альбом ята иде. Юлия аны аңа таба этәреп куйды.

—Карап ал. Открыткалар анда. Саша—бик хирыс коллекционер бит ул.

—Открыткалар?

—Төрле кала күренешләре—Казан, Әстерхан, Мәскәү... Ул архитектура белән бүтән нәрсәләрдән тыш мавыга. Иске архитектура белән. Аның мондый альбомнары санап бетергесез.

—Математика, футбол, архитектура?!.

—Ә син үзең? Радиотехник, күгәрченнәр очыручы, җырчы...

Шәех җавап бирмәде, альбомны кулына алды. Калын дерматин тышлык астында иске, революциягә кадәрге мәчетләре, чиркәүләре, ак ташлы Император университеты һәм XIX гасырда ук янган агач шәһәр театры, Грузин Алла Анасы чиркәвенең биек манарасы һәм Дворяннар җыенының тәбәнәк йорты, алъяпкычлы, сакаллы ямщиклары белән бетмәс-төкәнмәс «барабыз» рәтләре һәм күпере буенча элеккеге камытлы Россиянең сафка тезелгән солдатлар строе аркылы үзләре сайлаган юлга—каторгага озатканда иң яхшы уллары һәм кызлары узган атаклы Себер заставасы...

—Кыйммәтле коллекция,—диде Шәех.

—Шулай булмыйча!

—Ә кайдан килгән ул аңа?

—Җыйды. Ләкин аз дигәндә, яртысы—мирас буенча.

—Бабагызданмы?

—Юк, әти бүләк итте. Яшьлектә ул моның белән үзе дә мавыккан булган. Ә Сашаның коллекциясе дә шактый арта башлагач, әти аңа үзенекен бирде.

—Баерагынмы?

—Әлбәттә. Ләкин Сашаның да бик кыйммәтле открыткалары бар иде.

Магнитофонның туктап калуын һәм пленка койрыгының кага башлавын да сизмәделәр.

Ишектән кыштырдаган тавыш ишетелде. Бу Кыям абый иде.

—И-и, шайтан туе!—дип куйды ул, магнитофонга караш ташлап.—Ни көе, ни сүзләре...

—Ритм, бабакай, ритм!—Юлия аның янына очынып килде дә, кулларыннан алды һәм чайкалдыра башлады.

—Үләм, үләм, җибәр!—дип ялынды бабасы, аның кулларыннан ычкынырга тырышып.—Мондый аллюрга өйрәтелмәгән мин. Ничек тә миннән башка гына инде сез... Мин бер генә минутка, Шәех белән саубуллашырга гына кердем.

Шәех, аны өскә пружина тотып аткандай, урыныннан сикереп торды.

—Без бергә бармакчы идек бит, Кыям абый!

—Менә кердем бит...

—Әй, бабай,—дип аптырап калды Юлия,—булдырасың да инде! Үзең дә биемисең, кавалерны да алып китәсең.

—Миңа, чыннан да, вакыт,—диде Шәех.

—Ә нәрсә, утыр.—Кыям абый оныкасы карашы астында кинәт алышынып куйды.—Иртәрәк әле...

—Барыгыз инде, бар.—Юлия, ясалма рәвештә ачуланган булып, тәрәзәгә таба борылды.

Ул көнне карт белән үсмер бер-берсен кичкә кадәр диярлек озатышып йөрде. Безнең өйгә тикле килеп җитәләр дә эскәмиядә утыралар, сөйләшәләр-сөйләшәләр дә—тагын биш катлы йортка. Шәехтә картлар белән карчыкларга карата нindидер сәер кызыксыну һәм тартылу бар иде. Хәер, бу ике яклы иде—карт-корылар да анда нәрсәдер таптылар. Кирәк бит Кыям абыйга көн буе диярлек шушы малай белән сөйләшергә! Яшьтәшләре менә Шәехтә бернинди аерымлык та тапмыйлар иде. Хәер, үзе да тапмый аларда. Ул: «Яшь акыл—буш акыл» яисә «Яшь акыл—өйрәнмәгән тай кебек»,—дип берничә мәртәбә генә кабатламагандыр. Ул яшьлеге өчен үзен дә кыралмый иде. Аның яшь кыяфәте астындагы ир-атны мин үзем генә сиздем. Һәм менә тагын—картлар да...

Алай да Шәехнең иң якын кешесе Кыям абый түгел, ә инде искә алынган галим күршебез Николай Сергеевич Новиков иде. Анын турында сүз аерым булыр.

## Сабантуй

Истәлекле ул Сабантуй көне аяз, эссе иде. Без, гамьсез-ваемсызлар (каникуллар бит!), ничек тә призсыз кайтмаска дигән уй белән паркка юнәлдек. Житәр җанатар булып кына йөрергә, инде үзебезне дә чын эштә күрсәтергә вакыт. Вакыт, бик вакыт! Барганда ярты юлыбызны үзебез өчен без катнашырга тиешле ярышлар төрен сайлауга, икенче яртысын стратегия һәм тактика билгеләүгә багышладык. Нәтиҗәдә шундый план килеп чыкты: табигатьтән килгән яхшы координацияле акыл сәләте иясе буларак, мин күзләрем бәйләнгән килеш чүлмәк ватырга һәм төп призны алырга, Шәех икенче ярышта—очына приз куелган шоп-шома, озын багана башына менү буенча җиңәргә тиеш.

Без паркка килеп җиткәндә Сабантуй башланган гына иде әле. Кызыксынучан халык арасыннан без, үз планыбыз буенча эш итеп, чүлмәк вата торган урынга үттек. Чүлмәкләр ватарга җыенучылар чиратында мин жиденче идем. «Жиде»—изге сан, бәхет, һичшиксез, елмаячак, диде Шәех һәм, багана янындагы хәлнең ничек икәнен белергә дип, разведкага китте. Мин исә үз көндәшләремнең ничек эш итүләрен күзәтә башладым. Аларның кулына таяк тоттыралар да үз күчәрләре тирәсендә егылып хәлгә житкәнче әйләндерәләр һәм җибәрәләр. Аннары приз алырга теләүче мескеннәр үзләренең тулгатылган вестибуляр аппаратлары белән балчык чүлмәкләрне эзләп китәләр һәм, тирә-яктагы халыкны көләргә мәҗбүр итеп, таяклары белән алардан бөтенләй читтәге чирәмне кыйнарга тотыналар. Бары тик чиратта миннән алда торган җирән берәүгә генә бер чүлмәкне чәлпәрәмә китерү бәхете тәтеде, аның өчен аңа кызуга чыдам балчыктан Васильеводa ясалган чәй пешергеч чәйнек бирделәр.

Минем чират җитте. Шәех миңа, кояш үз курсы буенча нәкъ чүлмәкләр читендә, ул бәйләвеч аша барыбер күренәчәк, дип хәтерләтеп куйды да, рухландырып, минем йомшак җиремә сугып алды. Һәм мин зур тәвәккәллек белән үземә сузылган таякны кулыма алдым да күзләремне бәйләргә ирек бирдем. Шуннан соң әллә ниткән куәтле куллар минем иңнәремнән тотып шундый көч белән әйләндерә башлады, әйтерсең мине шөреп шикелле җиргә борып кертергә телиләр иде.

Бәйләвеч аша кояш күренми. Ә аның кайчан кайсыдыр ягымны җылыта

башлавын күтәргә вакыт юк, баш әйләнә, әллә уң, әллә сул колагымда Шәех тавышы ишетелә, тик аның нәрсә диюе, нинди киңәш бирүен һич аңлап булмый. Аның соңыннан сөйләве буенча, мин таягымны баш өстенә күтәреп судья өстәленә таба атлап киткәнмен һәм түбәтәйләр киеп утырган ак сакаллы коллегия арасында паника тудырганмын. Ләкин аларга берничә адым барып җитмичә, бик ышанычлы адымнар белән, киртәләп куйган кызыл флагчыклы бау эченә кереп урнашкан җанатарларга таба юнәлгәнмен. Милиция эшли алмаганны, мин эшләгән: тәртип бозучылар ашыгыч рәвештә трибуналарга—үз урыннарына кире кайтканнар.

—Алдыйсың син!—дидем мин Шәехкә, чүлмәкләр белән килеп чыккан уңышсызлыктан туган ачуны аңа аударып.

Бозылган кәеф белән күңелсез генә алга таба атладык.

Очында агачтан бизәкләп ясалган матур гына «өй»дә шунда менеп җитүче өчен дип приз—хәрәкәтсез сары койрыгы аска таба салынып торган әтәч куелган багана янында бигрәк тә җанлылык хөкем сөрә иде. Тик ул призны алып төшәргә тырышучыларның берсе дә багананың яртысына да җитә алмый. Әйе, монда яхшы мускуллар гына түгел, баш та кирәк. Ничегрәк менәргә, кайчан... Багананың шомалыгын арттыру өчен, ул һәрвакыт ниндидер нәрсә беләндер сөртелә-буяла, шуңа күрә, беренчеләрдән булып файдасызга көчәнмәс өчен, аның вакытын тота белергә кирәк, ләкин шул ук вакытта кайсыдыр җитезе синең борының астыннан әтәчне менеп алганын да көтеп торырга ярамый.

Без ике чират алдык. Беренчесенә мин бастым, ә биш кеше аша—Шәех. Минем чиратым җиткәч, мин аңа: «Хәзергә уткәреп торыйк, әле багана яхшы ук корыланып җитмәгән, әнә малайлар ничек тәгәрәп төшәләр»,—дидем. Ләкин Шәех башка көтеп тора алмады, аяк киемен, чалбарын салып, бары тик футболка белән плавкидан гына калгач, багана янына килде дә, менә дигән матрос кебек, учларына төкереп куйды, шома багананы тотып карады һәм... сикерде. Җансыз дошманны кочагына алып кысты.

Шундук мин үземә, әтәчне, һичшиксез, алып төшәчәк бу, дип куйдым. Башка уйны башыма да китерә алмый идем, чөнки мин аны бик яхшы беләм: ул тешләре белән ябышыр, ләкин бирешмәс. Бу бит очраклылык та, җай килеп тору да була торган футбол түгел, монда, нәкъ менә монда, ул үз үҗәтлегенең бөтен көчен күрсәтергә тиеш.

Болай дип бер мин генә уйламый идем.

—Тавык ите өчен бу татар монда түгел, әллә кая менәр!

—Хе-хе, бу—һичшиксез, алачак, менә күр дә тор.

Борылып карасам—алар: Жбан белән Киләле.

—Ә син нигә калышасың?—дип авызын ерды Киләле.

Дәшмәдем.

Бу ике дус та сүзсез калды. Жбанның кечкенә күзләре баганадагы фигурага кадалды, аның яңакларында төерләр йөри башлады. Соңыннан гына белдем, ул безнең янга көрәшчеләр келәмендә аяусыз җиңелүгә дучар булганнан соң килгән икән. Ниндидер егет кисәге аны беренче секундларда ук биш ноктасы белән дә нык итеп келәмгә сылап куйган.

Шәех багананың яртысына җиткәннән соң һаман әкренрәк, һаман әкренрәк, еш туктый-туктый гына менә башлады. Ул туктап калган саен, инде ул көчен башка жыя алмас, әкрен генә аска шуып төшәр шикелле тоелды. Ләкин тикмәгә генә Шәех дип йөртмиләр бит аны, анда ниндидер бик нык төш-үзәк утыра иде. Ул өскә таба һәр метр саен һаман шомара төшкән бу агачны тагын да чамасыз ярсулык белән һәм тагын да көчлерәк кочаклый барды. Бар Сабантуй, үзенең бию мәйданнары, аттракционнары, калкулыклары, чокырлары, урманнары белән бөтен парк безнең аста ята

иде, янәшәдә генә болытлар очып үтә, тирә-юньдә кошлар очып йөри, оя-өйчектән төшкән кояш күзне чагылдыра, ә битне инде әтәч койрыгы кытыклый. Әйе, әйе, хәлиткеч бу минутта мин анда—багана башында. Шәех белән бергә идем һәм боларның барысын да тойдым, күрдем, сиздем һәм аның белән бергә багана башындагы серле ишеккә омтылдым.

Призны җиргә бик иплəп, сак кына төшерергә кирәк иде, чөнки аны алу өчен бик күп көч куелды лабаса. Кинәт әтәч Шәехнең арудан калтыранган кулларыннан ычкынып китте дә, канатларын кага-кага, каурыйларын чәчә-чәчә мәйдан уртасына таба очты. Шактый күп санлы ярышучылар арасында аны тотып алу ансат эш түгел иде. Һәркем әтәчне өркетү-куркытуны, аңа кагылышлы нинди дә булса шаярулы сүз ычкындырып тирә-юньдәгеләрне көлдерергә тырышуны, әлбәттә, иң беренче чиратта аның яңа хуҗаларыннан көлүне үзләренең бурычы дип саный иде бугай. Без кулларны тырпайтып йөгердек, мүкәләп шуыштык һәм инде безгә ирексездән килеп чыккан бу тамашаның ахыры булмас сыман тоелды.

Шунда бәхет миңа елмайды. Мин, җаен туры китереп, ерткыч сыман сикердем дә үҗәт кошны көрәш келәме кырыенда тотып та алдым. Бу мизгелдә батыр үзенең көндәшен җилкәсенә китереп салды һәм җанатарларның шатлыклы сокланулары миңа да, көрәшчегә дә җитте.

Әтәч токымлы экземпляр булып чыкты. Кара-сары-ал төстә, гаярь күкрәкле, озын, югары күтәрелгән койрыклы һәм тарак сыман уеп ясалган кикрикле. Кикригенең ике теше мәһабәт рәвештә өскә карап тора, ә калганнары кырын салынган, җитмәсә, зурлар, авырлар. Менә нинди табыш белән кайтып бара идек без! Шунда безгә бу очрашу хакында үзебез төшләрдә генә хыялланган, ә өндә исә бу турыдагы уйдан да курыккан кыз очрады. (Курыккан дигәннән, мондый халәт үсмер чакның беренче мәхәббәте чорында һәрвакыт һәм һәркем белән дә була икән). Юк, Шәех белән без бер-беребезгә йөрәк серләребезне чишми идек. Әгәр дә ниндидер ялгышлык белән сүз башласак та, ул болай гына, мәсьәләнең асылына кагылмыйча гына бара, дәвам итә иде. Ләкин бу хиснең бер-беребездә барлыгын, минемчә, һичшиксез, икебез дә сизенә идек. Кайчаннан бирле? Мөгаен, ялкын сыман янып торган әтәчне култык астына кыстырып паркның үзәк аллеясы буенча кайтып барган нәкъ әнә шул бәйрәм көненнән башлап.

## Ул мине түгел, башканы сөя

Әтәчне Шәех тотып бара. Шикле рәвештә тынычланып калган әтәч, тагын үзенең холкын күрсәтер өчен тиешле мизгелне көтә иде бугай, ләкин хәзергә тыелып тора. Ул булмаса, Юлия безне күрмәс тә иде, чөнки аның күкчәчәген хәтерләткән күзләре кемнедер эзли иде.

Ул үзенең кабатланмас йөреше белән безнең янга якынлашты. Аны ерактан ук күреп алдык, ә ул исә безне бездән берничә адымда, аның алдыннан атлаган тырпайган чәчле бер ит бүкәне, безнең әтәчкә күрсәтеп, иптәшен тарткалаганнан соң гына күрде.

Ул кашларын югары чөеп:

—Малайлар, сәлам!—диде.—Менә бу табыш! Кайдан килде сезгә бу чибәр әтәчкәй? Ә мин, беләсезме, Галяны югалттым. Китәсе дә килми, берүземә генә күңелсез дә.

Беренче булып мин өнгә килдем. Гомумән, әйтергә кирәк, эш Юлиягә яисә безнең мәктәпнең башка гүзәл зат вәкилләренә кагылганда, мин үземне Шәехтән иркенрәк хис итәм. Юлия белән, аңлашыла, югалып та калам һәм, инде әйткәнемчә, хәтта курку да барлыкка килә. Ләкин алдан әйтеп

булмый торган ниндидер бер мизгелдә минем тел башым, йөрәгем белән булган элеккеге барлык элемтәләрен өзә шикелле, һәм мин шундый сафсата куерта башлыйм, хәтта кайчак: «Кайдан килә икән миндә бу нәрсә?!»—дип, үземә-үзем дә гаҗәпләнеп калам.

—Әгәр шулай икән, бергә дүртәүләп йөрергә була,—дидем мин.

—Ә тагын кем?—дип тирә-ягына каранды Юлия.

—Безнең әтәчне кавалер дип санамыйсыңмыни син? Яисә безнең кайсыбызныдыр?

—Аһ, әйе!—диде ул, шаяртуны кабул итеп һәм, шикәр сыман тешләрен күрсәтеп, көлемсерәп куйды.

Ашыкмыйча гына парк аша кире якка таба киттек.

Казансу янында парк үзенең гаҗәеп матурлыгы аркасында әле революциягә хәтле үк Рус һәм Немец Швейцариясе дип аталган куе яшел калкулыкларга һәм текә кыяларга әйләнә. Бу калкулыклар тезмәсе елга буенча агымга каршы өскә таба сузыла, Арча кыры зираты артыннан Рус Швейцариясе Немецныкы белән алышына. Аннары елга кискен борылыш ясый һәм шәһәр тарафыннан кагылмаган диярлек таулар, урманнар, ерганаклар шәһәр бөҗрасыннан ireккә чыгалар.

Без яшь каенлыкның ярым күләгәсендә урнашабыз. Монда башка Сабантуй. Үзләренең эре, киң иероглифлары белән керәшәләр җәйгә дан җырлый, агач һәм куаклыкларда анда-санда алтын погонлы купшыллар тыкшынып йөри, аксыл-шәмәхә күкебаш чәчәкләрендә төклетуралар бал белән сыйлана, күренмәс чикерткәләр черелди, барча үлән чынлый-зынлый, андагы бар нәрсә җырлый, тавыш бирә, бии, сикерә, хәтта артык шатланудан тешли һәм чага.

Юлиянең бит очында беленер-беленмәс кенә ак үзәкле алсу «гөл» чәчәк ата. «Кайдан бу, кем?»—дип кызыксынам.

—Сизмәдем дә,—ди ул,—озынборындыр, мөгаен.

Мин бака яфрагы эзләп таптым да шуны битенә куярга тәкъдим иттем.

Бу вакытта Шәех бау белән әтәчне аягыннан бер агачка бәйләп куйды. Тегесе исә, тынычланып, нәрсәдер эзли-эзли һәм чүпли-чүпли шунын тирәсендә йөри бирде.

Яңагына бака яфрагы куйган Юлия Подлужный ягыннан Казансуны язын су баса торган болынга таба кисеп чыгып баручы моторлы көймәне күзәтә. Аның моторы озынборын сыман безелди, суның астын өскә әйләндерә. Инде Казансу монда, Иделгә таба, кечкенә елгачык кына түгел, ә мул сулы зур елгага әйләнә, киң дә үзе—ярлары арасы километрга, хәтта аннан да артыкка җәелә. Элек, әле плотина барлыкка килгәнче, аны тавыклар да ерып чыга иде, дип сөйлиләр. Ләкин минем хәтеремдә ул һәрвакыт шундый, караш белән айкап булмаган кебек калган.

*Дәвамы киләсе саннарда*



# Илдус Гыйләҗев

## Онытмасагыз иде

Шигырь язмыйча да яшәп була,
Таныш хезмәт түгел күпләргә.
Гадәтилек барса җирдән атлап,
Шагыйрь уе оча күкләрдә.
Шигырь укымый да яшәп була,
Очраштыра андый кешеләр.
Шагыйрь ачка коярык чәнчесә дә
Алар күрми, фәкать күшиләр.
Болай әйтмичә дә яшәп була...
Шигырь бит гел әйди яктыга!
Шагыйрь хакы да бар бу дөньяда!
Тел ялеру илтмәс яхшыга...

## Чатыр-тау иртәсе

Чатыртаудан томан төшеп килә,
Болытлардан калган өзелеп.
Бөдрә чәчле каен малайлары
Бит юалар сафка тезелеп.
Бер йөткерсәң кинәт сискәнер дә
Бетәр төсле тамчы коелып,
Бездә таулар таңны каршы ала
Томан чыкларында коенып.

## Кызганыч та, дөрес тә

«Аккош күле» балетыннан
Өзекләр уйнасалар,
Радио-экраннарда
Матур җыр куймасалар,

---

Илдус ГЫЙЛӘҖЕВ (1946) — *шагыйрь; «Җир китабы», «Мәгарә», «Кадерле китап» һ. б. шигырь җыентыклары авторы. ТР Язучылар берлегенең Һ. Такташ исемендәге премиясе лауреаты. Азнакай районы Туйкә авылында яши.*

**Күңел ачу урыннарын**
**Йозакка бикләсәләр,**
**Хакимият бинасына**
**Сак аша кертмәсәләр,**
**Илдә, димәк, нидер булган:**
**Шартлагандыр, янгандыр,**
**Берәр очкыч егылгандыр,**
**Шәһәр туңып калгандыр,**
**Һәм, әлбәттә, күпләп-күпләп**
**Ватандашлар үлгәндер,**
**Мәетләрне туганнары**
**Елый-елый күмгәндер...**
**Минем чират җитәрме дип,**
**Дерт-мөрт килеп барасың.**
**Бездә гомер озынлыгы—**
**Ике матәм арасы...**

## Авырайган китаплар

**Китап төяп кайтып киләм**
**Башкалабыз ягыннан.**
**Машинама Казаннан да**
**Авыр уйлар тагылган:**
**Алып кайтам кайтуын да,**
**Кайткач кая куярмын.**
**Китапның кадерсезлеген**
**Тагын бер кат тоярмын.**
**—Бүләк итеп бирерсез,—дип,**
**Түрәләргә керермен,**
**Битарафлык оеп торган**
**Сытык чырай күрермен.**
**Берсе әйтер:—Ул шигырьне**
**Нәрсәгә дип язасыз?**
**Барыбер бит укымыйлар,**
**Юкка көеп-янасыз...**
**Хаклык бардыр: халык аңы**
**Алды башка юнәлеш.**
**Китап таптап, китеп бара**
**Тискәрегә үзгәреш,**
**Без идек бит кайчан гына**
**Шул китапка табынган!**
**Уйларыма Казан түгел,**
**Ахмак заман тагылган...**

## Баскыннар кагыйдәсе

**Ил чикләрен сакларга да,**
**Амбразура капларга да,**
**Балта, чүкеч сапларга да,**
**Көчсезләрне якларга да—**
**Татар кирәк.**
**Шахталарга төшәргә дә,**
**Девон нефтен тишәргә дә,**
**Сазлыкка юл түшәргә дә,**
**Себер якка күчәргә дә—**
**Татар кирәк.**
**Рейхстагка менәргә дә,**
**Моабитларда үләргә дә,**
**Ил әҗәтен түләргә дә,**
**Илне данга күмәргә дә—**
**Татар кирәк!**
**...Бүләк бүлгән җирдә генә**
**Татар сирәк.**

## Үзләрен белсеннәр

*Татар барда хәтәр бар.*
Әйтем

**Татар барда хәтәр юк ул,**
**Татар барда—хәтер бар.**
**Безнең истә... Үз өлешен**
**Онытмасын... хакимнәр!**

## Чатаннар иле

**Таяк тотып йөрде безнең әти,**
**Сугыш гарипләгән батырны.**
**Тигез басып барып булмыйдыр шул**
**Ярчык чәрдәкләсә балтырны.**
**Бабам җәфаланды тыйтак-тыйтак,**
**Сул аягы яуда кыскарган.**
**Сызлавына түзә алмый иде,**
**Әй, интекте салкын кышларда.**
**Аксак-туксак калып күтәргән ил**
**Өметләрне никтер акламый.**
**Алтмыш биш ел тулды җиңгәнгә дә,**
**Рәсәй һаман туры атламый.**
**...Өметләрне нигә акламый?!**

## Күтәреп куясы бар

*«Возвысить степь, не унижая горы»...*
Олжас Сөләйманов

**Безнең гамәлләр дә шуңа охшаш:**
**Гаделлекне кире кайтару—**
**Түбәнсетми генә бүтәннәрне,**
**Үз халкыңны өскә күтәрү!**
**Башкаларны таптап яшәми ул,**
**Йөзе якты дөнья каршында.**
**Татар өчен түгел тау итәге,**
**Аның урын—кыя башымда!!**

## Мәргәннәр тансыкладым

*Әйткән сүз—аткан ук.*
Мәкаль

**Аткан ук бит тиеш тияргә дә,**
**Монсы, белмим, кая төбәлгән:**
**Ун укыдым—җанны чеметтерми—**
**Ни әйтергә шагыйрь теләгән?**

## Ялгышканбыз бугай ла

**Булды дәвер, замананың**
**Күз өстендә каш идек.**
**Тик шунсы җәл: кәгазь корты—**
**Ахмакларга баш идек.**
**Алар әйтте, без үтәдек,**
**Уйланмый бирдек әмер.**
**Шуны күргән чордашлардан**
**Оялып яшим хәзер.**

## Тигезлек булса гына

*Как нам обустроить Россию?!*
А. И. Солженицын

**Рәсәйдә тәртип урнашыр ул**
**«Өлкән абзый» чирдән котылса:**
**«Нам» дигәндә, түгел бирәү генә,**
**Һәр милләт тә күздә тотылса!**

## Җир һәм кеше

Җансыз гәүдәне дә, тересен дә
Җир күтәрә! Арган, туйгандыр.
Кайсы авыр–җиңел икәнлеген
Үзе генә белә торгандыр...

## Корткыч канун

Өчле–тугызлы, ди, татар
Акылга таман затын,
Никтер шуны хәтерләтә
Өч йөз тугызлы закон...

## Сүзләр кытлыгы

—Язмыш, ялгыш, сагыш, табыш...
Фикер кибә, ютәллим.
Бездә шигырь шул рифмадан
Ерак китмәс микәнни?!.

## Хәтергә ышансаң...

Оятымны тәмам югалттыммы?—
Кайнап чыга ачу, котырам:
Күзләреңнең төсен, вәйт бу картлык,
Искә төшералмый утырам.
Чәчләреңнең исен тоемлыйм бит,
Табып булмый андый хушбуйны.
Яшьлек суты тамган эликсирны
Онытырга Күкләр кушмыйммы?!
Бүген дә бит, сине уйлау белән,
Сихерләнә күңел, җылына.
Хәтер—арба, күзләр төшеп калган...
Чәчең исе сеңгән—җаныма!

## Ник кирәк чагыштыру

Авыл халкы ялкау диләр.
Ялган сүз бу—уйдырма!
Калаларны, салаларны
Алайса кем туйдыра?
Авыл халкы эчә, диләр,
Шәһәр дә шәп чөмерә.
Урамнар киң, якты булгач
Авылныкы күренә.
Ике як та кимен куймый,
Чагыштырсаң әгәр дә
Аерма тик шунда гына:
Сөйләнүче... шәһәрдә.

## Оттырмадым

**Үпкәләсәм, минем хакта**
**Бүген ни сөйләр идең?**
**Капка төбегезгә җиткәч:**
**—Кит инде, җүләр,—дидең.**
**Китмәдем шул... үҗәтләнеп,**
**Кочакка җыеп алдым.**
**Җүләр булсам—китәр идем,**
**Акыллы булгач—калдым!**
**...Һәм ялгышмадым...**

## Елаучылар да бар

*Кешелек дөньясы үзенең үткәне*
*белән көлә-көлә аерылыша.*

Б. Белинский

**Татар балалары киресенчә!**
**/Белмим, нәрсә өмет итәләр?/**
**Үткәннәре—туган авылларын**
**Елый-елый ташлап китәләр...**

***

**Яшьлек белән картлык—антиподлар,**
**Сәбәпләре тормый холыктан:**
**Мин чирканам елтыр шәрәлектән,**
**Яшьләр көлә минем толыптан...**

## Аңлап булмый

*Урыс баеса—чиркәү сала.*
*Татар баеса—хатын ала.*

Әйтем

**Алса алсын—саваплы эш—**
**Туздырсын бар акчасын,**
**Ә нигә соң, баю белән,**
**Оныта татарчасын?!**

## Имеш-мимеш

**Рәсәйнең артта калуына**
**Сәбәпне гел табып торалар:**
**Элек тоткан «татар эгосы»,**
**Бүген, имеш, яһүд «кодалар»...**



Рөстәм Галиуллин

# ӨЧ ХИКӘЯ

## Ата һәм ул

Кар ишеп ява. Иртә таңнан котырына башлаган буран, караңгы төшүгә карамастан, һич кенә дә тынычланырга уйламый. Житмәсә, суытканнан-суыта бара. Башына куян бүреген батырып кигән, калын бишмәте аша бөкресе беленеп торган, аягындагы «чүчинкә»сен авырдан сөйрәбрәк атлаган Галим карт урыс капкасын, инде шактый өелергә өлгергән кар көртеннән арындырып, жырлатып ачты да, тыгызланып, катылана башлаган карны усал шыгырдатып, урамга чыкты.

Авыл урамында берниндн хәрәкәт сизелми, гүя жиһанда бары нишләгәнен белми уйнаклаган, бәргәләнгән кар бөртекләре генә тереклек итә. Еракта, урамның иң очындагы бердәнбер баганадагы ут та шулкадәр тоник ки, Галим карт аны пәрәвез жепселләредәй бөтеркәләнгән кар бөртекләре аша көч-хәл белән шәйли алды.

—Ярый әле авылга керә торган юл буендагы багана яктырта икән,—дип куйды ул.

Йөзен рәхимсез камчылаган вак һәм житез кар бөртекләреннән кул аркасы белән ышыкланган килеш, шул тарафны беркавым күзәтеп торды да өйгә таба атлады.

—Болай буранлап торса, иртәгә бөтенләй үк күмелеп калуы бар,—дип, үзалдына сөйләнә-сөйләнә, капкасын төбенә кадәр ачык калдырды. Шуны гына көткәндәй, урамда арлы-бирле сугылып йөргән кар бөртекләре ургылып Галимнең ишегалдына үтеп керде дә, туфрак тузанын «биетә» торган «пәри туе» сыман зыр-зыр әйләнгәләргә тотындылар һәм чолан ишегенең тоткасын тартканда, каһкаһәле көлгәндәй, аның йөзен камчыларга өлгерделәр.

---

Рөстәм ГАЛИУЛЛИН (1987)—*язучы; «Гипнозчы малай» исемле китап авторы. Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы. Казанда яши.*

***

—Күренмиме?—Зәкия карчык бу сорауны бүген әллә ничәнче тапкыр кабатлады инде.

—Юк шул,—диде Галим карт ишетелер-ишетелмәс кенә. Ул үзен нигәдер гаепле тойды.

Зәкия карчык, караватының тутыккан тимер пружиналарын шыгырдатып, икенче ягына әйләнеп ятты.

—Шалтыратырыең...—диде Галим кыяр-кыймас кына.

—Әйтеп торам лабаса алмый дип. Син урамда чакта да әллә ничә җыйдым. Телефондагы маржа үзенчә такылдап тик тора.

Аларга кесә телефонын уллары Гомәр биргән иде. Авылга кунакка кайткач калдырды ул аны.

—Мин бүген Казанда, иртәгә—Мәскәүдә. Эшем шундый. Кесә телефоны аша хәбәрләшеп тормасак, тәмам югалтырсыз,—диде.

Галим белән Зәкия, калын кысалы күзлекләрен киеп, малайларының ян-ягына утырдылар да, җитди кыяфәт чыгарып, шул «тартма»ның кайчан телефон рәсеме уелган яшел төймәсенә, кайчан кызылына басарга кирәклеген өйрәнделәр. Тырышлыклары бушка китмәде: шул телефон аша алар атнасына бер тапкыр булса да газиз улларының тавышын ишетә башладылар. Зәкия карчык әйтмешли, бу уенчык, карт белән карчыкның балалары кебек булды. Алар аны инде төсе уңган, ишекләре асылынган шкафларының иң түренә—яшь вакытларында икесе бергә төшкән кадерле фотолары торган урында гына тоттылар. Зәкия кибет тирәсендә йөреп кайтса да, Галим лапас тирәсендә әйләнеп керсә дә, өй бусагасын атлап кергәч әйтелгән сүзләре бер булды:

—Телефон шалтырамадымы?

Соңгы тапкыр Гомәр белән атна-ун көн чамасы элек сөйләшкәннәр иде.

—Авылны сагындым. Сезне дә бик күрәсем килә. Яңа ел кичендә кайтам, көтегез,—диде уллары.

Моңарчы телефон аларга тугрылыклы хезмәт итте. Бүген генә менә, иң кирәкле вакытта һич тә элемтәгә кереп булмый үзе белән.

Галим, аптыраганнан гына, телевизорын кабызып җибәрде.

—Акыртмасаң ие шуны! Тавышы башка каба, сүндер!—дип мыгырданды карчыгы.

Һичнинди уйсыз бушлыкка карап утыра торгач, Галим бүген генә дә кат-кат укылган, инде җөмләләре ятланып беткән район гәҗитен янә кулына алды.

—Шыгырдатмасаң ие шуны!—дип кычкырып җибәрде бу юлы Зәкия карчык, башын мендәрдән калкытып.

«Һай, усал да соң син бүген, карчык»,—дип уйлады эченнән генә Галим.

Хәер, Зәкия элек тә юашлардан түгел иде. Тик картая барган саен, аның холкы да кырысланганнан-кырыслана бара шикелле. Әле Галим ир уртасы чагында, тавышын күтәреп җикеренеп алгалаганда, Зәкиянең күзенә аз булса да курку йөгерә, зәһәре дә басыла төшә торган иде. Гомәрне ничек тынлатырга белмәгәндә дә: «Әтиең ачулана»,—дип, шелтәләп алгалый иде. Гомәр үсеп җитеп, авылдан чыгып китүгә, йортка Зәкия тулы хуҗа булды да куйды. Күршедәге җор телле Җәвит абзый, пенсиягә чыгып, «картлач» дигән исемгә рәсми төстә лаек булгач:

—Галим, без, ирләр, балаларны үстергәндә, җегәрле чакта гына дилбегәне үзебезчә уйната алабыз икән. Аркаңа бөкре чыккач, кияү-киленнәр пәйда булгач, фәрманны карчыклар бирә башлый икән,—дигән иде—сүзләре раска

чыкты. Өйдә икәүдән-икәү генә торып калгач, Зәкия карчык кирәксә-кирәкмәсә дә пырларга өйрәнде, Галимнән гаеп табарга гына торды. Кая ул элеккечә: «Ашың тозсызрак булган, чәең артык кайнар»,—дип җинелчә генә төрттереп алулар? Алла сакласын, хәзер тузынып ташлый, гомер ишетмәгәненне ишеттерә.

Җәвит абзыйны бик хөрмәт итсә дә, аның белән бер тапкыр сүзгә килгәннән соң, һаман кичерә алмый Галим. Бервакыт аларның тавыклары Җәвит абзыйлар әтәченә ияләшеп, йомыркаларын күршедә сала башлады һәм ике арада низаг килеп чыкты. Галим һич тә вакланырга теләмәгән иде. Бары Зәкиянең сүзен тыңлап кына, Җәвит абзыйга шул йомыркалар хакында сүз катты. Сүз арты сүз китеп, күршесе аның йөрәгенә мәңге төзәлмәслек яра салды:

—Сиңа тавык тикшереп йөргәнче Зәкияңне карарга иде. Гомәреңне үз балаң дип беләсеңме әллә? Суйган да каплаган зимагур Хәйдәр бит! Алма агачыннан ерак тәгәрәми, ди. Хәйдәрне атасы анасына калдырып киткән булса, ул да үз баласын бар дип тә белми. Гомәр дә нәсел гадәтен ташламый. Әнә ничә ел инде әле тегендә, әле монда бәргәләнеп йөри...

Атна буе Галим беркем белән сөйләшмәде. Зәкия карчык тәмам аптырашка төшеп, ни уйларга белмәде: «Әллә алышындымы карт?».

Көннәр буе лапаста тулганган Галим колагыннан исә Җәвит абзый сүзләре китмәде: «Зимагур Хәйдәр малае!». Галим үсмер чагында да, егет булып җиткәч тә кызлар күз уңында булмады. Эштән башканы белмәгән, яше утызның теге ягына чыккан Галим сазаган кыз исеме ябышкан Зәкиягә әнисе димләгәнгә генә өйләнде. Дөрес, ул чакта авылда, Зәкия Хәйдәрне көтә, зимагур гына аны алып китүне сузып йөри, дигән сүзләр таралган иде. Үзе дә бозау кебек юаш ир белән гомер кичергән әнисе гайбәтләрне колагына алмады—малае белән Зәкияне кавыштыруга иреште.

Коры иде Зәкия. Аннан битәр Галим хатынын сөеп кинәндермәде. Әллә шуңа Зәкия Гомәрне тапканнан соң, башка бала алып кайта алмадымы, әллә теләмәдеме? Галим дә мәсьәләне кабыргасы белән куймады. Гомәр гаиләдә берДәнбер бала булып үсте.

—Ник әле мин тәрбияләп үстергән малай зимагур Хәйдәрнеке булсын ди?—Галим йодрыкларын йомарлады. —Шөкер, Зәкия тугрылыклы хатын булды, кеше телендә ул-бу ишетелмәде.

Мондый уйлар өермәсенең ахыры нәрсә белән тәмамланган булыр иде, билгесез. Шул атна ахырында Гомәр авылга кайтты. Аның уртачадан калкурак какча гәүдәсенә, ике колагы тырпаеп торган озынча башына, ике калын кашы астына яшеренгән яшькелт күзләренә, әллә каян балкып торган ике эре куян тешенә сынап карап, ул малаенда үзенең егет чагын эзләде. Капкадан керә-керешкә Гомәр, елмаеп, аңа ике кулын сузып:

—Исәнме, әти!—дигәч, аны хәсрәткә салган уйлары таралды да төште...

Шулай да Хәйдәр озак еллар чит җирләрдә яшәп, картлык көнендә авылга кайтып егылгач, Җәвит абзыйның сүзләре хәтеренә килеп, тагын бер үртәлгән иде ул. Урамда Хәйдәрне очраткач та, Гомәрне күз алдына бастырып, охшаш якларын эзләп, җанын телгәләде. Әнә зимагур Хәйдәр урам буйлап килә. Элек ул кордашларыннан бер башка озын булып аерылып тора иде, хәзер, әнә, шактый ук чүккән. Башын да элеккечә, менә мин кем, дип артка чөеп йөрми икән, карашын җиргә төбәгән. Көмеш йөгергән чәчләре әле куелыгын югалтмаган, чуалып-тузгып, тәртипсез булып маңгаена сибелгәннәр. Ябык иңсәләре авыр йөк күтәргәндәй салынып төшкән, шуңа да ул бөкресе чыккан бер гарипне хәтерләтә. Йөзен тирән эзле җыерчыклар сырып алган, чал кергән мыеклары нәүмиз генә аска караган... Юк, бу һич

тә анын янып торган малаена охшамаган! Көннәр үткән саен үзен җинә барып, Гомәрнең үзенеке икәнлегенә инанып, тынычланып калды. Хәзер зимагур Хәйдәр кызганыч бер бәндә иде анын өчен. Бичара, шәһәр арты шәһәр алыштырып та әллә ни мантымаган икән. Беркөнне кибет янында ирләргә зарланып торганын үзе ишетте:

—Ярый әле минем кан особый. Сирәк кешедә була торган группа. Акча бөтенләй калмагач, шуны больницага биреп, акча эшләштергәлим...

—Сиңа әйтәм, әй, карт дим, капкага орындылар бугай...—диде Зәкия карчык, ике кат салынган мендәрдән башын күтәрә төшеп.

Галим карт күлмәкчән генә ишеккә ташланды.

—Җил кага ла,—диде ул, әйләнеп кергәч.

Карчыгына кызганулы караш ташлады, һай, кинәт кенә йөрәге тотты шул үзен. Гомәрнең кайтуын көтеп, артык җилләнеп йөрүе ярамадымы, әллә буран башлангач, кан басымы кисәк күтәрелдеме—аңламассын. Иртәдән бирле урын өстендә ята.

—Гомәр кайтты бугай,—дип, кабат калкынды Зәкия карчык.

Чыннан да, ишек дөбердәткән тавыш ишетелде. Зәкия—каян көч тапкандыр?—торып утырды да яулыгын рәтләргә кереште. Кагучы кеше—күрше Җәвит абзый малае—Мансур иде.

—Галим абзый, Гомәр машинасы белән ауган бит,—диде ул, Зәкия карчык ишетә күрмәсен дип, салкыннан туңган иреннәре арасыннан сүзләрен кысып чыгарды.

—Һай, балакаем, исәнме ул?—Каян ишеткән диген, Зәкия карчык ишек катына килеп басты.

—Исәнен исән. Хәле бераз авыррак. Берничә тапкыр әйләнеп, ахырдан баганага сыланган. Каны да шактый аккан...

—Кайда ул?—диде Галим карт, аны бүлдереп.

—Бальниста. Мин Казаннан кайтып килә идем, карасам—юл кырыенда машиналар өелешкән. Гомәрне шунда танып алдым. Алып киткәннәрен үзем күрдем...

—Һай, балакаем, Гомәрем!..—Зәкия карчык илереп елый башлады.

—Анын хәле бик авыр бугай, Галим абзый. Әйдә, бальниска барыйк. Мин машина белән.

Галим карт, ярсулы тизлек белән чөйдәге шактый тузган бишмәтен җилкәсенә элде, киез итекләрен киде дә, бүреген кулына тотып, Мансурга иярде.

—Син кая? Мин дә!—Зәкиянең кабалана-кабалана ишектән чыгып килүен күреп, Галим карт кире борылды.

—Галим абзый, соңга калмагаек,—дип кычкырды Мансур.

—Хәзер, хәзер. Карчык, син тынычлан, чәеңне әзерләп безне көтеп тор. Гомәр белән кайтып та җитәрбез,—дип сөйләнде ул һәм ачык ишек аша урамга атылды.

Урамны кар баскан. Мансур машинасын авыл башында калдырган икән. Шунда кадәр ничек атлаганын, хастаханәгә кайчан килеп җиткәнне Галим карт хәтерләми. Юл буе кайсыдыр явызы зур, алагаем тимер торба белән башына сугып баргандай булды. Шул «даңк-доңк» килгән тавыш эчендә: «Ни өчен? Ник? Улым, Гомәр!»—дигән сүзләр бәргәләнде...

***

...Хастаханә ишеген кайчан ачып керде алар, сакта торган каравылчы аша ничек Гомәр яткан реанимация палатасына үтеп керә алдылар—үзләре дә аңышмый калдылар. Мансур, Галим карт һәм аларны туктатырга тырышкан каравылчыны палата ишеге төбендә күреп, дежур табиб—ак халатлы, бер

як бите буйлап озын гына җөй сузылган урта яшьләрдәге ир һәм шулай ук ак киемле шәфкать туташы бермәлгә югалып калдылар.

—Чү, тынычланыгыз, бар да яхшы,—диде кизү табиб.—Хәзергә чыгып торыгыз, комачаулыйсыз!

Шәфкать туташы Галим картның кулларыннан алып, Мансур җилкәсеннән тотып, сак кына ишеккә таба атладылар.

—Исәнме ул?!—дип сыкранды Галим карт.

—Тынычланыгыз,—дип табиб сүзен кабатлады яшь кыз—шәфкать туташы.

—Улым, Гомәр!..

—Тынычланыгыз, дим. Коридорда көтегез!

Озын, тар коридордагы урындыкка чыгып утыргач та, Галим карт тынычлана алмады, аңа һава җитмәде, йөрәге какты, башы әйләнде.

—Ул күп кан югалткан. Без аңа резервтагы канны җибәрдек, яраларын бәйләдек...

—Исән калачакмы?—дип бүлдерде ул шәфкать туташын.

—Әлбәттә,—диде кыз.—Ул вакыт-вакыт аңына килеп ала. Акыллы егет икән, күзен ачкан арада үзенең кан төркемен әйтеп өлгерде. Улыгызда сирәк очрый торган кан—дүртенче төркем. Ярый әле хастаханәдә кан бар. Өстәвенә шул төркемдәге донорларны алырга машина җибәрдек, хәзер алар да килеп җитәр.

—Әйдәгез, канны миннән алыгыз!—диде Галим карт.

—Сезнең тәгаен дүртенче төркемме?

—Шулайдыр. Мин аның әтисе бит! Әйдәгез...

—Тынычланыгыз! Донорлар килеп җитә дидем бит.

—Мин аның әтисе, кан бер!...

—Туктагыз, зинһар...Алай гына түгел ул, абый, ата-ана белән баланың кан төркеме төрлечә дә булырга мөмкин...

—Галим абзый, тынычлан,—дип сүзгә кушылды Мансур да.

—Миннән алыгыз!—дип үз сүзен тәкърарлады Галим карт.—Мин аның әтисе!

—Аның умыртка сөягенә һәм эчке әгъзаларына да зарар килгән. Хәзер баш табиб белән хирург та килеп җитәчәк,—дип пышылдады кыз Мансурның колагына.

—Нишләп сез миннән кан алмыйсыз?—дип сикереп торды миңгерәүләнгән Галим карт.

—Булды, Галим абзый, тынычлан,—дип, Мансур аны кире урынына утыртты.

Шәфкать туташы палатага кереп китте.

—Улым, Гомәр...—дип ыңгырашты Галим карт.

Шулчак коридорга шаулап бер төркем килеп керде. Алар арасында зимагур Хәйдәр дә бар иде. Килә-килешкә өс киемнәрен коридордагы урындыкка селтәп атып, күлмәк җиңнәрен терсәккә кадәр күтәрделәр.

—Сез менә монда кирәгез,—дип, ак халатлы ханым зимагур Хәйдәрне Гомәр яткан палатага кертеп җибәрде.

Галим карт Мансурның кулыннан ычкынып, ук кебек ишеккә ташланды.

—Менә монда ятыгыз,—дип, кизү табиб Хәйдәргә Гомәр караваты янәшәсендә хәзерләнгән урынны күрсәтте. Күзләрен палатаның ак түшәменә баккан килеш тын калган Хәйдәр тирәсендә табиб белән шәфкать туташы мәш килә башлады. Шулчак Гомәр авыр ыңгырашып куйды.

—Улым!—диде Галим карт, аңа атылып.

—Тынычланыгыз! Дәшмәгез!—диде табиб усал гына.

—Әти...Ә—ти...

—Гомәр!

—Ә...ти...и,—соңгы көченә бер талпынды да Гомәр тынып калды. Авыраеп калган башы акрын гына Хәйдәр яткан якка салынып төште.

—Улым!—дип ыңгырашты Галим карт.

Куркып калган Хәйдәр күзен әле табибка, әле Галимгә, әле кызга йөгертте. Шәфкать туташы тиз генә исен җыеп, Хәйдәр беләгенә шприцны кертә башлады.

Палатада тынлык урнашты. Бары Галим генә мизгел эчендә тараеп, кечерәеп калган җилкәсен дерелдәтеп, бирчәйгән, яргаланган, сөякчел кулларын калтыратып, эзләре тагын да тирәнәеп киткән җыерчыкларын, кытыршы ияге һәм яңакларындагы ак төкләр арасына тәгәрәгән эре яшь бөртеген күрсәтмәскә тырышып, тавышсыз гына сулкылдый иде. Иреннәре исә еракта‌н, әллә кайдан ишетелгән кебек иңрәүле авазларны пышылдады:

—У—л—ы—м, у...л...ы...м...

## Син елама, абый!

Җил, Казанның тар урамнарыннан йөгереп үтә дә, бөтерелеп-бөтерелеп, таш диварлар арасыннан ишегалларына кереп югала. Усал җил артыннан ияреп барырга өлгерә алмагангамы, әллә шулай тиеш булгангамы—бары чүп-чар өеме генә сибелеп кала. Кайчакларда җил шулкадәр тыныч, гүя ул шәһәрнең һәр баганасын, диварын үзенчә сыйпап уза. Талгын гына искән җил назыннан иркәләнәсе, җылысын тоясы килә...

Илһам, иркә җилгә яңакларын куйган килеш, рәхәтлектән күзен йомды. Күк йөзенең иң аскы катында иренеп кенә шуышкан соры болытлар арасыннан чагылган кояш нурлары керфекләр, күз кабагы аша үтеп кереп, йокымсырап барган Илһам күзалдында төрле төсләрдә уйнаклады, ниндидер шәүләгә әверелеп биеште. Берзаман алар төсләрен үзгәртә, әле сары, әле кызгылт божрага әйләнәләр дә, күнелнең нечкә бер җепселен кытыклап куялар. Ирексездән елмаясы, иң яшерен, серле авазлар чыгарып, рәхәтлектән кычкырып җибәрәсе килә... Илһам ойый баруын үзе дә сизде. Тик төш белән өнне аера алмый интекте. Төш дисәң, барысы да чынбарлыктагы кебек: әнә Илһам, әнә хатыны Гүзәлия, әнә яңа тәпи баскан кызлары Ләйсән. Өн дисәң, нигә соң аларны Илһам читтән, нәкъ телевизор экраныннан караган кебек күзәтә. Барысы да буталды...

—Әтием тайткан, миңа тәмле әйбелләл алып тайткан!—Ишек бусагасыннан эчкә узуга, алпан-тилпән атлап, табигый шатлыкны күзләрендәге көләчлеккә, тавышындагы ихласлыкка күчереп, нәни кызы Ләйсән аның кочагына атылды.

—Нәни кошчыгымдыр ла үземнең!—дип күкрәгенә кысып күтәрде аны әтисе. Бала исе! Бер гөнаһсыз, чип-чиста күнелле бала исе! Илһам башы әйләнгәнен сизде. Рәхәт!

Ләйсәнне идәнгә бастыруга, кесәсеннән алып тәмле конфетын сузды. Кыз, ялтыравыклы кәгазьгә төрелгән конфетка үрелгәндә, күкрәгеннән табигый, аңлатып та, әйтеп тә, кабатлап та булмый торган сөенечле аваз чыгарды. Конфетны нәни учларына кысуга, шатлану хисен тыя алмыйча, өй буйлап чабып китте.

—Әтигә рәхмәтне кем әйтә?—Кухня ишегенә сөялеп торган хатыны Гүзәлияне абайламаган икән Илһам.

—Исәнме, әнисе,—диде Илһам, назлы итеп.

—Ләкмәт, әтием!—Кай арада янадан йөгереп килеп, Ләйсән янә әтисенең

кочагына атылды.

—Дәү үс, кызым!

—Ялал, әтием!

—Иркәләп бетерәсең инде шуны,—дип куйды Гүзәлия. Шулай да хатынның тавышында бернинди шелтә-фәлән сизелмәде.—Аннары тынлатып булмый үзен!

—Ярар ла, без дә иркәләмәсәк, кем яратыр Ләйсәнебезне?—диде Илһам.

—Чамасын белергә кирәк!—дип сүзләште Гүзәлия.

—Кара әле, әнисе, мин бит сиңа да бүләк алып кайттым. —Илһам зур кара портфеле артына яшереп куелган ак розалар бәйләме белән тортны Гүзәлиягә сузды. Шушы мизгелне генә көткән сыман хатынның иреннәренә гүя кояш кунды, күзләрендә кабынган мәхәббәтле карашын иренә кызганмый бүләк иткәннән соң, ул дәртле сулышын тыя алмый, Илһамның күкрәгенә килеп сыенды.

—Рәхмәт, кадерлем! Рәхмәт...

Бер мәлгә бернинди уйларсыз рәхәт тынлыкка чумып торганнан соң, Илһам хатынының җилкәләреннән тотып үзеннән аерды.

—Булды, әнисе, кая, мине өйгә дә кертмисез мәллә? Кайчаннан бирле ишек катында торам.

Ялкынлы хисләр өермәсендә буталып калган Гүзәлия бераз айнып, иренең озын кара плащын салдырырга кереште. Кинәт ул гаҗәпләнү-шатлык тоташ тавыш белән кычкырып җибәрде:

—Бәрәч, монда бит бер йолдыз арткан!

Илһам хатынының күзендә чагылган кызыксынуны күреп, башын артка ташлап, көлеп җибәрде.

—Әллә тагын күтәрделәрме?—дип сорады хатын.

—Әйе! Бүген шатлыклы көн: Сабиров Илһам милиция капитаны булды!—диде Илһам ирләрчә нык тавыш белән.

—Урра!—дип кул чәбәкләде Гүзәлия.

—Улла!— Авыз кырыйлары конфетның шоколадыннан буялып беткән Ләйсән дә әнисенә кушылды.

—Мин өйгә тиз генә кереп чыгыйм дигән идем. Дуслар белән күл буена төшеп, мәҗлес оештырабыз бүген.—Хатынының карашында пәйда булган рәнҗү төсмерләре күренүгә, тавышын йомшарта төшеп дәвам итте.—Шунсыз булмый, Гүзәлия. Житәкчеләр дә киләчәк. Әле минем алга таба да үсәсе бар. Сонга калмам, озакка сузмый тәмамларбыз да кайтып житәрмен. Иртәгә өчәүләшеп бәйрәм итәрбез.

—Ниләр алып барасың күл янына? Әзерләп бирим...—Тавышына боз салкыннары йөгертеп, Гүзәлия иренең кочагыннан шуып чыкты.

Илһам җыенып беткәч тә, чыгып китәргә дип ишек тоткасын тотканда да, хатын күңеле йомшармады. Ирен ул төксе генә озатты. Бары Ләйсән генә аны җибәрми интектерде:

—Титмә, әти. Титмә... Минем белән тал!—дип үрсәләнде бала.

***

... Түгәрәк күл буе , кичке эңгер-меңгер якынлашканга, җәйге челләдән котылу чарасын эзләп килүчеләрдән арынган. Бары күлдән ерак түгел, каен һәм наратлар хасил иткән агачлыктан гына учак ялкыны дөрләгәне күренә. Җәйнең гаҗәп, илаһилыгын тоеп бетереп булмастай вакыты: көндезге шау-шу тынып калган, көне буе кеше күплектән төбе болганган күл, тынычланып, болытлар артындагы серле билгесезлеккә югалып барган кояшның нурлары белән кызарып, сурәтләп бетереп булмастай гүзәллек хасил итә; шулкадәр

талгын, ихлас искән җилдәнме, әллә үзарамы—каенның ямь-яшел, яшәү төсе, яшәү көче биргән вак яфраклары лепердәшеп ала; төз наратлардан үпкәне исертердәй хуш ис бөркелә; эссе кояш яктысында яклау тапкан канәчкеч зәхмәт кигәвеннәр күздән югалган, төн сихрилегән, төн матурлыгын урлаучы черки-мазар, әлеге тынлыкны бозарга оялуданмы, әлегә күренми; кичке концертка әзерләнүче бакаларның да тавышы ишетелми.

—Их, ә бит тормыш нинди матур!—Машинасыннан сикереп төшеп, бермәлгә табигатьтән әсәрләнеп калган Илһам кулларын җәеп җибәрде.

—Син, дускай, «булып» та килдең мәллә?—Каршына килеп баскан дусты Әскәргә Илһам, беренче кат күргәндәй, сагаюлы караш ташлады:

—Юк, аек мин. Менә күл буе матурлыгы белән хозурланып торам.

—Бүген барысы да синеке, дускай! Машина белән килмә дип әйтсәм дә тыңламадың тәки!

—Мин төнгә калмыйм, Әскәр. Хатынга вәгъдә бирдем.

—Шушындый шатлыклы көнеңне дә истә калырлык итеп үткәрмәгәч! Булмаганны! Әйдә, анда егетләр җыелып бетте. Тырыштык, дускай: табын да, шашлык та әзер. Хәзер полковник Сибгатов килеп җитәргә тиеш.

Илһам әрәмәлеккә таба атлаган дусты артыннан иярде. Тик нигәдер аны күл буе, Түгәрәк күл үзенә тарта, ымсындыра иде. Дөрләп янган учак янында биш-алты ир йөренә. Болар барысы да Илһамның дуслары, ингә-иң куеп эшләгән хезмәттәшләре. Берәр сылтау табылса, аларда шулай бәйрәм итү күптән гадәткә керде.

—У-у, иптәш капитан, төкле аягың белән! Рәхим ит!—дип каршылады аны ирләр төркеме.

—Нишлибез? Полковник Сибгатовны көтикме, әллә тамакларны чылата торыйкмы?—диде Әскәр.

—Башлыйбыз!—диде беравыздан ирләр.

—Туктагыз әле, дуслар! Миндә бер тәкъдим бар,—дип бүлдерде аларны Илһам. —Әйдәгез, иң әүвәл Түгәрәк күлдә коенып, тәннәрне сафландырып чыгыйк.

—Киттек!—диделәр беравыздан.

Түгәрәк күлнең ярлары шактый биек. «Бәлки, элек су монда хәтле күтәрелгән булгандыр, хәзер исә кимегәндер»,—дип уйлап куйды Илһам.

—Кем иң соңыннан чума, шул Түгәрәк күлне аркылыга-буйга йөзеп чыга,—дип кычкырды Әскәр. Гади генә сүзләрнең ирләргә тәэсире зур булды, һәрберсе күлмәк-чалбарларын тиз-тиз генә сала башлады. Илһамны элек-электән «җилле егет» диләр иде. Аның өлгерлегенә бүген дә тиңнәр булмады. Суга иң беренче булып ул чумды. Кинәт... «Дыңк» иткән ниндидер тавыш ишетелде һәм арка турысына кемдер тимер таяк белән суккандай тоелды. Башы күлнең кеше таптаудан шактый тыгызланган төбенә килеп төртелгәнен сизде Илһам...

***

... Йокымсырап, ниндидер бер сәер халәт кичереп утырган Илһам әле яңа гына үзен иркәләгән җылы җилнең салкыная төшүен тойды. Ул калтыранып, өшеп куйды. Тик юкка: ул төш белән өнне аера алмый өзгәләнде.

... Иптәшләре су төбеннән тартып чыгарганда, Илһам аңын җуйган иде. Гаҗизләнеп калган милиционерлар бер-берсенә карашты.

—«Ашыгыч ярдәм» чакырыйк!—Әскәр башына килгән беренче уен кычкырып әйтте, тораташтай калган дусларга шул сүз җан керткәндәй булды. Әскәр кесә телефонына дип әрәмәлеккә чапты да тиз арада әйләнеп тә килде:

—Шалтыраттым, хәзер килеп җитәрләр! Сулыймы ул?— Илһамга гүя үзләренең җылысын биреп, күзен ачтырырга теләгәндәй, чарасыз кулларын тоткалаган, башын боргалаган бер ир күзен читкә борды.

—Юк бугай...

—Хатынына шалтыратыйкмы?—диде икенчесе, иелгән башын күтәрми генә.

—Табибларны көтик инде,—дип җавап кайтарды кайсыдыр җансыз тавыш белән.

Бераз соңлаган полковник Сибгатов, килеп җитү белән, хәлне аңлап, үзенең таныш табибларына шалтыратты. Җаннарны өшетерлек аваз салып килгән «Ашыгыч ярдәм» озак көттермәде. Җилкәләрен салындырган, таралып төшкән капчыктай ирләрне табиблар Илһам яныннан этkәли-төрткәли куып җибәрде.

—Мин гаепле, егетләр,—Әскәр никадәр тыелырга тырышса да—түзмәде. Ирнең бите буйлап эре күз яше тамчылары тәгәрәде.

—Син нәрсә инде, Әскәр...

—Алай буласын кем уйлаган инде...

—Син гаепле түгел...—диеште ирләр.

Бер-берсенең күзенә күтәрелеп карарга батырчылык итмәгән егетләрне полковникның кырыс тавышы уятып җибәрде:

—Илһам исән! Аны ашыгыч операциягә, Казанга алып китәләр. Тик... Тик егетнең умырткасы сынган. Ә хәзер барыбыз да таралышыйк. Хатынына үзем хәбәр итәрмен. Син, Әскәр, Гүзәлияне хастаханәгә алып барырсың.

Сиренасын кычкыртып, шәһәр эченә кереп югалган машина артыннан калганнары да иярде. Әле генә уйнаклап, күкләргә үрләп дөрләгән учакның яктысы сүнде. Бары сизелер-сизелмәс таралган төтене генә әрле-бирле тулганган черки халкын үзеннән читкә куа иде...

***

Илһамның хәле беренче ярдәм күрсәткән табиблар фаразлаганнан шактыйга куркынычрак булып чыкты. Умыртка сөяге сыну нәтиҗәсендә, аның кул һәм аяклары бөтенләй хәрәкәтләнүдән туктады. Озак вакытлар аны кома хәленнән чыгара алмый интеккән Казан табиблары үзләренең көчсезлеген таныды:

—Мондый операцияләрне бары Германиядә генә ясату мөмкин. Без хәлебездән килгәнне эшләдек.

Әмма... Гүзәлия көн-төн елады. Реанимация бүлмәсенә кергән саен—ә аны монда бик сирәк уздыралар—ул иренең сулып, кибеп барган гәүдәсен күреп үрсәләнде: «Нигә? Нәрсә өчен? Ник андый кайгылар миңа гына килә?!» Бәхетсез хатынның күз яшьләре түгелеп, күңеле хисләрдән арына барган саен, ниндидер бер халәт кичерә башлады. «Нигә мин гомер буе чирле ир белән яшәргә тиеш соң? Илһам гарипләнгән икән, димәк, Ходай шулай кушкан. Бу хәлнең килеп чыгасы Ходай тарафыннан билгеләнгән булган. Мин баламны андый кимсетүле хәлдә үстерергә тиеш түгел. Димәк?...» Илһам Казан хастаханәсендә соңгы көннәрен үткәргән вакытта, Гүзәлия иренең абыйсы Таһир янына килде. Энесенең фаҗигасен ишеткәннән бирле, төн йокысы качкан Таһир кулыннан килгәннең барын да эшләде: Германиягә бару өчен акча тапты, хастаханә белән килешә алды. Шунысы гаҗәп: байлыгы булмаган, зур кәнәфи биләмәгән ир зур оешмаларга үтеп керә алды. Аны аңладылар, ярдәм иттеләр.

—Таһир абый, мин сезнең белән хушлашырга кердем.—Хастаханәдә реанимация ишеге төбендәге утыргычта уйларына чумган Таһир сискәнеп китте. Каршында озын керфекләрен түбән төшереп басып торган киленнәрен күреп, янә йөрәген кыеп-кыеп утлы пычак кисеп үтте.

—Таһир абый, мин сезнең белән хушлашырга кердем,—дип кабатлады хатын.

Ир сискәнеп китте.

—Хушлашырга? Килен...

—Кирәкми, Таһир абый, мин китәм...

Таһирның күңеле дертләп китте: «Нәрсә, үзенә кул салмакчы буламы Гүзәлия? Ә Ләйсән, күз нурлары?»

—Гүзәлия...

—Тыңлагыз, зинһар, Таһир абый! Мине аңлагыз... Мин көчсез кеше, беләм... Мин Илһамнан аерылам...

... Ул көнне Таһирга көчле уколлар ясап, көч-хәл белән тынычландырдылар. Ул, шулар тәэсирендә ыңгырашып яткан вакытта, шәһәр йортларының берсендә бер хатын, акылдан шашкандай сөйләнеп, өенең астын-өскә китерә иде:

—Менә, кызым, болары синең әтиеңнең киемнәре. Хәзер безгә алар кирәкми инде. Фатирны сатабыз да моннан күченеп китәбез. Син борчылма, кызым, син акыллы, бәхетле булып үсәрсең...

Хатынның миен томалап, Ләйсәннең тавышы ишетелде:

—Ә тая минем әтием?...

***

... Җилне һич чамалап булмый: иркәлиме, камчылыймы ул? Илһам шабыр тиргә батты. Үзенең халәтен аңлый алмау интектерде аны. Ә күзалдында, кинофильмнардагы сыман, бер-бер артлы сурәтләр алышынып тора...

... Илһамның чәрдәкләнгән умырткалыгындагы җепселләр тәмам өзгәләнгән иде. Шулай да Германиядәге операциянең файдасы искитәрлек булды: аякларына җылылык йөгерде. Кул бармаклары селкенә башлады. Әмма өметләнергә иртә әле. Илһам Германиядә генә хушына килде.

—Ләйсән!... Гүзәлия,—дип ыңгырашты ир.

Таһир түзә алмады, энесе караватына башын бәрә-бәрә сулкылдап елады.

Берничә көннән, сөйләшерлек хәлгә килүгә, Илһам:

—Абый, Гүзәлия минем нинди хәлдә икәнлегемне күрдеме?—дип сорады.

—Әйе, Илһам.

—Ул Казанда калдымыни?

—Әйе...

—Ярар, алай яхшырактыр да әле.

Илһам элек-электән нык ихтыярлы иде. Шуңа Таһир аңа булган хәлне яшерми сөйләп бирде. Тик Гүзәлиянең аңардан аерылуы турында гына әйтергә үзендә көч таба алмады ул. Әйтсә, энекәше шул мизгелдә үләр кебек тоелды аңа.

Германиядәге авыр айлар үтеп китте. Илһамны Казанда гариплек тормышы көтә иде. Бер кашык су йоттырганнарын көтеп, тилмереп ятучы инвалид тормышы. Таһирлар өенә кайтып җитүгә, Илһамга бер бүлмәне көйләделәр.

—Нигәдер, Гүзәлия һаман күренми,—диде Илһам.—Аэропортта да каршы алмады.

—Энем,—диде Таһир, хатынын бүлмәдән ым кагып чыгарып җибәргәч.—Гүзәлияне оныт инде син, зинһар.

—Нәрсә?

—Ташлады ул сине...

Илһам шундук күзен йомып, тынсыз калды. Күз алдында кечерәйгән гәүдәнең дерелдәвен күреп, Таһир күз яшьләренә буылды.

—Илһам, ела, зинһар, ела!—диде ул, ялварып.

Илһам күзен ачмады. Аның янында кизү торган Таһир, төн уртасында Илһам тавышын ишетеп, сискәнеп китте.

—Абый, чынлап ташладымы? Их, ә мин аңа ышана идем. Димәк, яратмаган!

Ә Ләйсәнне мин әле күрәчәкмен. Тик хәзер түгел, аякка баскач!

Таһир ни әйтергә дә белмәде.

—Син борчылма, абый! Үткәреп җибәрдем бусын да... Тынычлап чыгып йокла,—диде Илһам.—Нишлисең, язмыштан узмыш юк.

... Таһир эшеннән яллар алып, көне-төне энесе янында булды. Инвалид коляскасы юнәтте, табибларга даими күрсәтеп торды. Алга китеш күренмәсә дә, аны бер нәрсә канатландырды: Илһам сынып төшмәде. Киләчәгенә, үзенең сәламәт тормышына яңадан кайтасына өметләнә, ышана иде ул.

—Абый, мин бүген аягымны сиздем кебек. Кул бармакларымны селкетә ала башладым, ахры,—дип, ул Таһирны да, үзен дә сөендереп торды.

Ләкин савыгу, аякка басу турында уйларга иртә иде әле. Германия табибларына томография сурәтләрен җибәреп торсалар да, алардан сөендерерлек хәбәр килмәде.

Беркөнне Илһам:

—Абый, Казанда авыр хәлләләр, инвалидлар гына яши торган аерым йорт бар икән, шуны белеш әле,—диде.

Каян белгән диген? Таһир ул әйткән адрес буенча барып, әлеге йортны эзләп тапты. Диварлары ак кирпечтән өелгән өч катлы яңа йортны күрү белән, йөрәге сулкылдап куйды. Ишегалдында инвалид коляскасындагы берничә ир-атның ниндидер машина янында кайнашуын күреп, шунда атлады.

—Туган, булыш әле,—диде кайсыдыр.

—Ни булды?—диде Таһир.

—Менә Радик машинадан төшә алмый. Коляскасы монда, күтәреп кенә утыртчы шуны?

Таһир сары «Ока» руле артындагы кечерәк кенә буйлы ирне күреп, ярдәмгә ашыкты. Аны коляскасына утыртуга, алар янында башкача тора алмады. Күзенә килгән яшьләр, тамагына тыгылган төер аны читкә әйдәде.

—Әй, туган, бик зур рәхмәт сиңа!

—Кемне эзләп килдең соң син?—дигән тавышлар да аны туктата алмады. Ир елый иде.

—Елама син, абый!—дип кычкырды коляскасына күчкән Радик.—Без яшибез әле!

Илһамның үгетләүләре күпкә киткәч, Таһир башкача карыша алмады, энекәшен шул йортка урнаштырды. Ләкин ул анда бер генә көн дә бармыйча калмады. Коляскага утырган җиреннән селкенә дә, борыла да алмаган энесен карарга кирәк иде....

***

... Илһам саташты. Ул тирләде-пеште. Тән кайнарлыгын салкынча җил дә баса алмый иде. Ниһаять, күзен ачты. Инвалидлар йортының ишегалдын күреп, өн икәнен аңлады. Шулай да күз кабаклары эленеп, томан пәрдәсенә әйдиләр. Менә ул йортның капкасына таба ике кешенең килгәнен күргәндәй булды. Ана белән кыз. Тукта, берсе Гүзәлия түгелме соң? Икенчесе Ләйсән бит! Кызым! Ул ниндидер төпкелгә очкандай булды. Шунда иренендә тозлы тәм тойды, кемдер аның янагын иркәләп сыйпады. «Гүзәлиянең күз яшьләре, Ләйсәннең нәни куллары,»—дип уйлады ир. Илһам, йөрәгенең шашып-шашып тибүенә тыела алмыйча, күзен ачты...

—Абый?—Илһам сызланып елмайды.—Елама, абый! Бигрәк елак булып чыктың әле син. Кемгә охшагансыңдыр... Әллә җиңги белән сүзгә килдегезме?

—Юк ла,—дип Таһир кулындагы букчага ымлады.—Менә сиңа күчтәнәч җибәрде. Сумса белән чәй эчәбез хәзер.

—Рәхмәт. Яңалыклар юктыр?

Абыйсы аның нинди яңалык көткәнен белә иде, әлбәттә. Тик юк иде, юк иде яңалык.

—Бар!—дип шат тавыш белән кычкырып җибәрде Таһир.—Менә Ләйсән сиңа хат җибәргән.

Ул куен кесәсеннән дәфтәр бите тартып чыгарды.

—Үскән Ләйсәнем,—диде Илһам.

Шакмаклы дәфтәр битенә нәни генә кул рәсеме ясалган иде.

## Хикмәтле туган көн

Миңниса карчык бүген дә, гадәтенчә иртән-иртүк торып, ашыкмыйча, тәмләп чәй эчә башлады. Аның фатиры йортның беренче катында булганга, тәрәзәдән һәммә нәрсә уч төбендәгедәй күренә. Ул шулай өстәл янында озаклап утырып, өе каршында бер-бер артлы тукталыш ясаган трамвайларны сөенеп, куанып каршы ала,тәрәзә пыяласы аша гына танып белгән кешеләрне хәерле теләкләр теләп озатып кала. Инде менә ничә еллар аның тормышы гел бертөсле үтә. Күп еллар элек эшеннән бирелгән кеп-кечкенә фатирында ялгызы гомер кичерде ул. Нишләтәсең, яшьлеге сугыш елларына туры килде. Сөйгәне Газизне кавышканның икенче атнасында ук фронтка озатты. Ул чактагы елап аерылышулар мәңгегә булган икән. Иренең һәлак булуы турында өчпочмаклы хатта хәбәр килгәч, авылда таянычы калмаган Миңниса Казанга—заводка юл тотты.

«И-и, үтә гомерләр...»,—дип көрсенеп куйды ул. Инде урамдагы шау-шу басыла төште, кешеләр ташкыны да кимеде. Миңниса карчык та өстәл янынннан кузгалырга булды. Кинәт ишектәге кыңгырау аваз бирде. « Кем йөри икән иртә баштан? Ә-ә, фатирны бутагандыр...,»—дип сөйләнә-сөйләнә, ишек катына барды ул.

—Миңниса, ач әле! Мин бу—Сәлимә күршең.—Юка такта ишектән ахирәтенең тавышы ишетелде. «Мондый үтә күренмәле ишек Казанда башка юк, синдә генә»,—килгән бере шулай дип көлә аннан. «Минем яшереп саклаган малым юк»,—дип авызларын томалый аларның Миңниса карчык.

Ул ахирәтен аптырабрак каршы алды.

—Ник иртә таңнан килеп җитте бу аяксыз карчык дисеңме?—дип кеткелдәде Сәлимә карчык. —Күршекәем, туган көнең белән котлыйм сине! Исәнлектә-саулыкта яшәүләр насыйп булсын...

Миңниса карчыкның иреннәренә нур кунды. Күңеле тулып, мөлдерәмә яшьләре аша елмаеп җибәрде:

—Һай, Сәлимә ахирәткәй, кайлардан белдең минем бүген туган көн икәнен?

—Белмичә! Оныклар: «Хәтерең—тишек иләк»,- дисәләр дә, үземә кирәклесен истә тотам мин. Әй, Миңниса, сиңа да сиксән сигез тулды бит, ә? Әле кайчан гына урамда очраган ир-егетләрне абындырган чибәр хатын идең. Һай, үтә гомерләр...

—Әйтмә дә,—диде Миңниса карчык.—Ярый әле син бар, Сәлимә. Үзем дә онытып җибәргәнмен.

—Мин дә онытканмын ла! Кичә улым—Илдар иртүк таңнан шалтыратып искә төшерде.

—Мәскәүдәге улыңмы?—Миңниса карчык аптыраулы карашын Сәлимәгә төбәде.

—Шул инде! Сине бигрәк ярата иде бит ул. Әле дә: «Миңниса апаны сагындым, Казанда булсам, туган көне белән иң беренче булып котлар идем»,—ди...

—Һай, рәхмәт төшкере! Кечкенә чагында бик шук, сүз тыңламый торган

малай да иде соң! Нинди чибәр егет—маржага өйләнеп харап булды...

—Искә төшермә инде, күршекәем. Үземнең дә йөрәк яна, үзе дә Казанны сагынам, ди шалтыраткан саен...

—Кайтсын соң?!

—Кая, өйгә сыя торганмыни? Олы малай гаиләсе белән, мин карчык тагын...

—Ярар, Сәлимә, Ходай рәхмәтеннән ташламасын. Әйдә, бүген минем туган көндә бергәләп чәй эчеп алыйк, бәйрәм итик әле!

—Юк-юк,мәшәкатьләнә күрмә берүк. Өйдәгеләр әле генә таралышып бетте. Алар кайтышка ашарга пешереп куясым бар, башка эшләрем дә күп, иртәгә кич белән сугылырмын әле.

—Ярар инде алайса, керүеңә бик зур рәхмәт.— Миңниса карчык күршесен подъездга кадәр чыгып озатты.

Шул арада Миңниса карчыкның күңеле, ниндидер корт-мазар йөргәндәй, тынычсызлана башлады. Соңгы елларда аның туган көненә кунак чакырганы да, үзе белеп килгән кеше дә юк иде. « Менә бит, Сәлимә онытмаган, рәхмәт төшкере!»—дип сөенде ул.

Гадәтенчә, тәрәзә аша урамга күз салган иде: имәнеп китте, нәкъ аның өе турысында кара каурыйлы, соры муенлы берничә чәүкә, чыр-чу килеп, нәрсәдер бүлешә, чукыша иде. Миңниса карчык, аларны куып тарату нияте белән, тиз генә чөйдә торган озын, зәңгәр курткасын киде дә урамга чыгып китте. Берочтан кибеткә дә кереп чыгармын дип, кулына чүпрәк сумкасын да алды.

Урамда көзнең вак , салкын янгыры ява. Хәер, ява дип әйтү дөрес булмас иде. Йөзенә вак инәләр сипкән шикелле тоелды аңа. Миңниса карчык адымнарын кызулатып, үз тәрәзәсенә таба атлады. Чәүкәләрдән җилләр искән иде инде. Карчык җиргә иелеп, нәрсә бүлешкәннәрен белмәкче булса да, берни ачыклый алмады. Чырр! Шунда ул каршыдагы иске—кеше яшәми торган йортның түбәсенә кунаклаган чәүкәләрне күреп алды. «И-и, килбәтсезләр! Шул йортның чормасына оя корганнар икән!». Ул бу кошларны электән үк яратмады. Авылда моржага оя ясап интектерүләре дә бик җиткән. Әле дә, әнә, күзләрен тасрайтып карап торалар. Миңниса карчыкның йөрәгенә шом йөгерде. Кәефе китеп, әкрен генә кибеткә таба атлады.

Ул башка көннәрне озаклап йөреп керә торган иде. Бүген көне дә еламсырап торганга, шуңа өстәп чәүкәләр дә күңеленә корт керткәч, тегесен-бусын, алма, груша кебек җиләк-җимешләрне аз-мазлап алды да, кибеттән туры өенә юнәлде.

Ишекне ачып керүгә, телефонның ярсып-ярсып шалтыравы ишетелде.

—Әлү-ү?—диде ул, гадәтенчә сузып.

—Исәнмесез, Миңниса апа. Мин—Әлфинур...

—Ә-ә!.. Син кайларда йөрисең соң? Югалдың тәмам...

—Әй, Миңниса апа! Югалырсың да монда! Тормыш үзенекен итә—авылга кайтып әнине дә күргән юк хәтта. Аннары... э-э, мин сине туган көнең белән котлыйм, Миңниса апа! Сау-сәламәт яшә...

—Туктале, каян белдең минем бүген туган көнем икәнен?

—Синең яхшылыкларны онытып буламы соң? Соңгы елларда эш тә эш булды, шуңа күрә...

—Әйдә, бүген кунакка кил?

—Бүген үк булмас инде, иртәгә килермен. Ярый, исән-сау тор, Миңниса апа.

—Рәхмәт шалтыратуыңа, сау бул.

Миңниса карчык янгырдан шактый ук чыланган курткасын чөйгә элде. Ашыкмыйча, кибеттән алган ризыкларны өстәлгә бушатты. Җиләк-җимешләрне юып-турагач, тәлинкәләргә тезеп куйды. Үзенең уеннан

Әлфинур китмәде. «Әй-й, өметемне өзгән идем инде. Каян килеп исенә төшерде икән? Күпме яхшылыклар кылдым үзенә: авылдан килгән кызны бушка яшәттем, тәрбияләп тордым. Соңгы биш-алты елда ник бер хәбәре булсын. Телефон аша айга бер шалтыратса да күнелем булыр иде. Юкса якын туганым—мәрхүм энемнең кызы бит. Ярар, хет туган көнемне онытмаган икән,»—дип сөйләнде үзалдына.

Күз аллары бераз караңгылана башлагач—кан басымы хикмәте—бераз ял итим дип, кат-кат матрас түшәлгән биек караватына таба атлаган гына иде, ишектәге кыңгырау төймәсенә бастылар. «Ходаем, кем генә булыр бу? Тагын Сәлимәдер әле...»—Карчык күзчеге булмаган ишегенә колагын куеп, кычкырып сорады:

—Кем бар анда?

—Миңниса апа, бу мин—Халисә, синең ерак туганың...

Халисә ялгызы гына түгел, янында озын гына буйлы малае да бар.

—Нинди җилләр ташлады сезне?—диде ул ишекне ачып, кунакларны эчкә уздыргач.

—Бүген синең туган көнең бит—котларга дип килдек! Бу—минем улым—Илшат,—дип сөйләнә-сөйләнә, Халисә кулындагы бүләген—матур итеп төрелгән ак яулыкны карчыкка тоттырды.

—Һай, рәхмәт төшкере! Бигрәк матур яулык!

—Әйдә, хәзер үк башыңа бәйлик әле! Яраткан сеңлемнең яулыгы дип—салмый йөр.— Халисә Миңниса карчыкның акка кызыл чәчәкләр төшерелгән яулыгын чишеп, яңасын бәйләп тә куйды.

—Абау, әтәтер дә үзең! Элек тә шундый иден—үзгәрмәгәнсең бер дә...

Халисә җавап биреп тормады. Зур ике сумкага ишарәләп:

—Миңниса апа, менә сиңа авыл күчтәнәчләре төяп килдек, әйдә, урнаштырыйк әле,—дия-дия шул арада ит, сөт, каймак ише әйберләрне гөрелдәп эшләп утырган суыткычка тутыра да башлады.

—Бигрәк зурладыгыз бит әле сез. Киләсегезне белсәм, өстәл хәзерләп көтәдер идем...

—Бер дә уңайсызланма, апа. Бергә хәзерлибез дә куябыз аны. Мондый олы бәйрәм көнне кечкенә өстәлдә утыру килешмәс, әйдә, зурысын көйлик әле.—Аннары ул һаман да ишек катында басып торган улына борылды:—Әнә теге—җәелә торган өстәлне бүлмә уртасына урнаштыр!

—Сөбханалла, улың безнең якка тарткан, бик күркәм күренә...—Миңниса карчык өстәлне дөбердәтеп күчергән егетнең җилкәсеннән кагып куйды.

—Йомыкыйрак бераз. Кайчак җитәкләп йөртергә, юл күрсәтергә туры килә.

—Син инде үзең түземсез лә!

Өчәүләшеп чәй эчеп, соңгы яңалыкларны белешкәч, Халисә шундук кузгалырга булды:

—Быел улым институтка укырга керде бит. Кием-салым, азык-төлек ише әйберләр алып килгән идем, шуны минем апаларга илтергә барабыз. Шуңа вакыт тыгызрак әле. Иртәгә дә Казанда булабыз, тагын килеп китсәк, ачуланмассыңмы?

—Нинди ачулану ди ул тагын! Килегез, кил,—диде Миңниса карчык чын күңеленнән.

Халисә белән малае чыгып киткәч, Миңниса карчык өстәл түрендә озак уйланып утырды: « Оныткан иде Халисә. Югыйсә, минем киемнәремне киеп үскән бала иде. Бернинди хәбәре-хаты булмады соңгы елларда».

Өстәлне бераз рәткә китергәч, тәрәзә янындагы артсыз урындыгына утырып, урамга күз салды. Балаларын җитәкләп узган аналарга, оныкларына нидер сөйләп, аңлатып барган әбиләргә гомере буе кызыкты ул. Тик,

нишлисен, язмыштыр, картлыгын ялгыз гына үткәрергә туры килде. Шуңа да ул таныш-белешләренен, ерак кардәшләренең кызлары-улларына еш ярдәм итте. Дөресен әйткәндә, фатирында ялгызы гына яши башлаганына нибары биш-алты ел гына иде. Аңарчы студент, торыр җире булмаганнар—барысы да авыр чакларында яшәп киттеләр. Яшәп киттеләр дә ... оныттылар.

Уйларына чумып утырган Минниса карчык иске, ватылу белмәс телефонына игътибар да итмәде. Берөзлексез шалтырау инде ничәнчедер тапкыр кабаттан башлангач кына ишетте.

—Әлү-ү...

—Минниса апа-җаным, исәнме? Туган көннәрең белән сине, минем яраткан алма апам...

—Рәхмәт, рәхмәт. Кем әле бу?

—Абау, алма апам, әллә танымыйсыңдамы? Сафия бит, синең яраткан сеңлең...

—Ә-ә, исәнме? Син кайлардан?

—Казаннан шалтыратам—быел гына күчендек. Эш-мәшәкать—муеннан. Ин беренче итеп сиңа килермен дигән идем, барып чыкмый әле һаман да...

—Әйдә, бүген кил...

—Әй,алма апам, фатир ремонтлау эшләре, башкасы—туйдырды тәмам. Иртәгә килсәм, өйдә буласыңмы?

—Теләсә кайсы вакытта кил,—диде Минниса карчык.

Трубканы куюга, урамда кич җитеп, караңгы төшкәнен күрде. Озаклап урын җәеп, догаларын укып, йокларга әзерләнде. Башын мендәргә салуга, йокыга киткәнен сизми дә калды.

***

Кичә арылган булгангамы, карчык иртән соңга калып уянды. Шуңа күрә үзенең танышларын озатып калырга, иртәнге трамвайларны сәламләргә өлгермәде. Көн саен бер вакытта уянган карчык, борчылып куйды. Чәен дә тәмләп, озаклап эчә алмады. Тиз-тиз генә тамак ялгап алды да, өен җыештырырга кереште. Ул да булмады, ишектәге кыңгырау тавышы яңгырады, Минниса карчык сискәнеп китте, шунлыктан күз аллары караңгыланды. Кемлеген сорап тормыйча гына ачып җибәрсә,ишектә—Әлфинур иде. Кочагын җәеп, елмаеп басып торган Әлфинур артында зур тартма тоткан кызыл-сары чәчле егет тә бар.

—Танымыйсыңмы? Улым—Альфред бу. Безнеңчә—Әлфәрит инде.

—Шулаймыни? Чәче кара иде шикелле...

—Әй, мода галәмәте инде,—диде Әлфинур, исе китмәгәндәй кулын селтәп.

—Ә-ә,—диде Минниса карчык, аптыраудан.

Юк-бар сөйләшә-сөйләшә, чәйләп алдылар. Альфред кесә телефонына текәлеп, дөньясын онытты. Әлфинур исә урындыгын карчык янына ук күчереп, сүз башлады:

—Нәселдә быел зур эш көтелә әле—Альфредны өйләндерәбез.

—Шулаймыни? Кызы кем соң, кайсы яклардан?

—Казанныкы ла. Татар кызы булмады инде—марҗа, исеме—Наташа.

—Абау, Ходаем, урыс белән туганлашасызмыни?—диде Минниса карчык, Әлфинурдан читкәрәк авышып.

—Берни эшләп тә булмый. Яшьләрнең үз сүзе хәзер—олыларны тыңламыйлар. Аннары... Ни бит әле... Синең белән киңәш-табыш итәргә дип тә килгән идем...—Аның йөзенә сизелер-сизелмәс кенә кызыллык йөгерде. Минниса карчык дәшми генә, баш кагып куйгач, карашын аңа төбәп, сүзен дәвам итте:

—Ие, апа, ни бит, синнән зур ярдәм кирәк иде. Үзең беләсең инде, без

бай кешеләр түгел, улыбызга фатир бүләк итә алмыйбыз. Аннары ни... Э-э, яшьләрнен тормышы барып чыгармы—юкмы, бик шикләндерә. Наташаны үзебезнең фатирга кертсәк, аерылышып-бозылышып йөрмәсләрме икән дим. Шуна күрә,э-э, сиңа зур йомыш белән килгән идем.Э-э, Хөкүмәтнең бит яна карары чыкты. Быел ветераннарга фатир бирәләр бит. Син тол ветеран саналасың, сиңа ул һичшиксез тиеш.

—Кирәкми лә миңа бернәрсә дә...

Әлфинур аны ярты сүздән бүлдереп, тиз-тиз сөйләвен дәвам итте:

—Анда квадрат метрларга карыйлар. Әгәр-мәгәр дим, Альфред белән Наташаны...э-э... сиңа пропискага кертсәк, ул фатир тиз арада булып та куяр иде. Хөкүмәт ветераннарны бик олылый быел...

—Һай, Әлфинур, үз өем бик яхшы, бик житә. Нәрсәгә миңа яңасы? Шушында тынычлап үлсәм...

—Алай димә, апа! Бушка бирәм дигәндә—алырга кирәк. Аннары...—Әлфинур беразга гына туктады да, ашыга-ашыга, әйтеп салды:

—Ул яңасында син тормасаң, Альфред белән Наташага булыр. Сине ничек тә бәхилләтербез. Үзем тәрбияләп, соңгы юлга озатырмын...

Миңниса карчык, кинәт борылып Альфредка карады. Бер авыз татарча белмәгән бу егет бик тә ят тоелды ана. Ул бөтенләй аптырап калды. Кешегә гомере буе изгелек кылып яшәгән Миңниса карчык: «Юк!»—дип кистереп жавап бирә белми дә иде.

—Уйлап карармын,—диде ул, ничарадан-бичара.

—Яхшылап уйласаң бик яхшы булыр иде, Миңниса апа. Буш итмәбез. Берничә көннән шалтыратырмын әле, син сүзеңне әйтерсең.—Миңниса карчык авызын ача башлаган гына иде, ул малаен житәкләп чыгып та китте.

Карчык үзенең хәлсезләнеп китүен сизеп, караватына барып ятты. Әченнән генә Альфредны урыска өйләндергән, урыс киленгә каршы килмәгән Әлфинурны битәрләде ул. Керфекләре бер-берсенә тоташам дип торса да, күзенә йокы кермәде: боларның килүе аның бөтен тынычлыгын качырган иде.

Шул арада ишеге ачылып китте.

—Үләм, күршекәем, ишегең шыр ачык, нишләвең бу?—Сәлимә карчыкның сулышы капкан, йөгерә-атлый Миңниса карчык яткан карават янына килеп тә басты.

—Япкан шикелле идем дә, кара, оныткanмын икән әй...

—Берәрсе килгән идеме әллә?

—Ие, сугылып чыкканнар иде...

—Кемнәр ул?—Сәлимә карчык әллә ничек кенә—сәер итеп сорап куйды.

—Әлфинур, мәрхүм энемнең кызы...

—Каян исенә төшергән әле ул яхшылыкның кадерен белмәгән бәндә?

—Тәүбә, диен, Сәлимә. Авызыңнан жил алсын, андый көфер сүзләр сөйләмә. Туган көнем белән котлап киттеләр миңа.

—Моңарчы күзгә-башка чалынмагач кына әйтүем инде, күршекәем.—Ул, сөйләнә-сөйләнә, ишеккә таба атлады.—Биклә кал инде, дөнья бу,—диде ул, ишекне ябып.

Миңниса карчык, авырдан кузгалып, ишекнең келәсен төшерде. Үзе стенага тотынып кына караватына барып ауды да күзен йомды.

Аны ишек кыңгыравының шылтыравы уятты.

—Кара сана, төш вакытлары узган икән инде.—Миңниса карчык сөйләнә-сөйләнә ишекне ачты. Халисә белән малае килгән икән.

—Исән-сау тордыңмы, апа?

—Шөкер, әйбәт кенә.

—Кая әле. Минем яулыкны бәйлисеңме икән?—Миңниса карчыкның

кабаттан кызыл чәчәкле яулыгын бәйләп куюын күреп, Халисә аны сүгеп тә ташлады.

—Һай, салып ташлачы шул иске-москыңны! Менә дигәнен алып килдем бит үзенә!

—Әй, бер иялəнгəч,—дип акланды Миңниса карчык.

Халисә аны тыңлап тормады, үз сүзен башлады:

—Миңниса апа, сине мәшәкатьләү дә була инде, тик, нишләтәсең, тормыш шундый нәрсә—гел шәфкатьле кешеләрдән ярдәм сорап, өмет итеп киләсең. Менә улым шәһәрне өйрәнеп беткәнче апамда торыр дигән идем, сүзгә килдек тә, хәзер өеннән куып ук чыгарды. Бөтен Казанында белгән кешебез син... Улыбыз тәртипле, эшчән, начар гадәтләре юк, яхшы укый...

Миңниса карчык ирексездән башын иеп, кулларын укмаштырып торган Илшатка күз ташлады.

—Менә шуны фатирыңа кертә алмассың микән. Авыл ризыкларыннан өзмәс идек үзеңне...—Халисә ашыга-ашыга сөйләвен дәвам итте:—Әле, ишеттеңме икән, ветераннарга, сугышта үлеп калганнарның хатыннарына фатир бирәләр икән. Синең квадрат метрлар туры килә бугай. Илшатны Казанда калдырырга иде исәп. Документлары белән үзем йөрер идем. Теләсәң, сине авылга алып кайтып китәм. Яңа сауган сөт эчеп, каймаккатык ашап кына ятарсың...

Миңниса карчык тәмам миңгерәүләнде. Халисәнең сүзләрен ул ишетте дә ишетмәде дә. Үзенә төбәлеп карап торган ана белән малайга нидер әйтмәкче булып, иреннәрен кыймылдаткан иде, Халисә аны кырт кисеп бүлдерде:

—Юк-юк, син бүген үк әйтмә җавабыңны. Бүген шимбә бит, без авылга кайтабыз. Иртәгә шалтыратып сорармын.

Ул да булмады, алар саубуллашып, чыгып та киттеләр.

Миңниса карчык сулык-сулык килгән чигәләрен ике кулы белән кысып, уйга чумды. Үзара ызгышкан апалы-сеңелле ике туганның бу гамәлләрен өнәмәде ул. Югыйсә, кечкенә вакытларында нинди дуслар иде.

—Бәрәч, ишегең тагын ачык.—Бусагада кабат Сәлимә карчыкның тавышы ишетелде.

—Кунак кына озаттым әле, Сәлимә.

—Монысы кем булды тагын?

—Халисә...

—Теге, ерак туганыңмы?

—Ие, шул.

—Ул каян сине исенә төшергән тагын?

Миңниса карчык аңа гаҗәпсенеп карап куйды:

—Ник, туган көнем белән котларга килгән...

—Ә-ә,—авыз эченнән нидер мыгырданып, Сәлимә карчык үз фатирына кузгалды.

Миңниса карчык кабат караватына барып ауды. Көн кичкә авышканда, аңа янә бер кунак—Сафия килеп керде.

—Ай-яй, алма апам, һаман да унсигез яшьлек кызларга биргесез икәнсең әле, күз тимәсен!—диде ул керә-керешкә үк. —Менә сиңа җылы башмаклар алып килдем. Озак хезмәт итсен, җылы тәнеңдә тузсын.

—И-и, рәхмәт инде!

Алар өстәл янына утырдылар. Озаклап хәл-әхвәлләрне белешеп, элеккеләрне исә төшергәч, Сафия җайлап кына сүз башлады:

—Миңниса апа, кичә әйткән идем бит әле... ни дип... яңа фатирга күчтек дип. Дүрт бүлмәле, яңа йорттан. Бик яхшы фатир, тик хәлләр катлаулырак әле. Барысы да акчага төртелде. Евроремонт ясатмакчы идек тә, бик кыйммәт икән. Шуңа күрә, алма апам, сиңа тәкъдим белән килгән идем...

Миңниса карчык, берни аңламыйча, ана текәлде.

—...Яраткан сеңлеңә бераз ярдәм итә алмассыңмы икән. Хөкүмәт ветераннарга фатир бирә икән. Мондый мөмкинлекне кулдан ычкындырырга һич ярамый, апа җаным. Сина һичшиксез яңа фатирга күчәргә кирәк. Теләсәң, бездә торырсың. Ә синең бу иске фатирыңны сатарбыз. Әйбәт бит? Соңгы юлга үзем олылап, тәрбияләп озатырмын. Иртәгә сине үзебезгә кунакка алып китәм. Әле уйлый тор.—Сафия Миңниса карчыкны иңнәреннән кочып, ике битеннән үбеп алды да:

—Иртәгә очрашканчыга кадәр, апа җаным,—дип чыгып китте.

Миңниса карчык аның киткәнен сизми дә калды. Уйларына йотылып күпме утыргандыр, ишекне дөбердәткән тавышка сискәнеп, кинәт айныгандай булды.

—Алай, күршекәем, бигрәк мингерәүләнден бу көннәрдә—ишегең гел ачык.—Сәлимә карчык сөйләнә-сөйләнә түргә узды. Үзе өстәлдәге сый-нигъмәтләргә ымлады:

—Бик зурлап үткәрдең, ахры, быел туган көненне?

Миңниса карчык дәшмәде.

—Килүчеләр дә күп булды бугай...

—Әйе...кил-де-ләр...—диде ишетелер-ишетелмәс кенә Миңниса карчык. Аннары яшьле, моңсу күзләрен ахирәтенә күрсәтмәс өчен, карашын тәрәзәгә таба борды.

—Әле Илдар тагын шалтыратты,—диде Сәлимә карчык, Миңниса ишетсен өчен кычкырып.—Миңниса апамны котлап, бүләк керттеңме?—дип сорады. «Оныткамын»,—дигән идем,—сүгеп ташлады үземне. Менә, затлы яшел чәй керттем үзеңә. Илдар улым күчтәнәче. —Ул чәй тартмасын өстәлгә куйды. —Син мине ишетәсеңме соң, күршекәем?

Миңниса карчык баш селкеде.

—Сөенче димме, күршекәем, кайгы димме, улым марҗасыннан аерылган бит...—Сәлимә карчык, Миңнисадан сүз ишетергә теләп, бераз тын торды. Ул дәшмәгәч, кабат дәвам итте.—Хәзер Казанга кайтырга җыена. Бик сөенәм дә, нишләр инде менә, кая сыеныр? Бездә абыйсы гаиләсе белән тупләнде бит инде, мин бар. Кая торыр инде Илдар? Ул үзе сине бик ярата—галәмәт. Әле бүген дә телефоннан: «Миңниса апа белән серләребез туры килә инде безнең»,—дип сөйләп торды...

Миңниса карчык карашын тәрәзәдән алмаганга ачуы килеп, Сәлимә карчык тагын да кычкырыбрак сөйли башлады:

—И-и, күршекәем, моңарчы гел тату яшәдек. Ходай кушып моннан соң да шулай булсын. Күрше хакы—тәңре хакы дип юкка гына әйтмиләр инде ул. Әле ишеттем, сугыш ветераннарына, аларның тол хатыннарына быел фатир бирәләр икән. Синең иң якын кешеләрең без бит инде. Илдар дукументләре белән йөрер...

Миңниса карчыкның кинәт үзенә борылуын күреп, ул ярты сүздә туктап калды. Миңниса карчык берни дә дәшмичә, ияге белән тәрәзәгә ымлады.

—Ни бар, күршекәем?—Сәлимә карчык, шөбһәләнеп, урамга күз ташлады. Нәкъ тәрәзә турысында, кара каурыйлары тырпаешкан соры муенлы чәүкәләр, чыр-чу килеп, үзара чукыша иде.



Хәнәфи
Бәдигый

# И ТАТАРЛАР!

## Бөре җыры

*Табигатьнең бөек яңарышка*
*Әзерлеге тоела һәркайда,*
*Хәтта очкан кара каргаларның*
*Күләгәсе зәңгәр бу айда.*

Р. Фәйзуллин

**Бездән башлана һәр язда яңа чор,**
**һәр яңа чор сорый бездән яңа җыр.**

**Безнең байрак—яшел яфрак, җырлыйбыз,**
**Җырыбызда чорыбызны зурлыйбыз.**

**Без Ходайга сәҗдә кылып яшибез,**
**Шуңа яз саен яшәреп—яшьнибез.**

**Сезнең дә бар байрагыгыз, җырыгыз,**
**Ләкин бездән үзгә сезнең чорыгыз.**

**Без җилләрне сәламлибез шаулашып,**
**Давыл купса, йөгәнлибез даулашып.**

**Без яшел яфрак илендә бәхетле,**
**Чөнки һичкемгә бирмибез тәхетне.**

**И татарлар!**
**Фагыйләтен, фагыйләтен, фагыйләт,**
**Яшик бергә гомер бакый җыр көйләп!**

## Юл

*Аталарның соңга калган акыллары,*
*Ялгышлары белән баеп без яшибез.*
*Хәтерләтә бер максатсыз такыр юлны,*
*Чит бәйрәмне—ялыктыргыч тормышыбыз.*

М. Ю. Лермонтов (тәрҗемә)

**Татар дөньясы чикләрен**
**Җимереп эчтән-тыштан,**
**Биш гасыр байлыгын талап,**
**Типтереп яши дошман.**

**Бүген аның йөрәгенә**
**Каплан булып ятты ул,**
**Һәм телен йолкып ташларга**
**Мәкерле җай тапты ул...**

**Ул биш гасыр яскаланды**
**Динен таптап сытарга.**
**Булмагач, телен йолкыйм дип,**
**Ябышты ул татарга.**

**...Кем—алдан куркып, калтырап,**
**Күтәрде соң кулларын?**
**Кем алдап, ташларга кушты**
**Мөстәкыйльлек коралын?**
**Кем бар—ишәктәй иелгән**
**Дошманының йөгеннән?—**
**Шәм шикелле төз гәүдәсе**
**Көянтәдәй бөгелгән?**

**Юл бер: дауларга хаклыкны,**
**Йә сайларга коллыкны.**
**Алдалап булмас халыкны:**
**«Телсез татар» атын алмас,**
**Үз-үзен якламый калмас,**
**Зур тарихыннан югалмас,**
**Дәүләтен торгызмый калмас,—**
**Күтәрмәс ул хурлыкны!**

## Җепсәдәге урак

*Ай урагын салып иңбашыңа*
*Кояш нурларыннан нур алдың;*
*Кояш нурларыннан нур алдың да*
*Салкын чишмәләрдән су алдың.*

Н. Исәнбәт

**Бар иде ду китереп,**
**Ашлык урган чакларың:**
**Көлтәләрең нинди сылу**
**Яшь кызлар кочаклады.**

**Алтын-сары иде сапларың,**
**Энҗе-тигез тешәвең.**
**Уттай урак өсләреңдә**
**Ал-ял белми эшләдең.**

**Эшчән син-уракның йөзе**
**Бизәкләнеп какланган...—**
**Анда әнкәйнең күп еллар**
**Тамган тире сакланган...**

**Урак өсләре җитсә дә,**
**Ял итсә дә җепсәдә,**
**Яшь чакларың искә төшә,**
**Кызлар карап үтсә дә.**

**Кайчак җилкендерә сине**
**«Дон», «Нива» тавышлары.**
**Уянадыр айлы кичтә**
**Шатлык, моң, сагышлары.**

...Җепсәдә торсаң да үзең,
Ял итсә дә җисемең,
Дан булып яңгырый синең
«Урак» дигән исемең.

## Кайтаваз

*Кузгалалар эшафотка таба*
*Бу гомернең соңгы «әкбәре».*
*Сукты сәгать! Һәммәсенең бүген*
*Легендага күчкән мәлләре.*
Р Зәйдулла

Адәм башы—агач башы түгел,
Кызганмыйча кисеп атарга.
Фашист җәлладлары котырынып
Балта кайраганнар татарга.

Исән калыр иде җәлилчеләр
Тез чүксәләр, башны исәләр.
Белгән алар : гильотиналарда
Иелмәгән башны кисәләр.

Алар исән калган булса, безнең
Суырырлар иде җелекне.
Тез чүксәләр, башны горур тотып,
Бүген йөри алыр идекме?


Ярсып-шашып балта кайраганнар
Иелмәгән татар башына:
Ничә гасыр денсез кавем аның
Канын койган нигез ташына.

Казан татарына—палач Иван,
Кырым татарына—Сталин,
Плетцензееда—Гитлер фашисты...
Калдыклары гүя бүген әйтә:
«Без ул эшкә әзер—баш өсте».

Бөтен дөнья башын ия бүген
Иелмәгән татар башына.
Без барабыз җәлилчеләр белән
Мәгърур төстә тарих каршына!

**Редакциядән:**
*Бу айда каләмдәшебез, шагыйрь («Абага чәчәге», «Күңел ялкыны», «Яшел чирәм» исемле китаплар авторы), галим-педагог, филология фәннәре кандидаты Хәнәфи Бәдигыйга 70 яшь тула. Аңа яңа иҗат уңышлары, сәламәтлек теләп калабыз.*

Мөнир
Вафин



# ДӨНЬЯЛАР СЕРЛЕ, СЕРЛЕ...

***

**Аһ, мин шундый шашып яраттым шул,**
**Үз-үземнән ташып яраттым.**
**Җиргә генә хисләр сыялмагач,**
**Галәмнәргә ашып яраттым.**

**Галәмнәр дә кысан булып чыкты,**
**Кысанлыкка инде түзмәдем,**
**Җиде катлы күккә күтәрелгәч,**
**Сигезенче катны эзләдем.**

**Бар галәмнең иң-иң түбәсенә**
**Күтәрмәкче идем югары,**
**Баш әйләнә, диеп торып калды—**
**Ул җир кызы булган нибары...**

***

**Карында шундый шәп иде,**
**Хәтта сүз әйтәсе юк.**
**Тамак та тук, өс-башка да**
**Кием юнәтәсе юк.**

**Тугыз айдан—эшләр харап,**
**Зәһәр җилләр истеләр:**
**Үземнән сорап та тормый**
**Кендегемне кистеләр.**

**Яхшы көннәр тәмамланды,**
**Чыда гына, түз генә.**
**Барча дөнья мәшәкате**
**Урап алды үзенә.**

**Карындагы чакны уйлап,**
**Дөньядан үтеп барам.**
**Кемгә ялганырга белми,**
**Кендекне тотып барам.**

## «Бәхет» елгасы

Уйладым: бәхет елгасы
Ярлардан ташар тулып
Һәм шунда йөзәрмен дидем
Балыктай чумып-чумып.

Чынлыкта, өлешкә төште
Бары тик камчы, камчы...
Бәхет елгасы дигәнем—
Күздәге тозлы тамчы.

***

Язның иң-иң күркәм чагы,
Бар табигать гөрләп тора.
Кошлар бала чыгарганнар—
Оялары җырлап тора.

Кешеләр дә кошлар кебек—
Бер үк тәкъдирнең юллары;
Безнең өй дә нәкъ шул оя—
Бала-чага чыр-чулары...

Көзләр җиткәч, кошлар китте,
Оя-оя тезелешеп.
Артларыннан карап калдык
Күзләр төбәп, өзелешеп.

Безнең кошчыклар да үсте,
Канатлар нык. Әнә! Әнә!
...Салкын кышта буш ояда
Ике карт кош бәргәләнә.

***

Табигатьтә тагы да яз,
Кыш китмим дип елап ята.
Күз яшьләргә карамый җир
Ак толыбын салып ата.

Гөр-гөр килеп гөрләвекләр
Кемузардан ага, ага.
Һәм тамырлар баш калкытып,
Рөхсәт сорап җирне кага.

Дәрт-дәрманнар тугарылып,
Һич баш бирми ташып бара.
Хатын-кызлар сыешалмый
Киемнәрдән ташып бара.

Күләгәгә поскан карлар
Куырылып эреп бара.
Кәлтә булып гөрләвекләр
Офыкларга кереп бара.

Бер көн килеп, соң тамчылар
Мөлдерәшеп күзгә бага...

**Тамчы булып вакыт тама,**
**Гөрләвектәй еллар ага.**

***

**Биек-биек мәгъруp таулар,**
**Сырлы-сырлы сыртлары.**
**Болытларны яулык итеп**
**Шул сыртларны сөртмәле.**

**Елга ярлары да шулай—**
**Сырлар-ярлар тирәли.**
**Чал дулкыннар талгын гына**
**Шул сырларны иркәли.**

**Ул сырларны кемнәр уйган?**
**Дөньялар серле. Серле:**
**Ярлары да, таулары да,**
**Минем маңгайдай сырлы...**

***

**Яфраклар булып коела**
**Җанымның сагышлары.**
**Вакыт—дәвалаучы, диләр,**
**Каплар әле кышлары.**

**Ахры, чынлап, минем хәлгә**
**Кышлар колак салдылар,**

**Сары яфраклар күмелеп,**
**Кар астында калдылар.**

**Вакыт—дәвалады, дидем,—**
**Йөрәкне уа-уа.**
**...Сары яфраклар төялгән**
**Ташкыннар мине куа.**

***

**Күч-күч кәгазь арасыннан**
**Эзләгәндә яшьлек татын.**
**Килеп чыкты унсигездә**
**Миңа язган сөю хатың.**

**И самими, садә хисләр,**
**Һәр хәрефе шундый кайнар.**
**Без кавышмый калгангамы,**
**Алар шулай саргайганнар.**

**Елгаларны бора ала,**
**Һәм тау күчерә алсак та,**
**Әмма кире кайталмыйбыз**
**Һич кенә дә без яшь чакка.**

**Коръән-Кәрим арасына**
**Бөгәрләнеп кереп ятты**
**Яшәвемдә яшьнәп алган**
**Ак көннәрнең сары хаты...**

**Редакциядән:**
*Бу айда Уфада яшәүче шагыйрь Мөнир Вафинга 50 яшь тула. Каләмдәшебез, журналыбызның даими авторын ихлас котлыйбыз, аңа яңа иҗат уңышлары, сәламәтлек телибез.*

# ПОЛЬШАДА ТАТАРГАҺӘЙКӘЛ КУЕЛДЫ

*25 ноябрьдә Польшаның Гданьск шәһәрендә Республиканың Леон Крычинский исемендәге Татар мәдәнияте үзәге бинасы урнашкан паркта татарларга һәйкәл куелды. Атка атланган хәрби киемле татар угланының сыны Польша-Литва дәүләтенең Грюнвальд бәрелешендә тарихи җиңүенә 600 ел тулу уңаеннан, полякларга сугышта өстен чыгарга ярдәм иткән татарларның батырлыгы хөрмәтенә барлыкка килде.*

*Бу олуг тантанада Польшада яшәүче милләттәшләребез, илнең президенты Бронислав Коморовский, Кырым татарлары Милли мәҗлесе рәисе Мостафа Җәмилев җитәкчелегендәге вәкиллек, Литва, Беларус татарлары, Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты рәисе Ринат Закиров, Татарстан Республикасының Санкт-Петербург һәм Ленинград өлкәсендәге даими вәкиле Шамил Әхмәтшин, М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театры солисты Владимир Васильев, Уфадан татар морзалары оешмасы җитәкчесе Зөфәр Әюпов катнашты. Һәйкәл ачылу тантанасы кысаларында Польша Республикасы татарлары берлеге татарларның Европага йогынтысы мәсьәләләренә багышланган фәнни-гамәли конференция дә уздырды.*

*Әлеге чара барышында Польша мөселманнары мөфтие Томаш Мишкевич дога укыды, Гданьск мэры Павел Адамович Польша татарларының мәдәни үзәгенә рәхмәтен белдерде. Президент Бронислав Коморовский әнисе Ядвига ханым белән һәйкәлгә чәчәкләр куйды. Ядвига Коморовская кунаклар белән очрашу вакытында әтисе ягыннан татар булуы белән горурлануын да җиткерде.*

## ПОЛЬША ПРЕЗИДЕНТЫ БРОНИСЛАВ КОМОРОВСКИЙНЫҢ ҺӘЙКӘЛ АЧУ ТАНТАНАСЫНДАГЫ ЧЫГЫШЫ



Бирегә җыелучыларны—рәсми вәкилләрне һәм йөрәкләре кушканга килүчеләрне—һәммәгезне дә сәламлим. Шулай ук күп гасырлар дәвамында хәзерге Польшаны төзүгә ярдәм иткән Польша татарларынын нәселләренә сәламемне җиткерәм.

Мин үзем бирегә йөрәгем кушканга килдем. 600 ел дәвамында Польшага тугрылыклы хезмәт иткән Польша татарларының нәсел дәвамчыларына чын күнелемнән рәхмәтемне белдерер өчен әлеге һәйкәлне ачу тантанасында катнашырга теләдем.

Мәгълүм ки, татарның ир-егетләре ат өстендә туа—моны бүген Польша татары хөрмәтенә ачылган һәйкәл дә раслый. Без барыбыз да Польша татарларынын—дөньядагы иң яхшы җайдакларның Речь Посполита[1], дәүләт тажы һәм Литва дошманнарын ничек итеп тар-мар итүләрен хәтерлибез. Без аларның батырлыгына, сугышчанлыгына һәм гаять югары кимәлдәге хәрби осталыкларына соклансак, дошманнарда бу гадәттән тыш курку тудырган.

[1] Речь Посполита полякча—республика. Ред.

Польша татарлары Речь Посполитага дан китерде. Речь Посполита тарафыннан игътибар һәрвакытта да булып тормауга карамастан, алар ана һәрчак намус белән хезмәт иттеләр. Һәркемгә дә билгеле бит: әгәр татар кешесе ярата икән, ул бар йөрә-ген биреп ярата инде. Польшада төпләнеп калган татарлар да безнең илне нәкъ менә шулай ихластан яратты. Аларның данлы эшләре китабын Грюнвальд бәрелеше ачып җибәрә. Бүгенге тантана унаеннан ул сугышны искә төшереп үтәсем килә. Ул чакта



*Тантананың шәрәфле каравылы.*

алар Литва гаскәрләре составында сугыша. Сонрак яна җиңүләр килә, нәүбәттәге яу-бәрелешләр кабатлана. Шулай итеп алар үзләренең яңа ватаннарына—Польшага үзләрен тулысынча хуҗа итеп тойган һәм дусларча мөнәсәбәт хөкем сөргән яңа өйләре өчен бик күп корбаннар белән түлиләр. Татарлар монда ул заманнарга хас булмаганча диннәрен һәм мәдәниятләрен саклау хокукына ия булалар.

Речь Посполитаның бер генә дошманы да аларның корал көчен татымыйча калмады. Татарлар москальләрне, шведларны һәм итальяннарны тар-мар иттеләр, бер диндә булуларына карамастан, кирәк чакта төрекләрне дә аямадылар.

Польша татарларыннан башка шанлы Вена җиңүе булмас иде. Бу җиңүдән соң король Ян III Собеский аларны аеруча ярата башлый. Татарлар үзләре дә аны ихтирам итә. Кайнар татар каны Костюшко баш күтәрүләреннән алып, барлык милли восстаниеләрдә дә түгелде. Ул 1918 елда торгызылган Польша дәүләте—икенче Речь Посполита нигезенә дә сеңеп калды. Без күргән татар нәкъ менә шул хөрмәткә маршал Пилсудский угланы мундирын кигән дә инде. Аны 1939 елның сентябрь бәрелешләрендә катнашкан Вильнюс угланнарының 13нче полкы һәм татар кавалериясе эскадронында да кигәннәр.



*Һәйкәл ачуда катнашучылардан бер төркем. Уртада—Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты рәисе Ринат Закиров.*

1939 елның сентябрендәге Монте Кассинодагы бәрелешләрдән башлап, Речь Посполита гражданнары булган Польша татарлары Икенче бөтендөнья сугышының барлык фронтларындагы яуларда да катнаштылар. Монте Кассинодагы зиратка килүчеләр ахыргы минутларынача Польшага намус белән хезмәт итүчеләрнең каберләрен күрә ала. Анда алар соңгы солдатларынача тугры калган Польша мөселманнары каберенә дә тап булачак.

Катынь урманында атып үтерелүчеләр һәм поякларның башка бик күп хәрби зиратларында ятучылар мәңгелек сакта калачак.

Бүген без ачкан һәйкәл хәтеребезнең саулыгын һәм соңгы 600 ел өчен аларга хөрмәт һәм ихтирам белдерүебезне раслый. Бу ватаныбызның күп халыкларның уртак Речь Посполитасы булган вакытларын яд итү дә әле. Ул төрле халыклар, диннәр һәм мәдәниятләрне очраштырган «зур казан» булды. Һәм алар барысы бергә ага-энеләрдәй яшәделәр, төрлелектән, үзгәлекләрдән илһам һәм көч алып,

туган илебез куәтен ныгыттылар. Нәкъ менә төрлелек бергә яши белүчән Речь Посполитага бик зур эчке һәм тышкы куәт бирде. Шушы үзгәлекләр берлеге хөрлек һәм демократияне ул чакларда Европада күзәтелмәгәнчә мул тараткан Польша дәүләте төзелешенә сөйкемлелек өстәде.

Бу мирас—безнең олы уртак горурлыгыбыз, һәм без аны башкаларга да кыю рәвештә күрсәтергә тиешбез. Әлеге традицияне Европа берлегендә Польшаның ярты ел дәвамында президент булуы алдыннан искә төшерү аеруча мөһим. Президентлык итү вакытында ватандашыбыз Иоанн Павел Икенченең Люблин униясеннән Европа бергәлегенә илтә торган тарих күпере турындагы сүзләрен девизыбыз итәргә кирәк. Люблин униясе безнең, шул җөмләдән борынгы Речь Посполитаның көнчыгышында яшәгән татарларның да, уртак тарихы, гореф-гадәтләре һәм мәдәниятенә яшәеш бирде.



*Тантанадан бер күренеш.*[2]

Бер-берсенә ярдәм итеп яшәгән халыкларны берләштергән Речь Посполитаның казанышларын искә төшерү бүген бик тә мөһим. Шулай ук яңа Польша да аны хәтерләсен иде. Юкса күреп торабыз, бергә яшәү, хезмәттәшлек итү һәм янәшә яши алу сәләте һәркемгә дә бирелми. Төрле халыкларны үзенең канаты астына алган Речь Посполита безгә толерантлык һәм кооперация үрнәге булып тора. Бүген әнә шул сыйфатлар һава сыман кирәк. Әгәр аларны үзебездә эзләп тапмасак, «Бердәмлек»нең бөек җиңүе нәтиҗәсендә язмыштан һәм тарихтан кабул итеп алган гаҗәеп мөмкинлекне кулдан ычкындырачакбыз. Польшаның бердәм була алуына шикләнүчеләрнең барысын да 30 ел элек могҗизалы көчне—«Бердәмлек»не тудырган, димәк ки фикер-карашлары, симпатияләре төрле-төрле булган кешеләрне берләштерә алган Польша яр буйларына чакырам. Барлык шикләнүчеләрне менә монда да—татар ир-егете һәйкәле янына да чакырам, татар җайдагының, икенче Речь Посполита кавалеристының гаярь сынын күреп, Польшаны хәтта бер-берсеннән бик үзгә кешеләрнең дә зур бирелгәнлек белән ярата һәм аңа намус белән хезмәт итә алуын тойсын алар.

Аңласак, төшенсәк иде: ватанпәрвәрлек бер генә төрле булмый ул. Тарих менә ни дип өйрәтә: Польша ватанпәрвәрлеге—ул бер-берсеннән күп яктан үзгә булган кешеләрнең ватанпәрвәрлеге. Моңа ышанырга һәм үз мөмкинлегенне низаглар үрчегән җирдә түгел, үзара килешү хөкем сөргән урыннан эзләргә кирәк.

Гданьск шәһәре хакимиятенә һәм Орунья районы идарәчеләренә чын күңелемнән рәхмәтемне җиткерәсем килә. Татарлар турындагы хәтерне һәм иң мөһиме—күп милләтле, төрле мәдәниятләр, диннәр һәм телләрне берләштергән Речь Посполита рухын сыендырган өчен шәһәр халкына зур рәхмәтемне әйтәсем килә.

Монда килгән һәркем, татар ир-егете һәйкәленә карап, без, polякларның башыннан кичкән матур тарих турында уйланыр. Бүген без, узган гасырларның тәҗрибәсенә һәм мирасына таянып, үз тарихыбыз белән хәзерге заманның барлык интеграция процессларын уздырган мизгелләрне күрсәтә һәм башкаларга үрнәк була алабыз. Тагын бер кат ул традициянең мөһимлегенә басым ясар идем. Һәм анда иң бәһале нәрсә шушы җөмләне әйтә алу мөмкинлегедер дип уйлыйм: сүнмичә ян, борынгы Речь Посполитаның үзенә тартып торган берләштерүче яктысы!

Рәхмәт.

---

[2] В. Васильев төшергән фотолар файдаланылды.

Хәter
Хәтер



Фәнис
Яруллин

# ХӘТЕР ТӨПЛӘРЕНДӘ УТЛЫ КҮМЕР

КӨНДӘЛЕКЛӘР

* * *

*Бик күп вакыйгалар*
*Керми әсәрләргә—*
*Көндәлекләр булып*
*Ята дәфтәрләрдә.*

*Тик алар да әле*
*Барсын сыйдыра алмый,*
*Язмыш елгалары*
*Ага кайный-кайный.*

*Кала бозлар утырып*
*Күңел ярларында.*
*Тормышның иң чыны*
*Бары җаннарымда.*

*Ә җаннарны һич тә*
*Булмый киерep ачып.*
*Яшибез гел шулай*
*Үзебездән дә качып.*

## Җуелганны тергезсәк...

Көндәлекләрне кайчан яза башлаганымны хәтерләмим. Шунсын гына әйтә алам: күп алар миндә. Ачынып-әрнеп язганнары да, шатлыктан очынып язганнары да. Кызганыч, көндәлекләремнең күбесе юкка чыккан. Бары тик 1981 елда язылган бер дәфтәр һәм соңгы еллардагы егермеләп дәфтәр генә сакланып калган. Хәтта 1981 елдан соңгы еллардагы көндәлекләрнең дә дүрт дәфтәре юкка чыккан.

Шул югалтуларны әзме-күпме тулыландырыр өчен хәтергә мәңгелеккә уелып калган вакыйгаларны кәгазь битләренә төшерәм.

**1958 ел, 17 июль.** Красноярск краеның Канский шәһәре. Мин шунда хәрби шәһәрчектә укчы радистлыкка укып йөрим. Спорт белән шөгыльләнәм, парашюттан сикерәм һәм 17 июльнең ул край вакыты белән кичке сәгать тугызлар тирәсендә кинәт билгесезлеккә очам. Бары тик хәрби санчастьнең каты тапчанында гына аңга киләм. Күземне ачканда ике пар күз мина карап тора иде.

—Су!—дидем беренче сүз итеп һәм кызлар кулындагы стаканга үрелмәкче булдым. Шунда гына кулларымның мина буйсынмавын аңладым.

Кызларның берсе кулын минем баш астына тыгып, башны калкытмакчы булды. Мин:

—Алла!—дип кычкырып җибәрдем.

—Син татармы әллә?—диде ул. Мин керфек кагып кына җавап бирдем. Аннары кызлар сузып торган стаканнан бер-ике йотым су эчтем. Муеннын сызлавына чыдар

Фәнис ЯРУЛЛИН (1938)—*Татарстанның халык шагыйре, прозаик, драматург, публицист; күпсанлы китаплар, шул исәптән сигез томлык «Сайланма әсәрләр» авторы. Казанда яши.*

хәл юк. Житмәсә, санчастьның ятагы каты, бүлмәсе бөркү. Кызлар минем хәлне аңлап мине чишендерә башладылар. Муен тирәсенә куллары якынлаша башласа—кычкырып җибәрәм.

Бу кызлар медчастьтагы дежур медсестралар булып чыкты. Берсе минем күт битенә укол чәпәде. 10-15 минутлар үтүгә авыртуым бераз басыла төште. Кызлар да минем белән шаяртып сөйләшә башладылар.

—Чибәр егет, нишләп монарчы безгә бер дә килмәден?

—Менә иртәгедән килеп йөри башлармын инде. Ләкин кайсыгыз янына килергә соң?

—Кайсыбызны ошатасың, шуңа инде.—Кызлар халатларын салып каршыма бастылар. Аларның икесе дә миңа бик чибәр күренде. Армиядә кызларга сусап торасың, бәлки, шуңадыр.

—Сез икегез дә миңа бик ошыйсыз. Ике колактагы пар алкалар кебек.

—Алайса, икебез янына да килерсең.

—Мондый чибәрләрнең егетләре күптер шул. Кабыргаларыңны санап җибәрерләр.

—Санаттырмабыз!—диде кызлар.

—Алайса, иртәгә мин сезнең янда булырмын.

Мин ул чакта әле гомерлеккә урын өстендә ятып калырмын димим, менә-менә муенымның авыртуы бетәр дә аякка басармын дип уйлый идем.

**18 июль.** Күләгәдә үскән чыбык төсле нечкә һәм төссез бер капитан керде. Ул врач икән, резина башлы чүкече белән аякларга-кулларга бер-ике суккалады да:

—Одевать!—дип команда бирде. Шул арада шүрәледәй шыксыз бер хатын килеп басты һәм тарткалап-йолыккалап мине киендерергә тотынды. Мин авыртуга түзә алмыйча акырдым-бакырдым. Кичәге кызлар киендерсен дип таләп иттем. Ләкин гади курсантның таләбе буыны катмаган капитан белән шүрәле нәселеннән булган затның ачуын гына арттырды.

—Молчать!—дип акырды алар икесе ике тавыш белән. Капитанның тавышы ыслаган еланныкына ошаса, шүрәле затыныкы авызына су капкан гөберле баканыкына охшаш иде.

Капитан белән теге усал хатын миңа берни әйтми чыгып киттеләр. Мин шул каты тапчанда ятып калдым. Башыма төрле уйлар килде. Нишләп бу муенның авыртуы һаман басылмый икән? Шул авыртудан туктаса, чыгып качар идем. Нишләп кешеләр шундый мәрхәмәтсез була ала икән? Юкса мин бит аларга берninди начарлык эшләмәдем. Дөньяда 20 яшь ярымга кадәр яшәп минем кешеләргә түгел, малларга да усал тавыш белән эндәшкәнем булмады. Сүгенү сүзләрен башкалардан ишетсәм дә, колак яфракларым кызышып кызара иде.

Авыртуларымны онытып шундый уйларга бирелеп ятканда теге капитан белән носилка күтәреп ике солдат килеп керде. Капитан миңа карап алды да, солдатларга ымлады. Солдатлар тычкан тотарга җыенган мәче тизлеге белән миңа ташландылар. Берсе куллардан, икенчесе аяклардан күтәреп алып носилкага салдылар. Шул чактагы авыртулардан исән калырмын дип уйламаган идем. Күздән яшен утлары чәчрәп чыкты. Аннары бөтен дөнья караңгылыкка чумды. Уянып китсәм, мин брезент белән каплаулы машина әрҗәсендә. Кански шәһәренең асфальтсыз юлыннан аэропортка барабыз. Носилканы бау белән әрҗә кырыена асканнар. Бусы инде авыру турында кайгырту дип атала. Әгәр машина әрҗәсе төбенә салсалар, носилка тагы да катырак сикерер, бер баштан икенче башка шуышып иде, ә бауда бары тик сикереп-сикереп кенә аласың.

Кырыйларында командирлары булмагач, солдатларның бераз теле ачылды.

—Сине Красноярск хәрби госпиталенә илтәбез.

—Әле моннан бер атна элек кенә синең кебек муены сынган бер егетне илткән идек.

—Әйе, ул ике метрлы таза егет иде. Тирән суга чумам дип башы белән сай җиргә төшкән. Баргач очрашырсыз әле.

—Әйе,—диде солдатның берсе ни өчендер көрсенеп.

Без аэропортка килеп җиткәндә 10-13 пассажир сыешлы самолетта берничә кеше утыра иде инде. Аларны бер якка кучереп, теге солдатлар минем носилканы урындыклар өстенә куйдылар.

Без, кайчандыр суында коенган, ташлы урамнарында маржа кызлары белән үбешеп йөргән Канскийны мәңгелеккә калдырып, Красноярскига очтык. Самолет һава бушлыкларына төшеп киткәндә күкрәкләр кысыла, эчләр актарыла, сынган муенны

башы-ние белән алып ташлыйсы килә.

**18 июль, кичке 4ләр тирәсе.** Ниһаять, самолет җиргә төште. Самолет утыргычларына төрттерә-төрттерә алып төшеп киттеләр. Анда мине нәкъ Канскийдагы кебек әрҗәсен брезент белән төргән йөк машинасы көтә иде.

Красноярск хәрби госпиталенә килеп кергән чакта ни үле, ни тере түгел идем. Шулай да тимер кебек каты рентген өстәленә салып әле бер, әле икенче якка әйләндерә-әйләндерә рентген ясауларын хәтерлим.

Палатага кертеп салгач, газапларым бетәр дип уйлаган идем, әле тәмугның ишегалды гына булган икән. Палатада тимер карават өстенә такта җәйделәр. Аннары караватның баш ягын ярты метр күтәртеп һәм тышлыгы нинди төстә икәнлеге беленми торган түмгәк-түмгәк булып оешкан матрас салдылар да минем өстемдәге киемнәрне кайчы белән кисеп алып, карават өстенә ыргыттылар. Ләкин мине җәзалау моның белән генә бетмәгән икән әле. Үгез суючы адәмгә охшаган таза бер ир кулына брезент тасма тотып яныма килде. Ул дәшми-тынмый гына тасманы минем култык асларыма тыкты, ниндидер элмәк ясап башка кидерде, аннары тарттырып карават башына бәйләде. Минем әчәсем килә, тыным кысыла, өстәвенә ике көн сигән юк. Теге үгез суючы чыгып киткәч, медсестраны, врачны кереп утырды.

—Йә, нихәл, егеткәй?

—Сиясем килә,—дидем.

Минем янда утыручы «шәфкать иясе» өстемә ябылган одеалны ачып, монарчы беркемгә дә күрсәтмәгән җиремне тотып карады, бармагы белән сидек куыгына бәргәләп алды да минем өстемне дә япмыйча чыгып китте. Шунда ук идән юучы яшь кенә бер кыз мина карап-карап куя. Оятымнан кызарынып ятам. Житмәсә, чебеннәр нәкъ шул җирне тешләп ала. Куып җибәрергә куллар эшләми.

Ниһаять, каталка тартып ике кыз керде. Алар мине кысан гына тәрәзәсез бүлмәгә алып керделәр. Түшәмдә тонык кына лампа яна.

—Син татаринмы әллә?—диде кызларның берсе.

—Ясное дело,—диде икенчесе,—вот же обрезанный.

Мин инде хәзер оялудан уздым. Төрле яклап тикшереп чыккач, алар үз эшләренә тотындылар. Мин түшәмгә карап ятам. Нәрсә эшләгәннәрдер, бер мәлне кызлар кызыксынган җир ачытып, авыртып алды һәм мин сиеп җибәрдем.

Мине палатага кертеп салдылар. Шушы көннән соң гомерлеккә сузылган газаплар башланды. Ике тапкыр муен умырткаларына наркозсыз-нисез операция ясаулар, кузгатырга ярамый дип клеенкага җәелгән чүпрәк өстендә ятулар тәнне тәмам черетте. Кечкенә чактан суда коену, мунча керүләрне төштә күрергә генә калды. Шулай да, врачлар белән тарткалаша торгач, өч айдан соң мунчага алып бардылар. Ләкин, бәхетсезгә җил каршы дигәндәй, мунчада су юк икән, мине юындырырга дип алып барган санитаркалар котельныйга киттеләр. Алар китүгә минем өстемә душтан салкын су коела башлады. Шушы «мунча»дан соң температурам 40 градуска күтәрелде һәм ул атна буе төшмәде. 9 ай хәрби госпитальдә ятып, исән калу чаткылары беткәч, миннән котылырга теләп туган якка җибәрергә булдылар.

**1959 елның 9 мае.** Салкын яңгыр явып тора. Өскә кием киеп булмый. Иске-москы җаймә һәм балык сөзәргә генә ярарлык тишек-тошык одеалга төреп вагон сәкесенә илтеп салдылар. Вагонның икенче сәкесендә кузен ярым йомып берәү ята иде. Ул миннән бер атна элек су коенганда муенын сындырган Маслов фамилияле егет икән. Грозный шәһәреннән. Уфага чаклы бергә кайттык. Безне ике солдат, бер медсестра озата барды. Без Маслов белән адресларны да алышкан идек. Ләкин безнең поезд Уфада биш минутка гына тукталыш ясый икән. Бик ашыгыч рәвештә генә поездан төшерделәр. Адреслар һәм хезмәт иткәндә язып барган куен дәфтәре мендәр астында Грозныйга китеп барды. Бер солдат һәм шәфкать туташы Грозныйга Масловны озата китте. Мине икенче поездда бер солдат озата барды.

**1959 ел, 12 май.** Урыссу станцасында мине Баян җизни, әни һәм абыем Фәһим каршы алдылар. Якын кешеләремнең якты чыраен күргәч, күңел күтәрелеп китте. Ләкин бу күтәренкелек, Урыссу больницасына килеп кергәч, өреп сүндерелгән керосин лампасыдай, бик тиз сүнде. Чөнки мине каршылаучы табиб һәм шәфкать туташларының чырайлары көл төсенә керде.

—Берсеннән котылып тын алырга өлгермәдек, икенчесе...

Күрәсең, мина хәтле умыртка сөяген сындырып кемдер яткан булган.

Минем үземнең дә Урыссу больницасына кайтасым килмәгән иде. Ләкин гади

солдатны Мәскәүгә җибәрмиләр шул. Юкса мин госпиталь башлыгына: «Мине йә Мәскәүгә, йә Казанга җибәрегез!»—дип күпме ялындым. Алар: «Сиңа туган якларында яхшырак булыр»,—дип, үтенечләремә колак салмадылар. Һич югы Баулы хастаханәсенә салсалар, туганнар, дус-ишләр килеп йөрергә әйбәтрәк булыр иде.

Урыссуга салуның сәбәбе: Н. Хрущев хакимияткә килгәч, «оптимизация» дигән нәрсә башлап җибәргән иде. Безнең Баулы районын, Ютазыны һәм Бөгелмәне бергә кушып, без Бөгелмә районына кереп алдык. Берничә елдан ул оптимизация үзен акламады. Кире тарката башладылар. Без бераз Ютазы районы кешеләре булып тордык. Ә Ютазының район хастаханәсе Урыссуда иде.

1959 елның сентябрендә, ниһаять, Баулы хастаханәсенә күчтем. Билгеле инде, анда мине сөенеп каршыламадылар. Шулай да туганнарга, дус-ишләргә килеп йөрергә якын иде. Баулы хастаханәсендәге хәлләр «Җилкәннәр җилдә сынала» повестенда шактый чагылыш тапты. Дөрес, әдәби әсәр буларак күп кенә вакыйгалар гомумиләштереп бирелде. Укучылар андагы геройларның чынбарлыкта ничек булганын сорыйлар. Авыр вакытта ташлап киткән Фәүриягә нәфрәтләнәләр. Укучылар гына түгел, укытучылар да әдәби әсәр белән чынбарлыкның берүк түгеллеген анлап житкермиләр. Әлбәттә, минем тормышта әдәби әсәр кысаларына сыймастай хәлләр күп булды. Һәм әле дә булып тора.

Кайбер вакыйгалар көндәлекләргә керде, кайберләре күпмедер үзгәртелеп, хикәя-повестьларда чагылыш тапты.

Көндәлекләрнең кайберләре югалса да, хәтердә мәңге җуелмаслык вакыйгалар күп. Аларның бөтенесен язып тормыйм, чөнки көндәлекләр урынына истәлекләр яза башлавым мөмкин.

Тагын бер вакыйганы язмый калдырсам, көндәлегемдә өзеклек килеп чыгар.

1961 ел, 12 апрель. Гагаринның космоска очкан көне. Нәкъ шул көнне мине Баулы хастаханәсеннән «очырып» чыгардылар. Моңа шигырьләр язуым сәбәпче булды.

1962 елның июненә кадәр авылда әни һәм туганнарым янында яшәдем.

1962 елның июнендә Казанның «Иске клиника»сына китереп салдылар. Монда килгәндә инде минем хакта газеталарда М. Шабаев, Шевченко язган мәкаләләр һәм үземнең шигырьләрем укучы күзенә күренгәли башлаган иде.

Шушы көннән минем Казан тормышым башланып китте. Түбәнсетүләрнең, кимсетүләрнең бер этабын үтеп, күтәрелү юлына килеп кердем.

## Көндәлеккә ни языла?

Көндәлекне әдипнең автобиографиясе, автор шәхесен күпмедер дәрәҗәдә ачучы, аның тормышка, яшәешкә карашы, яши-яши әдипнең фикерләү эволюциясенең борылышлары, үзе белән аралашкан кешеләргә мөнәсәбәте дияргә мөмкин. Ләкин көндәлек әдәби әсәр булмаганлыктан, авторның фикерләре субъектив. Көндәлек ул истәлек тә, тормыш вакыйгаларын шәрәләндереп бирү һәм тарихка әйләнеп баручы вакыйгаларның чагылышы да.

Бер уйлаганда, язучылар, шагыйрьләр үзләренең күргән-белгәннәрен хикәя-повестьларында, шигырь-поэмаларында теге яки бу формаларда чагылдырып бара. Әйе, бу шулай. Ләкин зур шәхесләрнең, дөньяны киң колачлап язган язучыларның шәхси тормышлары, әдәбият кануннарына сыймаслык вакыйгалары, эчтән кичереп йөреп тә башкаларга әйтәсе килмәгән уйлары, фикерләре була. Кайвакыт бик якын дусларың да берәр этлек эшләргә, сиңа аяк чалырга мөмкин. Арадагы мөнәсәбәтләр бозылмасын дип, үз принципларыңа каршы килеп булса да, аралашып йөргән кешеләреңнең чын йөзләрен дөньяга фаш итмисең. Шунсы да бар: сиңа начарлык эшләгән кешенең башка берәүгә яхшылык кылуы мөмкин. Кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләр бик катлаулы. Гомумән, тормыш турында гына түгел, аерым кешеләргә биргән бәяләребез дә субъектив бәя. Шуңа күрә үзеңнең шәхси тормышыңны ничек булган шулай көндәлеккә генә язып була. Көндәлекнең кыйммәте шунда—анда вакыйгалар кайнар килеш бирелә. Күп вакытта теге яки бу шәхескә интуитив рәвештә көндәлеккә теркәлеп куелган бәяләр еллар үткәч объектив бәягә әверелә.

Көндәлекнең иң әһәмиятле ягы—аны язучының үз шәхесен ачучы документ булуында. Ул кемнәр белән аралашкан, нинди китаплар укыган; рухи һәм матди байлыкка ничек карый; кайсына өстенлек бирә, нинди шартларда үскән; язучылык сәләтенең ачылып китүенә кемнәр яки кемнәрнең әсәрләре ярдәм иткән һ. б.лар, һ. б.лар. Кыскасы, көндәлек ул—язучының биографиясе. Ләкин әдәбиләштерелмәгән, яна туган баладай шәрә һәм

гөнаһсыз. Монда сәясәткә, хакимнәргә яраклашу юк. Укучы өчен көндәлек шунысы белән кыйммәтле. Телиме-юкмы, көндәлегендә язучы үзенә бәя бирә. Көндәлекләр аша аның эрудициясен, фикер зигзагларын, тышкы дөнья, ягъни сәясәт, иҗтимагый тормыш аның акыл үсешенә ничек тәэсир иткәнен күрәсең.

Минә көндәлекне иҗат белән бер чорда яза башларга туры килмәде. Һәр нәрсәнең җае бар, шалканның да мае бар, диләр бит. Көндәлек язарга башта җаем булмады. Беренчедән, армиядә хезмәт иткәндә гомер буена сузылачак имгәнү алып, үлем белән яшәү арасында ятканда көндәлек язу кайгысы башка да килмәде. Андый уй туса да яза алмас идем: кул-аяклар эшләми. Муеннан аркага кадәр сузылган умыртка баганасын ачып операция ясаулар, авызга алюмин кашык белән кайнар аш тутырулар, ашаганнан соң бер уч таблетканы авызга салып, аларны мин төкереп ташламасын өчен санитаркаларның идән юган кулларын ак икәнлеге дә беленми торган халат итәгенә сөртеп, дарулар эреп беткәнче авызны каплап торулар; караватның буеннан-буена сузылган клеенка өстендә ятулар, шул кузгалмыйча ятуларның нәтиҗәсе буларак тәндәге бөтен итнең череп таркалуы һәм бер ай эчендә 65 килолы егетнең 35 килога калуы—тышкы дөнья барлыгын оныттырды.

Бераз рәтләнә төшеп, хәрәкәтсез бармаклар арасына каләм кыстырып кәкре-бөкре хәрефләр белән булса да яза ала башлагач, күңелгә яшьтән тупланып килгән тәэсирләр, кичерешләр шигырь юллары булып иреккә бәреп чыга башлады.

Шунда мин системалы белем алу кирәклеген аңладым. Казан шәһәренең 18нче эшче-яшьләр мәктәбе укытучылары минем укырга теләгемне белгәч 9-10 класслар программасы нигезендә больницаның кысан палаталарына килеп миңа дәрес бирә башладылар. Мин бер елда ике еллык программаны үзләштереп, больницадан өлгергәнлек аттестаты алып чыктым. Мине кеше итәргә теләп үз вакытларын җәлләмичә һәм шул хезмәтләре өчен бер тиен хезмәт хакы алмыйча зур сабырлык белән укытып йөрүче ул укытучыларга мең-мең рәхмәт. Алар мине укытып кына калмадылар—университет ишекләрен ачарга ачкыч тоттырдылар. Билгеле, больница шартларында көндәлек язу мөмкин түгел. Һәркөн дәресләргә хәзерләнәсе, сәгатьләр буена сузылган системалар, яраларны бәйләүләр бөтен вакытны һәм көчне ала иде.

Шулай да үземдә ниндидер көч табып, кулга каләм тотып нидер язган булам. Китаплар укыйм. 60нчы еллар китап уку чоры иде. Газета-журналларның зур тираҗлар белән чыккан чагы. Укыган саен укыйсы килә. Күңелнең баеганы сизелә. Хәзер бит инде миңа өметле яшь шагыйрь дип карыйлар. Ә моны акларга кирәк. Мин университетка керергә әзерләнә башладым. Янымa килеп йөрүче яшь шагыйрьләр Тәүфикъ Камалиев, Рушания Арслановалар әзерләнергә ярдәм итешәбез дип тора.

Тәүфикъ үзе үк минем исемнән Казан дәүләт университеты ректоры Нужин исеменә гариза язып, миннән кул куйдырды да гаризамны университетка илтеп бирде. Беренче керү имтиханын өемә килеп галим һәм шагыйрь Зәет абый Мәҗитов алды.

Больницада ятканда Сибгат абый Хәким, Абдулла ага Гомәр, Шәүкәт Галиев, Илдар Юзеевлар үзләренең китапларына автографлар язып миңа бүләк иткән иде. Палатаның тәрәзә төбе, янымдагы тумбочка китаплар белән тулды. Бер бүлмәле хрущевкага күчкәч, ул фатир миңа хан сарае булып тоелды.

Иң беренче эш итеп бер китап шкафы алып куйдым. Татарстанда чыга торган барлык газета-журналларга язылдым. «Совет әдәбияты» (хәзерге «Казан утлары») минем бәләкәй чактан укып үскән һәм сигезенче класста укыганда беренче шигырьләремне җибәреп, «яз да яз әле» дигән хат алышкан журнал. Беренче булып шуңа язылдым. Һәм баштан ахырга кадәр бер җөмләсен дә калдырмый укый идем.

1962 елда, әле мин Республика клиникасында ятканда, яныма Хәсән Сарьян килде. Кулында «Азат хатын» (хәзерге «Сөембикә») журналы. Хәсән Сарьян ул вакытта «Азат хатын» журналында җаваплы секретарь булып эшли иде. Ул берничә журнал һәм минем журналга җибәргән кульязма хикәямне алып килгән.

—Синмени инде Фәнис Яруллин дигән кеше,—диде ул һәм:—Мин Хәсән Сарьян булам,—дип килеп күреште.

Миңа аның кырыс чырае һәм миеңне тишәрдәй булып карый торган күзләре ошамады. Ул минем хикәямне селтәштереп: «Синең бу хикәяң ике җирдә басылды бит инде, җитмәсә әле монда искитәрлек вакыйга да юк»,—диде. Минем ачу килде. «Синең үзеңнең хикәяләрең өчәр җирдә чыга бит. Башкортстанның «Һәнәк»не ачсаң да син, «Агыйдел»дә дә син. Инде синең шул ук хикәяләрең безнең Баулы һәм Ютазы район

газеталарын басты. Хәзер шуларны «Азат хатын»да бастырып ятасын»,—дидем. Ул чакта мин Башкортстанда чыга торган «Агыйдел», «Һәнәк» һәм «Кызыл таң» кебек газета-журналларны укып барам һәм сирәк-мирәк булса да «Һәнәк»тә кыска юморескаларым, «Кызыл таң»да шигырьләрем дөнья күргәли иде. Хәсән Сарьянның Башкортстаннан килгәнлеген белми идем. Ул минем сүзләрне тыныч кабул итте.

—Башкортстан әдәбияты белән дә танышмени әле син? Ярый, ярый, әйбәт. Үзеңнең әсәреңне шулай кайнарланып яклавың да ошый. Миңа әйткән сүзләреңдә дә хаклык бар. Ә синең бу хикәяңә килгәндә, ул әле йомшак. Казанның таләпләре зур аның. Синең бит шигырьләр шәбрәк. Әзер шигырьләрең булса, бир, алып китәм,—диде.

Әзер шигырьләрем юк иде, бераздан соң хат белән салдым. Ул минем шигырьләрне журналда чыгарды. Ләкин «Доктор әткәмә» дигән шигырьгә карата мондый сүзләр язып җибәрде: «Үзең турында артык зур фикердә икәнсең, доктор булалсаң бик шәп әле ул»,—диелгән иде хатында. Мин ана: «Бу бит шигырь, автобиография түгел»,—дип яздым аның хатына каршы.

Хәсән Сарьян белән бер кызны да «бүлешергә» туры килде безгә. Нәсфия исемле бер чибәр кыз килеп йөри иде миңа. Чибәр кызларга мин битараф карый алмыйм. Хәсән Сарьянның да ул кызга күзе төшеп йөри икән. Кыз, мактанырга теләпме, үзенә багышлап язган шигырьләремне Хәсән Сарьянга укыткан. Шуннан безнең арага салкынлык керде. Хәсән Сарьян белән аралашмый башладык. Шулай да ул безнең туйга килде. Озын көйләр, башкорт җырлары җырлады. Ә теге чибәр кыз каядыр «очып» киткән иде инде.

Күрәсең, минем сүзләрне авыр кабул иткән булгандыр, туй вакытында тост әйтергә рюмкасын күтәргәч: «Фәниснең ачы теле кебек шушы ачы аракыны эчеп куйыйк әле»,—диде.

«Азат хатын»да ул ничә ел эшләгәндер, хәтерләмим, аның урынында Марс Шабаев эшли башлады. Ул да минем иҗатка бик таләпчән булды. «Үзең ничек кенә авырсаң да иҗатың авыру булмасын»,—диде ул һәм мин бу сүзләрне һәрвакыт истә тоттым.

Университетта мин алты ел укыдым һәм аны 70нче елда тәмамладым. Анда миңе Н. Юзиев, М. Мәһдиев, З. Мәҗитов, В. Хаков кебек зур шәхесләр укытты. Университетка кергән елны, ягъни 1964 елны беренче китабым чыкты. Бу шигырьләр авыруым белән көрәшеп, төрле больницаларда язылган шигырьләр иде.

60нчы еллар башында Баулы район больницасында ятканда 90 битлек, амбар кенәгәсе дип йөртелә торган зур дәфтәрне шигырьләр һәм больницада эшләүче кешеләр турында төрле язмалар язып тутырган идем. Ул дәфтәр кулдан-кулга йөрде һәм, ниһаять, шәфкать туташлары кулына, аннары дәвалаучы табибларга барып җитте дә юкка чыкты. Аның юкка чыгуына исем китмәде. Чөнки андагы кайбер шигырьләр 1960 елда Баулы район газетасында басылган иде инде. Андагы язмаларда, зур әһәмияткә ия булмасалар да, минем өчен иң авыр чорның кайбер төсмерләре чагылмый калмагандыр. Ләкин иң кыйммәтле нәрсәсен—сәламәтлеген югалткан кеше өчен бер дәфтәр язма югалту—анализга кан алганда бер-ике тамчы канның читкә тамуы кебек кенә иде. Дәфтәр югалган икән—минем бит әле хәтер бар. Ә хәтердә балта белән дә юнып алып булмаслык вакыйгалар саклана. Менә гаҗәпкә калдырганы шул булды: иң гуманлы һөнәр ияләре мине аллау-йоллау юлы белән больницадан чыгардылар. Имеш, алар мине Казанга җибәрергә җыеналар. Ә анарчы миңа туган-тумачаларым янында ял итәргә, авыл һавасы суларга кирәк. Ә мине Казанга алып китәчәк самолет бер-ике атнадан килеп җитәчәк икән. Ул бер-ике атна дигәне ел ярым булды. Үкчәдән алып муенга кадәр сузылган яраларны әни һәркөн бәйләп торды. Абыем Фәһим күтәреп мунчага алып барды. Яманлык белән яхшылык янәшә йөргәнлеген шунда барлык күзәнәкләрем белән татырга туры килде. Өйдә сәгать саен бер яктан икенче якка әйләндереп яткырулар, мунчада чабына-чабына юынулар, ә иң мөһиме—сиңа артык кеше итеп карамаулар үзенекен итте: җәрәхәтле урыннарның мәйданы кимеде. Шигырьләр, хикәяләр туып кына торды. Шигырьләрне мин гадәттә төнлә уйлый идем. Кайбер төнне икешәр-өчәр шигырь туа, ә иртән аларны сеңлем Һәнүзәдән дәфтәргә күчертәм. Аннары аларны бөтен гаилә белән кычкырып укыйбыз, бәхәсләшәбез. Гаилә «редколлегия»сендә әйбәт дип табылганнарын Баулы, Ютазы һәм Башкортстанның Октябрьский каласында чыга торган (газетаның исеме онытылган) газеталарына җибәрәбез. Район газеталарының таләпләре бик югары булмагандыр, күрәсең. Җибәргән шигырь-хикәяләремнең күбесе басылып чыга иде. Район газеталарында дөнья күргән әсәрләремнең берсен дә китапларыма

кертмәдем. Әмма ул газеталар минем күнелемдә зур ышаныч уяттылар. Өйгә хатлар һәм төрле авыллардан яшь кызлар килә башлады. Мин кыюлана төштем. Шигырь-хикәяләремне республика газета-журналларына да юлларга тотындым. Казаннан безгә язучылар килә башлады. Бу хакта «Сөенечләр бүлешү» дигән китапта язылганлыктан, кемнәр һәм кайчан килүләре, ничек ярдәм итүләре турында язып тормыйм. Бары тик «Яшь ленинчы» (хәзерге «Сабантуй») газетасыннан Марс Шабаев килеп, ике көн буе минем хикәя-шигырьләремне укып, кайберләрен күчереп алып Казанга алып китүен, ә Казанга кайткач «Татарстан яшьләре», «Яшь ленинчы» газеталарына зур-зур мәкаләләр язуын һәм шигырьләремне бастыруын кабатлап булса да әйтми кала алмыйм. Республика газеталарында шигырьләрем чыгу мина яна дәрт өстәде.

Иҗатымның башында ук шактый шигырьләрем рус теленә тәрҗемә ителеп, Мәскәү газета-журналларында фоторәсемем белән басылуга, рус кызларыннан хатлар, фоторәсемнәр ява башлады. Авиация формасында бик горур кыяфәт белән чыккан фотомны күргәч, кызлар мине бик гайәр егет дип күз алдына китергәндер, күрәсең. Ленинградтан Инна Латынина дигән бер кыз белән шактый хатлар алыштык. Ул минем авыруымның диагнозын сорап язды һәм диагнозны Ленинград профессорларына күрсәтеп, Ленинград больницасына алырга да теләгән иде, ләкин барып чыкмады. Больницага алмадылар. Аннары ул Инна үзе килде. Мине күргәч, «аһ» итте. Чибәр яшь кыз. Ә мин 35 килолы сөяк җыелмасы. Ул минем өскә ябылган одеялны ачып карады да тәгәри-тәгәри елады. Безнен Нурсөя белән өйләнешмәгән чак. Чибәр Инна елап туйгач: «Мин иртәгегә Ленинградка кайтырга билет алырга барам, кунарга сезгә кайтам»,—дип чыгып китте дә юк булды. Күрәсең, аның нияте мине сәламәтләндерү генә булмаган, егет кеше буларак мин нииндирәк, шуны үз күзе белән күрәсе килгәндер. Мине кызлар нишләптер урын өстендә генә ята дип күз алдына китерми иде. Күбесе: «Син бераз йөрисеңдер инде»,—диләр иде. Мин шаяртып: «Кай көннәрдә кызлар озатып кайткалыйм»,—дия идем.

Мин көндәлекләрнең баштарак ни өчен язылмавы турында сүз башлаган идем. Хәер, көне-сәгате белән укылган китапларны, килгән кешеләрне көндәлек формасында дәфтәргә теркәп барырга вакыт та калмый иде. Көне буе кешеләр килә: кемдер миннән кинәш сорый, кемдер үземә кинәш бирә.

Шигырь, хикәяләр иҗат итәргә, газета-журналларга яна шигырьләр әзерләп бирергә, китап нәшриятына яна җыентык туплап тапшырырга, университетта укырга, димәк, күпме контроль һәм курс эшләре язарга кирәк. Житмәсә әле кайбер укытучылар укыган китапларга конспект язуны таләп итәләр иде. Яза идем инде, язмасаң, имтиханны алмыйлар. Уку авыр. Ләкин бер башлагач ташлыйсы килми. Үзеңнең офыкларыңның киңәя баруын сизәсең. Психологик моментларны сурәтләгәндә кайсы язучы нинди ысуллар кулланган, табигать белән кеше гармониясен кемнәр ничек тасвирлаган—шуларны өйрәнәсең. Ләкин бу аларча язу өчен түгел. Киресенчә, элгәрләрне кабатламас өчен кирәк. Тора-бара шуны аңладым: кешегә таләпне никадәр күбрәк куйсаң, ул шуның кадәр күбрәк эшли. Кешенең мөмкинлекләре чиксез. Марс Шабаев: «Син күп язма, ашыкма»,—ди иде. Без бу мәсьәләдә еш кына бәхәсләшә торган идек. «Бер шигырьне ун көн язсаң, ул ун төрле була, кайнап торганда гына ул әйбәт чыгарга мөмкин»,—дия идем. Университетта укыган алты ел өчендә мин алты китап чыгарганмын. Беренчесен әйткән идем инде. «Мин тормышка гашыйк»,—1964. Шигырьләр җыентыгы.

1966—Май төне. Проза

1967—Бакчалар бәскә төренә. Шигырьләр.

1968—Минем елмаю. Балалар өчен шигырьләр.

1969—Ачсаң күнел тәрәзәләрен. Хикәяләр.

1970—Гел ашыгам. Шигырьләр.

Дөрес, алар калын түгел, йомшак тышлы, кечкенә форматлы китаплар. Кечкенә булып чыгуларының сәбәпләре бар. Беренчедән, мин ике жанрда берьюлы эшләдем. Ә нәшрият хикәя белән шигырьләрне бергә чыгармый иде. Икенчедән, мина таләпне бик зурдан куйдылар. М.Шабаев беренче килүендә үк: «Синең әсәрләрең сәламәт кешеләрнекеннән, кимендә ике башка югары торса гына дөнья күрәчәк. Таза кешеләр үз әсәрләрен яклап редакцияләргә, нәшриятка бара алалар. Кайберләре редакторларны туйдырып бетереп булса да әсәрләрен бастыралар. Ә син алай итеп йөри алмыйсың. Икенчедән, авыру кешегә киләчәге юк кеше дип карыйлар. Тагын шул: син артык күп язасың. Күп эшләгәндә, җибәрмим дисән дә брак китә».

М. Шабайның бу сүзләре белән мин килешмәдем. Күбрәк язган саен остарасың, дидем.

«Бакчалар бәскә төрәнә» китабы мин Бәкер курортында дәваланып ятканда чыкты һәм аны Разил Вәлиев тиз арада күреп алып, миңа почта белән җибәргән иде. «Фәнис абый,—дип язган иде ул хатында,—менә, бер уч шигырьләрең китап булып басылып чыккан. Мин ул шигырьләрне бер сулышта укып чыктым. Синең өчен шатландым. Үзең дә шатлана торсын дип почта белән китабыңны үзеңә җибәрәм. Миңа шигырьләрең ошады. «Яратмыйм ясалма чәчәкне» дип башланган шигыреңне ятлап та өлгердем».

Разил миңа карата нишләптер бик игътибарлы булды. Унынчы класста укыганда бер иске мотоцикл белән Бәкер курортына мине күреп, сөйләшеп утырыр өчен килгән иде. Үзенең йөрәгендә шигырь уты дөрли башлаган чак булгандыр инде. Гомумән, Разилдә кешене шатландырудан тәм табу хисе көчле. Мондый сыйфат кин күңелле кешеләрдә генә буладыр.

Күп кенә шагыйрьләр китабың чыккач исәнләшми дә башлыйлар. Китапларым ел саен чыгып торгач: «Син авыру кеше булганга, җәлләп чыгаралардыр инде»,—дип әйтүчеләр дә очраштыргалады. Андыйларга мин болай дип җавап бирә торган идем: «Менә син аяк-кулларыңны селкенмәслек итеп бәйләт тә һич югы бер-ике ай түшәмгә генә карап ят. Авызыңа ашны хатының алюмин кашык белән салып торсын. Түшеңә дәфтәр белән каләм куйдыр. Бер бармагың да селкенмәгән килеш шигырьләр, хикәяләр яз, китаплар укы. Университет укытучыларына имтихан бир. Атналык «Литературная газета», журналлар укы. Нәрсә яза алырсың икән һәм язганнарыңны сине кызганудан басарлар микән?!» Әле бит бәйләнеп яту авыру дигән сүз түгел, бәйләнгән кеше үзен бер чишәселәрен белә. Авыру исә өметсезлеккә бирелергә, сызлануларга түзә алмыйча еларга, сүгенергә, дөнья күрә алмаслык дәрәҗәдә нәфрәтләнергә, сәламәт кешеләрнең бөтенесен үзе кебек авыру итәргә теләргә мөмкин. Шушы түбәнлеккә төшмичә, упкыннарны сикереп үтү һәм үзеңне түбәнгә сөйрәүче канлы яраларны ялый-ялый күтәрелү кирәк иде. Ә моның өчен фани дөньяның ваклыкларын иңнәреңнән коеп төшереп, хыялың белән булса да һавада очкан аккошларның канатына утырып диңгезләр кичәргә, Робинзон Крузо кебек үз утравыңны табып үз дөньяңны корырга һәм һәр иртәне сине олы дөньяга алып чыгучы караб килүенә өметләнеп яшәргә кирәк. Җаныңда өмет уты булганда кеше барлык авырлыкларга да түзә ул.

Университетта укыган вакытта һәр көнне бер китап укып чыгуны үземә максат итеп куйдым. 300 битлекме, 400 битлекме—шуны укып, эчтәлеген күңелдән сөйләп чыгам. Шунсыз өлгереп булмый. Әле бит дистәләрчә газета-журналлар көтеп тора. Китап-журналлар укыйммы, үз әсәрләремне язаммы—андый чакта минем янда бер кеше дә булмаска тиеш. Башка авторларны укыганда да, үзем язганда да бөтенләй башка дөньяга чумам: Э. Хемингуэйның балыкчы карты белән диңгездә йөзәм; Д. Лондон геройлары белән ерак сәфәрләргә чыгып алтын эзлим; Драйзер персонажларына сабын сатышам; П. Мерименың Дон Жуаны белән сәяркәләр кочагына керәм; О. Бальзак героиняларын монастырьдан алып кайтышам; Л. Толстойның Наташасына гашыйк булам; А. Пушкиннан Натальясын тартып алам; Гогольның Ревизоры булып йөрим; Г. Тукайга әверелеп яланаяк салкын идәннәрдә басып торам; Г. Ибраһимовның Алмачуарына атланып хыялыма чабам. Кыскасы, һәркөн мин кемдер булам; кемнедер җиңәм, кемнәндер җиңеләм.

Болары әле язучылыкка әзерлек кенә. Төннең кара пәрәнҗәсе күк йөзен каплагач, мин хыял дөньясына чумам. Көндез яныма килеп йөргән кызларга гашыйк булам. Аларга багышлап шигырьләр язам. Ул образлар минем төшемә кереп, миңа мәхәббәтләрен аңлаталар. Бергә булыйк дип кулларын сузалар. Тик куллар-кулга тоташырга өлгерми, әллә каян төн ефәгенә очкын төшә дә пәрдә дөрләп яна башлый. Сузылган куллар тартып алына. Ике арага бушлык элено.

Әмма тамырларда кайнар кан агудан туктамый. Хыял аты мине Каф тауларына алып менеп китә. Тауның иң биек кыясына шигырь язам, ә уянгач, истә калганнарын дәфтәргә төшерәм.

Врачлар: «Ятып уку күзеңне бетерә»,—дисәләр дә, башкача уку һәм язу мөмкинлеге булмагач, ятып укырга, ятып эшләргә, ятып ашарга туры килә. Бер уйласаң, ятып уку-язуларның файдасы бар икән. Язу өстәле кирәкми, кухняга чыгып ашыйсы юк; артык урындык һәм артык урын кирәкми. Шуңа күрәдер инде, миңа озак еллар буе кухнясы 5 кв.метрлы хрущевкада яшәргә туры килде. Елый белгәннәр тиз арада фатирдан

фатирга күчтеләр. Халык: еламаган балага имчәк бирмиләр дип дөрес әйтә. Мин елый белмәдем.

Алтмышынчы еллар ахырында мина «Крутушка» санаториена путевка бирделәр. Ана кадәр инде мин биш мәртәбә «Бәкер» курортында дәваланып яткан идем. Казан больницасыннан соң монда мина оҗмах булып тоелды. Авыруларга мөнәсәбәт әйбәт. Ашсулары мактап бетергесез. Ә ин шәбе—монда яшь кызлар эшли. Һәр елмаеп караучыга гашыйк булам. Кич белән кызлар мине кресло-караватка яткырып табигатькә алып китәләр. Мәхәббәт анлашулар, татлы үбешүләр...

Йә, ярый, боларын сөйләп тормыйм. Мактануга китә. Ә менә «Бәкер»гә Илһам Шакировлар, Габдулла Рәхимкуловлар килеп концерт куюларын онытырлык түгел. И. Шакиров әле гармунчы белән генә җырлый иде. Кулын кая куярга белмәгәнлектән, шырпы кабы кебек бер нәрсәне ике куллап тотып, сәхнәдә селкенмичә дә басып җырлавы хәтердә. Әле мин сәламәт чакта безнең авылга Фәридә Кудашеваның, бераздан Рәшит Ваһаповның килгәне бар иде. Алар сәхнәдә үзләрен иркенрәк тоттылар. Рәшит Ваһаповның концертын клуб мөдире магнитофонга яздырып алган иде. Аны үзебезнең колхоз радиосы күп тапкырлар кабатлады.

Ә Рәхимкулов «Бәкер»гә Нажия Теркулова белән килгән иде. Эмоциональлеге тәэсир иттеме, аны халык яратыбрак тынлады. И. Шакиров моңа үпкәләмәс дип уйлыйм: артистның концерты тамашачыдан тора. Клубка бит татарлар гына түгел, башка милләт халкы да килә. Бәлки И.Шакиров концертында башка милләт халкы күбрәк булгандыр. Алтмышынчы елларда әле И.Шакиров танылып кына килә иде.

Без «Крутушка»га әни белән бардык. Нурсөя заводта эшләгән чак. Мине карарга кеше кирәк. Әмма мине берничә кеше ята торган палатага салдылар. Әни шунда бер тапчанда ята. Ә минем ашау-эчү һәм башка эшләр караватгөстендә эшләнә, мин әни белән икебезгә аерым бүлмә сорасам да, үтенечемә колак салучы булмады. Әмма кайвакыт бәхет кояшы да елмаеп куя бит ул. Мин тышта раскладушкада яткан чагында кырыема ике кеше килеп туктады. Боларның берсе Габдулла Шамуков, икенчесе Мәсгуть Имашев иде. Г. Шамуков: «Кемне күрәм, Фәнис туган, син түгелме соң бу?—дип кочагына алды.—Теге вакыт авылыгызга килгәч, тәнеңне сыпырып карарга кыймаган идем, бик ябык икәнсен, туганкай»,—дип, ул өскә япкан юка җәймә өстеннән бөтен гәүдәм буйлап кулын йөртеп чыкты. Аннары мине М. Имашев белән тыныштырды. Сөйләшә киткәч, минем кайсы палатада икәнемне сораштылар. Дүрт кешелек палатада икәнне белгәч, Г. Шамуковның ачуы чыкты. Без сөйләшеп торганда әни читтәрәк иде. Г. Шамуков әнине күреп алды да: «Ә-ә, апа да монда икән, бик әйбәт,—диде һәм:—Әйдәгез әле, апа, бер кабинетка кереп чыгыйк. Мәсгуть, син дә ияр»,—дип, әнине санаторийның баш врачы утыра торган кабинетка алып кереп китте. Берничә минуттан күзләрен яулык чите белән сөртә-сөртә әни, аның артыннан минем яңа дусларым килеп чыктылар.

—Булды,—диде Габдулла абый,—сезне аерым палатага салачаклар.

Әнинең күзләре шул сөенечтән яшьләнгән икән. Безне ике кешелек бүлмәгә күчерделәр. Артистларның дәрәҗәсе язучыныкыннан зуррак икән дип уйладым. Бәлки бу тама-тама ташны тишүче тамчы булгандыр. Чөнки мине аерым палатага салу өчен санаторийда эшләүче врач Магаз Галиәхмәт улы Галиәхмәтов та тырышып йөри иде. Магаз Галиәхмәтович, мине элек Бәкер курортында дәвалаган табиб, нигәдер мине якын итә иде. Монда, «Крутушка» санаториенда, анарга ике бүлмәле фатир биргәннәр. Санаторийдан киткәндә: «Киләсе елда үзебезгә кунакка килегез, балыкка йөрербез»,—дип калды. Без Нурсөя белән аларда бер атнага якын кунак булып яттык. Урманга, су буйларына бардык. Балык каптырдык. Су коендык.

Җәйнең матур вакыты иде. М.Имашев белән Г.Шамуков урманнан сабагы белән каен җиләге җыеп безгә алып керәләр. Без төрле мәзәкләр сөйләшеп чәй эчәбез.

Шулай 26 көннен үткәне сизелми дә калды.

*Дәвамы киләсе саннарда*

# БӨЕКЛЕК БАСКЫЧЛАРЫ

## 1910 ел

**Кыш—яз.** Тукайның дусты һәм замандашы Вафа Бәхтияров истәлегенә караганда, шагыйрь 1910 елның кышында 4—5 ай чамасы «Амур» номерларында (хәзерге Киров урамы, 70 нче йорт), 3 нче катта, 33 нче бүлмәдә яши. «Ачы тәҗрибә авазы», «Авыл җырлары», «Ник? Нигә?» исемле шигырьләрен монда яза.

**1 гыйнвар.** «Татар мөхәрриренә» исемле шигырен яза. И. Нуруллин: «Тукай 1910 елны... гаять тәшвишле шигырь белән каршы ала»,—дип искәртә.

М. Бигиев «Рәхмәте илаһия гомумияте хакында борһаннарым» дигән күләмле мәкаләсенә эпиграф итеп Тукайның «Васыятем» шигыреннән дүрт юлын китергән:

*Дустларым, кордашларым! Сез муллаларга әйтегез:*
*Шул ике юлны мин үлгәч укырлар кабремә.*
*Әһле тәкфир бер гаҗәпләнсен күреп актык сүзем:*
*«Күр, нә рәсмә тулган иман илә Коръән садремә!»*

**3 гыйнвар.** «Татар мөхәрриренә» шигыре басылып чыга.

**7 гыйнвар**. «Нәсыйхәт» шигыре басыла.

**12 гыйнвар.** Г. Ибраһимовның «Габди» имзасы белән басылган «Татар матбугаты» дигән тәнкыйть мәкаләсендә Тукай шигырьләре, аларның татар әдәбиятында тоткан урыны һәм укучыларның бу иҗатка мөнәсәбәтләрен күрсәтеп язылган мондый юллар бар: «Хәзер шигырь мәйданында иң шәүкәтле вә галәбәле рольне мөхтәрәм Тукаев уйный. Шул дәрәҗә ки: татар шагыйре диелүгә, укучы зиһенендә Тукаев мәүҗүд була. Бу шагыйребез көннән-көн күтәрелә. Халык күңелендә хак вә ихтирамлы урын ала барадыр. Татар шигыре мәйданында Тукаев иң гали ноктада тора... шулай булуы табигыйдер, чөнки табигый талант вәһаби истигъдад янында әһбабе һәвәс вә әҗ-ваф яшәргә мөмкин түгел». Бу озын мәкаләдә Г. Тукайдан тыш, Г. Исхакый, Ф. Әмирхан һ. б. язучыларның иҗатына да күзәтү ясалган.

**19 гыйнвар.** «Идел» газетасы Тукайның шигырьләр җыентыгы басылып чыгу унаеннан игълан урнаштыра: «Балалар күңеле» ибтидаи сыйныф балаларына укытыр өчен Габдулла Тукаев тарафыннан тәртип ителмеш дәрес китабы, шигырьләр мәҗмугасыдыр. Гаять гыйбрәтле вә гаять файдалы, балаларның рухларын вә милли хиссиятләрен уйгатуга хезмәт итәчәк».

**4 февраль.** «Яшен» журналы чыгудан тукталганнан соң, 8 ай үткәч, демократик яшьләрнең һәм Тукайның тырышлыгы белән Әхмәт Урманчиев «Ялт-йолт» дигән сатирик журнал чыгарырга рөхсәт ала.

«Мәҗрух указ» шигырен яза. Ул элекке Самар губернасы (хәзерге Оренбург өлкәсе) Бозаулык шәһәре мулласы, язучы Галиәсгар Гафуровның (Чыгтайның) «Исабәт» исемле китабына каршы күтәрелгән шау-шу унае белән язылган.

*Дәвамы. Башы 8 санда*

Кадимчеләрнең басымыннан куркып, Чыгтай, үзенең фикерләреннән кайтып, китабын яндыра һәм «тәүбә» итү һәм указын саклап калу өчен, Уфага Духовное собраниегә бара.

**7 февраль.** «Мәжрух указ» шигыре басылып чыга.

**23 февраль.** «Кәҗә тугрысында» шигыре «Шүрәле» имзасы белән дөнья күрә.

**15 март.** Казанда Әхмәт Урманчиев редакторлыгында һәм нәширлегендә, секретаре Г. Тукай булган рәсемле сатирик «Ялт-йолт» журналының 1 нче номеры чыга. Демократик юнәлештәге бу журнал 1918 елга кадәр дәвам итә.

Истәлекләрдә (мәсәлән, К. Бәкер, Г. Камал) бу журналның Тукай инициативасы белән чыгарыла башлавы, үлгәнчегә кадәр журналда аның берьялгызы эшләве әйтелә.

**23 март.** «Жәйге таң хатирәсе» исемле шигыре басыла. Әсәр рус шагыйре А. М. Федоровның «Рассвет» дигән шигыреннән файдаланып язылган.

**26 март.** «Яңа әсәрләр» исеме астында рецензия басылып чыга. Биредә «Кәшшаф Патин шигырьләре» исемле җыентыкны мактап язылган. Кәшшаф Патинның иҗатын Тукай белән чагыштырып: «Г. Тукайдан соң беренче шагыйремез»,—диелә.

**1 апрель.** «Ялт-йолт» журналының икенче номеры басылып чыга. Биредә Тукайның түбәндәге әсәрләре урнаштырылган: «Шүрәле» имзасы белән «Авыл җырлары» (дүртенче көлтә) шигыре, «Догачы шүрәле» имзасы белән «Яшен» мәрхүм» исемле мәкаләсе.

Шунда ук «Тиле» имзасы белән «Ихтар», «Шүрәле», имзасы белән «Авыл җырлары» (дүртенче көлтә) урнаштырылган. «Үзе сәркатип булган журналда ике әсәре арасына башка берәүнең биш-алты юллык кына текстын кертеп җибәрмәс иде Тукай. ...«Ихтар»—һичшиксез, аныкы. «Тиле» имзасы текстның эчтәлегеннән чыгып куелган»,—дигән фикер әйтә З. Рәмиев.

**12 апрель.** «Күңелле сәхифәләр» исемендә рәсемнәр белән бизәлгән, балалар өчен язылган шигырьләр җыентыгы басылып чыга. («Мәктәп мөкяфәте»ннән 4 нче китап. Казан, «Сабах» көтепханәсе, «Милләт» матбагасы. 16 б., 5000 данә.) Бу китапта «Имтияз алган бала», «Һәр ялтыраган алтын түгел», «Безнең гаилә», «Гали белән Кәҗә», «Фатыйма белән Сандугач», «Һәркемнең ашыйсы килә», «Ялкау Маэмай», «Шаян Песи», «Кызыклы Шәкерт», «Бичара Куян», «Ак Бабай», «Кичә һәм Бүген» дигән шигырьләр кертелгән.

**8—13 апрель.** Йолдыз газетасында «Лекция. Ушбу тиз арада «Шәрык» клубы залында Габдулла әфәнде Тукаев халык әдәбияты тугрысында лекция укыячак»,— дигән игълан урнаштырыла.

**15 апрель.** «Йолдыз»да «Катиле нәфескә» шигыре басыла һәм шунда ук игълан-реклама бирелә:

«Бүген, пәнҗешәмбе, 15 апрель, кич 9 сәгатьтә «Шәрык» клубында Габдулла әфәнде Тукаев халык әдәбияты турында лекция укыячак. Билет бәясе утыз тиеннән унбиш тиенгә кадәр».

Тукай «Шәрык» клубында үзенең «Халык әдәбияты» дигән лекциясен укый. Тыңлаучыларның күбесе Казанның зыялы яшьләре һәм шәкертләрдән гыйбарәт була.

Язучылардан Гафур Коләхметов катнашканлыгы мәгълүм.

Лекциянең тарихын ул үзе болай аңлата: «Мин халык әдәбияты тугрысында лекция укыйм»,—дип әйткән идем. Ул, шунар ышанып, Тукаев лекция укыячак икән, дип, могтәбәр гәзитәләребезнең берсенә язып та өлгергән.

Мин, ул иптәшем яныннан чykканда, уйнап әйттем, ышанып калма тагы, дип әйтергә онытканмын.

Менә шулай итеп, ялгыш, уеннан уймак чыгып куйгандай булып, мин, теге гәзитә хәбәрен тәкзибкә-фәләнгә керешмичә, чынлап та халык әдәбияты хакында үземнең белгән вә хис иткән кадәр фикерләремне сөйләргә җәсарәт итәм».

Татар теле һәм фольклор галиме, профессор Хуҗа Бәдигый Тукайның әлеге лекциясен тыңлаган кеше, үзенең истәлегендә болай яза: «Теоретик материал күп булмаса да, лекция миңа бик ошады. Тукай үзенең лекциясендә, хәзерге күзлектән караганда да, халык әдәбиятының (фольклорның) эчтәлеген яхшы ук дөрес билгеләп бирде».

**21 апрель.** «Ачы тәҗрибә авазы» шигыре басылып чыга.

**29 апрель.** «Халык моңнары» исемендә халык җырларын эченә алган китабы *(Казан, «Сабах» көтепханәсе, «Милләт» матбагасы)* «Җыючысы Шүрәле» дигән имза белән басылып чыга.

Бу җыентыкка кыска һәм озын көйләргә җырланган халык җырлары, «Сак-Сок» бәетләре кертелгән.

**1 май.** «Ялт-йолт» журналының дүртенче саны басылып чыга. Бирелә: «Киләчәктә «Яшен» журналының мөштәриләренә «Ялт-йолт» җибәреләчәк»,—дигән игълан урнаштырылган. Бу факт. Әлеге ике журнал бер-берсенең традицияләрен дәвам иттерүче икәнлеген тагын бер кат раслый.

Бу санда шагыйрьнең:

*Биек тауның башында күренәдер бер авыл;*
*Хатын өстенә хатын асрау менә шулай була ул,—*

дигән ике юллы шигыре рәсем асты рәвешендә имзасыз басылган. Аска «Авыл җырлары»ннан» дип куелган. Рәсемдә татарча җыештырылган бүлмә. Сандык өстенә мендәр өелгән. Стенада Мәккә-Мәдинә сурәте. Ике хатын өстәл кырыенда бер-берсенә артларын куеп утырганнар; әле генә кычкырыш-канлыклары аңлашыла. Кәҗә сакаллы, кара түбәтәйле ир-ат пары чыгып торган самовар күтәреп килә.

Шунда ук «Тутый» (З. Бәшири) имзасы белән «Мулла» дигән шигырь басылган. *(«Г. Тукаевнын «Ишан» шигыренә гыйлавә» дип куелган.)*

2 май. «Кайчакта» шигыре басылып чыга.

12 май. «Гомер юлына керүчеләргә» шигырен яза.

16 май. «Гомер юлына керүчеләргә» шигыре басылып чыга.

20 май. «Вакыт» газетасы игълан урнаштыра.

«Яна китап... «Халык моңнары» «Шүрәле» әфәндене камил муаффәкыять илә интихаб иткән, һәркемнең милли хисләрен кузгатырдай җырлар мәҗмугасыдыр».

**22 май.** «Өмидсезлек» шигыре басылып чыга.

**Май.** Г. Тукай Ташаяк ярминкәсендә була, карусельдә әйләнә. «Туйганчы бала чакта эләкмәгәннең «үчен алдым»,—дип сөйли азактан дусларына.

Петропавловскида җәдид мәктәбе укытучысы Кәшфи Мостафин хосусый рәвештә русча укыр өчен Казанга килә. Тукай белән танышып, аннан киңәш сорый. «Репетитор профессионал» студент Моисей Адольфович Берлин турында сораштыра. Тукай аңа: «Ул студент бөтен фәннән берүзе өлгерү аттестаты алуга әзерли ала, өч-дүрт тел белә. Ул гыйлем тәпәне инде. Мин сезгә аннан укырга киңәш итәм»,—ди.

Кәшфи Мостафин белән Панаев бакчасына спектакль карарга баралар.

«Бу вакытта Тукай «Болгар» кунакханәсендә яши иде»,—ди истәлек авторы.

**Җәй.** Замандашларының истәлекләренә караганда, каләмдәш дуслар—Г. Тукай, Ф. Әмирхан, В. Бәхтияров, Я. Байбурин Казанда Ботаник бакча (хәзер Зооботаника бакчасы) каршында квартира алып, дача сыман итеп яшиләр. Тукай һәм Әмирхан аерым-аерым бүлмәләрдә, Вафа белән Якуб бергә торалар. Алар янына еш кына дуслары, интеллигентлар килеп йөриләр.

**1 июнь.** «Акыллы башлар» исемле фельетоны «Гөмберт» имзасы белән басылып чыга.

**6 июнь.** «Хәле хазир» исемле шигырен яза.

**10 июнь.** «Хәле хазир» шигыре дөнья күрә.

**20 июнь.** «Халык әдәбияты» китабы *(Казан, «Сабах» көтепханәсе, И. Н. аритонов матбагасы, 43 б., 2000 данә)* басылып чыга.

Китапка нәширләр тарафыннан язылган кереш сүздә мондый юллар бар: «Габдулла әфәнде бу әсәрендә халык әдәбияты, халык җырларының нидән гыйбарәт идекене вә аның сонгый әдәбият вә сонгый җырлардан ничек аерылдыгы хакында ачык вә төпле мәгълүмат бирә.

Татар халәте рухиясенең аңларга теләүчегә бер данәсене алып уку һәм бөти кебек үзе илә саклау лаземдер».

**28 июнь.** «Үкенеч» исемле шигырен яза.

**1 июль.** «Үкенеч» шигыре басылып чыга.

«Нечкә хиссият» әсәре «Шүрәле дип белгәйсез» дигән имза белән, «Фәлсәфи сүзләр» әсәренең беренче кисәге «Фәйлә-сүфләр» имзасы белән басылып чыга.

**2 июль.** «Хасият» шигырен яза.

**2 июль.** Вакыйф Җәләлнең «Истикъбаль өмидләре» *(Тукаевның «Өмидсезлек» әсәренә каршы)* шигыре басыла. Оптимистик рухта, төшенкелеккә бирелмәскә, киләчәккә өмет белән карарга чакырып язылган бу шигырьдә автор Тукайны ялкынлы шагыйрь дип атый.

**6 июль.** «Хасият» шигыре басылып чыга.

**9 июль.** «Әдәбият» исемле шигырьләр китабы («Шигырьләр көтепханәсе»ннән 10 нчы дәфтәр. 2 нче басма. Казан, «Мәгариф» көтепханәсе) дөнья күрә.

**13 август.** «Яңа әсәрләр» дигән рубрика астында «Идел»дә Тукай әсәрләренә реклама рәвешендә игълан басыла: «Халык моңнары». Мәшһүр җырчы «Шүрәле» әсәре. «Халык әдәбияты» китабы—бәетләр, җырлар хакында, бөтен булмаса да, күңелле мәгълүмат биргән бер китап. Беренче шагыйрьләребездән Г. Тукаевның әсәре. Ул, «Шәрык» клубында Тукаев тарафыннан лекция итеп укылганнан соң, «Сабах» көтепханәсе тарафыннан табгы ителеп нәшер ителгән».

**15 август.** «Сибгатуллин» шигыре, «Гөмберт» имзасы белән «Бозау кадәрле зур фәлсәфә» исемле фельетоны басылып чыга. Тукай бу әсәрен үз чорында Россиянең төрле өлкәләрендә чыккан газета-журнал, китап бастыру оешмалары, типографияләр, әдәби әсәрләр исемнәренең сүзлек мәгънәләрен файдаланып язган.

**22 август.** «Иссез чәчәк», «Баскыч» шигырьләре дөнья күрә.

**23 август.** «Бер мән» шигырен яза.

**15 сентябрь.** «Мөбарәк тәсбих өзелде» исемле нәсере басылып чыга. (1910 елның көзендә (7 ноябрь) Л. Н. Толстойның вафаты уңае белән язылган нәсер.)

Л. Н. Толстойның үлемен Тукай бик авыр кичергән, аны олы кайгы итеп, тетрәнеп кабул иткән. Бу зур югалту турында хисләрен белдерү өчен нәсер жанрына мөрәҗәгать итүне үзенең вөҗдан эше дип караган. Әсәргә китергән эпиграфта шагыйрь:

*Ушбуны яздырды нәсрән вөҗданымның көчләве,*
*Мәсьәлә бик зур—сыйдырмый тар шигырьләр үлчәве,—*

дигән. Толстой иҗатын Тукай бәяләп бетергесез әхлакый кыйммәт дип саный, аны «бөтен җанварларның җаны һәм бөтен инсаннарның вөҗданы» дип олылый. Нәсеренең башыннан алып азагына кадәр Толстой һәм кояш образларын янәшә куеп тасвирлый. Аның үлеме турында йөрәк өзгеч хәбәр килгәч, бөтен дөньяны караңгылык һәм салкынлык чолгап ала: «Кояш йөзен чытты. Елады. Инде көлми. Агар сулар дәфгатән бозландылар...»

Тукай Л. Н. Толстойның рус әдәбияты тарихындагы урынын бик тә югары куя, аны рус әдәби «дисбесенең» Мәрьям анасы, Имамы, ягъни рухи җитәкчесе дип атый.

«Милләткә файда урынына зарар» мәкаләсе «Гөмберт» имзасы белән басыла. Ул шагыйрь Мәҗит Гафуриның «Милли шигырьләр», «Кызларга махсус милли шигырьләрем» исемле шигырь җыентыклары басылып чыгу уңае белән язылган.

**22 сентябрь.** «Актык тамчы яшь», «Бер мән» исемле шигырьләре басылып чыга.

**5 октябрь.** «Яңа кыйраәт» исемле китабы *(үзгәртелгән, өстәлгән 2 нче басма. Казан, «Үрнәк» матбагасы)* басылып чыга.

**15 октябрь.** «Мөфти җүбәләе» исемле фельетоны имзасыз басылып чыга. Биредә 1886 елда Россия һәм Себер мөселманнарының дин башлыгы итеп сайланган мөфти Мөхәммәдьяр Солтановның (1827—1915), мөселманнарның дин эшләрен, көнкүрешләрен рәткә салуда берни дә эшләмәсә дә, 25 ел мөфти булып торуын юбилей ясап билгеләп үтүдән көлә.

**1 ноябрь.** «Шура»да «Яңа кыйраәт» әсәренә аннотация басылып чыга: «Яңа

кыйраәт»—(икенче табгы) Габдулла әфәнде Тукаев әсәре булып, балалар укыр өчен күңелле хикәятләр вә гүзәл шигырьләр җыелмыштыр. Ушбу китап Казанда «Мәгариф» тарафыннан нәшер улынмыштыр».

**5 ноябрь.** Г. Камалның әдәби эшчәнлегенә 10 ел тулу мөнәсәбәте белән үткәрелгән юбилей кичәсендә катнаша.

«Ушбу сәнә 5 ноябрьдә «Новый клуб» залында «Сәйяр» мөселман артистлары тарафыннан Галиәсгар әфәнденең 10 сәнәлек әдәби вә милли каләм хезмәте Шәрәфенә аның «Бәхетсез егет» драмасы илә «Бүләк өчен» комедиясе куелды».

Тукай, бу пьесаларны карап, үзенең бәяләмәсен дә яза: «Галиәсгар әфәнденең бу ике әсәре чын татар тормышыннан бик белеп алынган тасвирлар булып, хосусән «Бүләк өчен»дәге угылын өйләндерә торган татар хатынының халәте рухиясен белү, аның издиваҗ кеби олугъ бер эшкә ничек бер уенчык кына итеп караганын күрсәтү вә шул хатын авызыннан кыз атасы тарафыннан киләчәк бүләкләрне Әлхәм укыган кеби яңлыштырмый, гармонично санату фәкать, фәкать Галиәсгар әфәнденең нечкә хиссенә вә тирән күрүенә генә хас бер эш булганга, аннан соң «Сәйяр» артистларының сәхнәдә һәрвакыт, һәр җирдә, һәр шәһәрдә күрсәтәчәк мабиһил-ифтиһарлары шушы Галиәсгар әфәнде әсәрләре булганга, шул сәбәпле алар күп уйналганга, бу әсәрләрне уйный белүдә артистлар бөтенләй мөтәхассыйс булып киткәнгә, табигый, уен яхшы чыкты».

**13 ноябрь.** «Мәктәптә милли әдәбият дәресләре» исеме белән матбугатка әзерләгән дәреслек-хрестоматия рәвешендә төзегән китабына кереш сүз «Мөкаддәмә» яза.

**20 ноябрь.** «Төш» шигыре басылып чыга.

**29 ноябрь.** «Өзелгән өмид» шигыре басыла. Хөр фикер эзәрлекләнгән реакция елларында иҗат ителгән бу шигырь монсу, хәсрәтле кичерешләр белән сугарылган. 24 яшьлек Тукай инде иҗатының житлеккән чорына аяк баскан шагыйрь кебек хис итә. Аның өчен әшьяләр төсе дә үзгәргән. Гасырлар дәвамында шагыйрь халкы өчен илһам чыганагы булган мәхәббәт тә, җир гүзәлләренең матурлыгы да анда иҗат дәрте уятмый. Лирик герой образы белән тәңгәл килгән шагыйрь үз җисми яшәешенең һәм моңлы сазының, ягъни шигъриятенең кыска гомерле булачагын пәйгамбәрләрчә алдан сизә.

*И Мөкаддәс моңлы сазым! Уйнадың син ник бик аз?*
*Син сынасың, мин сүнәмен, аерылабыз, ахрысы!*

**1 декабрь.** «Кайда? Кем?» шигыре «Шүрәле» имзасы белән басылып чыга. Анда шәхескә кагылышлы мондый юллар да бар:

*Кем, дисез, бу фетнәле эшләр башы?*
*Кайда бу хаксызга тәфтишләр башы?*
*Бәдбәхет, мәлгунь кеше кем, дусларым?—*
*Түнтәр аулы чалмалы карт марҗасы.*

**15 декабрь.** «Кушмый ишан җилкәсендә...» дип башланган дүрт юллык рәсем-карикатура асты итеп басылган. Рәсем өстенә «Әннәсолул хәдидә» кайда тәсниф ителгән?» дигән баш куелган. Чалмалы, түбәтәйле искеләр тезелешеп утырган, уртада Гыйлаҗ мулла (өстенә «Әннәсолул хәдидә» язучы» дип куелган...) «Кушмый хәзрәт бер китап җазарга кушкан иде»,—ди. Реакцион мулла Гыйлаҗетдин Мөхетдинов-Сәрдәи язган «Әннәсолул хәдидә ли-иб татыйль ысулы җәдидә»не... («Ысулы җәдидәне юкка чыгара торган тимер кебек нык китап») исемле китап турында сүз бара.

**18 декабрь.** «Балалар күңеле. Мәктәптә милли әдәбият дәресләре» *(Әдәбияттан хрестоматия. Казан, «Мәгариф» көтепханәсе, «Үрнәк» матбагасы)* басылып чыга. (Тышлыкта—1911 дип куелган). 144 б. 5200 данә.

Китапка сүз башында («Мөкаддәмә»дә) автор болай ди:

«Үземезнең яңа үсеп килмәктә булган милли әдәбият бакчамыздан җыеп, ...ушбу «Мәктәптә милли әдәбият дәресләре» китабыны тәртип иттем. Сабый

балаларымызның кулына... шушы китап кеби чәчәк бәйләмнәре бирелергә тиештер.

Кечкенәдән гүзәл нәрсәләр укыган балаларның күнелләре дә назик вә ләтыйф булып, анчак гүзәл вә мөкаддәс нәрсәләрне генә сөючән буладыр.

Моның киресенчә: кечкенәдән тупас вә ямьсез нәрсәләр күреп үскән балаларның язгы ачык күк кеби саф күңелләре томаланып, рухлары яхшыны вә начарны аермый, һәрнәрсәгә бертигез караучы буладыр.

Рус тәрбия голямасының соң заманда мәйданга китердекләре «Живое слово» нам кыйраәт китабы минем «Мәктәптә милли әдәбият дәресләре»нең тарзы тәртибендә рәһбәр итеп тотылды.

152 сәхифәлек бу китап «Мәктәптә милли әдәбият дәресләре»нең беренче кыйсьмедер... киләчәк кыйсемнәр тәртип ителсә, аларга күбрәк хезмәт кертеләчәк вә шаять мәшһүр кешеләремезнең тәржемәи хальләре вә рәсемнәре дә дәрж улыначактыр»,—дип, бу өлкәдә киләчәккә планнарын күрсәтә.

Китапның титул битендә Тукайның:

*И туган тел, и матур тел, әткәм-әнкәмнең теле,*
*Дөньяда күп нәрсә белдем, син туган тел аркылы,—*

дигән юллары китерелгән.

**Ноябрь—декабрь.** Дуслары һәм фикердәшләре Г. Газиз һәм Г. Коләхметов белән өчәүләп фотога төшәләр.

---

# «КАЗАН УТЛАРЫ» ЕЛЪЯЗМАСЫ



85 ел элек (1926 ел) «Безнең юл»ның 1 санында **Һади Такташның «Нәни разбойник»** шигыре;

80 ел элек (1931) «Яңалиф»нең 1 санында **Ибраһим Газиның «Көмеш сулы Нурминкә»** хикәясе;

75 ел элек (1936) «Совет әдәбияты»ның 1 санында **Шәриф Камалның «Матур туганда»** романыннан өзек;

55 ел элек (1956) «Совет әдәбияты»ның 1 санында **Нурихан Фәттахның «Сезнеңчә ничек?»** романының башы;

45 ел элек (1966) «Казан утлары»ның 1 санында **Әмирхан Еникинең «Әйтелмәгән васыять»** хикәясе;

30 ел элек (1981) «Казан утлары»ның 1 санында **Гомәр Бәшировның «Сарут»** хикәясе дөнья күргән.

Печән Базары

*Сатирик әсәрләр конкурсы*

Рөстәм Зарипов

## ЯҢАРТЫЛГАН МӘКАЛЬЛӘР, ӘЙТЕМНӘР

***

**«Яңа гасыр» үзен мактар...**

***

**Хаклык сүзе кыска: «юк», йә «бар»,**
**Депутатлар исә «кар!» да «кар!»...**

***

**Күл сасыса, балык кими,**
**Россиядә халык кими...**

***

**Үләксә күп җирдә**
**карга котыра,**
**Бездә бюрократлар**
**арта отыры...**

### «Без булдырабыз!»

**«Алтын мөнбәр», «Алтын мөнбәр»,**
**Катрин Денев килгән безгә,**
**«Мөселман»тамгасы алган**
**Кинофестивалебезгә...**

**Ай-һай күркәм, бигрәк затлы**
**Гүзәлкәе французның, –**
**Керфекләре түбән карый,**
**Түш каплаулы, итәк озын.**

Ә безнекеләр сер бирми,
Кер кундырмый имиджка, –
Кұлмәк үтә күренмәле,
Кендек ачык, ими тышта...

## Кәҗә монологы

Авылда чакта да сер бирмәдек,
Ягъни күз өстендә каш идем;
Урын һәрчак түрдә, алда булды,
Сарык көтүенә баш идем.

Көнләштеләр, чәйнәделәр гайбәт,
Имеш бакчаларда урлашам;
...Кадерне белмәгәч авыл халкы,
Башкалага барып урнашам.

Коерык ягы дан түгел түгелен,
Әмма мөгезләр бит күрекле,
Ит комбинатында эш табылды,
Вазифама җәһәт күнектем.

Авыл сарыкларын каршы алам,
Алар мине танып, тагыла,
Сугым залларына керәбез дә,
Арттан шартлап капка ябыла...

Яшерен ишектән чыгып таям,
Авылдашлар кала – нишлисең,
Миңа дигән тагаракта печән,
Чәчәк-җиләкле, хуш ислесе...

Үз-үземне сәясмәнгә чутлыйм,
Алар да бит миндәй калыккан,
Алар да бит, күпме тырышып та,

Рәхмәт ишетмиләр халыктан...

---

*Юбилейлар*



*Язучы-прозаик, тел һәм мәдәният белгече Адлер Камил улы Тимергалинга 80 яшь тулды. Котлыйбыз!*
*Әдип белән әңгәмә киләсе санда бирелә.*

Раиф
Мәрданов

# МАНСУР ХӘЛЛЯҖ КЫЙССАСЫ

Татар әдәбияты тарихы гаҗәеп бай безнең. Ул шактый тулы өйрәнелгән шикелле тоелса да, борынгы мирас җәүһәрләре һаман табылып тора. Сүзебез соңгы вакыттагы табышларның берсе турында.

Татарстан Милли китапханәсенең Казан дәүләт университеты белән берләштерелгән, халкыбызның кульязма истәлекләрен туплау максатындагы фәнни-археографик экспедициясе 1998 елның җәендә Оренбург өлкәсендә эшләгән иде. Әсәкәй районы Яңа Солтангол авылында яшәүче Халисә Нәжмиевадан алынган кульязмадагы шигъри әсәр игътибарыбызны җәлеп итте. Анда Мансур Хәлляҗгә багышланган, безгә таныш түгел бер кыйсса язылган иде. Кульязмада әсәрнең башы юк, ә төп өлеше һәм ахыры бар. Россиядә эшләнгән, зурлыгы 16х22 сантиметрны тәшкил иткән кәгазендәге су билгеләрендә 1784 һәм 1785 еллар күрсәтелгән. Димәк, бу кульязма XVIII гасыр ахырына нисбәтле. Аның сакланышы уртача, бернечә бите генә төбеннән аерылган. Бу кульязмада әсәрнең 743 бәйте язылган. (Ул хәзерге вакытта Милли китапханәдә «1860 т» шифры белән саклана). Әлеге кызыклы поэманың тексты тулаем сакланмаган булуы пошаманга төшерде.

Тик бу халәт озак дәвам итмәде. Чөнки 1999 елның язында Кукмара районының Уразай авылында яшәүче Имаметдин ага Ибраһимовлардан Татарстан Милли китапханәсенә алынган язма истәлекләр арасында Хәлляҗ турындагы шул ук кыйсса бар иде. Иң әһәмиятлесе—монысында әсәрнең Оренбург кульязмасында булмаган башлангыч өлеше сакланган. Дәверләр кичкән кульязма җыентыкларның берсендә борынгы татар әдәбиятының ике ядкәре: мәшһүр суфый Мансур әл-Хәлляҗга багышланган күләмле поэма тексты (1б—11б кәгазьләрдә) һәм Казан ханлыгы чорында яшәп иҗат иткән мәшһүр татар шагыйре Мөхәммәдьярның «Нуры содур» поэмасы (12а—28б кәгазьләрдә) теркәлгән. Әлеге кульязма җыентык 15,5х19,5 см. зурлыктагы, 1701—1710 елларда Һолландиядә эшләнгән юка саргылт кәгазьдә. Кәгазенең эшләнгән вакытына нигезләнеп фикер йөрткәндә, бу әсәрләр җыентыкка XVIII йөзнең беренче чирегендә күчереп язылганлыгы аңлашыла. Барлык текстлар да бер үк кеше кулы белән язылган. Кульязманың сакланышы уртача. Әлеге кыйммәтле ядкәр Татарстан Милли китапханәсенең Кульязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә «1116 т» шифры белән саклана. Анда әсәрнең барлыгы 288 бәйте бар.

Менә шушы ике кульязманы җентекләп өйрәнгәч, Мансур әл-Хәлляҗ турындагы кыйссаның тулы тексты 867 бәйттән (ягъни 1734 шигъри юлдан) гыйбарәт булуы ачыкланды.

Иң аянычлысы, текстның үзендә аның авторы кем булуы һәм кайчан иҗат ителгәнлеге күрсәтелмәгән.

***

Иранда дөньяга килгән Мансур әл-Хәлляж (Әбел-Могыйс әл-Хөсәен бине Мансур әл-Бәйзави, 858—922) Ислам тарихында «әнә әл-Хак» (Мин—Хак) дигән сүзләре белән мәшһүр суфыйчылык юлбашчыларыннан. Суфыйлар карашынча, илаһи мәхәббәттә эреп, Аллаһ бөеклегенә ирешеп, аның белән кушылу (ягъни, «әнә әл-Хак»)—суфыйчылыкның иң югары дәрәҗәсе дип саналган.

Суфыйчылык галимнәре Хәлляжне илаһи серләрне ачканлыгы һәм могжиза-кәрамәт күрсәтүе өчен гаепләгәннәр. Чөнки суфый юлбашчылары халык алдында хикмәтле эшләр күрсәтүне катгый тыйганнар. Андый гамәлгә Мөхәммәд пәйгамбәр генә хаклы булган дип, шулай ук суфый кеше үзенең рухи халәтен башкалар алдында фаш итмәскә тиеш дип каралган.

Хәлляж югары сыйныф (хакимлек һәм дин башлыклары) тарафыннан гаепләнсә дә, фәкыйрьләр арасында үзенә күп тарафдарлар тапкан. Гади халыкның күпчелеге аның фикерләренә ияргән. Фәлсәфи чыгышларында экстаз халәтендә «әнә әл-Хак» дигән күп мәгънәле сүзләр дә әйткән. Галимнәр фикеренчә, бу сүзгә төрле мәгънәләр салынган. Ягъни, «Мин—Хак булган Аллаһ», «Мин—хакыйкатьнең нәкъ үзе» һәм «Мин—Хакның барлыгы белән бәйле үзгәрмәс һәм бер». Вәгазь-нәсихәтләрендә ул шәхси гөнаһлары өчен генә түгел, ә барлык мөселманнарның гөнаһлары өчен корбан булырга әзерлеген белдергән.

Хәлляж нотыклары җәмгыятьтә үзгәрешләр ясау турында уйланырга этәргеч биргән. Хакимнәр һәм рухани башлыклар, мондый коткы салучының халык арасында чуалышлар китереп чыгаруыннан куркып, Хәлляжне эзәрлекли башлаганнар. Бәгъдадта булып узган берничә баш күтәрү һәм сарайдагы эчке фетнәләрдә аны һәм яраннарын гаепләгәннәр. 911 елда Хәлляжне тотып Бәгъдад төрмәсенә япканнар, Хөсәен бине Мансур әл-Хәлляж Ислам диненең төп өйрәтмәләреннән тайпылуда гаепләнгән һәм 922 елда аңа үлем җәзасы чыгарылган. Җәза ысулы итеп камчы белән суктыру һәм гәүдәсен тураклап яндыру билгеләнгән. 922 елның 26 мартында Хәлляжнең кул-аяклары чабылган, гәүдәсе гыйбрәт өчен дарга асылган. Икенче көндә башы чабып өзелгән һәм гәүдәсен яндырып, көлен су буендагы манарадан Тигр елгасы өстенә җилгә очырткannар.

Ачыктан-ачык аңа ияргән тарафдарлары шулай ук җәзалап үтерүгә хөкем ителгән. Качып котылган санаулы фикердәш һәм шәкертләре Урта Азиягә килеп сыенган. Алар аша хакыйкый хәбәрләргә гадәттән тыш төсмерләр өстәлеп, бөтен мөселман дөньясына Хәлляжнең әүлиялыгы турында риваятьләр таралган, үзенең исеме дә Мансур әл-Хәлляж буларак шөһрәт тапкан.

Хөсәен бине Мансур әл-Хәлляжнең 11 бүлектән гыйбарәт «Китабет-тавасин» исемле кечкенә бер әсәре һәм тагын берничә язмасы фәнгә билгеле. Суфыйчыл фәлсәфи «Китабет-тавасин» хезмәте илаһи берлекне дәлилләүгә багышланган. Хәлляж, кеше үзенең җисмани барлыгыннан ваз кичеп, даими камилләшеп һәм рухи сафланып, Аллаһ белән кушылуга омтылырга тиеш булуы, шулай ук дәрвишлекнең башка сыйфатлары турында мантыйкый фикерләүгә нигезләнеп һәм схематик символлар аңлатмасы ярдәмендә язган.

Ислам динен тоткан төрле халыкларның авыз иҗатында һәм суфыйчылык әдәбиятында Мансур әл-Хәлляж шәхесенә зур игътибар бирелгән, әдәби әсәрләр иҗат ителгән. Төрки телле суфыйчылык әдәбиятының Әхмәт Ясәви, Юныс Әмрә, Нәсими кебек күренекле вәкилләре үз әсәрләрендә Мансур Хәлляжне зур хөрмәт белән искә алганнар. Танылган фарсы шагыйре Фәридетдин Гаттар (1230 елда вафат) «Тәзкирәтел-әүлийа» исемле әсәрендә Хәлляжнең тормыш юлы, тәгълиматы, фаҗигале үлеме һәм аңа бәйле риваятьләрне туплап калдырган. Гаттар, аерым алганда, Хәлляжнең диндар булып кыйланган руханиларны әче тәнкыйтьләвен, ә бервакыт зиндандагы богаулы өч йөз тоткынны могжиза белән азат итүе һәм берүзе качмыйча калуын, аны дарга асарга китергәч, йөз мең кеше җыелганлыгы, җәлладның кул-аякларын чабуны тасвирлаган, шулай ук Хәлляжнең гәүдәсен яндырып көлен чәчүне, Диҗләгә (Тигр елгасына) көле төшеп елганың ташып чыгуы, бары тик Мансурның хиркасен (дәрвишләрнең өс киемен) суга салгач кына суның элекке хәленә кайтуы турында язган. Менә бу вакыйгаларның бөтенесе

дә яңа табылган Мансур Хәлляҗ кыйссасында шигъри бизәкләр белән үтемле итеп сөйләнгән. Ягъни, Мансур турында татар телендә язылган поэмага Гаттар мәгълүматлары нигез итеп алынганлыгы ачык күренә.

Оренбург өлкәсеннән һәм Кукмара районыннан табылган кулъязмалардагы поэма тексты фәндә монарчы билгеле түгел иде. Дөрес, төрек шагыйре Акмөхәммәднең «Кыйссател-Мансур әл-Хәлляҗ» исемле әсәре әдәбият тарихында мәгълүм, тик аның эчтәлеге бүтәнчә. Акмөхәммәд кыйссасында Мансур әл-Хәлляҗ вакыйгалары шундый ук язмышка дучар булган әзәрбайҗан шагыйре Гыймадетдин Нәсиминең (1369—1417) фантастик биографиясенә бәйләп тасвирланган. «Татар әдәбияты тарихы» китабының икенче томында (Казан, 1985) Акмөхәммәд иҗат иткән кыйссаның фарсыча проза әсәренә ияреп язылганлыгы әйтелгән. Төрек авторының «Кыйссати Мансур әл-Хәлляҗ» исемле ул әсәре Казанда беренче мәртәбә 1857, аннан соң 1859, 1866, 1889, 1904 һ.б. елларда 16 битле җыйнак кына китапчык рәвешендә басылып чыккан.

***

Мансур Хәлляҗгә багышланган, яңа табылган кыйссаның эчтәлеге белән кыскача танышып үтик. Тик суфыйчылык әдәбиятында сүзләр берничә төрле яшерен символик мәгънәгә ия булганлыгын алдан ук искәртеп куйыйк. Шул сәбәпле бу поэмадагы кайбер гыйбарәләр турыдан-туры үз мәгънәсендә генә бирелгән дип кабул ителергә тиеш түгел. Мәсәлән, суфыйлар телендә «сер» сүзе—ул кешенең илаһи барлыгы. Мансур Хәлляҗнең серне фаш итүе турында сүз барганда нәкъ менә шул мәгънә күздә тотылган. Суфыйлар гарәп әлифбасындагы хәрефләргә дә аерым символик мәгънә биргәннәр. Әйтик, «саф» сүзендәге беренче хәреф (сад) суфыйлар карашында илаһи сафлыкның, ягъни үзлегеннән чистарып котылган, Аллаһ белән кушылган дигәнне белдергән. Мансур Хәлляҗ да «Китабет-тавасин» әсәрендә гарәп хәрефләрен Аллаһның билгеләре (тамгалары) дип атый һәм аерым хәрефләрнең серләрен шәрехләп бирә.

Поэмада «нур» сүзе илаһи нур мәгънәсендә кулланылган. Суфыйлар (шул исәптән Хәлляҗ карашынча), бөтен галәм илаһи нур белән тулган, шунлыктан бөтен нәрсә кебек үк, һәр кеше дә Аллаһның бер өлеше, кисәге итеп каралган.

Суфый әдәбияттагы кайбер гамәл һәм хәрәкәтләр дә символик мәгънәгә ия булган. Мәсәлән, суфыйчылык юлбашчысы үз хиркасен (киемен) алмаш булып калачак мөридена бирү традициясе булган һәм бу күренеш әлеге поэмада да бар. Әсәрдәге шәраб һәм исерү турындагы сүзләр күчерелмә мәгънәсендәге илаһи эчемлек, Аллаһка гашыйклыктан исерүне күздә тота. Шулай ук зилзилә, яшен, елганың ташуы һ.б. вакыйгалар—бөтенесе дә илаһият белән бәйле символикага нигезләнгән.

Кыйссаның кереш өлешендә Аллаһка һәм Мөхәммәд пәйгамбәргә дан һәм мактаулардан соң, илаһи мәхәббәтнең асылы аңлатылган. Шуннан соң автор:

*Җан колагың тот сүзең әсрарена,*
*Беләсән кем—сүз нәдер, әсраре—нә?!*

—дип, төп хикәяләүгә керешә. Мансурның Бәгъдадка барып зур галим булып житешүе, илаһи гашыйклыкка ирешеп, Аллаһы Тәгалә белән сөйләшкән сүзләре бәян итеЛә. Мансур болай ди:

*Җандан үзгә нәснәм юк, йа, Илаһ,*
*Лотфың илә кыйл кабул, әй, Падишаһ!*

Аллаһы Тәгалә аңа җавабында шартларның катгыйлыгын белдерә:

*Бәңа гашыйк уланны үлдерүрем,*
*Җөмлә мәхлукы аңа көлдерүрем.*
*Парә-парә туградурым җисмени,*
*Мәху идәрем исмени вә рәсмени.*

Мансур, карарында нык торып, үзлегеннән ваз кичә һәм Аллаһ таләпләренә һичсүзсез риза була. Шуннан соң Аллаһның әмере белән Мөхәммәд пәйгамбәр Мансурга гыйшык шәрабен эчертә. Җаны-рухы белән Аллаһка тулаем кушылган Мансур дөнья халкына игълан итә:

*Хак—бәнем, Хак бәндәдер, йа, кауме дүн,*
*Шөйлә кем, Хак улды бәңа раһнәмүн.*
*Хакка ирдем, җан-у-башым нәйләрәм?*
*Җөмлә Хак улдым, «әнә-л-Хак» сөйләрәм.*

Бу хәлдән соң галимнәр җыелып, Мансурның илаһи серне фаш итүенә пошынып, хәлифә янына кинәшкә баралар.

*Диделәр кем: «Әй, хәлифә! Хале күр—*
*Ошбу Мансурың дидүке кале күр!*
*Ки дәлү улмыш, «әнә-л-Хак» чагырыр,*
*«Хак—бәнем» дир, нәгърә орур-багырыр.»*

Галимнәр Мансур үтерелмәгән очракта, дөнья халкы фетнәгә батачак дип белдерә. Хәлифә үзе Мансурга барып, аны үгетләргә алына.

*Диде Мансура хәлифә: «Әй, олу,*
*Әй, мәгани тәхте үзрә бәхетлү!*
*Гыйлем эчендә галиме Рәббани сән,*
*Шөйлә кем, җан тәхтенең солтаны сән!*
*Имди бу дәгъва сезә лаек дәгүл,*
*Бу сүзең мәфһүме баек дәгүл.»*

Әмма Мансур сүзеннән чыкмаячагын кистереп әйтә:

*Бинишанны белдем—улдым бинишан,*
*Бән—Ул улдым, Ул—бәнем, белең гайан!*
*Хак—бәнем, Хак—бәндәдүр, Хак сөйләрәм,*
*Зате Хәййем бән ки, мотлак сөйләрәм.*
*Бу сүзүм Хакдан дорур, хакдыр, белең,*
*Һәр нә кем кылырсәңез, имди кыйлың!*

Мондый көфер сүзләре өчен аны богаулап зинданга ябалар.

*Җөмлә галимләр голү итде рәван,*
*Диделәр: «Тотың буны, вирмәң аман!»*
*Дотубән Мансуры чөн бәнд итделәр,*
*Гыйшык йебен буйнына такуб китделәр.*

Зинданга барышлый бер мәзиннең манарадан азан әйткән тавышын ишетеп Мансур хафага төшеп ярсый. Ул мәзиннең теле «Аллаһ» сүзен әйтергә лаек түгел дип белдерә.

*Дил кәрәк «Аллаһу әкбәр!» димәгә,*
*Кани агыз, шәһде шәкәр йимәгә!»*

Ягъни, шикәр ашау өчен авыз кирәк булган кебек, «Аллаһу әкбәр!» дияр өчен йөрәк саф булырга тиеш, ди. (Ф.Гаттар язган мәгълүматта Хәлляҗнең ялган диндарларны тәнкыйтьләве турындагы сүзләрне искә төшерик). Мансур үзе азан әйтеп күрсәтә һәм кайбер хикмәтләр күрсәтеп халыкны таң калдыргач, сихер һәм җеннәр белән эш итүдә гаепләнә.

*Диделәр: «Сихер әймешсән, әй, кеши!*
*Җенләр берлә кыйлурсән һәр эши.»*

Аларга җавап итеп,

*Диде Мансур: «Эш—бәнем, кодрәт—бәнем,*
*Белең, хаким, эш—бәнем, хикмәт—бәнем.»*
*Гыйшыҡ йебе буйнында, алыб китделәр,*
*Та зиндан капусына йитделәр.*
*... зиндан ҡапусын беркетделәр,*
*Йәнә халык, эшлү—эшенә китделәр.*

Зинданда ятучыларны Мансур хикмәтле кодрәте белән азат итә. Үзе зинданда кала, сакчы бу хәлгә аптырап, аңа сәҗдә кыла. Мансур Аллаһка шөкерана укый:

*Бәне зиндана салан гыйшкың дорыр,*
*Бәнлекем бәндән алан гыйшкың дорыр.*
*Гыйшык илә кылдуң бәшарәт җаныма,*
*Төхфә илттүм җанымы җананыма.*

Бу вакыйгага таң калган Бәгъдад халкы җыела. Суфый галимнәр шәехе Шибли икенче бер шәех Җүнәйдкә барып (ә болар чынлыкта Хәлляҗнең замандашлары: берсе—остазы, икенчесе сабакташы булган) мөрәҗәгать итә:

*Имди сән, лотыф әйләеб, Мансура вар,*
*Диң—ҡылмасун «әнә-л-Хак» ашикяр.*
*Кемсәйә әсрарне белдермәсүн,*
*Бу җиһан халкын безә көлдермәсүн.*
*Бер нәсыйхәт вир аңа ихлас илә,*
*Шаять ула, ошбу гауга басыла.*

Җүнәйд зинданга бара.

*Ачдылар зиндан ҡапусын шул заман,*
*Эчрә керде ул шәйхе кямәран.*
*Лотыф илә ул вирде Мансура сәлам,*
*Диде: «Әй, Мансур! Бозылды низам—*
*Заһир әйләдең «әнәл-Хак» серрени,*
*Мөнтәшир кылдың бу вәхдәт дөррени.»*

Күпме әүлиялар һәм күпме пәйгамбәрләр килеп тә, бу серне ачмадылар бит, инде син дә белгертмә, сүзләреңнән ваз кич дип, Җүнәйд Мансурга ялвара:

*Сүземез рәдд әйләмә, әй, җанымыз,*
*Без—колуз, сәнсән—безем солтанымыз!*

Мансур, икесе арасында булган әңгәмәдән соң, Җүнәйдкә хакыйкатьне халыкка аңлатырга куша. Тик аптыраган Җүнәйд бер сүз дәшмичә, Шибли янына килә һәм аның үгет-нәсихәт биреп каравын үтенә. Шәех Шибли белән әңгәмә дә файда итми. Мансур үзен һәлак итәргә фәтва чыгара.

*Хөкем идүб галимләр шул дәм рәван,*
*Дар агачын декделәр ул заман.*

Мансурга алар:

*Парә-парә әйләрүз назук тәнең,*
*Сәңа чөн яр улмады гаклың сәнең.*
*Диде Мансур: «Уш Хакка сондым әлем,*
*Иллә белең кем—бәңа юкдыр үлем!*
*Чөн үзүмдән фани улдум мотлакка,*
*Юлымы тугры илтәм ул Хакка.»*

Изге әүлияләр Мансурны хуплап, дар янына килеп, елашып, «Дар—синең өчен мигъраж (күккә ашу) булсын!» дип теләкләр телиләр. Шунда Мансур халыкка мөрәҗәгать итеп:

*Шәрхә-шәрхә паралән ошбу тәни,*
*Бу тәни соң кинә булам бән бәни.*
*Кәсең имди әлүме-айагымы,*
*Таки җөзем бәндүме вә багымы.*
*Күрмәз улсун—чыкаруң күзләреми,*
*Һәр нә дидүм—сез тотың сүзләреми.*
*Соңра гыйшык ибен дакуб бәрдар идүң,*
*Юклыгымдан кортарубән вар идүң.*
*Индүрүб ахыр, җисмем яндырың,*
*Җаныймы абе хәятә кандырың.*
*Йилә каршы саурың көлем рәван,*
*Таки хушнуд ула сездән Мөстәган.*

Җәллад башта Мансурның кулларын, аннары аякларын кисә. Әмма, ни гаҗәп—кан аккан саен туфрак өстенә «Әнә әл-Хак» дигән сүз языла һәм халык хакыйкатькә ышана.

*Акдыгынча кан «әнә-л-Хак» язылыр,*
*Бакдыгынча тар күңүлләр язылыр.*

Мансур җәлладка эндәшеп, күзләрен чыгарырга куша:

*Кәлде җәллад иләру. Бәс, нәйләсүн?*
*Сүзе калмады, нә дисүн-сөйләсүн?*
*Тотды чыкарды мөбарәк күзләрен,*
*Дыңлаңыз, Мансур имди сүзләрен.*
*Диде Мансур: «Әй, хәлаикъ, шад улың,*
*Варуң имди, госсадин азад улың!*
*Тән күзене вирдем ул Хак юлына,*
*Җан күзе илә бакыла Хак юлына.»*

Мансур барлык халык өчен Ходай каршында үзе җавап тотуын белдереп, һәммәсен ярлыкауны сорап Аллаһка ялвара. Бу хәлдән тәэсирләнгән халык аһ-зар елый.

*Олу-кече ул дәм улды бикарар,*
*Яшь идүбән агладылар зар вә зар.*
*Шәйхе Җүнәйд, шәйхе Шибли баш ачар,*
*Күзләрендән яшь йиренә кан сачар.*

Шул вакыт бөтен җир һәм күкләр тетрәп, дөньяны зилзилә каплап ала.

*Җәмегъ улуб галимләр ул дәм, әй, олу!*
*Чөн хәлифә катына килде каму.*
*Диделәр кем: «Әй, хәлифә, нәйдәлүм,*
*Чарасыз калдук, нә тәдбир идәлүм?»*

Хәлифә тынычландыра:

*Сез варың, Мансур өчүн кайгу йыймаң,*
*Ул тередер, сез аны үлде димәң!*
*Ул нә дирсә, сүзе хакдыр аның,*
*Һәр кәляме дәхи мотлакдыр аның.*
*Сезә ул димәк—«Җисмем яндырың,*
*Җанымы аба хәятә кандырың!*
*Һәм йимыш көлүм саурың йилләрә,*
*Бу хәбәр варуб беленсүн илләрә!»*
*Чөн хәлифә сүзен анлар алдылар,*
*Йәнә ул дар агачына килделәр.*

Халык уттан калган көлне җыя һәм

*Бер йүчә йирә чыкубән, әй, гаму,*
*Ул көле йилә саурдылар каму.*
*Кодрәте Хак ул көле нәйләде—*
*Канда акдисә «әнә-л-Хак» сөйләде.*

Көлнең бер өлеше Дижлә елгасына төшеп, су ташып чыга, яшеннәр яшьнәп, күкләр күкри. Елга шул кадәр ташый ки, аздан гына бөтен Бәгъдадны батырмыйча кала. Барча халык куркышып кан-яшь түгә. Ә Мансур бу хәлләрнең булачагын белеп, үзенең бер мөриденә алдан сөйләп, әйтеп куйган була. Ягъни, су ташып шәһәрне басканда үзенең хиркасен алып, аның җиңнәрен елгага батырырсың, шуннан соң су тынар дип өйрәткән була. Ул мөрид халыкка хикмәтне анлаткач, һәммәсе аңа ялвара.

*Диделәр кем: «әй, Хак әһле, чара кыйл,*
*Өстемездән афәте әварә кыйл?!»*

Хирканең җиңнәрен Дижләгә төшерүгә су элекке хәленә кайта. Шулай итеп барча халык афәттән котыла.

*Шәйхе Җунәйд, шәйхе Шибли шул заман,*
*Күзләрендән яшь акузды рәван.*
*Эшләренә һәп пошиман улдылар,*
*Аглашубән зар-у-гирйан улдылар.*
*Тәүбә ирмагында йывындылар каму,*
*Дыңла, имди нәйләделәр, әй, гаму!*
*Әһле Бәгдад анда кыйлды иттифак,*
*Диенелкән җәмегъ әйләделәр бинифак.*
*Заһидан-у-габидан, шәйх-ү-имам,*
*Бер йирә җәмегъ улдылар бонлар тәмам.*
*Өч көн, өч кичә зыяфәт кыйлдылар,*
*Ул диярың халкыны туйладылар.*
*Диделәр: «Дәрдә дәрига, әй, Ходa!*
*Аh, кем Мансурдан дөшдек җөда.*
*Күрүклү йөзендән аның улдык ерак,*
*Та кыямәт җанымызига фирак.*
*Без гөнаһкяруз, үгүш кыйлдук гөнаһ,*
*Рәхмәт ит вә ярлыка, әй, Падишаh?!»*

Әсәр, шул рәвешчә, халыкның бердәм булып, үз гөнаһлары өчен тәүбә итеп, ярлыкау сорап, берләшүе һәм шатлык-куанычы, тугры юлга күнүе белән тәмамлана.

Берләшү—поэманың үзәк максаты итеп куелган һәм әсәрдә бердәмлеккә дан жырланган. Ягъни үзара низагларга, эчке тарткалашуларга, таркаулыкка каршы көчле чара буларак берләшү тәкъдим ителгән. Автор әсәрнең ахыргы юлларында Аллаһ юлында, изге максатлар өчен жанны кызганмау кирәклеген тагын бер кат искәртә.

*Әй, бәрадәр, дыңла җан илә йанә,*
*Җан фида улсун, сүзе аңла йанә!*

Югарыда китерелгән өзекләрдән авторның тел-сурәтләү чараларын мул куллануын һәм шигърият хәзинәсенең байлыгын күзаллап була. Тагын берничә шигъри юлга игътибар итик.

*Дордылар чөн кальб-у-кальб вә саф-у-саф,*
*Санки бер йирә екылды күһе Каф.*

Ягъни автор халык турында Каф таулары бер урынга өелгән кебек саф-саф чолгап тордылар дип, кызыклы чагыштыру уткәрә. Әсәрне иҗат итүче «гыйшык даруханәсе» дигән кызыклы гыйбарә дә куллана:

*Гыйшык даруханәсендән килерем,*
*Гашыйкың дәрд-дәвасын белерем.*

Түбәндәге юлларның шигъри янгырашы, гүя Мансурның йөрәк тибешедәй, фикеренең какшамаслыгын көчәйтә:

*Әмер—Аныңдыр, эш—Аның, хикмәт—Аның,*
*Кадыйр—Улдыр, һәр эшә кодрәт—Аның.*

Әсәрдәге менә боларга охшаш шигъри сурәтләү чаралары авторның иҗади алымнарны зур осталык белән кулланганлыгын күрсәтә. Фикеребезчә, бу әсәр—татар суфыйчылык әдәбиятының иң күренекле истәлекләреннән берсе дип бәяләнергә хаклы.

***

Әсәрнең алда язылып үтелгән өзекләреннән күренгәнчә, тел үзенчәлекләре, шигъри аһәң һәм куәсе ягыннан бу поэма Казан ханлыгы чоры әдипләре әсәрләрен хәтерләтә. Хәлляжга багышланган поэма, аерым алганда, Мөхәммәтәминнең «Могжизнамә», Мөхәммәдьярның «Төхфәи мәрдан» һәм «Нуры содур» әсәрләре белән авазлаш.

Хәлляж турындагы әлеге күләмле әсәрнең хәзергә без ачыклаган кульязма күчермәләреннән берсе 1701—1710 еллардагы кәгазьгә теркәлгән булуы әсәрнең шул вакытка кадәр иҗат ителгәнлеген белдерә. Ул җыентыкта Мөхәммәдьярның «Нуры содур» әсәре дә теркәлгән булуы шулай ук әһәмиятле. Чөнки язма җыентыкларда, гадәттә, бер чор-дәвергә караган әдәби истәлекләр тупланган.

Мавыктыргыч сюжетка корылган һәм шигъри яктан төзек булган Мансур Хәлляж кыйссасының авторы текстның үзендә тәгаен күрсәтелмәгән дидек. Шәрык-мөселман һәм төрки-татар әсәрләрендә авторның үз исеме яисә аның кушамат-псевдонимын күрсәтү хас булганлыгы билгеле. Авторның кем булуы еш кына әсәрнең ахырындагы юлларда аталган, ә кайчагында текстның башындарак та күрсәтелгән. Әмма татар әдипләренең әсәрләрендә иҗат иткән авторын язу һәр очракта да тотрыклы сакланмаган. Менә бу кыйссаның авторы да исемен белдермичә калдырган. Һәрхәлдә, Мансур әл-Хәлляж турындагы әсәрнең безгә мәгълүм булган күчермәләрендә авторының исеме юк. Әдәбиятыбыз тарихында мондый табышмаклар, әлбәттә, шактый. Әмма нәкъ менә бу әсәр очрагында, автор исемен күрсәтмәүнең сәбәбе, ахрысы, нииндидер битарафлыктан яисә иҗади традицияләргә илтифат итмәүдән түгелдер. Мансур Хәлляж карашлары ислам дине тарихында «көферлек» буларак бәяләнгәнгә һәм кыйсса үз эчтәлеге белән иҗат

ителгән дәверендәге дин юлбашчылары тарафыннан кискен ризасызлык тудыру ихтималы булганга, аның авторы исемен белдермичә калуны мәгъкуль күргән дип фаразласак, ялгышмабыз шикелле.

Мондый төстәге әдәби әсәрнең авторын ачыклау шактый кыен. Тик шулай да, авторлары төгәл билгеле булган бүтән әсәрләр белән чагыштыру ысулына нигезләнеп, бу мәсьәләне чишүгә омтылыш ясадык. Җентекләп өйрәнүебез нәтиҗәсендә, Мансур турындагы кыйссаның авторы «Могҗизнамә» исемле (1515 елда иҗат ителгән) күләмле әсәрне язган Мөхәммәтәмин булгандыр дигән фикергә килдек.

Мөхәммәтәминнең 1518 елда вафат булганлыгын исәпкә алганда, «Мансур Хәлляҗ кыйссасы» XVI гасыр башында язылган дип билгеләргә мөмкин. Мәгълүм ки, Мансур әл-Хәлляҗнең тарих мәйданында пәйда булып, гыйсъяный карашлары белән танылуы гарәп хәлифәлегенең каршылыклы чорына туры килгән. Гаять катлаулы эчке һәм тышкы сәясәттән кайнап торган Казан ханлыгында мондый эчтәлектәге әсәрнең барлыкка килүе очраклы гына түгел. Казан ханлыгы чоры әдипләренең тарихта булып үткән охшаш вакыйгаларга мөрәҗәгать иткәнлеге фәндә мәгълүм.

Мөхәммәтәмин тарихта мәгълүм шәхес. Ул Казан ханлыгы дәверендә яшәп, 1487—1496 һәм 1502—1518 елларда Казан ханы булып торган. Мөхәммәтәмин ханлык иткән чор төрле катлаулы вакыйгаларга бай булган. Аның «Могҗизнамә»дән тыш, «Гыйкаб» исемле шигыре билгеле булуын һәм әдәбият-сәнгатькә мөкиббән хөкемдар булганлыгын искәртәбез. «Могҗизнамә» әсәрен галим Мәсгуд Гайнетдин өйрәнеп, 2004 елда Татарстан китап нәшриятында 295 битле күләмле китап итеп бастырып чыгарган иде.

Мансурга багышланган кыйссаның авторы турындагы фикеребезне куәтләү өчен кайбер дәлилләргә игътибар итик.

«Могҗизнамә» белән Мансур Хәлляҗ турындагы кыйссаның сүзлек составы бер-берсенә бик якын. Рифмадаш сүзләрнең бердәйлеге бу әсәрләрнең авторын ачыклауга ярдәм итә торган дәлилләрдән. Ике әсәрдә дә «кеше = эше, каму = гаму, олу = бәхетлү, сафа = Мостафа, падишаһ = Илаһ, мәгәр = могтәбәр, вөҗүд = сөҗүд, сүз = күз, ачылыр = сачылыр, җан = кан, таш = баш, насиб = табиб, хас-у-гам = тәмам, дәм = дәдәм, җәлил = зәлил, әйләде = сөйләде, гаҗәб = Чәләб» кебек рифмалар очрый һәм кабатлана. Шулай ук, «сәлам, тәмам, рәван, заман, һаман, әман, җәван, җәһан, җан, җан-җәһан, җанан, җан-у-тән, гайан, бәйан, гөман, зыян, елан, яман, фиган, ниһан, нишан, мәкян, нагяһан, бигиран, мәрдеман, җавидан, шадиман, һомам, тәгам, мәкам, никнам, низам» кебек һәм «хәбәр, мәгәр, пәдәр, писәр, ширнәр, әшикяр, Кәрдигяр, һөнәр, пәр һөнәр» һәм боларга охшаш бүтән сүзләр «Могҗизнамә»дә һәм Хәлляҗ кыйссасында үзара гаять еш рифмалашып килгәннәр. Дөрес, андый рифмалар Мөхәммәдьярда (бигрәк тә «Нуры содур»да) һәм ул чордагы башка авторларның әсәрләрендә дә бар. Ләкин охшаш рифмаларның һәм сүзлек хәзинәсенең тәңгәллеге ягыннан, «Могҗизнамә» белән Хәлляҗ кыйссасы дәрәҗәсендә, бер-берсенә гаять якын әсәрләр юк.

Чагыштырып карау өчен кайбер шигъри юлларны күчереп китәбез. Хәлляҗ кыйссасындагы шигъри юлларның поэмадагы бәйт саннары, ә «Могҗизнамә» әсәренең 2004 елда басылган китап битләре курсив белән җәяләр эчендә күрсәтелде.

| *Мансур Хәлляҗ кыйссасында* | *«Могҗизнамә»дә* |
|---|---|
| *(8)* Кем аның дустлыгына улды җиһан,<br>Җөмлә варлык әшикярә вә ниһан. | *(238)* Беленез кем: анчалаен, бу җиһан,<br>Каим улды әшикярә вә ниһан. |
| *(113)* Ки гаҗәб мәҗнүн улубдур ул кеше,<br>Йухса качан кыйлды ошбу эше? | *(80)* Ничәсәр кыздан тугар кари кеше!<br>Ничә шәхс ула ки, кыйлды бу эше? |
| *(140)* Тулды ул хәлвәт «әнә-л-Хак»дан тәмам.<br>Күрделәр бу сирре җөмлә хас-у-гам. | *(71)* Ул ләгыйнь йигдырды шәһр әһлен тәмам.<br>Хәзер улды анда җөмлә хас-у-гам. |
| *(153)* Шәргъ арасындан купрудың чөнки таш,<br>Таш йиренә корсун ана Мансур баш. | *(59)* Чөн ишетте бу нидае анда таш,<br>Һәрбере, илан кеби, күтәрде баш. |

| | |
|---|---|
| *(160)* Һәр кем ул дәрйада гарык улды тәмам,<br>Жан-у-баш фәрекъ әйләмәз, әй, һомам! | *(187)* Ягъни: Вирдем нигъмәтем сәңа, тәмам,<br>Динене һәм кямил иттем, әй һомам. |
| *(175)* Һәрберенә Хак биребдүр бер насиб,<br>Кемесе—рәнҗүдер, кемесе—табиб. | *(60)* Дәрдә дәрман улмаз улырса насиб,<br>Кем, шифа өчен, аңа нитсен табиб. |
| *(204)* Диде Мансур анлара: Әй, мәрдеман!<br>Хак сезе кортарур, сез тотмаң гөман. | *(68)* Диде: «Тәхкыйк итеңез әй мәрдеман,<br>Берлекенә юктыр ул Хакның гөман. |
| *(205)* Вакыт ирешде, ул Чәләб лотыф эшләя,<br>Сезе азад әйләйеб багышлая. | *(286)* Чөн Хак аңа, күр, нәчә эш эшләя:<br>Беренә—йөз, йөзенә—мең багышлая. |
| *(296)* Ачдылар зиндан капусын шул заман,<br>Ичрә керде ул шәйхе кәмран. | *(34)* Чөнки бер кач дүнде бер дәүре заман,<br>Хак аны дөньяда кыйлды кәмран. |
| *(315)* Бәнде суратдә әсир улса кеше,<br>Улмайа бу мәгънәдән бәхшаише. | *(286)* Һәм дога кылды аның өчен ул кеше:<br>Әйләсен Халикъ сәңа бәхшаише! |
| *(419)* Варыб Мансурдан алам бән хәбәр,<br>Ул хәбәрдән сорам хален, могтәбәр. | *(172)* Равилардан заһир улды бу хәбәр,<br>Сөйләмешләр һәм сарих, могтәбәр. |
| *(479)* Имди тәгъжил әйләсүнләр бу эше,<br>Калмайа такем уларун тәшвише. | *(101)* Та, Рәсүлә димәясән бу эше.<br>Улмая сәгъйең габәс, куй тәшвише. |
| *(519)* Сәждә кыйлуб дорды йирендә шу дәм,<br>Дыңла, Мансуры нәйдәрләр, әй, дәдәм! | *(101)* Олысы кечесенә димеш у дәм:<br>Углагы күр, нәчә үлдерде дәдәм. |
| *(548)* Чөнки Мансур ошбу сүзе сөйләде,<br>Ул хәляикъ, аглайуб, аһ әйләде. | *(169)* Ул моны безә васыять әйләде,<br>Нәчә ки, мәхсулә хәлен сөйләде. |
| *(558)* Йәнә чагырды «әнә-л-Хак» шул заман,<br>Шөйлә кем—вәжед улдылар пир-ү-жәван. | *(159)* Ләшкәренә диде Жәмһүр ул заман:<br>Бу—нә сөйләр? Күрең, әй пир-ү-жәван! |
| *(618)* Безә белдүр бу эши, әй, пәр һөнәр,<br>Деләрүз кем, вирәсән бондан хәбәр. | *(251)* Диде ул гаурәт аңа: «Әй пәр һөнәр,<br>Өч йөз елдыр—монда мән, белгел хәбәр. |
| *(642)* Йәнә җәллад ул заман килде иләрү,<br>Диде Мансура: «Айагын кәлтүр бирү!» | *(212)* Типте атын, ул дәм Харис иләрү<br>Диде: Лафы нә диерсен? Кил бирү. |
| *(659)* Бу хәрабең соны мәгъмүр улисәр,<br>Ошбу зольмәтдән кәчүб нур улисәр. | *(167)* Өче дәхи ахирәттә улисәр;<br>Һәүле мәхшәр рәстәлеккә улисәр: |
| *(760)* Бу нә кодрәтдүр ки кыйлдун, йа, Илаһ,<br>Сән гыйнайәт кыйл безә, әй, Падишаһ?! | *(162)* Олуглыгын хөрмәте чөн, йа Илаһ,<br>Хажәтем әйлә кабул, әй Падишаһ! |
| *(772)* Һәр йирә кем дөшде, ул көлләән һаман<br>Чагыруб диде: «Әнә-л-Хак» бигөман. | *(183)* Диде чөнки: Мән кире килдем, һаман,<br>Яттыгым йир эссе иде бигөман. |
| *(795)* Бонлара шул рәсмә чөн дөшде фәган,<br>Яшь йиренә күзләрендән акды кан. | *(157)* Диде: Беленез, кемнеңдер бу фәган?<br>Дәрт илә гамьдин улыбтыр бәгъре кан. |
| *(839)* Гәр безе бу гамьдән азад идәсән,<br>Рухы Мансуры, кәрәк шад идәсән! | *(231)* Дошман тотмыш икән, азат итәсән,<br>Баш вирәп, гамьдән аны шат итәсән. |

Хәлляж турындагы поэмада һәм «Могҗизнамә»дә рифмаларны бер-беренә охшаш рәвештә уйнату күренеше дә бар. Мәсәлән, «Могҗизнамә»дәге (275 бит):

*Бакмагыл, Максуди, дөнья хәленә,*
*Халк илә күр, ул фәнаның хәле нә?*

—дигән юлларга охшаш алым Хәлляж кыйссасында да очрый. Андагы 50нче һәм 534 бәйтләрдә түбәндәгечә язылган:

*Гыйшкы Хак тулмышде аның серренә,*
*Дыңла имди, кәнду кемдер, серре нә?*

*Талиб улың сурәтең мәгънәсенә,*
*Мәгърифәтсез сурәтең мәгънәсе нә.*

Хәлляж кыйссасында матдилеккә караганда рухи як өстенлек итәргә тиешлеге әсәрнең башыннан-ахырынача кабатланып килә. Автор, укучыга мөрәҗәгать итеп, болай ди:

*Җан күзе илә күр сән—гыйбрәт нәдер,*
*Җан колагы илә ишет—хикмәт нәдер!*

Мансур Хәлляж кыйссасындагы «Дот колагын имди гыйшык әхваленә» (39 бәйт), «Җан колагын дотың, Кодрәт нәйләде» (80 бәйт), «Дыңла җан илә сүзе, әй, бәхетдар!» (277 бәйт), «Дыңла имди җан илә, әйдәм саңа!» (827 бәйт) кебек, бик еш кулланылган гыйбарәләр «Могҗизнамә»дә дә бар. Мәсәлән, «Тот колагын, мөстәмигъ улгыл моңа» (131 бит), «Дыңла, әй җан, сөйләем хали гаҗәб» (29 бит), «Һәркем аның җан илә дыңлар сүзен» (57 бит), «Сабыр итәм җан илә, Хактан киләнә» (121 бит).

Укучының игътибарын тагын да җанландыру өчен автор кулланган бу сүзләрдән тыш, бүтәнчә гыйбарәләр дә бар. Мәсәлән,

| Мансур Хәлляж кыйссасында | «Могҗизнамә»дә |
|---|---|
| Дыңла имди, нә улисәрдүр мажара!» *(579 бәйт)*<br>Йәнә Мансуры күр имди—нәйләди *(639 бәйт)* | Сән хәбәрдар ул: нә улмыш мажара! *(126 бит)*<br>Хикмәте Халик күр, ул дәм нәйләде *(98 бит)* |

Ике әсәрдә дә охшаш гыйбарәләрнең кулланылуы шулай ук поэмаларның бер үк автор каләменә нисбәтле икәнен раслый.

Мансур Хәлляж кыйссасының күпчелек өлеше әңгәмә ысулына корылган. Ягъни, анда тасвири хикәяләү аз булып, вакыйгалар агышы күбрәк җанлы диалог рәвешендә бирелгән. Бу үзенчәлек «Могҗизнамә» әсәренә дә хас. Әңгәмәдәшләрнең бер-берсенә түбәнчелек һәм хөрмәт белән мөрәҗәгать иткән сүзләренең мул һәм охшаш булуы шулай ук әлеге ике әсәрнең авторы бер кеше дигән фикерне ныгыта.

| Мансур Хәлляж кыйссасында | «Могҗизнамә»дә |
|---|---|
| Диде Мансур: Әй, Ходавәнди җиһан (58 бәйт) | Диделәр ки: Әй Ходавәнд-и җиһан (204 бит) |
| Диде Мансур анлара: Әй, мәрдеман! (204 бәйт) | Диде: Мәгълүм итенез, әй, мәрдеман (62 бит) |
| Диде Мансур ана, әйдер: Әй, һомам! (236 бәйт) | Сөйләде итеп тәвазегъ: Әй һомам (235 бит) |
| Диде Мансур: Әй, Ходайи Мөстәган! (248 бәйт) | Диде ул дәм: Әй, Рәсүле Мөстәган (215 бит) |
| Диде Мансур ана: Әй, җан җиһан! (310 бәйт) | Диде Газраил: Әй, җан җиһан (200 бит) |
| Диделәр Мансура кем: Әй, гыйшык әри! (509 бәйт) | Мәрхаба харбенә, әй мәйдан әри! (227 бит) |
| Диделәр: Нәйләрсән, әй, сахиб кәрәм? (612 бәйт) | Бәс, Рәсүлә диде: Әй әһле кәрәм (166 бит) |
| Иләрү керде, әйде: Әй, җани мән! (617 бәйт) | Атасы диде: нә дирсән, җаны мән? (133 бит) |
| Диде Мансур ана: Әй, әһле якыйн, (625 бәйт) | Диде ки: Әй, галиме гыйльмел якыйн (72 бит) |

Монда китерелгән мисалларга өстәп, Хәлляж кыйссасында киләчәк заман фигыль формасының борынгыча бирелешен дә (күрисәр, улисәр, булисәр, куписәр һ.б.) әйтеп китәргә кирәк.

Югарыда тасвирлап үтелгән тел-сурәтләү үзенчәлекләренең Мөхәммәдьяр әсәрләрендә дә шактый очравы табигый. Чөнки М.Гайнетдин язганча (Могҗизнамә, 12—13 битләр), Мөхәммәдьяр шагыйрь буларак Мөхәммәтәминне үзенең рухи остазы итеп таныган һәм үз әсәрләренең сюжетларына «Могҗизнамә»дәге вакыйгаларны нигез итеп алган.

***

Яна табылган поэманы текстологик яктан өйрәнү дәвамында Казан дәүләт университетының Н.И.Лобачевский исемендәге фәнни китапханәсендә Мансур Хәлляҗ кыйссасының ике кульязма күчермәсе һәм Россия Фәннәр академиясенең Көнчыгыш кульязмалары институты фондында (Петербург) бер күчермәсе барлыгын ачыкладык.

Әсәрнең Казан университеты китапханәсендә саклана торган күчермәләренең берсе күләмле генә җыентык эчендә. Ул китапханәгә 1968 елда Буа районының Кул Черкене авылында Рабига Минһаҗевадан алынган. «2213 т» шифры белән саклана торган әлеге кульязма җыентыкның 1б—27б кәгазьләрендә Хәлляҗ турындагы поэма язылып, аның исеме «Мансур китабы» дип күрсәтелгән. Кульязма җыентыкны Исмәгыйль бине Мөхәммәт исемле кеше 1828 елда мулла Габденнафигъ бине мулла Габделморад мәдрәсәсендә күчергән. Анда мәдрәсәне төзеткән кешенең исеме дә—мулла Сәйфелмөлек бине мулла Ибраһим Тархани дип язып куелган. Бу кульязмада поэманың 834 бәйте бар. Әсәрнең башы һәм бетем өлешләре булса да, ягъни ул, беренче карашка, тулы кебек тоелса да, аның 33 бәйте җитешми.

Поэманың шул ук китапханәдә «397 т» шифры белән саклана торган икенче нөсхәсе китапханә хезмәткәрләре тарафыннан «Кыйссати Мансур әл-Хәлляҗ» дип исемләнгән һәм башы-ахыры юк дип искәртелгән. (Әмма әсәрнең башы булмаса да, ахыры бар, аның бары тик битләре генә буталган). XVIII гасыр ахырына караган, ундүрт кәгазьдән гыйбарәт бу кульязманың 1а—12а, 13а—14б кәгазьләрендә Хәлляҗ турындагы поэма язылган. Бер битендә «Авык кыйссасы» язылган. Кульязмада Мансур кыйссасының 447 бәйте теркәлгән. Шуны искәртергә кирәк, әлеге текст бик хаталы язылган. Аның Казан вилайәтендәге Көчек авылында мулла Илкәй бине Мостафа мәдрәсәсендә мулла Нигъмәтулла бине Габдессәлам тарафыннан күчерелүе күрсәтелгән. Бу кульязманың танылган археограф Сәет Вахиди (1887—1938) китапханәсендә булганлыгын раслый торган автографлары бар, галимнең түгәрәк мөһере сугылган.

Россия Фәннәр академиясенең Көнчыгыш кульязмалары институтындагы кульязма җыентыкның башындагы бер бите җуелган. Сакланган беренче кәгазенең түбәнге өлеше дефектлы (ертылган). Калган битләрендә тексты тулаем диярлек сакланган, ахыры бар. Бу кульязманың 1б кәгазендә 41 һәм 42 бәйтләр арасында «Кыйссаи Мансур» дип, әсәрнең исеме язылган. Кульязманың башында 1—17нче һәм текст эчендәге кайбер бәйтләре язылмыйча калуы сәбәпле, бөтенесе бергә 25 бәйте җитешми. Ә сакланган бәйтләр саны—842. Бүтән кульязмаларга хас булганча, текстта хаталар, төзәтүләр һәм палеографик үзенчәлекләр бар, язуы уртача камиллектә. Җиде урында бәйтләрнең урыннары үзара алыштырылып язылган. Әсәр ахырында хаталы язылган колофонда аның Мазарбаш исемле авылдагы Фәтхулла әфәнде мәдрәсәсендә Букәнбай угылы Кылычнияз тарафыннан күчерелүе күрсәтелгән. Төгәл датасы юк. Ләкин аның XIX гасырның беренче чирегендә күчерелгәнлеген билгеләп була. Кульязманы институтка татар археографы Сабир Алимов (1871—1939) тапшырган. Ул институтның штаттан тыш хезмәткәре сыйфатында, 1935—1939 елларда иске кульязмалар җыю белән Әстерхан шәһәрендә һәм аның янәшә-тирәсендәге төбәктә шөгыльләнгән.

Мансур кыйссасының без ачыклаган биш күчермәсе дә татар җирлегендә табылуы—аның татар әдәбияты ядкәре булуын куәтли торган көчле дәлил.

Бу әдәби ядкәрнең тулы тексты, Татарстан милли китапханәсендә саклана торган ике кульязма нөсхәсе нигезендә, аерым китап итеп бастырырга әзерләнә. Ул «Милли китап» нәшриятында чыгып килә торган «Татар археографиясе» сериясенең алтынчы китабы буларак дөнья күрәчәк. Шуннан соң филолог галимнәребез әсәрне төрле җәһәттән өйрәнеп, Мансур Хәлляҗ кыйссасы турында тагын да дәлилләрәк һәм нигезле фикерләрен әйтерләр дип өметләнәбез.

## Кыйссаның эчтәлеген тасвирлаган өлеше өчен сүзлекчә:

***абе хәятә кандырың***—*тереклек суына сал*
***аглашубән***—*елашып*
***алан***—*алган*
***әймешсән***—*әйттең*
***әл***—*кул*
***әсрар***—*серләр*
***баек***—*ачык, анык*
***бәнд***—*тоткын*
***бәндәдер***—*миндә*
***бәрадәр***—*туган*
***бәшарәт***—*шатлыклы хәбәр*
***бинифак***—*ялгансыз, чынлап*
***бинишан***—*билгесез (Аллаһ)*
***варуң***—*барыгыз*
***вәхдәт дөрре***—*бердәнберлек энҗесе*
***вирмәң әман***—*тынычлык бирмә*
***гайан***—*ачык*
***голү итде рәван***—*нык ярсыды*
***госса***—*кайгы*
***гөнаһкяруз***—*гөнаһлыбыз*
***дәгүл***—*түгел*
***дәлу***—*мәҗнүн*
***дәм***—*вакыт*
***дәрдә дәрига***—*газап-үкенеч*
***дередүр***—*тере*
***дидүке кале***—*әйткән сүзе*
***дийар***—*илләр*
***димәк***—*дигән*
***диң***—*әйт*
***дорур***—*торыр*
***дотубән***—*тотып*
***дөшдек җөда***—*аерылдык*
***дыңла***—*тыңла*
***җанан***—*сөекле (Аллаһ)*
***җан-у-баш***—*җан һәм баш*
***җәмегъ улуб***—*җыелып*
***зате Хәййем***—*үлемсезмен*
***заһир әйләдең***—*белдердең*
***зыяфәт***—*кунак иту, бәйрәм*
***ибен дакуб бәрдар идүң***—*җебен тагып ас*
***иләру***—*тагын*
***индүрүб***—*иңдереп*
***ирдем***—*ирештем, кушылдым*
***ирмаг***—*елга*
***йилә саруң***—*җилгә очыртыгыз*
***йүчә йирә чыкубән***—*биек җиргә чыгып*
***йывынды***—*юынды*
***каму***—*барлык*
***канда***—*кайда*
***кауме дүн***—*түбән дәрәҗәләләр*
***кәлям***—*сүз*
***кәсең***—*кис*
***кемсәйә***—*кешегә*
***кинә***—*янә*
***колуз***—*колбыз*
***кортарубән***—*коткарып*
***күрүклү***—*күркәм, матур*
***кылмасун ашикяр***—*ачмасын*
***кямәран***—*бәхетле*
***лотф***—*мәрхәмәт*
***мәгани тәхте үзрә***—*мәгъналәр төхетендәге*
***мәфһүм***—*мәгънә*
***мәху***—*юкка чыгу*
***мөнтәшир***—*чәчү, тарату*
***Мөстәган***—*ярдәм көтелгән зат (Аллаһ)*
***нәдер***—*нәрсә*
***нәйдәлүм***—*нишлик*
***нәйләрәм***—*нишләтим*
***нәснә***—*нәрсә*
***раһнәмун***—*юлбашчы*
***Рәббани***—*Аллаһның*
***рәдд әйләмә***—*кире какма*
***салан***—*салган*
***сезә***—*сезгә*
***сөйләрәм***—*сөйлим*
***та зиндан капусына***—*зиндан капкасына хәтле*
***таки җөзем бәндүме вә багыми***—*йөзем белән бәйләп торган буыннарга хәтле*
***та кыямәт җанымызига фирак***—*кыямәткәчә җаныбыз аерылды*
***тәдбир***—*чара*
***төхфә***—*бүләк*
***туградурым***—*туратырмын*
***улан***—*булган*
***үгүш***—*күп*
***Хак бәнем***—*мин—Хак*
***хале***—*хәлне*
***хушнуд ула***—*канәгать була*
***һәп***—*һәммәсе*
***шайәд ула***—*шәт файдасы булыр*
***шәрхә-шәрхә***—*вак кисәкләр*
***шөйлә кем***—*шундый ки*
***чагырыр***—*кычкыра*
***эб***—*җеп, бау*

Фирдәвес
Гарипова

# АВЫЛЛАРЫБЫЗ ТАРИХЫ

## Багыш

Багыш авылы Апас районында, район үзәге Апастан —34, җирле үзидарә советы үзәге Чирмешән авылыннан 2 чакрым ераклыкта урнашкан.

Археологлар Багыш авылы янында борынгы Болгар чорларына нисбәтле авыл хәрабәләре тапканнар.

XVIII йөз мәгълүматларын үз эченә алган белешмәдә (Д.А.Корсаков) Багыш авылы Өченче Чирмешән дип тә атала. Бу чорда авылда 117 йомышлы, 5 ясак түли торган 11 һәм 3 керәшен татары күрсәтелгән. Багыш, Югары Балтай, Урта Балтай, Түбән Балтай, Зур Бакырчы, Кече Бакырчы, Кара Борнаш, Чиру, Каратун, Колчык, Көлкәш, Чирмешән, Чәтбаш, Коллар, Шәмәк, Күкшем, Тутай, Аксу, Дәүләки авыллары июнь урталарында Кушкапка исемле җыен бәйрәмнәре үткәргәннәр.

Аксакаллар сөйләвенә караганда, авыл XVI йөз урталарында оешкан. Аны иң беренче булып нигезләгән кеше Багыш баба булган. Элек авыл урынында калын урман үскән. Авыл яныннан Чирмешән суы ага.

Багыш аксакаллары сөйләвенә караганда, Явыз Иван 1552 елда Казан ханлыгын яулап алганнан соң, аның тарафдарлары Тәрбит авылы халкын Орым суына куып кертеп, барысын берьюлы чукындырырга омтылып караганнар. Христиан динен кабул итәргә теләмәгән Тәрбит мөселманнары шыпырт кына Багыш авылына күченеп килеп утырганнар.

Авылның кыйблысы нык, халкы эшчән, булган кешеләр. Күл урамы, Яңа Акбай, Иске Акбай, Усак, Арттагы урам, Өчмунча, Күл, Карга, Үрмәт урам-җыеннарында (җыен дип халык урам исемнәрен атый) авылны нигезләгән кешеләрнең һәм чукындырудан качып килеп утырганнарның ерак оныклары тыныч кына яшәп ята.

Багыш авылында хуҗалыклар саны 100дән артык. Анда башлангыч мәктәп, балалар бакчасы, медпункт, китапханә, кибет, мәдәният йорты бар.

Хәзерге вакытта авылда мәчет эшли. Бу мәчет «Татарстан Республикасы: тарих һәм мәдәният һәйкәлләре» дип аталган китапка кертелгән. Авыл халкы әби-баба, ата-ана күмелгән зиратны кадерләп саклый, карап тора.

## Базарлы Матак

Базарлы Матак авылы—Әлки районының район үзәге. Ул Казаннан 152 чакрым ераклыкта урнашкан.

Әлки районы 1965 елда оеша. Ул республиканың көньяк өлешендә. 1993 елда Базарлы Матакта 4,2 мең кеше яшәгән. 1989 елда Әлки районында 61,7 процент татарлар, 21,3 процент чуашлар, 16,5 процент руслар көн күрә. Районда 21 җирле

---

*Дәвамы. Башы 2006 елның 6нчы санында.*

үзидарә советы һәм 73 торак пункт бар.

Район жирләре буйлап Алексеевск—Базарлы Матак—Болгар автомобиль юлы үтә. Игенчеләр бодай, арыш, солы, арпа, борчак игәләр. Терлекчеләр мөгезле эре терлек һәм дуңгыз үрчетү белән шөгыльләнә. Район үзәгендә кирпеч заводы һәм типография эшли, урман хуҗалыгы бар.

Авыл Актай суының Кара елга дип аталган кушылдыгы ярына утырган.

Олы буын кешеләре сөйләвенә караганда, элек авыл урынында чуашлар яшәгән. Соңыннан бу урынга әкренләп татар-мишәрләр дә килеп утыра башлаганнар.

Авыл тирә-юнендә Кара тау, Җиләкле тау, Нарат урманы, Кыр урманы, Чуаш урманы, Олы юл, Туры юл дип йөртелгән географик берәмлекләр бар.

Базарлы Матакта мәдәният йорты, китапханә, хастаханә, даруханә, балалар бакчасы, кибетләр халыкка хезмәт күрсәтә.

Мәчет салынган, теләгән кеше мәчеткә йөри.

## Яңа Дума

Яна Дума авылы Аксубай районында, район үзәге Аксубайдан—7, жирле үзидарә советы үзәге Яна Кармәттән 3 чакрымда урнашкан.

Дума атамасы тарихи чыганакларда очрый. Рус галимнәре А.Артемьев һәм С.М.Шпилевский Яна Дума авылы янында борынгы шәһәрлек урыны күрсәтәләр. Д.А.Корсаков (XVIII йөз) Яна Дума авылында 97 йомышлы татар яшәгәнлеген күрсәтә. Шунда ук номерсыз гына Иске Дума да искә алына. Анда 21 керәшен татары яшәгән.

Авыл халкы сөйләвенә караганда, элек бу тирәләрдә тоташ нарат урманы булган. Биредә кеше яшәмәгән, 300 еллар элек кенә өч гаилә килеп, Кара чишмә тирәсен ошатканнар һәм шул тирәгә утырганнар. Авыл нигездә шушы өч төптән оешкан. Алар кабыктан 5 өй корганнар. Өчесендә үзләре торган, икесе мал-туар өчен булган. Соңыннан алар йортларын бүрәнәдән салалар.

Авыл нигезләүчеләрнең бер тармагын алатырьлар, икенчесен мыгриннар, өченчесен кузюрлар дип әйтәләр. Алатырьларның йөзләре каракак, күз-керфекләре кара, сабыр холыклы таза халык, күп сөйләшмиләр. Мыгриннар буйга кечерәк, ак чырайлы, чәчләре дә аксыл, күзләре зәңгәр, чибәрләр, чисталар. Кузюрлар бөтен яктан мәдәниятле, сәнгатьне нык аңлыйлар, кап-кара чәчле, озынчарак йөзле, холыкларында көнчелек бар, кызу канлы кешеләр.

Авылда тагын морза һәм татарлашкан чуаш нәселләре дә бар дип сөйлиләр. Халыкның бер өлеше чукындырылган булган. Ләкин алар яңадан исламга кире кайтканнар. Керәшен татарларын элек халык мөртәтләр дип йөргән. Аларның зиратлары аерым булган, халык аларга кыз бирмәгән һәм кыз алмаган. Хәзер авылда татарлар гына яши.

Авыл янында тарихи һәм изге урыннар, иске зиратлар, елга-инешләр, чишмә-кизләүләр, күл һәм күлләвекләр хәйран күп.

Авыл янындагы тау өстендә Мәүлем Хуҗа, таш баганалы урында Җәдәйхан Хуҗа каберләре бар. Алар изге урыннар дип йөртелә. Туган туфрак—изге туфрак.

Шагыйрь, прозаик, публицист, әдәбиятчы-тәнкыйтьче, тәрҗемәче, педагогикага караган хезмәтләр авторы Нәжип Думави (1883—1933) Яна Дума авылында туган.

*Дәвамы киләсе саннарда.*

# Л

**ЛИМОНОВА** Инна Валерьевна (3.9.1955, Чиләбе ш.), шагыйрә. 1972 дә комсомол юлламасы б-н КамАЗ төзелешенә килә. 1973-75 тә Казан ун-тында укый, 1982 дә Мәскәүдә Әдәби ин-т тәмамлый. 1990-95 тә Алабугада М.Цветаева музее директоры. 1995тән Мәскәүдә яши. «Российский обозреватель», «Инвестиции в России», «Дорожный патруль» ж-лларында эшли. 2001 дән «Лимпресс» нәшриятен житәкли. «Шәһәр каеннары» («Городские берёзы», Чиләбе, 1980), «Иртәнге сәгатьтә» («В час предутренний», 1982), «Чаллы өстендә ак кошлар» («Лебеди над Челнами», М., 1982) шигъри җыентыклар, проза һәм драматургия әсәрләре китаплары («Елга буена алып төш мине...»—«Отнеси меня к реке...», 1990) авторы. Л.ның шигъриятендә һәм прозасына гадилек, эчкерсезлек, дөньяны кабул итүдә самимилек һәм эчке каршылыксызлык хас.

Әд.: Даутов Р.Н., Нуруллина Н.Б. Совет Татарстаны язучылары: Биобиблиогр. белешмә. К., 1986.

*Р.Р.Мусабәкова.*

**ЛИПКИН** Семён Израелевич (6.9.1911, Одесса ш.—1.4.2003, С.-Петербург ш.), шагыйрь, тәрҗемәче. Мәскәү инж.-экон. ин-тын (1937) тәмамлый. «Шаһид» («Очевидец», М., 1967), «Саз» («Лира», М., 1989) исемле шигъри җыентыклар, «Фатирчы язмалары» («Записки жильца», 1992) автобиографик повесте, А.А.Ахматова, О.Э.Мандельштам, Э.Г.Багрицкий һ.б. турындагы мемуарлар авторы. 1930 еллардан соң тәрҗемәләр б-н шөгыльләнә. Рус теленә «Җангар» калмык, «Манас» кыргыз эпосларын, Низаминың «Ләйлә вә Мәҗнүн», Фирдәүсинең «Шаһнамә» поэмаларын; Г.Тукайның шигырьләрен, «Шүрәле», «Су анасы» поэмаларын, «Идегәй» дастанын (ТРның Г.Тукай исем. Дәүләт премиясе, 1992), Г.Чокрый, Акмулла, Дәрдемәнд, М.Җәлил, Г.Кутуй, Ә.Ерикәй, Ф.Кәрим, С.Хәким һ.б. татар шагыйрьләренең шигырьләрен тәрҗемә итә. Әдәбият һәм сәнгать өлкәсендә РФ Президенты премиясе б-н бүләкләнә (2002).

Әд.: Рассадин Ст. «Кровь» рифмуется с «любовь» // Вопр. Литературы. 1990. №2.

*Р.Р.Мусабәкова.*

**ЛИРИК ПРОЗА**, эпосның бер төре, анда мәгънәви һәм композицион үзәк булып күңел кичерешләре һәм уй-фикерләр чылбырында гәүдәләндерелгән герой анының эволюциясе тора. Л.п.ның төп билгеләре аның поэтикасында лирика һәм эпос сыйфатлары кушылудан аларның үзара бәйләнешләреннән үсеп чыга. Лирик компонент йә эчтәлегендә, йә формасында өстенлекле булырга мөмкин. Шул уңайдан, «Л.п.» атамасы татар әдәбият белемендә ике мәгънәдә кулланыла: 1) шигъри формада язылган прозаик әсәр (шигъри роман, шигъри повесть, шигъри хикәя). Л.п.ның жанр булып оешуы урта гасыр төрки-татар әдәбиятына барып тоташа. Ул чорда зур күләмле сюжетлы әсәрләр (Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф», Котбның «Хөсрәү вә Ширин», Сәйф Сараиның «Сөһәйл вә Гөлдерсен» поэмалары) бер үк вакытта шигъри яки элогиаль (кушма тип) рәвештә яшиләр. Эчтәлеге б-н алар кыйсса яки дастан жанрына тартым, формаль сыйфатлары б-н исә—мәснәвигә. 19 йөздән башлап татар эпосы проза б-н языла, традицион эпик хикәяләүдән тайпылу яңалык кебек кабул ителә. Ә.Давыдовның «Йокысыз төннән соң», С.Батталның «Чирмешән якларында» романнары, С.Батталның «Олы юл буйлап», Ә.Давыдовның «Күмер көйри», Ш.Маннурның «Җир-әнкәнең сылу кызы», Ш.Мөдәррисның «Яшел тасма» повестьлары һ.б. нәкъ шулай бәяләнә дә. Эпик һәм лирик башламнарны, автор һәм персонажлар дөньясын сурәтләү һәм белдерү якларын бергә тоташтырып, шигъри форма жанр төзүче шартка әверелә. 2). Хикәяләүнең шәхсиләшүе, үзенчәлекле тышкы дөньяның шәхси анда чагылышы, чынбарлыкны шул анның элементы итеп күзаллау хас булган лирик характердагы прозаик әсәр. Прозада лирик башлангычның көчәюенә китергән сәбәпләр аркасында хикәяләүнең берүзәкле, сөйләү кебек оештырылуын, мәгънәви һәм образлар ягыннан тыгызлыкны, сурәтләү чараларының катлаулануын, күпмәгънәлелекне аерып күрсәтергә кирәк. Эпик сыйфатларга Л.п. да сюжетлылык, сиземләнү, игътибарның төп герой характерын, колачлавын мотивлаштырулар, дөньяви танып белү юнәлешен саклавы карый. Татар прозасында бу төрнең чишмә башы сәҗегъ дигән гарәп әдәби жанрына

*Дәвамы. 2005 елның 4нче саныннан басылып килә.*

барып тоташа. Татар әдәбиятында Л.п. ике тапкыр: 20 йөз башында (Ф.Әмирхан, М.Хәнәфи, Ә.Тангатаров һ.б.) һәм 1960-80 елларда (Ф.Хөсни, М.Мәһдиев, Г.Сабиров, Ә.Баян, М.Галиев һ.б.) күтәрелеш чорын кичерә. Татар Л.н.ның поэтикасы дигәндә, геройның эчке монологы, тәүбә итү, психологизм формалары, төрле хронологик күчешләр, үткәнгә мөрәҗәгать итү, импрессионистик сурәт, әкренәйтү, композиция һәм стиль алымнары күздә тотыла.

Әд.: Шарипов А.М. Зарождение системы стихотворных жанров в древнетюркской и тюрко-татарской литературе (VIII—XV вв.). К., 2001; Хатипов Ф.Х. Әдәбият теориясе. К., 2000.

*Д.Ф.Заһидуллина.*

**ЛОТФИ** (1366, Герат ш., хәзерге Әфганстан—1465/66, шунда ук), Урта Азия шагыйре. Иске үзбәк (чыгытай) һәм фарсы телләрендә яза. Чама б-н күпмедер вакыт Алтын Урда башкаласында яши, Болгар ш. килгәли. Яшь чагында дөньяви фәннәрне өйрәнә, соңыннан суфичылык б-н мавыга, дәрвишләрчә яши. Шахрух солтан үтенече буенча Аксак Тимернең шигъри биографиясен (тәрҗемәи хәлен)—«Зәфәрнамә» («Җинүләр китабы») дастанын яза башлый, ләкин әсәр язылып бетми (кулъязмасы сакланмаган). «Гөл вә Нәүруз» (1411) героик-романтик поэмасын Л. шул исемдәге фарсы шагыйре Ж.Табиб поэмасына нәзыйрә рәвешендә иҗат итә. Күп сынаулар үтеп, ике гашыйкның кавышу сюжеты Л. тарафыннан гадел хөкемдар идарә итүче идеаль дәүләт турында фикер раслау өчен файдаланылган. Поэманың бер кучермәсе Казанда 1960 нчы елларда табыла. Л.ның төрле жанрларда язылган 4 мең шигъри юлы (газәл, кыйтга, робагый, кыйсса) билгеле; үзенең уй-хисләрен шагыйрь укучыга төрки телле халыклар фольклоры чаралары б-н житкерә. 1914 тә Казанда беренче тапкыр шагыйрьнең шигырьләре басыла. Аның иҗаты татар шагыйре Мөхәммәдъярга сизелерлек йогынты ясый.

Әсәр.: Лирика. Гуль и Науруз. М., 1961; Девон. Гул ва Навруз. Тошкент, 1965.

Әд.: Рустамов Э.Р. Узбекская поэзия в первой половине XV в. М., 1963; Эркинов С. Лутфий. Таш., 1965; Абилов Ш., Максудова З. Лотфи Идел буйларында // Казан утлары. 1968. №8.

*Ш.Ш.Абилов.*

**ЛОТФИ** (Лотфуллин) Гасыйм Фатих улы (16.4.1900, Царёвококшайск өязе, Иске Йөзем а.—3.6.1991, Казан), язучы, тәржемәче. 1937 дә Көнчыгыш пед. ин-тын тәмамлый, 1937-41 дә Казан ун-тында укый. Бөек Ватан сугышында катнаша. 1943-49 дә ТАССРның Мәгариф министрлыгында, 1960 ка кадәр «Совет мәктәбе» ж-лында (бүлек мөдире) эшли. Беренче хикәяләре 1920 елларның ахырында «Безнең юл», «Мәгариф», «Ярыш», «Башлангыч мәктәп» ж-ларында басыла башлый. «Тамчылар» (1947), «Шомырт» (1949), «Китап турында китап» (1952) җыентыкларына кергән хикәяләр һәм «Әнисәнең альбомы» (1949), «Канатлы дуслар» (1951) җыентыкларына кергән шигырьләр мавыктыргыч, балаларда кызыксыну, дөньяны белергә омтылучанлык тәрбияләлиләр. Л.—урта мәктәп өчен татар әдәбияты буенча дәреслекләр һәм методик әсбаплар авторы. Татар теленә А.П.Чеховның «Акмангай» («Белолобый», 1932) хикәясен, Е.Ильинаның «Дүртенче биеклек» («Четвёртая высота», 1953) повестен, Б.Полевойның «Без—Совет кешеләре» («Мы—советские люди», 1950) хикәяләр җыентыгын, М.Горькийның «Әкиятләр»ен (1949), Дж.Лондон хикәяләрен тәрҗемә итә.

Әд.: Гиниятуллина А. Татар Совет язучылары: Биобиблиогр. белешмә. К., 1970.

*Ф.И.Ибраһимова.*

**ЛЬВОВ** Михаил Давыдович (чын фам. һәм исеме Габитов Рәфкать Дәүләтша улы) (4.3.1917, хәзерге Башк. Респ-касы, Салават р-ны, Нәсибаш а.—25.1.1988, Мәскәү), шагыйрь. Рус телендә яза. 1941 дә Мәскәүдә Әдәби ин-т тәмамлый. Бөек Ватан сугышында катнаша. 1945 тән Мәскәүдә яши. Л. шигырьләренең төп темасы—замандашлары тормышы, кеше язмышының кабатланмас булуы. Аның лирик герое—бай эчке тормышлы, бөек рухка ия кеше. Л.ның иҗат манерасына тормышны фәлсәфи яктан аңлау, кырыс батырлык һәм нечкә лиризмның үрелеп баруы хас. «Бүген яшим» («Живу сегодня», 1973), «Бирелгәнлек» («Одержимость», 1977), «Мин сезне яраттым» («Я вас любил», 1977), «Тәүлек буе» («Круглые сутки», 1980), «XX гасырда яшим» («Живу в XX веке», 1984), «Каршы хәрәкәт» («Встречное движение», 1984) җыентыклар авторы. Рус теленә С.Рәмиев, М.Җәлил, Ә.Исхак, Ш.Маннур, М.Садри, С.Хәким, Н.Дәүли, Ә.Давыдов, М.Хөсәен, М.Әхмәтгалиев һ.б. шигырьләрен тәрҗемә итә. Ватан сугышы, I нче һәм II нче дәрәҗәле Хезмәт Кызыл Байрагы, Халыклар дуслыгы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Әсәр.: Шигырьләр. К., 1971; Собрание сочинений. В 3 т. М., 1987—88.

Әд.: Гәрәй Р. Ул безнең үз шагыйребез // Казан утлары. 1972. № 12; Әхмәтҗан М. Тормыш мизгелләре // Казан утлары. 1997. № 2.

*Р.Р.Мусабәкова.*

*Дәвамы киләсе саннарда.*

# ТАРИХ КАЛКА ГАСЫР ТҮРЕННӘН...

*Үткәннәргә ук атсаң,*
*киләчәгең синә туптан атып*
*җавап бирәчәк.*

Борынгылар сүзе

Музей ишекләрен кагарга керешкәнче, иң элек аларның туу-оешу тарихына кыскача гына тукталып китү кирәктер.

Музей—грек сүзеннән: (museion) алынган, ягъни музалар йорты дигәнне аңлата. Безнең эрага кадәр үк инде Борынгы Грециядә һәм Римда, бигрәк тә эллинизм эпохасында, музейлар барлыкка килә. Сәнгать һәм фән казанышларын системалы рәвештә туплау исә Яңарыш чорында—Италиядә, аннары Франция, Англия, Германия h. б. Көнбатыш илләрендә киң чагылыш таба. Гадәттә, бу коллекцияләр корольләр, эре феодаллар, бай купецлар, руханилар кулында булган. Әлеге музей йортларына ул чакта тар даирә кешеләре генә керә алган, билгеле.



*Милли музей бинасы*

Лондонда Британия музее, Парижда Лувр музее ачылу (XVIII гасыр)—мәдәният-тәрәккыят үсешендә яңа бер этап. Француз архитектурасының күренекле һәйкәле Лувр, король сарае буларак, 1546 елда ук салына. 1793 елны, Конвент декреты нигезендә, аны милли нәфис сәнгать музее итеп үзгәртәләр, киң катламга да керү мөмкинлекләре ачыла. Луврда дөньяның атаклы сәнгать үрнәкләре, әйтик, Леонардо да Винчиның «Мона Лиза Джоконда»сы да саклана.

Россиядә дә XVIII гасырда барлыкка килеп, Петр I 1719 елда кунсткамера оештыра. Атаклы Эрмитажны, Мәскәүдәге Кораллар палатасын, Третьяков галереясен, А. С. Пушкин исемендәге рәсем сәнгате һәм Дәүләт Тарих музейларын кемнәр генә белми икән! Мисал өчен: бүгенге көндә Россия музейларында ел саен 70 млн. кеше була.

Сәнгать һәм мәдәният һәйкәлләрен, табигый-фәнни коллекцияләрне, техника казанышларын туплау, саклау һәм күргәзмәлек эшчәнлегенә карап, музейлар аерым төркемнәргә бүленә: рәсем сәнгате, әдәбият, музыка, сәнгать, этнография, туган як, тарих h. б.

Җыйнап кына әйткәндә, музейлар—милләтнең, кайсы да булса халыкның өлгереп житүен билгеле торган югары бер күрсәткеч.

Безнең тарихыбыз—зур, бай, данлыклы. Аның битләрендә бөек янарышлар да, кан һәм күз яшьләре белән юылган сәхифәләр дә житәрлек. Алтай далаларында сакланып калган таш балбалларның сүзсез карашы яисә мәгарә диварындагы сынык рәсемнәр безгә мәңгелек сагыш һәм вакытның үлемсезлеге турында сөйли. Әйе, безнең ерак бабаларыбыз—скифлар, һуннар, кыпчаклар, Идел буе болгарлары арасында искиткеч оста сынчылар һәм рәссамнар булган. Күлтәгин, Орхон-Енисей язмалары, дин һәм магиягә бәйле рун язуындагы сурәләр—галимнәрнең йокысын качырган серле табышмак, өтерге яки каурый каләм эзләреннән барсак, без борынгы акылга һаман саен ныграк якыная барабыз.

Борынгы Болгарның яралы ташларын тыңлый беләбезме? Андагы чиркәү нигезенә салынган, гарәп имласындагы каберташлар әле һаман да елый, сыкрана. Алар: «Без—вандализм корбаннары», дип рәнҗеп ята кебек. Ак һәм Кара палаталарның күз-тәрәзәләреннән безгә тарих үзе карап тора шикелле. Юк, үткәннәрне онытмыйк, хәтерле без. Менә тиздән Болгар тарихи-архитектура тыюлыгын яңарту, аның тарихи йөзен торгызу буенча төзелеш-реставрация эшләре башланачак. Свияжск (Зөя) каласы да яңадан төзекләндереләчәк. Бу эшләрнең дилбегәсен экс-президент М. Шәймиев үз кулына алды. Тик менә... Казан ханлыгын яулау өчен 1551 елны салынган бу кала-крепостьне яңарту—үз-үзебезне мыскыл итүгә кайтып калмасмы? Халык шуның өчен борчыла. Үлчәү тәлинкәләренә Мәскәү ярдәм йөзеннән акча сала башласа, Свияжск ягы басып китмәсме? Уйланырлык нәрсәләр бар...

Татарстан территориясендә беренче музейлар ачылу XIX гасырның башына туры килә. Казан университеты каршында төзелгән музейларны әйтеп китү белән чикләнәбез. Чөнки киләсе елдан башлап «Казан утлары» журналы Татарстан Республикасындагы төп музейлар һәм аларның тарихы, эчтәлеге, эшчәнлеге белән якыннан таныштырып барачак. Татарстаныбызда эшләп торган дәүләт музейлар саны 100дән артып китә. Ә инде республикабыз авылларында төзелгән туган якны өйрәнү музейларын да, мәктәп һәм вузлар музейларын һ. б. китереп өстәсәк, бу сан бик күпкә артачак.

«Казан утлары»—барыннан да элек әдәби-нәфис журнал. Шуна күрә Казандагы әдәби музейларны искә төшереп китү урынлы булыр, болар—Габдулла Тукай, Муса Җәлил, Шәриф Камал, Каюм Насыйри, Максим Горький, Евгений Боратынский музейлары.

Музейлар—олуг Тарихның ерак сәхифәләре.

Музейлар—олы Хакыйкатьнең кече кыйпылчыклары.

Дөрес, СССР дигән тоталитар җәмгыятьтә байтак нәрсәләр ялганга, сыйнфый көрәш кагыйдәсенә, акны кара дип күрсәтүгә,—ягъни фактларны бозып яисә үзгәртеп бирүгә дә корылган иде. Совет заманындагы әнә шушы идеология «җимеш»ләре музей залларына да үтеп керде, билгеле. Үзгәртеп кору җилләре исә башлагач кына алардан күпмедер арыну мөмкин булды. Ышанам ки, якын киләчәктә гаепсезгә хөкем ителгән, атылган яисә исән калган тоткыннар язмышын чагылдырган Реабилитация музее да төзелми калмас әле. Аннары... барып күргәнем юк-югын, әмма ләкин Төркиядә Солтаннар музее барлыгын укып белгәч, төрекләрнең үз тарихына зур хөрмәт белән карый белүенә сокландым. Тарихта Казан ханлыгы (дәүләте) белән унсигез ханның җитәкчелек итүе мәгълүм. Эзләнергә, материаллар тупларга һәм башкалабызда Ханнар музее оештырырга вакыт түгел микән безгә?..

Көнбатыш Европа үзендәге музейларның күплеге, байлыгы белән аерылып тора. Андагы халыкның менталитеты да бөтенләй башка шул: алар Азатлыкның татлы сүз икәнен дә, Ирекнең тәмен дә яхшы беләләр, үзләренең тарихлары белән хаклы рәвештә горурланалар.

Музейлар—бер дигән тәрбия мәктәбе.

Бирегә килгән яшь буынның күзләре ачыла, күңелләре сафлана, хыяллары канат

кагына. Чөнки алар тарих белән очрашалар, киләчәк хакына яшәгән һәм көрәшкән шәхесләрнең язмышы белән танышалар. Өлкәннәр исә үз биографиясенә, тормыш юлына кагылышлы сәхифәләр белән очраша. Яшьме-картмы, бирегә кергән һәркем музей белән ихлас сөйләшә, аралаша, үзенә кирәкле мәгълүмат ала, белемен һәм карашларын тирәнәйтә.

Шәһәрдәге тарихи урыннар һәм йортлар-биналар, архитектура үрнәкләре—болар бар да тере, соклангыч һәйкәл! Әнә, Казан Кремле, Сөембикә манарасы, Кол Шәриф мәчете...—болар макетише генә нәрсә түгел, үз зурлыгындагы натураль корылмалар, шәһәребезнең йөзек кашлары. Исеменә жисеме туры килсен дип, аларга горур янгырашлы исем дә кушылган—музей-заповедник! Бирегә төрле төбәкләрдән һәм чит илләрдән туристлар агыла. Экскурсоводлар. Алар инде хәзер коммунистик идеология кушканны үтәп, Казанны яулап алу прогрессив күренеш булды, бердәм совет халкы барлыкка килде һ. б. шунын кебек «әкият»ләрне сөйләмиләр, тарихи дөреслекне алга сөрәләр. Шөкер, бу җәһәттән заманалар яхшыга таба үзгәрде.

Кайда гына урнашкан булмасын, музейлар кешелек җәмгыятенең аерылгысыз бер өлешенә, тарихи һәм рухи тәрбия үзәгенә әверелде. Ә инде үз-үзебезне, цивилизацияне коткарып калу җәһәтеннән карасак—Әфганстанда яисә Чечняда сугыш-сугыш уйнап, туплардан атып, самолетлардан үлем бомбалары ташлап шәһәр һәм авылларны, йорт-җирләрне җимергәнче, музейлар төзү, мәгърифәт һәм белем учаклары кабызу, тарихны тергезү, йөз тапкыр, мең тапкыр кыйммәтрәк, кирәклерәк түгелме соң?!.

Музейларда—гадәттә, илаһи тынлык. Әйе, биредә күпвакыт диярлек тынлык хөкем сөрә. Әмма тоя-тынлый-анлый белгән кешегә яу кырындагы кылыч чыннары, туплар гөрелтесе, агач өйдә самавыр гөжләве, башаклар кыштырдаганы аермачык ишетелә биредә. Болар бар да—хакыйкать авазлары, тыныч тормышка чакырып торган өннәр.

Кеше музейларда Тарих һәм Хакыйкать белән бергә-бер кала...

**Редакциядән.**

*Иң беренче нәүбәттә укытучыларны һәм студентларны күздә тотып, «Казан утлары» журналы үзенең битләрендә «Безнең музейлар» дигән яңа рубрика ачып җибәрә. Игълан такталарына, диварларга, колач җитмәслек панноларга игътибар иткәнегез бардыр: безне төрле туристик агентлыклар ерак илләргә, мавыктыргыч сәфәргә, экскурсияләргә чакырып кына тора. Ә бит үзебезнең Казанда гына да тарихи урыннар, музейлар әллә ничә дистәләп санала. Әллә кая барасы юк, кем әйткәндәй, алар безнең аяк астыбызда.*

*Музейлар белән танышу, таныштыру еллар буе дәвам итәчәк. Сезне сәфәргә чакырабыз һәм хатлар көтеп калабыз, дуслар!*

# ГАСЫРЛАР БЕЛӘН КҮЗГӘ-КҮЗ...

*Ни генә юк: таш энәдән алып—*
*Чуен ядрә, тупка кадәрле!*
*Тарих өчен чуен гасыры да,*
*Таш гасыр да—изге, кадерле.*

## Татарстан Республикасы Милли музееның ВИЗИТ КАРТОЧКАСЫ

*Казан шәһәр фәнни-промышленность музее буларак, 1984 елда оеша. Рәсми төстә 1985 елның 5 апрелендә ачыла. Башкалабызның Кунак сарае (Гостиный двор) бинасына урнашкан.*

*Музей фондларында барлыгы 800 меңгә якын экспонат саклана. Алар тарихи һәм тематик яктан 22 коллекциягә тупланган. Күргәзмә заллар 2000 кв.метр чамасы мәйданны тәшкил итә.*

*Узган ел (2010) музейга һәм аның бүлекчәләренә барлыгы 25 меңгә якын кеше килгән.*

*Музейның адресы: 420111, Казан, Кремль урамы, 2.*

*Интернет-сәхифәсе: www.tatar.museun.ru*



**Гөлчәчәк Рәхимҗан кызы НӘҖИПОВА,**
**Музейның генераль директоры, тарих фәннәре докторы:**

*—Баш музейдагы хәзинәләрне сөйләп-санап-аңлатып бетерерлек кенә түгел, билгеле. Шулай да безнең иң зур байлыгыбызның берсе —кешеләр, ягъни музей-йортыбыздагы залларны, күргәзмә, экспонат һәм коллекцияләрне карарга килүчеләр. Бездә алар тарих белән күзгә-күз очраша, үзләренә бай мәгълүмат һәм өр-яңа тәэсирләр ала. Музейлар—кешелекнең хәтерен, белемен ныгытуга хезмәт итә, еракта калган гасырларны бүгенге көнгә китереп ялгый. Музей ишеген ачып керүчеләр—безнең көтеп алган һәм иң кадерле кунакларыбыз.*

***

Әле кайчан гына XX гасырда яшәгән идек.

Инде менә яңа–XXI гасырның да беренче унъеллыгын вакыт хәтеренә төйнәп куйдык. Ә Вакыт галиҗәнапләре, үзенең яңа тамгаларын калдырып, һаман алга таба чапмакта...

Тормыш дәрьясында уелып калган вакыт тамгаларын югалтмас һәм саклап калыр өчен ярый әле музей дигән тылсым сараен уйлап тапканнар! Музейга аяк баскан кеше бирeдә үткәннәр белән очраша, ерак бабаларыбызның яшәү рәвешен һәм энергетикасын тоя, тарихи хәтерен яңарта. Биредә кеше үзен гасырлар чатында басып торган кебек хис итә.

Татарстан Республикасының Милли музее. Өлкәнлеген, анда саклanган хәзинәләренең муллыгын, тарихи-мәдәни эшчәнлегенең колачын күздә тотып, аны хаклы рәвештә Баш музей дип тә йөртәләр.


Гадәттә, зур һәм мактаулы эшне һәрвакыт кемдер яисә кемнәрдер башлап йөри. Казанда музей төзү мәсьәләсен XIX гасыр азагында Казан университеты галимнәре күтәреп чыга. Ә нәрсәдән башларга? Бәхеткә күрә дип әйтикме, булачак музей көтмәгән-уйламаганда үзе өчен кирәкле олуг хәзинәгә тап була. Россия флотының вице-адмиралы И.Ф.Лихачев үзенең туганы–археолог, тарихчы, туган як белгече, коллекционер Андрей Федорович Лихачевның 40 меңлек коллекция-тупламасын бүләк итә. Болар Европа һәм Россия рәссамнары иҗат иткән 425 данә картина, тарих һәм сәнгатькә кагылышлы 1,5 мең китап, борынгы Болгар заманындагы

уникаль экспонатлар, корал, фарфор һәм башкалар. Саран, үзе өчен генә яшәүче бүгенге көннең кайбер байлары белән чагыштырганда, бу ике туганның меценатлыгы гайре табигый хәл, әкият шикеллерәк кабул ителә.

***

Үзенең эш көннәрендә музей ишекләре һәркайчан һәм һәркем өчен ачык. Шунысы куанычлы, нинди һөнәр иясе булуларына карамастан, кешеләр музей сукмакларын онытмыйлар. Күргәзмә яисә галерея залларында чал чәчле өлкәннәрне дә, мәктәп яшендәге балаларны да күрергә мөмкин. Тарих хәтере буыннан-буынга әнә шулай күчә. Музей–гасырларның телен, вакыт сандыкларын ача. Биредә кеше үзе өчен күп ачышлар ясый, гыйбрәт ала. Балалар һәм үсмерләр өчен дә биредә «Эврика!» мизгелләренә мәйдан житәрлек.

Менә «Татарстанның борынгы тарихы» дигән экспозиция. Ул 40 мең еллык дәверне, ягъни палеолит (таш гасыр) эпохасыннан алып тимер гасыр башланган вакытларга кадәрге чорны үз эченә ала. Шунысын да әйтик, музей хәзинәсендә хәтта безнең эрага кадәрге экспонатлар да бар... Болар бит барысы да–үзе бер могжиза лабаса!



*Патшабикә Екатерина II каретасы. XVIII г.*

Сугышлар яисә туфан афәтләре нәтижәсендә кешелекнең, аерым алганда, татар дигән кавемнең дә күпме авыл һәм шәһәрләре һәлак булган, жир астында мәңгелеккә күмелеп, йомылып калган...

Инде бу темага кереп киткәч, кораллар коллекциясе турында аерым сөйләү урынлы булыр. Музейда алар күп түгел, аз да түгел–барлыгы 900 берәмлек. Тере жан ияләрен (кешеләрне дә) кыру-үтерү өчен уйлап табылган салкын һәм утлы кораллар гел камилләшә барган. Менә туры почмаклы яисә ромб рәвешендәге ташбалталар, ук һәм сөнге очлыклары, кистән, таш ядрәләр... Шушы борынгылар янәшәсендә инде чагыштырмача «яшьрәк» күренгән шлём (очлым), тимер сөнге, Алтын Урда кылычлары, төрле калибрдагы мылтыклар, пистолетлар... Дуэль пистолетлары исә ату коралына караганда күбрәк сәнгать әсәрен хәтерләтәләр. (Аларны күргәч, ирексездән Пушкин, Лермонтов һ. б.ның дуэльдәге хәтәр мизгелләре күз алдына килеп баса). Ассириядә туган, соңрак Россиягә дә үтеп кергән тимер көбәләрдән исә сугышның салкын сулышы бөркелә кебек... Кеп-кечкенә кылыч йөзләрендә олы тарих күгәреге посып ятканын күргәч, бер мәлгә телсез калгандай буласың...

«Максимка» пулеметы, пушкалар, тып-тын яткан снаряд, гильза, каска рәтләре безне өлкәннәребез яшәгән гасырга таба якынайта. Их, боларны гына түгел, бүгенге танк һәм самолетларны, дөньядагы барлык-барлык дәһшәтле коралларны да кырлар-полигоннарда түгел, бары тик музей залларында гына күрәсе иде, дип сабыйларча хыялланып та куясың бу мизгелләрдә...

Шунысын да искәртик, Милли музей татар халкы тарихына һәм Татарстанга бәйле хәзинәләр белән генә чикләнми, аның йөзләгән «киштәләре»ндә борынгы цивилизация һәм Россия тарихына кагылышлы гажәеп хәзинә үрнәкләре дә саклана. Кыска гына язмада боларның барысы хакында да тулаем сөйләп чыгу кулдан килмәс. Аннары, күк йөзендәге йолдызларны санап чыгу мөмкин булмаган кебек, музей-сарайдагы барлык экспонатларны атап-тасвирлап чыгу да мөмкин хәл түгел. Ин яхшысы–боларны үз күзләрең белән «тере» килеш күздән кичерү, нәтижә ясау, әлбәттә.

Әйтик, археологик казылмалар хәзинәсендә генә дә 200 меңнән артык берәмлек

бар. Билгеле ки, боларның байтак өлеше Алтын Урда һәм Болгар заманнарына карый. Бу дәүләтләрнең Европа һәм Азия уртасында, Идел буйларына урнашкан булуын искә төшерсәк кенә дә күп нәрсәләр аңлашыла. Биредә һөнәрчелек һәм сәнгать үскән, мәдәният чәчәк аткан, алар күрше дәүләтләр, илләр белән ныклы рәвештә сәүдә иткәннәр. Археология димәктән, килер бер көн: кулларына көрәктән гайре корал тотуны белмәгән археолог галиҗәнапләренә һәйкәл салынмый калмас, мин моңа ышанам.

Тагын шунысы бар: татар халкының тарихын, мәдәниятен, тормыш-көнкүрешен ныклап торып һәм фәнни-системалы рәвештә өйрәнү 1920-30 елларда гына башлана. Әмма утызынчы елларда музей хезмәткәрләренең күбесе репрессия корбаны була яисә эштән азат ителә.



*«Татар алтын хәзинәханәсе» бүлмәсендә. XVII-XIX г.*

... Урак, сука, җеп эрләү станогы кебек эш кораллары, чүлмәк, сандык, төсле металлдан чүкеп ясалган эшләнмәләр, бизәнү әйберләре, этнографик материаллар–болар һәммәсе дә әби-бабаларыбызның элеккеге тормышы турында сөйли, халыктагы легенда һәм риваятьләрне искә төшерә.

Фарфорлар коллекциясе белән танышканда аларның Кытай, Япония, Германия, Франция, Англия, Австрия кебек илләрдә һәм шулай ук Россия заводларында эшләнгәнен беләбез.

Китаплар һәм язма чыганаклар хәзинәсе безне тагын бер өр-яңа дөньяга алып керә. Борынгы китап тышлыкларының («күлмәге»нең) агачтан, тиредән яисә тарттырылган тукымадан эшләнгән булуы күпләрнең игътибарын үзенә җәлеп итә. XVI гасырларда ук басылган Библия, Евангелие (Инҗил) китаплары... Хаттатлар кулы белән күчерелгән татар мәҗмугалары һәм кулъязмалар... Казан ханы Сәхибгәрәйнең (1523 ел) гарәп имласы белән татар телендә язылган ярлыгы... Академик Арбузов һәм беренче космонавт Юрий Гагарин култамгасын салган истәлекле китаплар...

Сирәк әйберләрдән–мамонтның теш казнасы, Әби патша каретасы, татар хатын-кызларыннан Сорбонна университетын тәмамлаган С.Шәкүлованың архивы һәм шәхси коллекциясе, М. Җәлилнең атаклы «Моабит дәфтәре» нөсхәсе һәм башкалар.

Ярый, хәзергә тукталып торыйк. Уйландыра: әгәр менә шушы тау чаклы хәзинәләрне киләчәк буыннар өчен саклап кала алмаган булсалар, без никадәрле байлыктан, матди һәм рухи мирастан мәхрүм калган булыр идек...

Форсаттан файдаланып, шәхсән үземә кагылышлы бер нәрсәне дә әйтеп китү урынлы булыр кебек. Беренче татар балеты «Шүрәле»не язган Фәрит Яруллин турында ЖЗЛ сериясеннән роман-хроника язарга керешкәч, композиторның әтисенә һәм хатынына карандаш белән (сугыш кырыннан!) язган хатларын һәм сирәк фотоларын мин нәкъ менә үзебезнең Милли музей фонды архивыннан табып алдым...

Музей эшчәнлегендә информатика, мәгълүмати һәм интернет-технологияләр куллану тәҗрибәсе арта, үсә, киңәя бара. Күп кенә галереяләрнең заманча җиһазланган, сыйфатлы эшләнгән сурәт-картиналар базасы гамәлдә, болар исә файдаланучылар өчен бер дигән чыганак. Республикабызның дистәдән артык кечерәк музейларын үзенең канат астына җыйган, Россиядәге коллегалары һәм ЮНЕСКО белән тыгыз бәйләнешләрдә яшәүче Милли музей хаклы рәвештә тәҗрибә-методика мәктәбе һәм фәнни-тикшеренү үзәге булып тора, заман белән бергә атлый.

**Рашат НИЗАМИЕВ,**

*Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе.*

*Һади Такташның тууына 110 ел*

# ТАКТАШ ИЛЕНӘ ИКЕ СӘЯХӘТ

## СЫРКЫДЫГА БЕРЕНЧЕ СӘЯХӘТ

*...Поезд ыргый, ә мин тәрәзәдән*
*Күрмәмме дип бер-бер танышны,*
*Һәрбер станциядән күзем алмый*
*Карап барам үтеп барышлый...*

Поезд кузгалып китү белән, Һади Такташның шул юллары искә килеп төшә дә, туган якны, бөек шагыйребезне сагыну хисләре белән бергә уралып, күңелне ниндидер бер хыял дөньясына алып керәләр. Шундый минутларда мин дә ничәмә тапкырлар, Такташча, «каен кызларын», «усак егетләрен», урман чәчәкләренең «керфек кагуларын» күзәтеп уздым, һәрбер станциядә анынча сагынып, танышларны эзләдем һәм һәр очракта шагыйрьнең туган як табигатен, кешеләргә мәхәббәтен тасвирлау көченә сокландым.

*Бер җирдә юк андый ак каеннар,*
*Бер җирдә юк андый урманнар,*
*Бер җирдә юк камыш сабаклары—*
*Андагыдай шаулый торганнар...*

Һәм менә, ниһаять, сөекле шагыйребезнең юбилее якынлашып килгән көннәрдә, мин аның «үз поездына» утырып, иҗатында аеруча җылылык тапкан туган авылы—Сыркыдыга бару бәхетенә ирештем. Максатым—ул кайткан юлдан, ул үткән урманнардан, ул үткән станцияләрдән барып, әдәбиятыбызга кабатланмас бунтарь йөрәкле олы шагыйрьне бүләк иткән Сыркыды авылы һәм аның кешеләре белән танышу. Шул уйлар белән Казан-Харьков поездына утырып, Рузаевка станциясенә кадәр барам һәм күчеп Рузаевка-Пичкиряево поездында Торбеево станциясенә юл тотам. Уйлавымча, шагыйрь дә нәкъ шушы юлдан йөргәндер, шул ук станцияләрне үткәндер, шуңа күрә ул тукталышларга Такташның танышларына кебек булган кызыксыну уяна. Поезд Пайгорм, Кадомкино, Инсар, Кавылкино станцияләрен, Мокша елгасын үтә. Тәрәзәдән матур урманнар күренеп кала. Югарыда әйтелгән шигъри юллар, әлбәттә, шушы урманнарны үткәндә язылгандыр. Чөнки туган авылга, туып-үскән йортка, сине зарыгып көтеп торган әти-әни янына

Азат ЗЫЯТДИНОВ (1939)—*галим, техник фәннәр докторы, ТФАның вице-президенты. Татарстанның фәнни техника өлкәсендәге Дәүләт премиясе лауреаты. Казанда яши.*

кайтканда гына күңел шулай илһамлана, табигатьне сөя, ашкына. Шагыйрьнең яшьлеген уйлап, шул юллардан дулкынланып, Торбеево станциясендә төшеп калам. Станция Такташ заманында да шундый ук булгандыр, бик борынгы бина, һәм ул үзгәрешсез калган. Күңелнең, түземсезләнеп, бөек шагыйребез турында ни дә булса беләсе килә: эзләнәм, карыйм, тыңлыйм. Милиционер янына киләм дә ана «Такташ урамы кайда дип», хәйләкәрлек белән сорау бирәм. Ул күрсәтә. Ниндидер шатлыклы хис туа: «Әһә, монда да аны беләләр икән». Тукта, мәйтәм, болай булгач, сәяхәт мәсьәләсен масштаблырак итеп төшендерим дип, Торбеево райкомына юнәләм.

## Беренче очрашулар

Пропаганда һәм агитация бүлеге мөдире Валентин Яковлевич Аникеев, яшь, энергияле генә егет, мине ачык чырай белән каршылады. Мин үземнең Татарстаннан килүемне һәм бу якларда туган бөек шагыйребезнең юбилеена әзерләнүебезне әйтүем булды, ул ниндидер бер горурлык хисе белән: «Әйе, шагыйрь Һади Такташ безнең якташ, аның туган авылы Сыркыды моннан 12 генә чакрым», дип сөйләп китте. Сыркыды авылында Һади Такташ исемендәге колхозның үзеге урнашуын, Мордовиядә 45 меңнән артык татарлар булуын һәм мордвалылар белән үзара бик тату яшәвен, райкомның икенче секретаре Коновалов Әхәт Абдулловичның да Сыркыдыда туып-үскән кеше икәнлеген шушы мордва егете ирештерде. Аның Советлар Союзы Герое мордва егете Девятаевның Торбеевода туып-үсүе, монда аның музее булуы, татар кызына өйләнеп, хәзер Казанда яшәве турында шатланып сөйләүләре (инде минем өчен билгеле мәгълүмат булса да), ике халык арасындагы дуслыкка бер матур мисал буларак, кызыклы яңгырады.

Бүлек мөдире мине өченче секретарь белән таныштыруны кирәк тапты. Валентина Николаевна Журавлева ниләр белән кызыксынуымны һәм, Такташның хәзерге татар совет поэзиясендә тоткан урыны турында сорашкач, аның рус, мордва теленә аз тәрҗемә ителүенә, китаплар табып булмавына үпкә белдерде, юбилее да татар шагыйрьләре, язучылары катнашында туган ягында да үткәрелсә, бик әйбәт булыр иде, диде.

Кунак йортына кереп, шагыйрьнең туган ягында беренче чәйне эчкәннән соң, Валентин Яковлевич мине машинага утыртып Сыркыды авылына алып китте.

Такташның шигырьләрен аңлап, аларга соклана башлаганнан бирле мине бик кызыксындырган бер сорау бар: нинди авыл ул Сыркыды?

Чөнки табигатькә, кешеләргә багышланган шундый гүзәл шигъри юлларын язу өчен шагыйрь яшьтән күңеленә каяндыр зур илһам көче, рухи энергия алырга тиеш иде. Ул көчне күзәтүчән, нечкә күңелле, талантлы балага, булачак олы шагыйрьгә гүзәл авыл табигате һәм җор күңелле авыл кешеләре генә бирә ала. Туган җирнең шәхесне тәрбияләүдәге роле һичбернигә алыштыргысыз бит ул.

## Сыркыды авылы

*Төнге җилләр уртасында*
*Сыркыды авылы тора!..*

Ул Саранск белән Мәскәүне тоташтырган әйбәт асфальт юл буена, тигезлеккә урнашкан. Мордовиядә күбесенчә көлсу туфрак булса да, бу авылның иркен кырлары кара туфраклы булуы күзгә ташлана. Без барганда декабрь уртасында да кар төшмәгән иде әле. Боргаланып аккан Парча суы, аның иркен болыннары, туралы сазлыклары һәм елга артындагы сөзәк таудагы урман авыл табигатен бик ямьле күрсәтәләр.

Сыркыды олы юлдан 500 метр читтәрәк, «Т» хәрефе формасында урнашкан. Аның уң очы «Яна авыл», сул очы «матау» һәм төп өлеше «урыс» очы дип атала. Авыл шул өч урамнан тора. Урамнар бик киң, йортлар иркен урнашкан. Сугышка кадәрге

чорларда 700дән артык йорт булып (5 мәхәлләле авыл), зур мәйданны биләгән. Хәзерге көндә Сыркыдыда 120ләп йорт бар. Алар күбесенчә 6 почмаклы, урамга яны белән урнашканнар. Түбә кыеклары, каралты-куралары һәм бәрәңге (алар аны жир алмасы диләр) бакчасының уртасына урнашкан җиләк-җимеш бакчалары мордвалыларныкына охшаган. Йорт саен диярлек сай буралы сиртмәле коелар.

Монда яшәве шулкадәр күнелледер сыман, ирексездән телдән Такташ сүзләре очып чыга: «Юкка гына йорттан кузгалдык...» Сирәкләнгән авыл йортларын карый-карый мин урамнан «урыс» очына, шагыйрьнең туган йортының нигезен карарга ашыгам. Менә кайда икән ул курорт булырлык урын! Урам уртасында күл башлана һәм шул күл тармакланып берничә йортны утрауда калдыра. Басма аша «утрау»га керәм. Авыл кырыеннан өченче йорт аларныкы булган. Искергәч, 1950 елларда аны сүткәннәр. Йорт урынын фотога төшерәм: инде ул тигезләнеп беткән. Каршында, күл буенда, бер карт тал сакланган. Бу—кайчандыр гөрләп торган, тормыш өчен көрәшкән, халкыбызның рухи дөньясына искиткеч шигъри ачышлар өстәгән шагыйрьне үстергән йорттан бердәнбер истәлек.



*Сыркыды авылында Һ. Такташ туган йорт нигезендә. Сулдан—Рәшит Коновалов, Такташларның элекке күршесе Сания Такташова һәм Азат Зыятдинов. Июнь 2010.*

Күнелдә әрнү туа. Әлбәттә, кемне дә булса берәүне гаепләп түгел, ә менә шундый олы шәхесләребезнең дә йорт-җирен, истәлекләрен яшь буынга «җиткерә алмавыбызга», үз-үзебезне хөрмәтли белмәвебезгә әрнү.

Күл буена урнашкан йортта туып-үсү... Менә кайдан икән ул Такташта үзенне табигать кочагында тою. Нечкә күнелле, бәләкәй Һади ничек инде «күлдә йөзеп йөргән бакалар»ны үз итмәсен дә, ничек инде күл буендагы чирәмдә кызынып ятучы «үрдәк малайларын сөя-сөя...» эшләрен онытмасын. Яки ничек инде көн-төн күлдә каңгылдашып йөргән казлар аның күнелендә «мәңгегә» калмасын. Алай гынамы, Парча суы үзенең борылышында шагыйрьнең туган нигезеннән күп булса 300 метрдан уза. «Уймакланып, ишелеп» аккан бу елга хәзер дә әле гүзәллеге белән үзенә җәлеп итә. Мул һәм тирән сулы Парчаның ярлары тәбәнәк булып, күп урында бөдрә таллар, камышлар белән капланган. Шагыйрь нигезенең хәзерге күршесе—мине озатып йөрүче 6 класс укучысы Искәндәр исемле малай Парчаның бик балыклы булуын сөйли, миңа аның дилбегә җитмәслек тирән урыннарын күрсәтә. Без аның белән басма аша елганың аръягына чыгып, шагыйрьнең әнисе Шәмсениса түти һәм җан дусты—Мокамае күмелгән зиратны карыйбыз, «изге» чишмәләреннән су эчәбез һәм таяклар белән «коралланып» (Искәндәр кабан дуңгызлары булуын әйтә), «яман куллар урлап кисмәгән» урманга юнәләбез.

Парча елгасының уң ягына урнашкан сөзәк кенә таудагы бу урман, аның уйсулыкта урнашкан тугайлары, күлләре, сазлыклары авыл табигатенә искиткеч бер матурлык өстәп торалар. Әлбәттә, бәләкәй Һади яшьлегендә шушы урманнарда хыялланып йөргән һәм югарыдагы юллар аларны сагыну хисеннән туганнар. Искәндәр миңа колхозның урман буена урнашкан умарталыгын һәм сугышка кадәр утыртылып, соңгы елларда гына өшеп беткән бик зур алма бакчасын күрсәтә. Без тип-тигез иркен болыннар, сазлыклар аша кире авылга юнәләбез. Әйе, мондый табигатьтә үскән бала, җирнең матурлыгын аңлап, «шагыйрь» күнелле була ала...

## Сыркыды кешеләре

*Дус агайлар минем җырларымда*
*Мәңге шәүлә булып йөрерләр...*

Бәхетемә, әле Такташны белгән, аның белән уйнап үскән кешеләр дә исән икән. Шуларның берсе—шагыйрьнең күл аша күршесе, зәп-зәңгәр күзләре белән аны хәтерләткәне—Яхин Низаметдин. 1908 елда туган, авылдашлары Низам дип йөрткән, күп каз асрап, зәңгәр йортта яшәүче бу бабай әле күп нәрсә хәтерли: «Алар 6 бала—3 кыз, 3 ир бала үстеләр, барысы да укыдылар. Олы абыйлары Хафиз агроном булып эшләде. Кече энеләре Абидулла, Пешлә мәдрәсәсен бетергәч, Һади янына Казанга китте. Хәзер кече сенелләре Мәрзия генә исән, ул Мәскәүдә яши. Һади безне мәктәптә укытты, балаларны бик ярата иде, бик яхшы укытты. Ул безне әдәпле, яхшы сүзе белән тәрбияли, олылар белән исәнләшеп йөрергә куша, шигырьләр укырга ярата иде. Минем энем Шакирны балыкка алып йөри иде. Шакирга балык тотарга кушып, үзе китап укып утыра торган булган. Әнисе Шәмсениса үлгәч, балалары кайтып әтиләре белән кече сенелләре Мәрзияне Казанга алып китәләр, йортта әниләренең сенлесе торып кала».

Низам бабайның хатыны Мәхфүзә әби дә Һадины «матау очы»нда туйда күргән һәм туганнан туган сенлесенең киявен каршылаганда җырлаган җырын әйтеп күрсәтте:

*Сәгать келт-келт итәдер,*
*Төн уртасы җитәдер.*
*Йокласа да курка мескен,*
*Усал ирен көтәдер.*

1902 елда туган Йосыф Надыршинның «Без Һадилар, Мокамайлар белән бергә уйнап үстек, дип сүз башлавы күңелне бигрәк тә нечкәртеп җибәрде. Алар малай чакларда дус булалар, бер-берләренә якын торалар: шуна уртак истәлекләре дә күп. Ул Һадины матур, чибәр, таза, зиһенле малай итеп тасвирлый. Шул сүзләргә дәлил итеп аның әйбәт укуын, сүзгә тапкыр булуын, малайларны җыеп шигырьләр, хикәяләр сөйләргә яратуын, урманда ат саклаганда мукшы малайлары белән көрәшкә керүен сөйли. Революциядән соң кайткач та, яшьләрне җыеп, алар алдында чыгышлар ясаган. Йосыф бабай Хәйрулла абыйны, Шәмсениса апаны зур хөрмәт белән искә ала, аларның уңган, яхшы күнелле кешеләр булуы, хуҗалыкларын әйбәт алып баруы, әйбәт балалар үстерүләре турында сөйли. Мокамай турында да ул «Бик ярлы кешенең баласы иде шул, мескенне харап иттеләр», дип әйтеп куйды.

Такташова Маһирә әби дә шагыйрь һәм аның туганнары, әти-әнисе турында күп истәлекләр сөйләде. Хуҗалыкчан Хәйрулла абзый сугымчылык белән шөгыльләнә, кешеләр белән әйбәт мөгамәләдә яши. Шагыйрь үлгәндә Шәмсениса апа параличтан урын өстендә ятып кала, улын күмәргә Хәйрулла абзый Казанга үзе генә бара. Ул чагында Маһирә әби дә Казанда абыйларында була һәм ул да Такташ белән саубуллашырга бара. Аны күмүдә катнаша. Күмүдә бик күп халык җыела.

1912 елгы Фатыйма апа Коновалова—Такташның авылдагы ерак туганы. Аның әтисе Ибраһим белән Хәйрулла абзый туган булганнар. Ул әле шагыйрьнең хатыны, улы Рафаил белән Сыркыдыга кайтып йөргән заманнарны хәтерли, туганнарын әйбәт белә.

Авылның зур булуы һәм Такташның бик яшьли чыгып китүе сәбәпле, Сыркыдының кайбер бик олы кешеләре дә инде аны хәтерләмиләр. Минем фатир хуҗасы, искиткеч сабыр холыклы, 1901 елгы Заһирә апа да ниндидер бер сагышлы мөлаемлык белән: «Алдашмыйм, маем, бер дә хәтерләмим мин аны», диде.

Заһирә әби дә, авылның башка олы кешеләре дә Сыркыдыныҥ шушылай таркалуының сәбәбен сугыш чорларыннан күрәләр. Бөек Ватан сугышына Сыркыды авылыннан 350дән артык ир-егет чыгып китә һәм илебез азатлыгы өчен 111 кеше һәлак була. Үлгән Такташовлар гына да 17 кеше.

Сыркыдылылар генерал Надыршин Хәлил Садретдинович, полковник Нәҗип Такташов, техник фәннәр кандидаты Норкин Ибраһим, данлыклы нефтьче, дәүләт премиясе лауреаты Мостафин кебек авылдашларын зур горурлык белән искә алалар.

## Һади Такташ исемендәге колхоз

*... Авылыбызны Ленин юлы белән*
*Чыгарырбыз тормыш төбеннән...*

Сыркыдыда колхоз 30 нчы елда оеша. Заманына һәм бигрәк тә зур авыл шартларына хас булганча, колхозлашу чорлары бик күп гаугалар белән үткән. Шушы ызгышлар очкыныннан чыккан 1931 елгы янгын авылның 500ләп йортын көл итә. Бу фаҗига әле дә авыл кешеләренең хәтерендә ачык саклана. Колхоз рәисе 30 яшьләрдәге ыспай егет Равил Базаев мине колхозның төп белгечләре: баш агроном Мостаев Нәҗип, баш механик Иртуганов Искәндәр, партком секретаре Әюпов Җиһанша белән таныштырды. Алар бары да яшьләр, бары да шушы авылныкы. Колхозга 1974 елда Һади Такташ исеме бирелгән. Хуҗалыкның 5350 гектар җире булып, шуның 4060 гектарын чәчү җирләре тәшкил итә. 1500 баш мөгезле эре терлеге, 3670 сарыгы, 66 аты, 40 тракторы, 24 автомашинасы, 12 комбайны бар. Сыркыдылылар үткән ел дәүләткә 17600 центнер ашлык, 14070 центнер сөт, 2300 центнер ит тапшырганнар. Авылда калучы яшьләргә йортлар салып бирәләр һәм башка төрле кызыксындыру чаралары күрәләр.

Авыл Советы рәисе Җиһанша Такташов колхозда 440 кеше эшләп, шуның 51е коммунист булуын һәм тугызынчы бишьеллык нәтиҗәләре буенча Сыркыды авылыннан өч кешенең Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнүен әйтте.

## Сыркыды мәктәбе

Сыркыды балалары башта мәдрәсә биналарында укыганнар. Шуларның берсендә (ул бина хәзер юк инде) Һади Такташ та 2 ел укытучы булып эшләгән. 1930 елда ук инде авыл кешеләре җыелып, мәктәп өчен махсус бина төзегәннәр һәм авыл кырыенда салынган шул матур йортта 1933 елда тулы булмаган урта мәктәп ачып җибәргәннәр. Мәктәпнең стенасына Һади Такташка багышланган мемориаль такта куелган. Ишекне кергәч тә, залда шагыйрьнең зур портреты һәм аңа багышланган стенд. Инде күп еллар Сыркыды сигезьеллык мәктәбенең директоры булып сугыш ветераны Хәлил Хәсәнович Янакаев эшли. Укытучылар яшьләр, тату коллектив. Алар белән очрашу шигырьләр, җырлар белән барды һәм күңелдә матур истәлекләр калдырды.

*Сау булыгыз инде,*
*Сау булыгыз...*

Саубуллашу күңелдә һәрчак авыр хисләр уята. Такташ та «Мин җир йөзен артык сөйдем бугай», дип шундый минутларда уфтанып куйгандыр. Мина да бу авылдан китү авыр булды. Шул кыска гына вакыт эчендә мин аның мөлаем йөзле кешеләре белән якынлашып өлгердем. Заһирә әби белән бик дуслаштык. Ә инде саубуллашканда 80 яшьлек карчык күзләрендә яшь бөртекләре күргәч, күңел тулды.

Лəкин рəхмəт хислəре барыннан да өстенрəк иде. Рəхмəт сина, Сыркыды, «бунтарь» улың өчен! Синең кебек авыллар: Кырлайлар, Мостафалар, Күлле Кимелəр, Кармəтлəр яшəгəндə халкымның иҗат чишмəлəре дə мөлдерəп агуларын дəвам итəрлəр!

*Сезгə, Такташка гашыйк*—**Азат ЗЫЯТДИНОВ,**
*«Нефтехим» производство берлəшмəсенең өлкəн инженеры, техник фəннəр кандидаты.*
*1980-1981.*

## СЫРКЫДЫГА ИКЕНЧЕ СƏЯХƏТ

Такташ дустым, синең «Мокамаең» искиткеч əсəр! Ул эчтəлеге белəн романга, моң куəте, янгырашы белəн симфониягə тиң поэма. Анда балачакның сихри моңнары, дуслыкка, табигатькə мəдхия, тормыш трагедиясе ... Син башка бер əсəр язмасаң да, валлаhи, «Мокамай» белəн шагыйрь булып танылыр идең. Аның башлануы ук матур бер җыр кебек. Моңлы. Күңелне иркəли:

*Белмим,*
*Əллə күпкə,*
*Əллə бик озакка,*
*Ахры мəңге оныта алмамын*
*Тамбов урманнары уртасында*
*Усак яфраклары шаулавын...*

Бала чактан күңелне «əсир иткəн», инде кадерле ядкарьгə əверелгəн шигъри юллар! Мокамайны үз итмəгəн бер генə авыл малае да юктыр. Əдəбият укытучысы аны «Мокамай» поэмасы белəн таныштырсын гына, ул инде бөтенлəе белəн аның тəэсирендə. Мин үзем дə гомерем буе аны сөйлим һəм бераз көнлəшəм дə. Ни өчен безнең урманнардагы усаклар лепердəп кенə утыра, шауларлык көчлəре юк микəнни? Такташныкы шаулый бит! Безнең як имəннəре үз баласын озатып та куя белми микəнни? Такташныкы озата бит. Ничек инде безнең капка төбендəге каеннар иң агы түгел дə, безнең як урманнары иң шəбе түгел? Югыйсə, каеннарыбыз җете ак иде, бигрəк тə уртадагы кушкаен. Ə безнең яктагы «ике катлы» һəм Абышка елгасы буендагы урманнар... Такташныкыннан ким микəнни? Без аларны чын кара урманнар рəтенə кертə идек бит. Чөнки нəкъ шул урманнар Кырлайдагы Шүрəле урманына барып тоташа. Ə безнең Шушманың кызыл ярга борылып киткəн урынында нинди шəп камышлык! Минем абыйлар алабуга һəм алтын балыкларны сөкəгə шунда гына элəктерəлəр иде. Шубан ягыннан җил искəндə, алар да гаҗəеп серле итеп шаулыйлар иде бит...

«Мокамай»ны укыган баланы шушы уйлар бимазалый һəм бу бик тə табигый—аның Сыркыдыны, аның бер җирдə булмаган урманын, ак каеннарын, камыш сабакларын күрəсе килə. Мин дə шулай. Озак еллар күңелемə тынгылык бирмəгəн ул. Телəк үземне 1980 елның декабрендə Сыркыдыга—Мокамай иленə алып китте. Бу минем беренче баруым иде һəм мин аны нəкъ син кайтканча—поездда «Казан-Рузаевка-Торбеево» маршруты белəн бардым. Шул сəяхəтнең нəтиҗəсе буларак, «авылыбыздан тагын үтəрмен» дигəн синең сүзлəрне исем итеп алып, күлəмле генə мəкалə яздым. Сыркыды хəллəрен якташларыма, шəһəрдəшлəремə җиткердем. Режиссер Наил Нуретдинов, сценарист Рахмай Хисматуллин, синең шигъриятькə булган олуг ихтирамнарын биреп, Түбəн Камада бик көчле юбилей кичəсе үткəрделəр һəм шул кичəдə тамашачыларга əлеге мəкалə дə таратылган иде...

Гомер уза. Күп санлы өмет-хыяллары, тетрəндергеч фаҗигалары белəн XX гасырны йомгаклыйбыз, синең зур юбилеең инде яңа гасырда узачак. Сыркыдыга беренче сəяхəттəн соң сизелми дə тагы 20 ел узып киткəн. Əмма еллар агышы синең туган авылны кабат бер барып күрү телəген һич кенə дə баса алмады. Юбилееӊ

алдыннан мин, һичшиксез, синең балачак эзләреңнән үтәргә тиеш. Бу минем күңелдә туган катгый карар. Кайчан барырга? Сыркыды табигатенең матурлыгын күрү өчен бу бик мөһим шарт. Монда инде сине хөрмәтләүче заманыбызның танылган шагыйре, халкыбызга багышланган бик җылы шигъри юллар авторы Нәҗар ага Нәҗминең «Кунакка чакыру» шигыре искә төшә:

*Кайчан килсәм сиңа ошар икән,*
*Туган җирем, туган якларым?*

Без августны сайладык. Улым Нәриман каникулга кайткач, юлга җыендык. Видеокамера, фотоаппаратлар белән кораллandык һәм, ниһаять, 17 август көнне үзебезнең машинада иртәнге 7 сәгать 15 минутта юлга кузгалдык. Сәяхәткә чакырып дусларга әйтеп карасам да, иярүче булмады. Кызганыч. Берише сырхау, икенчеләре—дөнья куа. Шулай инде бәндә дигәнең, җәйнең гүзәл бер мәлендә шундый сәяхәткә чыгарга да үзендә көч тапмый, вак ыгы-зыгы корбаны булып кала. Күрәсең, әле ана яшәү ямен аңлау житенкерәми.


*Сыркыдыда шагыйрь музее һәм һәйкәл-бюсты.*

Әйе, сүз башым бит шүрәле, дигәндәй, без Аллага тапшырып, сәяхәткә кузгалдык. Янгыр ява. Ширәмәт, Яңа Чишмәләр аша Нурлатка життек. Монда район һәм шәһәр хакиме минем якташым, үзебезнең Шушма буендагы Апаз авылында үскән Фатыйх Сәүбән улы Сибагатуллин. Бунтарь егет, колачлы оештыручы. Хәзер районы турында күп сөйлиләр, күп язалар. Нәрсәләр майтарган икән, танышырга кирәк. Керәм хакимияткә, үзе юк. «Кайчан киләсе билгеле түгел, ул хуҗалыкларда, элемтәгә кереп булмый»,—диделәр. Яхшы, хуш, мин бит алдан кисәтеп килмәдем. Кем булуымны әйттем дә, шәһәр карарга киттек. Яңа матур биналар күзне иркәли. 50 нче елларда салынган рәвешсез ике катлы биналарга яшел, кызыл черепица калайдан өченче кат өстәп, үзенчәлекле генә матурлык бирәләр. Бу да чишелеш. Автовокзал салына. Ерактан, инде күп кенә район үзәкләрен бизәүче бинага әйләнгән, «Ак Барс» бинасы балкып тора. Жиренә житкереп салынган, зәвык белән бизәлгән балалар сәнгать мәктәбе. Жиһазлар заманча, чисталык, тәртип. Яшьләр үзәге, милиция бинасы, мәчет, чиркәү—бары да яңалар. Чиркәүнең ярымае өстенә утыртылган тәре?.. Спорт комплексы бик шәп. Зур теннис мәйданы, баскетбол, волейбол залы, яхшы бассейн, төрле спорт мәйданнары, заманча жиһазлар, сауна, душлар. Мөгаен, республикабызда иң шәп залларның берседер бу. Өч сәгать йөрдек. Нурлат зур куәт белән янара. Димәк, якташым булдыра, эшли.

Самара өлкәсе Кошкига юл алдык. Анда Мәләкәскә борыласы, аннан Ульяновск, Саранск, аннан инде Сыркыдыга да күп калмас. Нурлаттан соң янгыр туктады. Рульдә чиратлашып, иркенләп барабыз. Кәеф күтәренке. Сәяхәтнең тәмен тоеп, улым белән тормыш турында гәп сатып барабыз. Бәхетле мизгелләр... Такташ, син дә туган ягыңа кайтканда, матур уйлар кичергәнсен бит.

Тәрәзәдән дә күп нәрсә күренә. Бу якларда алабута, билчән кырлары, эшкәртелмәгән басулар күзгә ташлана. Юл буенда суган, алма сатып утыручы әби-бабайлар еш күренә. Авылларда яңа йортлар, ялтырап торган калай түбәләр юк дәрәҗәсендә, булса да сирәк. Дүрт кыеклы каралып беткән шифр түбәләр... Казан арты авылларында андый түбәләрне таба алмассың инде. Күрәсең, тормыш башка, матурлыкны тою башка. Матур янгырашлы Чардаклыны узабыз, Идел

аша салынган бик озын күперне узып, тауга күтәреләбез. Ульяновск. Аста Идел җәйрәп ята. Аннан Ленин мемориалына менү юллары шәйләнә. Инде кичке 6, юлга ашыгабыз. Саранскига кичке 10га гына барып җиттек һәм чыгып та киттек. Әле, бәлки, барып җитеп булыр?..

Әмма куе томан. Бер заправка тирәсенә туктарга мәҗбүр булдык. Түбән Камадан 690, Саранскидан 40 чакрым юл үтелгән. Юлдагыча гына юынып алдык та, кичке ашка керештек. Саниянең (хатыным) җыйган ризыклары муллан, ашыкмый гына ашадык, чәйләдек. Юл буенда, томанлы кара төндә без икәү—улым Нәриман да мин. Уйланырга менә дигән форсат. Тормыш нинди юлдан китәр? Минем өчен изге булган төшенчәләр балаларга—улым Нәриманга, кызым Гөлнарага, оныкларга күчәрме? Туган телебез, җыр-моңнарыбыз, милли үзенчәлекләребез нишләр? Радио, телевидениенең ят шаукымнарыннан саклап кала алырбызмы аларны? Татарстаныбызның мөстәкыйльлеге турындагы якты хыялларыбызның язмышы ничек булыр? Уйлар, уйлар, кара төндә якты уйларым. Иртән биштә үк уянам. Томан. Таң беленә. Без торып юынабыз, машинада гына тамак ялгап алабыз һәм, бисмиллабызны әйтеп, кабат юлга кузгалабыз—Сыркыдыга. Әле иртә, Такташ, нәкъ синдәгечә..

*Юл буенда яшь бер каен кызы*
*Тынып йоклый баскан көенә.*
*Исерек усак, җәеп канатларын,*
*Аны үбәр өчен иелә.*

Томан тарала башлый, юл буйлары җәтерәк күренә.

*Юл буенда йомылып йоклап яткан*
*Урман чәчәкләре, сискәнеп,*
*Уяналар...*

Без барып житәргә ашыгабыз. Атюрьево, менә Торбеево районы, Торбеево үзе. Көн дә ачылды. Юл аның кырыеннан уза, без карап чыгу өчен, махсус, керәбез. Гадәти район үзәге. Юлыбызны дәвам итәбез. Чиркәүле Никольск авылы. Аның тавыннан аста, талларга төренеп, боргалана-боргалана Парча елгасы ага, аның аръягында таралып утырган Сыркыды авылы күренә. Төп юлдан уңга борылып авылга кергәндә ике катлы кирпеч бина—Сыркыды авылы урта мәктәбе. Ишек алдына кереп туктыйбыз. Директор бүлмәсенә кереп, кем булуыбызны, килү максатыбызны аңлатабыз. Укытучылар җыела, танышабыз: Бәхтиева Антонина—мәктәп директоры, математик; Коновалова Равилә—рус теле укытучысы, элек килгәндә завуч иде, аннан соң 14 ел мәктәпне житәкли, яңа бинаны төзүне оештыра; Бадаева Румия—химик; Бикмаева Мария—тарихчы, мәктәп музее өчен җаваплы; Халюшова Татьяна—физкультура укыта, завуч; Иртуганова Нәсимә—биология, татар теле һәм әдәбияты дәресләре алып бара. Бу чибәр ханымнар барысының да ирләре татар булуын әйттеләр. Канәгать күренәләр татар киленнәре...

Укытучылар бүлмәсендә табын җыйдылар. Без дә күчтәнәчләр чыгарабыз. Чәй өстәле артында, Такташ, синең хакта, әдәбият, мәдәният хәлләре, тормыш турында әңгәмә корабыз. Татарстан яңалыкларын сорашалар, алар хәбәрдар, кызыксыналар. Юбилей алдыннан хәтерне яңарту, хәзерлек чаралары күрү максатыннан килүемне аңлатам. Укытучылар юбилей тантаналарының Саранскида һәм Сыркыдыда да үтүен телиләр. Саранскида Такташ урамы булдырып, анда аның бюстын кую һәм мәктәпкә Такташ исеме бирелергә тиешлеге турында без барыбыз да бер фикердә. Сыркыды мәктәбендә ул укытып та ала бит. Туган телебез балалар бакчасында өйрәтелми, беренче сыйныфтан ук укытылмый, Казан белән элемтә юк... Болары уфтану хисе уята.

Мария Николаевна белән икенче катка менәбез. Коридорда, Такташ, синең зур портретың эленгән. Матур эшләнгән. Куе чәчләрең, артка таралып, сыеша алмыйча кырыйга төшкәннәр; уйчан йөз, зәңгәр күзләр... музей бүлмәсен карыйбыз.

Мария ханым татарча да сүзләр кыстырып куя. «Татар егетен яраткач, телен дә бик тырышып өйрәндем, шулай кирәк саныйм»,—ди. Йөрәккә сары май булып ята торган сүзләр.

Бүлмәсе таррак булса да, музейга бик күркәм экспонатлар куелган: милли киемнәр, йорт җиһазлары, хуҗалык кирәк-яраклары, затлы итеп эшләнгән агач кроватька 100 елдан артык икән, чыбылдыклар, Такташка багышланган стенд. Синең китаплар, Рафаилең фотосы, хатлар һәм «үзе усал, үзе сөйкемле»—синең күңел кылларында төрлечә уйнаган Гөлчәһрә ханымның фотосы. Минем өчен «сюрприз»: шунда ук аерым рамкада минем 1980 елда басылган «Авылыбыздан кабат үтәрмен» дигән Сыркыдыга беренче сәяхәт турындагы мәкалә урын алган... Чигелгән итекләр һәм чабата!.. Җиледән үргән.

*Ник, Мокамай, соң син тормышыңны*
*Чабатаңдай матур үрмәдең?!..*

Без, ниһаять, шушы ике штансыз малай—Һади белән Мокамай илендә. Алар бергәләп дөнья белән танышып йөргән эзләрне карарга кирәк, ниләр сакланган?

Без Равилә ханымнарга барып урнашабыз һәм аның әнисе Рабия апа белән күрешәбез. Ул 1912 елгы. Такташ, сине күреп белә, сенелкәшенә килгән булгансың. «Шәһәрчә киенгән чибәр егет, бик матур сөйләшә иде»,—ди Рабия апа Айсина. Ул урамның каршы ягында үз йортында яши, дүрт бала үстергән, өчесе читтә. Равилә ханым белән авылның үзәгенә киләбез. Монда Такташ исемендәге колхоз идарәсе, кибет, яңа салынган күркәм мәчет. Аны салу турында рәис итеп сайланганда мордва егете Николай Иванович Нудиков вәгъдә иткән булган. «Ышанмаганнар иде, тәки сүзендә торды, башкарып чыкты»,—ди Равилә ханым. Аның уңганлыгын, тырышлыгын күрсәтеп, авылга газ кертелүен, урамга асфальт җәелүен, колхозның алдынгылар рәтендә баруын әйтә.

Сүз дә юк, шушы сүзләрдән соң без колхоз идарәсенә, бухгалтериягә сугылабыз. Баш бухгалтер Рустаева Мария Петровна чибәр мордва кызы—татар килене. Колхоз тормышының авырлыгы, техниканың, ягулыкның кыйммәт булуы, бөтен табыш—440 баш сыердан, бөртекләрне сатудан килгән керемнең кредит түләүгә китеп баруын әйтә. Уңай үзгәрешләргә өметебезне өзмик, дип, саубуллашабыз.

Мәчет янында бер йорт шәйләнә. Аны яшь өрәңге үсентеләре, кычыткан каплап бетерә язган. Бу, Такташ, синең шигырьләреңдә аерым урын алуга лаек булган авыл советы бинасы. Кайчандыр монда зур авылның тормышы кайнаган, төннәрен сакчы булып Шәхми карт торган:

*Шәхми бабай һәр төндә дә*
*Ялгыз утырып чабата үрер,*
*Төн үтәр...*

Кибеткә кереп чыктык та, Такташ дустым, синең урамга, син туган йортның нигезен, син үскән табигать мохите белән очрашырга юнәлдек. Урам асфальтсыз, август яңгырлары үз эшен эшләгән—пычрак. Йортлар күп түгел, буш урыннар байтак, кайбер йортлар хуҗалары кайткач, җәйгә генә ачыла икән. Ә сезнең оч гомумән буш калган. Ә теге сиңа мәгълүм зур янгын Сыркыды таралуга сәбәп булгандыр. Синең авылдашларың ул янгында 350дән артык йорт, 3 мәчет янганын әйтәләр. Күрәсең, кабат йорт сала алганы үз нигезенә сала, сала алмаганы китеп бара. Колхозлашу, сугыш, аннан соңгы авыр еллар гел авыл таркалуга этәргеч булып тордылар шул. Сыркыдының бер урамы 3 чакрымга, ә сезнең урам 1,5 чакрымга сузыла, шунда 80 тирәсе генә йорт (элек 700дән артык хуҗалык булган). Авыл таркау.

Әйе, без бит сезнең нигезгә барабыз. Юл уңды, безне озатырга синең әниең ягыннан кардәшең Такташев Заһит белән аның хатыны (сезнең күл аша булган нигездә үскән чая Сания, Морат кызы) чыкты. Сезнең тирәдә кемнәр, күлнең теге ягында кемнәр яшәгәнлеген алар белеп сөйлиләр. Анда барысы да сезнең туган-тумача булган икән. Бергә, матур яшәгәнсез. Алар әле дустың Мокамайның

яна авылда торганын һәм балыкка Яхин Низамның энесе Әхмәтне алып барып, кармакны аңа биреп, үзеңнең китап укып утырганыңны да «хәтерлиләр». Дмитриевка авылының элек сезнең очка орынып торуын, шуңа аны урыс очы ди йөртүләрен, соныннан Парча суының түбәнрәк агымына күчеп утыруларын, хәзер инде ул авылның бетеп баруын сөйләделәр. Ә синең күл әле дә күл, һәм аның хуҗалары да—казлар, син яраткан жан ияләре. Алар күп һәм бик иркен яшиләр: үзләре суда, янда бодай кыры.

Без сезнең нигездә. Буш, кычыткан баскан нигез. Йөрәк кысыла. Монда кайчандыр тормыш кайнаган, шау-гөр килеп сезнең балачак еллары үткән, киләчәк турында хыялланган сездыр. Шул күренешләр сиңа гомер буе иҗат итәрлек илһам биргәннәр. Мен рәхмәт бу нигезгә. Дога кылып, авыр хисләр белән китеп барабыз. Киләчәк язмышың ничек булыр?

Парчага таба юл тотабыз. Берни булмагандай бөтерелеп ага таллар арасыннан. Шарлавыклары да бар. Синең теләкләр искә төшә:

*«Парча» суларың да куермыйча,*
*Уймакланып ишелеп аксыннар.*

Бөтен күренешләрне видеотасмага, фотога төшереп алабыз. Һәм елга аръягына, зират, урман, тау ягына юнәләбез. Максатыбыз—«ике ыштансыз малайның дөнья белән танышып йөргән» урыннарын күрү. Син дә бит, Такташ:

*«Зурлар кебек, кулны артка куеп,*
*Йөри идек таптап болынны»,*

—дисең һәм уфтанып:

*«Әкияттәге ике бала кебек,*
*Күпме «җәфа» чигеп яшәдек»,*

—дип өстисең.

Без дә күрдек күрмәгәнне бу болынны үткәндә! Чабып ташланган печән, яңгыр астында калып, җыелмыйча күгәреп ята, житмәсә, болын камыллы. Ә өстә кара болыт булып сукыр черки бөтерелә, авызны да ачып булмый. Ни итсәк иттек, зират, урман буйларын үтеп, тау кырыйларын буйлап, Парчада су коенып, кире авылга кайту юлына чыктык. Имеш, турыдан, бодай басуы аша гына кайтабыз! Күрдек күрешне. Сезнең «җәфа» чигү болай ук булмагандыр, билләһи.

Әмма иң куанычлысы—без Сыркыдының бай табигатен, иркен кырларын күрдек, аның зур үзәнлектә бик иркенләп утырганын аңладык. Син:

*«Шулай инде,*
*Тормыш башка эздән ага...*
*Теге, ничек әле?*
*Хисамилар яши дөньяда?»*

—дип сорыйсың. Без дә шул сорауга җавап алу өчен Заһит Такташевлар йортына ашыгабыз. Чакырып та калганнар иде. Алар икесе дә ачык чырайлы, зәп-зәңгәр күзле, яхшы күңелле кешеләр. Табын әзер: «авыл әле һаман катык ашый», йорт икмәге, алма пирогы, яна суыртылган бал, йомырка, каймак... Сания апа, елмаеп һәм күзен кыса төшеп, кунаклар хөрмәтенә әче буза тәкъдим итә. «Үзебезнеке, гөнаһсыз», дип өсти. Сыйланабыз, әңгәмә куертабыз. Аларда ашны шти диләр, Хөсәен—Ксюк, Ибраһим—Ибрюк, Лотфулла—Ләтүк. Заһитның бабасы Такташев Ксюк комиссар була, Такташны җирләүдә катнаша.

Заһит абый умартачы булып эшләгән, Сания апа—сыер савучы. Ике бала үстердек, диләр. Уллары Рушан, киленнәре Гөлнара (чыгышы белән Сыркыды токымы. Пекарня аның бабасыныкы). Кызлары Рәйсә, кияүләре Исмай—Сергач мишәре.

Оныклары бишәү. Барысы да Мәскәүдә яшиләр, җәй кайтып булышалар. Заһит абыйларның хуҗалык зур: ике ат, бер тай, сыер, тана бозау, сигез баш сарык малы, казлар 4 оя—30 баш, куяннары сигез баш, «тавыклар—без счет», дип көлә Сания апа, аннан «60 тирәседер», дип өстәп куя. «Пенсиям хәзер 960 сум»,—ди һәм башта 22 сыерны кул белән, аннан машина белән савып мастер исемен алуын, депутат булып сайлануын, почетта гомер итүен, җырлап та йөргәнен сөйләп китә. Хәтере бик әйбәт. Авылның, колхозның үткәнен әйбәт хәтерли. Гаҗәеп тә матур сөйләшеп утыру булды бу. Табынга дога кылып, бу зәңгәр күзле кунакчыл хуҗаларга зур рәхмәтләр әйтеп, саубуллашабыз. Төп хуҗаларыбызга—Равилә белән Рәшит Коноваловларга кайтып житәбез. Инде соң. Тагын табын, иркенләп сөйләшеп утырып, хуҗаларның пөхтә итеп җыештырылган йортларында йокларга ятабыз. «Хисамилар» менә шулай яши икән.



*Сыркыдыда яңа мәчет. 2010.*

19 август, 2000 ел. Бүген көн матур, кояшлы. Без иртүк торып, хуҗабыз Рәшит белән синең соңгы өметеңне:

*...Тамбов урманнары сагынып әле*
*Үзе үстергән бунтарь баласын*

—Тамбов урманнарын карарга барабыз. Алар турыга барсаң 10 чакрым тирәседер, ләкин юл юк. Без әйләнеп асфальт юлдан киттек. 20 чакрым тирәсе юл узылды. Менә, ниһаять, без син дан җырлаган урманда, Такташ! Каеннарын, усакларын, карт имәннәрең янында. Алар чыннан да сине сагыналар бугай, бик «кызыксынып» шаулаша башлагандай тоелдылар. Тик бу урман син язган матур исем белән аталмый икән инде хәзер. Ә үзенең Потьма станциясенә якын урнашкан күпсанлы төрмә-лагерьлары белән яманаты чыккан Мордовия урманнары дип йөртелә. Шуңа без дә синең агачларга фотоаппараттан, видеокамерадан тиешле сәламнәребезне бирдек тә, тизрәк китү ягын карадык.

Үзидарә рәисе Аюков Жиһан белән очрашабыз. Авыл кешеләрендә 160лап эре мөгезле терлек, 60лап ат булуын, колхозның 3500 гектар сөрү җирләре, шуның 1800 гектарын бөртекләләр белән кукуруз биләвен, 6 комбайны булуын әйтә.

Элеккеге мәктәп директоры Хәлил абый Янакаев белән күрешәбез. Авырып урында ятса да, хәтере бик әйбәт, беренче очрашуны сагына. Такташ, синең шигырьләрне укый. Газап күрмә, Хәлил абый!

Кичке 5тә без кайту юлына чыгабыз. Равилә апа озатып кала. Китү авыр. Тау башына менгәч, тагын бер туктап, Сыркыды белән саубуллашабыз. Хуш, бәхетле бул, халкыбызга бөек шагыйрь биргән авыл!

**Азат ЗЫЯТДИНОВ,**
*техник фәннәр докторы.*
*Түбән Кама, 2000-2001.*

ҺАДИ ТАКТАШ ЯДКАРЕ



*Һади Такташның әнисе Шәмсениса. Узган гасырның 20нче еллары.*



*Шагыйрьнең әтисе Хәйрулла. Узган гасырның 20нче еллары.*



*Сыркыды авылы күренеше. 50нче еллар.*



*Замандашлар. Сулдан уңга— Мәҗит Гафури, Һади Такташ, Галиәсгар Камал. 1929 ел.*



*Татар язучылары һәм сәнгать әһелләреннән бер төркем. Беренче рәттә уңнан икенчесе Һади Такташ. 1928 ел.*



*Дуслар (сулдан уңга): Габдрахман Минский, Һади Такташ, Гадел Кутуй. 1928 ел.*



*Һади Такташ бюсты. Скульптор Васил Маликов эше.*



*Һади Такташ каберендәге таш билге. Казанның М. Горький исемендәге Ял паркы янындагы туганнар каберлеге.*

## Мансур Гыйләҗевка 50 яшь



Әдәби гаиләдә туып, милли тәрбия алып үссә дә Мансур Аяз улы Гыйләҗев үзенең тормыш юлын үзгәрәк һөнәр алуга ният итеп—Казан төзүче-инженерлар институтының архитектура факультетына укырга керә. Әлеге уку йортын тәмамлаганнан соң ул Мәскәү проектлар төзү фәнни-тикшеренү институтына эшкә китә. Күнелендә иҗат дәрте уянып, Мәскәүдә яшәгән елларында (1983-1986) «Кәгазьдәге шау-шу», «Бәби арбасы» h.б беренче пьесаларын иҗат итә. «Рәхәт яшибез» исемле сатирик драмасы исә 1986 елда Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры сәхнәсендә куела, 1986 елда талантлы яшь режиссер Дамир Сиражиев белән берлектә Чыңгыз Айтматовның «Плаха» романы буенча сәхнәләштерелгән драмасы да тамашачы күнелендә урын ала. 1990 елда ул драматург буларак Татарстан Язучылар берлегенә кабул ителә.

1961 елның 29 гыйнварында Казан шәһәрендә туган егет авыл тормышын да яхшы белүен, социаль проблемаларны тирәнтен аңлавын күрсәткән «Бичура» (1989), «Казан егетләре» (1991), « Тагын Казан егетләре» (1993) исемле пьесаларын иҗат итә. Республикабызның башка театрларында да—Әлмәт драма театрында «Сафиулла» (1996), «Туй күлмәге» (2006), Чаллы драма һәм комедия театрында «Дон Жуан Балчыклыда» (1997), Минзәлә театрында «Яратылыш» (2002), Уфаның «Нур» театрында «Бичура», «Өзелгән юллар» (2002) пьесалары куела.

2002 елда исә республикабызның төп театры булган Камал театры сәхнәсендә күренекле режиссер Марсель Сәлимҗанов аның «Баскетболист» исемле пьесасын сәхнәләштерә. Шулай ук М. Гыйләҗев тарафыннан 2004 елда Аяз Гыйләҗевнең «Яра» повесте буенча эшләнгән әсәрен дә тамашачы җылы кабул итә.

Татар кинематографиясен булдыру, анда төшерелгән фильмнарны дөньяга танытуга да ул беренчеләрдән булып керешә. Аның сценариесе буенча 2002 елда «Күктау» (режиссеры И. Ягъфәров) исемле фильм дөнья күрә.

Соңгы елларда киң танылу алган «Алтын мөнбәр» мөселман фильмнары конкурсында Аяз Гыйләҗевнең «Җомга көн кич белән» әсәре буенча эшләнгән «Бибинур» фильмының (М. Гыйләҗев сценариесе) Гран-прига лаек булуы (2010) татар сәнгате, мәдәнияте өчен дә горурлык булды.

М. Гыйләҗев 2002 елдан Россия Федерациясенең Театр әһелләре җәмгыяте әгъзасы, «Рамай» киностудиясенең баш мөхәррире һәм продюсеры.

## Фәрит Яхинга 50 яшь



Шагыйрь, язучы-прозаик, әдәбият галиме Фәрит Зәкиҗан улы Яхин 1961 елның 2 гыйнварында Татарстанның Сарман районы Дүсем авылында туа. Ләшәүтамак авылындагы урта мәктәпне тәмамлаганнан соң, Казанга килеп, 1978-1983 елларда Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетында белем ала, аннары, СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалына караган Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты каршындагы аспирантураны тәмамлап, 1988 елда «Фикер» газетасы һәм «Әлгасрелҗәдид» һәм «Уклар» журналларының татар әдәбияты үсешендәге роле» темасына татар әдәбияты тарихы һәм журналистика белгечлекләре буенча—кандидатлык, 2000 елда исә «Татар шигъриятендә дини мистика һәм мифология» дигән темага докторлык диссертацияләре яклый.


1993 елның башыннан 1999 елның августына кадәр Фәрит Яхин Казандагы Г. Тукай музееның директоры була. Монда эшләгән елларында музейны янарту, экспозицияләрен үзгәртеп кору, яңа экспонатлар белән баету, музейда даими рәвештә «Тукай укулары»н уздыру, сынлы сәнгать күргәзмәләре, төрле кичәләр, күренекле әдәбият-сәнгать әһелләре белән очрашулар оештыру кебек мәдәни эшләр башкара. 1999 елның августыннан Фәрит Зәкиҗан улы Татар дәүләт гуманитар институтының әдәбият белеме кафедрасы мөдире хезмәтендә була, аннары исә Татар дәүләт гуманитар-педагогика университетында эшли башлый.

Фәрит Яхин—өч шигъри җыентык («Гүргә кадәр сакланган сөю», «Таңга кайту», «Хис керфегемдә күз яшең») һәм балалар өчен «Могҗизалы ел фасыллары» дигән әкият-поэма (1994) авторы. Аның «Мөхәммәдьяр» исемле драматик поэмасы 1997 елда Татар дәүләт академия театры сәхнәсендә спектакль итеп куела. Ул проза жанрында да актив иҗат итә, укучыларга «Казан утлары»нда һәм көндәлек матбугатта басылган дистәләрчә хикәя вә повестьлары һәм ике кисәктән торган «Август ае» дигән романы белән билгеле. 1994 елда аны Татарстан Язучылар берлегенә әгъза итеп алалар. Соңгы елларда дөнья күргән Әхмәд Ясәви хикмәтләре, Сәйядинең «Дастаны Бабахан»ы, Аллаһиярнның «Сөбател-гаҗизин»е («Гаҗизләргә терәк»), Мәҗлисинең «Сәйфелмөлек» кыйссасы, «Бакырган китабы»—болар барысы да Фәрит Яхинның турыдан-туры катнашы белән әзерләнгәннәр.

***Каләмдәшләребезне юбилейлары белән тәбрик итәбез, аларга саулык-сәламәтлек, яңадан-яңа иҗат уңышлары телибез.***

# ШИГЪРИЯТКӘ БАГЫШЛАНГАН ГОМЕР

Каләмнәрен әдәбиятның төрле жанрларында чарлап, житди уңышларга ирешкән исемнәрне хәтерли сүз сәнгатебез. Башка юнәлешләрдә дә Ходай биргән сәләтен сынап карарга, үстерергә мөмкинлеге булып та, энә белән кое казыгандай, бөтен гомерен, бер жанрны ныклап, төбенә төшеп өйрәнүгә багышлаган шәхесләр дә була. Прозаик, шагыйрь, драматург булып үсеп китәргә



эчке җегәре сизелеп торса да, Нил Гафур улы үзен татар тәнкыйтенең, әдәби-нәзари белеменең татар поэзиясе белән бәйле тармагын сайлап, бар көчен, талантын шигъриятебезнең эчке серләрен,поэтикасын өйрәнүгә юнәлтте.

Әйе, Татар мәдәнияте мәгърифәтле Юзиевләр нәселенә рәхмәтле булырга тиеш. Нил абыйның энесе Илдар татар шигъриятенең С. Рәмиев, Такташ кебек бөекләребез юл салган романтик юнәлешен, куе психологизм белән бизәлгән өслүбен яңа баскычка күтәрде. Нил абыйның улы Айдар Юзиев исә татар иҗтимагый фикере үсеше һәм ислам фәлсәфәсе турында фәнни китаплар чыгарып, татар халкының бу юнәлештәге фикри бөеклеген ачты, фәннәр докторы, профессор булды. Илдар Юзеевның улы Салават—кинорежиссер, прозаик, драматург. Халкыбыз юкка гына «алма агачыннан ерак төшми» дип әйтми торгандыр. Бу юлы «сүзебез» Юзиевләр нәселенең өлкәне Нил Гафур улы турында.

Күренекле әдәбият галиме, тәнкыйтьче, Тукай бүләге лауреаты, филология фәннәре докторы, Татарстан фәннәр академиясенең әгъза мөхбире Нил Гафур улы Юзиев Башкортстанның Янавыл районы Ямады авылында укытучы гаиләсендә туа. Гомуми урта белемне туган авылында алганнан соң, татар әдәбиятына мәхәббәте булачак галимне Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә алып килә. 1953-1956 елларда аспирантурада укый. «Муса Җәлил поэмалары» исемле хезмәте өчен фәннәр кандидаты дәрәҗәсенә лаек була(1958). «Татар совет поэзиясенең поэтикасы» дигән гыйльми тикшеренүен докторлык диссертациясе итеп яклый(1974).

Илленче елларда вакытлы матбугатта басылган, агымдагы поэзиягә багышланган мәкаләләре белән Нил Юзиев теоретик яктан әзерлекле, белемле, татар телен яхшы тоемлаучы,катып калган традицияләрдән баш тартып, янача фикерләүгә омтылучы тәнкыйтьче буларак танылa. Татар әдәбиятының, бигрәк тә шигъриятенең кайсы чоры турында язса да, нинди генә проблеманы күтәрсә дә, аның өчен Тукай иҗаты нигез өлге, сыйфат биеклеге, сәнгатьчә камиллек һәм халыкчанлык үрнәге булып кала. «Сәнгатьчә матурлык һәм осталык» (1969), «Шигырь гармониясе» (1972), «Хәзерге татар поэтикасы» (1973), «Әдәбият хәзинәләре» (1978), «Шигърият дөньясы»

(1981), «Татар шигыре» (1991) һәм «Әдәбият чыганаклары белеме» (1998) кебек киң колачлы, тирән эчтәлекле гамәли-нәзари хезмәтләренең үзәгендә Тукай иҗаты, шәхесе тора. Н. Юзиев халык шагыйренең мирасына яңача караш ташлый, аның татар әдәбиятына, гомумән мәдәниятенә ясаган тәэсирен киң колач белән иңли. Бу хезмәтләрендә галим шагыйрь иҗатын барлауда, бәяләүдә элегрәк җибәрелгән хаталарны төзәтү юлларын да күрсәтә. Аерым алганда, ул Г. Ибраһимовның заманында шактый бәхәс уяткан «Татар шагыйрьләре» (1913) китабында Тукай иҗатына берьяклы бәя бирүгә алып килгән тамырларны ачыклый. Г. Ибраһимов поэзияне субъектив бәяләп, «лириканың хис, тойгыны гына сурәтләргә тиешлегеннән чыгып һәм шуңа җайлаштырып, поэзия тарихын үзенчә әйләндереп куя: хис-тойгылар ягы өстенлек иткән Сәгыйть Рәмиевне алгарак, Тукайны арткарак күчерә» («Хәзерге татар поэтикасы».) Тукай иҗатында тормышка аек, тәнкыйди караш өстенлек итә, дип раслый галим.Шуңа да «...тирән кичереш рәвешендә гәүдәләнгән акыл, фикер гаҗәп көчкә ия булган танып-белү коралына әйләнә».

Тукай поэзиясе тирәсендә барган бәхәсләрне Н.Юзиев хәзерге шигъриятнең үсеше белән бәйләп тикшерә. Сәгъде Вәккас имзасы белән шагыйрь С. Сүнчәләй «Шура» журналында Тукай рифмаларын ямьсез, отышсыз, уңышсыз дип бәяләп чыга. Бу шәхси, хата карашны галим кире кага һәм Тукай рифмаларының Такташ, Туфан, М. Җәлил, Ф. Кәрим, Ә. Фәйзи, С. Хәким иҗатларында яңача үстерелүен күрсәтә. «Тукай рифманы фикер, эчтәлек белән аерылгысыз рәвештә карый, рифманың яхшымы-начармы, ятышлымы-ятышсызмы икәнен әнә шул бәйләнештән чыгып бәяли» *(«Татар шигыре».)*

Н. Юзиев халык шагыйре иҗатына гомуми һәм югары бәя бирү белән генә чикләнми. Җөмләдән, ул Тукай поэзиясендә тарихилыкның көчәюе тирән психологизм, рухи дөньяның катлаулы һәм серле кыйтгаларына үтеп керү белән үрелеп баруын дәлилли. «Тукайның бөеклеге дә шунда: ул лирик талант буларак халыкның алдынгы өлешендә туа башлаган яңа кичерешләр дөньясын күреп алды, аларны үзенеке итте, үзләштерде һәм шундый яңа кичерешләргә үзенең шигъри ялкынын өстәп...халыкка кабат кайтарып бирде. «Хәзерге татар поэтикасы».) Н. Юзиев тарихи шәхесләрне сурәтләү үрнәге итеп Тукайның «Хөрмәтле Хөсәен ядкаре» әсәрен ала. Шагыйрь «тормыш пычрагын гәүһәр кебек вөҗдан белән» үткән бу шәхесне үткен акылы, шул ук вакытта гадилеге белән тарихи шәхес дәрәҗәсенә күтәрелгән зат итеп сурәтли.

Тукай иҗатының югары казанышы булган «Өмит», «Алдандым», «Соры кортларга», «Пушкинә», «Китмибез», «Сөальләр» кебек шигырьләрендә Н.Юзиев «рухи халәтнең катлаулы, каршылыклы күренешләрен» ачуны күрә. Хәзерге поэзиянең үсеш авырлыкларына тукталып, тәнкыйтьче анда шәхси башлангычның җитмәвен, шуның нәтиҗәсе буларак чынбарлыкны өстән-өстән генә сурәтләүне күрә. Татар шигърияте башкарак рухтагы юнәлешләрне дә иҗади үстергән икән. «Тукай,Гафури, Рәмиевләрдә шәхси тормыш язмышлары гаять зур урын били». Бу очракта галим тәэсири, хисси кабул итүдән бигрәк, фәнни, дәлилле хөкемгә өстенлек бирә, архив чыганакларына, шәхси истәлекләргә таяна, бөртекләп җыйналган табышлар нигезендә киң гомумтеоретик нәтиҗәләргә килә.

Галим шигъриятне аерым утрау итеп карамый, аны сурәтле фикерләүнең башка тармаклары,юнәлешләре белән тыгыз элемтәдә, үзара бәйләнештә, байлыклары белән уртаклашып яшәгән үзенчәлекле төре буларак тикшерә. Поэзияне кино, рәсем, театр һәм музыка сәнгатьләре белән чагыштырып өйрәнү аның яңа кыйтгаларына, әлегәчә күзгә чалынмаган сыйфатларына үтеп керергә мөмкинлек бирә.Театр сәнгатендә бу яңа төрләрнең калыплануына, үсешенә дә Тукай иҗаты нигез-таяныч булган икән. «Татар профессиональ музыкасы,—дип яза Н. Юзиев,—Тукай поэзиясенә, халык күңелендә ул ачкан байлыкка һәм шул байлыкны сурәтләү алымнарына таянды». «Тукай бүгенге көндә дә композиторларга остаз, укытучы». («Сәнгатьчә матурлык һәм осталык».) Тукайны «халык титаны» дип зурлап, аның рәссамнарга, театр әһелләренә, драматургларга ясаган шифалы тәэсирен галим дәлилле өйрәнә. Татар балет сәнгатенең югары үре «Шүрәле» нигезендә халык мифологиясе, Тукай хыялы тудырган әсәр ятканны искәртә. «Шүрәле», «Таз», «Эш беткәч уйнарга ярый»,

«Теләнче», «Печән базары яхут яңа Кисекбаш», «Су анасы», «Япон хикәясе», «Кәҗә белән сарык әкияте» әсәрләрендә исә нинди театраль картиналылык! Үтәдән-үтә хәрәкәт аларда шулкадәр оста оештырылган—үзләре үк инсценировкага, сәхнәгә, тамашага сорап торалар». («Сәнгатьчә матурлык һәм осталык».)

Җыеп әйткәндә, галим Тукай иҗатын өйрәнүнең яңа юлларын, әлегәчә берәү дә игътибар итмәгән үзгәрәк кыйтгаларын эзли, таба, әйләнешкә кертә. Туксанынчы елларда Нил Юзиев вакытлы матбугаттан, агымдагы тәнкыйтьтән, кайнар сүздән беркадәр читләшә. Галим үзе өчен яңарак өлкәгә, бай тарихлы мәдәниятебез мирасын—кульязмаларны, архив чыганакларын, язучыларның тормыш шәҗәрәләрен өйрәнүгә, аларны бастырып чыгарып, халыкка кайтару шөгыленә керешә. Бу тармакта да ул төп игътибарын Тукай иҗатына юнәлтә. Ошбу җәһәттән «Тукай шигырьләреме?» исемле хезмәте дикъкатькә лаек. «Соңгы елларда Тукайның фәнни басмаларына урнаштырылмаган әсәрләрен барлау һәм аларны матбугатта чыгару белән мавыгу күзгә ташланып торган бер тенденция рәвешен алды» («Тукай һәм XX гасыр мәдәнияте».) Тукай иҗатын яңача өйрәнү заруриятен яклап, үткәндәге казанышларны кире кагу, аның мирасын ясалма рәвештә, башка шагыйрьләрнең әсәрләре исәбенә тулыландыруга галим кискен каршы чыга. Тукай моңа мохтаҗ түгел. Кайберәүләрнең ышанычсыз чыганакларга таянып, халык шагыйренеке дип тәкъдим иткән «Корьән укысам» шигыренең М. Укмаси, «Корьән» шигыренең Н. Думави тарафыннан язылган булуын исбатлый ул. «Кадер кич», «Доносчы колагына хор белән әйтелер», «Йолдыз һәм кояш» шигырьләрен тәгаен Тукайныкы дип санау белән дә килешми, әлегә алар «текстологларны уйландыра, эзләндерә торган шигырьләр рәтендә генә йөри алалар» дип яза.

Н. Юзиев сәясәт үзгәрү, Тукайның яңа әсәрләре табылу, беришесенең чын иҗатчылары ачыклану белән бәйле рәвештә,шагыйрьнең дөнья таләпләренә җавап бирерлек академик тулы басмасын бастырып чыгару хыялы белән яшәде. Галимнең бу өметен хәзер исәннәр тормышка ашырырга тиеш.

Н. Юзиев тикшеренүләренең үзәгендә Тукай иҗаты ятса да, ул татар поэзиясе үсешенә Кол Галидән башлап, 90нчы елларда иҗатка килгән иң яшь шагыйрьләр иҗатына кадәр игътибарлы булды. Дәрдеманд, С. Рәмиев, Такташ, Туфан, Р. Фәйзуллин, Р. Харис һ. б. иҗатлары төгәл бәяләрен алдылар, һәркайсына хас үзенчәлекләре, шигърият поэтикасына алып килгән яңачалыклары белән ачылдылар. Н. Юзиев әдәбият фәне өчен югары белемле кадрлар әзерләүгә, урта һәм югары мәктәпләр өчен дәреслекләр язуга зур өлеш кертте. Иң мөһиме: ул иң четерекле нәзари,шигырь төзелешенә, иҗат лабораториясенә караган катлаулы мәсьәләләр турында төрле катлам укучысы аңларлык телдә язып булуны исбатлады, татар әдәбияты белеменең өслүбен камилләштерүдә үз сүзен әйтте. Аның тәнкыйть мәкаләләренең әдәби әсәр кебек укылуы шуңа дәлил була ала. Н. Юзиев Татарстанның иҗтимагый тормышына, халкыбызның азатлык, мөстәкыйльлек өчен көрәшенә дә битараф була алмады, хәленнән килгәнчә, милләтенең тарихи дәүләтчелеген тергезү омтылышын һәрдаим хуплап, ярдәм итеп яшәде. Университетта укыту дәверендә ул үзен әзерлекле лектор, сүз остасы итеп танытты. Шулай шаулап-гөрләп, һәр җиргә дә өлгерергә тырышып, мирасыбызны,чыганакларны өйрәнү белән дәртләнеп, учына йөткергәләп йөрде дә, Нил Гафур улы, картлыгын күрмичә безне—күп санлы укучыларын, дусларын, гаиләсен, әйләнешкә кертеп бетерелмәгән әдәби-тарихи кульязмаларыбызны—ташлады да китте. Соңгы көннәренә чаклы татар әдәбияты, мәдәнияте өчен янып-көеп яшәде, уйлау, бәяләү сәләтен, фикерләү тирәнлеген саклый алды. Ифрат тырыш, эшчән вә тумыштан сәләтле булуы, бай фәнни мирасы Нил Юзиевны Ж. Вәлиди, Г. Гали, Г. Нигъмәти, Х. Госман, Г. Халит кебек күренекле галимнәребез белән бер рәткә куя. Аның фәнни, тәнкыйди хезмәтләре һаман хәрәкәттә, халыкка хезмәт итә. Үзен күреп белгән, аралашкан кешеләр хәтерендә дә ул саф күңелле, ихлас, ярдәмчел, фидаи һәм зыялы зат булып калды.

**Тәлгат ГАЛИУЛЛИН**

# БӘЛӘКӘЙ БАТУЛЛА

## Зичәбашка килгәч

Зичә суының башланган урынына урнашкангадыр, ахрысы, бу керәшен авылын «Зичәбаш» дип атаганнар. Без үскәндә Зичә суында берәр килолы бәртәсләр, кара балык каптыргалыйлар иде. Әти-бабайлар үскәндә балыкны Зичәдән сәнәк белән каерып ярга ата торган булганнар. Хәзер Зичәдә ташбаш, этләй, сирәк-мирәк кенә чабаклар күренгәли.

Мөгаллимәләр житешмәү сәбәпле, әнине шунда, Зичәбашка күчергәннәр.

Шыкмайдан барганда карурманны чыгып, басу юлыннан бераз киткәч, Зичәбаш авылы күренә. Уйсу җиргә урнашкан ике урамлы матур авыл. Бакчаларны сап-сары буяу белән буяп чыкканнар. Сап-сары шул бакчалар уртасында кара мунчалар күренә. Сап-сары буяу дигәнем ул көнбагыш икән. Керәшенчә—айбагыр. Айбагырлар арасында буй-буй түтәлләр: кәбестә, кыяр, шалкан, кишер түтәлләре. Нишләп соң күрше мөселман-татар авылларындагы бакчаларда көнбагыш, яшелчә үсми?

Мөселман-татар гөмбә ашамый, бакчада җимеш агачлары, яшелчә үстерми. Бу—мөселман-татарның элек далада яшәп, утрак тормышка күчкән булуыннан килмиме икән?

Без Зичәбашта бөтенесе дүрт ел яшәгәнбездер. Әмма шушы дүрт ел сабый күңелендә, сабый хәтерендә мәңге җуелмаслык матур тәэсир калдырган. Сигез яшьтә чагымда, 1946 елда бөтенләйгә ул авылдан китеп барсам да, мин һаман, өзлексез Зичәбашны сагынып яшәдем, сагыну гына да түгел, мин Зичәбашны төшләремдә күреп жирси идем, хәзер дә жирсим. Еш булмаса да, мин берничә тапкыр Зичәбашка кайтып килдем. Кайтырга мөмкин булмаганда, мин шул җирсүемне, сагынуымны басар өчен гел-гел керәшен җыруларын көйлим.

Зичәбашка килү белән безнең өч кешедән торган гаиләбезне Захарлар янындагы буш йортка урнаштырдылар. Мин, сабый, бу йортка килеп керүгә үк шундый арманы сизеп алдым. Керәшен йортының сул як түренә тәре куелган була.

Урамның икенче ягында, безгә каршы якта Начтый түти улы Сашук белән яшәп ята. Алар безгә туган кебек якын булып китте. Без Сашук дәдәй белән иртән урманга җиләккә барырга сүз куешкан идек. Мин иртүк Сашук дәдәйләргә кердем. Начтук түти күзикмәк пешереп маташа иде. Сашук дәдәй йокы симертә.

—Сашу-ук!—диде Начтый түти.—Сашук! Тор! Әнә, Ырабит әллә кайчан торган. Тор, Сашук, юын, чукын, аннан ары сун күзикмәк ашарсыз. Аннан ары сун урманга китәрсез.

Сашук торды, юынды, почмактагы тәрегә карап, иелә-бәгелә чукынды, чукынганда ул гел бертөрле тавыш белән дога укый иде:

—И, Къодай, мине коткар, жараулылар бетте, адәм улларында чынлык әзәйде. Әр кем үз жакынына бушны сөйләй, күнелендә, аузында жумалаулык, күнелдән усаллык сөйлиләр. Жумалаучы авызны, мактанучан телне Къодай барын да бетерер. И, Къодай, Син безне карарсын да бу заттан сакларсын да гумергә. Әйләнәдә бозоклар жөриләр, Син югартын тороб, адәм уллары өчөн күб сагышланасың. Гаспадый, памилуй, амен!

Тәредән нечкә, озын сакаллы, чәче хатын-кызныкы кебек урталай аерып таралган, суалчан кебек сыгылмалы озын бармаклы бер зат Сашукның чукынганын карап тора иде.

Бу урында «тәре» белән «хач» сүзләрен ачыклау кирәк. Мөселман-татарлар шушы ике сүзне буташтырып сөйли. Керәшеннәрдә ул сүзләр төгәл һәм үз урыннарында гына кулланыла. «Тәре» булса—икона, сурәт. Ул тәредән кайбер өйләрдә бала кочаклаган Мария-ана яки ябык чырайлы, нечкә сакаллы Иисус Христос карап тора. «Хач» (керәшенчәсе: къач) булса, крест, аркылы сурәт, «кызыл хач, кайчы», «крестовые походы—хач яулары» сүзләренең тамырында шул «хач» сүзе ята. Шулай итеп, христианнарның муеннарына тага торганнары—хач, түргә куя торганнары тәре була. «Тәре» сүзенең килеп чыгышын «Тәнре» заманнарыннан ук исәпләргә мөмкин. Димәк, «тәре» сүзе Тәнре—Алла дигән сүз.



Сашук дәдәй яхшылап чукынды, ашады, аннан соң без жиләккә киттек. Мин жиләк жыя белмим, кулыма эләккән бер жиләк авызыма керә дә югала, савытымның төбен күмәр-күммәс жиләк жыйганмындыр. Кайтыр вакыт житте. Сашук дәдәй бик тиз-оста жыя, аның савыты тулган, өстенә ул әрекмән яфрагын очлайтып төргән дә шуңа күп итеп жиләк жыйган. Минем буш савытымны күргәч, Сашук көлемсерәде:

—Урман тикле урманга килеп тә буш савыт белән кайтмассың бит инде!—дип ул әрекмән яфрагына жыйган жиләген минем савытка салды.

Минем савыт тулганчы жиләк жыйды.

Тәреләрнең кысалары чигүле бистәр (сөлге) белән урап алынган була, тәренең киштәчегендә бер яки берничә шәм янып тора.

Керәшен өйләренең олы ягында дивар буйлый тар сәке ясалган. Ул көндез утырып ашау, кул эше эшләү өчен, төнлә ятып йоклар өчен хезмәт итә. Керү ишеге өстендә биш-алты кеше сыярлык сәндерә. Керәшенчә—сүндәрә.

Керәшен өйләренең тәрәзәләре турыдан-туры урамга чыга икән. Албакча бер-ике йортта гына күренә. Хәллерәк хужаларның өй каршысында албакча була. Йомышы булган кеше сөйләшәсе сүзен өйгә кереп түгел, урамнан гына, тәрәзә ачып кына әйтә, бригадирлар да, эшкә әйткәндә, урам яктан торып тәрәз шакый да:

—Начтый жинги, сиңа бүген арыш жилгәрергә!—дип кычкырып уза.

Өс киемнәрендә дә, баш яулыкларында да, ашъяулык, тастымалларда да кызыл, кара, коңгырт төс күбрәк. Гомумән, керәшеннәрнең төскә булган зәвыгы чуаш, мари, башкорт, удмуртларныкына бик якын.

Зичәбаш авылына килеп керү белән мине гаҗәпләндергәне урам буйлый чиный-чиный чабып йөрүче кечкенә чучкалар булды. Мин шул чучкаларны тотып, муеннарын кашып йоклата идем. Муенын кашып, иркәләсән, чучка рәхәтләнеп мыркылдап ята бирә. Кунакка килгән әбием Мәгъсүмә минем бу эшемне күреп, бик каты ачуланып ишегалдына алып керде дә, бирде кирәкне:

—Чукынмышмы син? Дуңгыз баласын кочаклап ятасың калган!—дип бик озак мине ачуланды, дуңгызны тотарга, дуңгыз ите ашарга ярамаганы турында дәрес бирде.

Шуннан соң ул мине жилтерәтеп мунчага алып керде дә:


—Көл белән, сабын белән жиде тапкыр кулларыңны ю, жүнсез бала!—жиде

тапкыр кул юганымны карап торды, аннан соң үземне чишендереп жиде кат сабын-мунчала белән баштан-аяк юып, өйгә алып керде.

Гомумән, Зичәбаш халкы миһербанлы, киң күнелле халык булып хәтердә калган. Керәшендә хөсет юк. Күршесен чагу юк. Күршесенең малына кызыгу, аның байлыгыннан көнләшү юк керәшендә. Мохтаж кеше керсә, соңгысын биреп чыгара торган юмарт халык ул керәшен.

## Песнәк туе

Зичәбаш халкын сугыш елларындагы ачлыктан урман коткарды. Язга чыгуга ук карурманда сәрдә калкына. Сәрдәне күпләп җыеп, шулпага салып ашыйлар. Гөмбә, чикләвек, кура җиләге, шомырт күп була Зичәбаш урманында. Юкә яфрагын да ашый идек. Ләкин барыбер кешеләр фәкыйрь тормышлы иде. Бөтен ирләр сугышта. Бөтен бәрәнге, икмәкне фронтка алып бетерәләр. Керәшеннәрнең бердәнбер карап торган дуңгызларын да өттермиләр, тунатып алып китәләр. Янәсе, дуңгыз тиресеннән күнитек табаны тегәләр икән.



Шулай да, керәшеннәр дуңгызларын үзләренчә чәнчеп, учакта өтеп, тиресен налугчылардан яшереп, кышка ысланган чучка боты ясап калдырырга тырышалар иде. Һәркем дә мондый мая туплый алмый. Күпчелек ачлы-туклы яши иде.

Беркөнне Югароч Түле (Анатолий) безгә килеп:

—Карале, Ырабит, әйдә безгә песнәк туена. Әниләр Кабан авылына кунакка китте.—диде.—Түлке безнен тоз жук. Син бераз тоз ал инде.

Чыннан да, тозга кытлык чак, тоз-шикәр укытучыларда гына була торган иде.

Кышкы суык кичләрнең берсе иде. Мин әнидән рөхсәт сорап, Түлеләргә песнәк туена киттем. Түле, күрше малайлары белән тәбегә, бик күп песнәк тоткан. Зичәбаш малайлары тәбене оста ясый. Тәбе капкачын очлы чыра белән чак кына элдектереп, чыра өстенә жим куялар. Песнәк капкач астына кереп, жимне чукуга, капкач шалт итеп ябыла. Песнәк бичара тәбе эчендә кала.

Малайлар мәш килеп, песнәкләрне суеп, пешекләп маташа. Песнәк суыкта кабарынкы, зур булып күренә, пешекләп йонын йолкыгач, нәкъ уймак кадәр генә кала. Утыз биш данә песнәкне дүрткә бүлеп, сигезәр песнәк тиеп, артык чыккан өч песнәкне хуҗага—Түлегә биреп, песнәк ите белән шулпа ашадык. Янында гөмбәсе, бәрәңгесе дә бар иде. Чыннан да туй булды бу. Ашаудан битәр аулагөйдәге уеннары кызык булды.

Кызык уен дигәннән, ул чакта, сугыш вакытында балалар арасында гына түгел, олылар арасында да күрәзә багу гадәте бар иде. Без дә күрәзә карарга җыендык. Шомлы уен ул. Кичен, караңгы төшкәч, өй артында буран улаганда, утны сүндереп, ап-ак мич янына урындык куеп, урындык өстенә тимер төпсә куеп, шул төпсәгә күп итеп коры яфрак, кәгазьдә салып яндырасың. Ялкын шәүләсе ак мичтә уйный, ялкын бетkәч, кәгазьдә, яфракларда очкыннар йөри башлый, шул очкыннарның шәүләләре мичтә олаеп күренә. Син тавыш чыгармыйча гына шул шәүләләргә карап, сугышта хәбәрсез югалган атаңны эзләргә тиеш буласың. Кайберәүләр, әллә шомлы мохиттә экстазга бирелеп, әллә юрамалый гына:

—Мин әтине күрдем. Мин дәдәмне таныдым,—дип әйткәлиләр иде.

Минем әти дә сугыш башланган елны ук хәбәрсез югалган. Ләкин мин бу спиритизм сеансларында бер дә кешегә охшаш сурәтләр күрми идем. Шулай да, песнәк шулпасы ашаганнан соң оештырылган бер сеанстан соң Түле миңа әйтте:

—Синең атаң исән!—диде.

## Бабай консерваториясе

Бабакаемның ике күзе дә тома сукыр иде. Аның әнисе Хәбибҗамал да сукыр булган. Юк, нәселдән түгел икән бабамның сукырлыгы. Аның бер күзе элеккеге Ярман сугышында ядрә тиеп сукырайган. Икенчесе тимерлектә кайнар кыйпылчык тиеп күрмәс булган. Әбием Мәгъсүмә карчык мин-сабыйга гел башкача сөйли иде. Имеш, бабай урман кырында кояшта кызынып ятучы җыланга сыек тал чыбыгы белән суккан да, җылан һавага сикергән, һавадагы җылан бабайның күзенә сигән: бабай шуннан сукыр булып калган. Йоклап ята торган җыланга да, шуышып бара торганына да сугарга ярамый икән шул.

Сукыр булса да, бабай көн саен үзенә эш таба. Капшана-капшана итеккә олтан сала, утын яра, пычкы теши. Мин аның пычкы тешәгәнен карап утыргалыйм. Пычкы үткерләргә өйрәнүдән битәр, эш азагында бабамның пычкыдан көй чыгарганын тынлыйсым килә. Пычкының бер сабы ике тезе арасында, икенче сабы сул кулында: сул кул пычкыны ия-бөгә, пычкы: уй-юуй-юуй, диеп тавыш чыгара, уң кулындагы игәү белән бабай пычкыга тиеп-тиеп ала—гаҗәеп матур көй чыга. Электрон музыкаң бер кырда торсын!

—Бабаң балтада да уйный белә әле ул,—диде әбием.

Мин ышанмадым.

—Ничек уйныйсың инде ул балтада?—дидем.

Бабай миңа келәттәге бөтен балталарны да алып керергә кушты. Дүрт балта алып кердем. Бабай балталарны чиертеп-чиертеп тыңлап карады да икесен әбигә, икесен миңа тоттырды. Аннан соң игәү белән балталарга җиңелчә генә суккалый башлады. Зең-чең, зең-чең, чә-ча-чә, чә-чә, ча-чә ча-чә ча-чә-чә...

—Әпипә көе бит бу!—дип кычкырдым.

Шуннан соң әби тустаганнар тезеп, бераз су салып чыкты, кайсысына күбрәк, кайсына азрак салды да, балкашык белән сугып тагын «Әпипә» көен уйный башлады.

Әби җәмкинең бер ботына җеп тагып аса, икенче ботын авызына кабып, җәмки арасына чыра пычагы белән сугып көй чыгара иде.

Бабай тешәлгән пычкыны, балталарны келәткә чыгарып куярга кушты. Эше беткәч, бабай алачыкка, Югарочтагы тимерче агайлар янына бара. Агайларның сукыр тимерче Кәлимулла белән озаклап сөйләшергә вакыты юк, алар сука ясый, урак теши, дага яки арба күчәре ясый, амбар ишегенә күгән коя. Бабай сүзсез генә чүкеч тавышларын тыңлый.

Озак кына шулай утырганнан соң ул:

—Һәйдәле, улым,—ди.—Түбәноч алачыгыннан да бер әйләник. Таякның бер башын бабайга биреп, үзем икенче башыннан тотам, чакрым ярым араны шулай таяк житәге белән узабыз.

Мин ялан тәпи. Аяк йөзләре чебиләгән. Яңа гына юл уртасына сыер җылы, йомшак «күзикмәк» салып киткән, чебиле аяклар җылы тизәктә рәхәтләнә, мин тизәк ярып барам. Бабай кычкыра:

—Улы-ым, карап бар әле, тизәккә батырдың бит,—ди.

Түбәноч алачыгында да без икәү чүкеч чаңкылдаганын тыңлап утырабыз. Баш тимерче керәшен Кузнецов бәләкәй чүкеч белән кызган тимернең кай төшенә сугасын күрсәтә, Чикачи зур чүкеч белән шул урынга суга. Оста тоткан бәләкәй чүкеч «чең-чең» диеп суга. Сугыштан аяксыз кайткан Чикачи Миннәхмәте уткызган тимерне таптый: чаң-чең, чаң-чең...

Бабай монда да сүзсез генә «чаң-чең» тыңлый, күрек өрдергән кайнар тимернең салкын суга тигәч җылан кебек чыжылдаганы, олы чүкеч белән бәләкәй чүкечнең сандалга тиюе бабайның яшь-куәтле чакларын хәтерләтәдер.

—Һәйдә, улым, өйгә кайтык булмаса,—ди бабай.

Дүрт яшьлек сабый—мин алдан, сукырлыктан бөкерәя төшкән озын буйлы бабам арттарак, уртада таяк—без өйгә кайтып барабыз.

Капкадан керүгә үк болдырга басып безне әби каршы ала.

—Кайда йөрисез? Мунча шартлап өлгерде,—ди.

Бабай белән мунчаның беренче эссесенә китәбез. Мунча өйалдында чишенәбез. Бабай кушучлап үзенең «шәҗәрәсен» каплый.

—Алъяпкычны бир, улым!—ди бабай.

Мин почмактагы агач чөйдә эленгән бабай алъяпкычын кулына тоттырам.

—Син дә алъяпкыч бәйлә,—ди бабай.

Мин дә чүпрәк белән «шәҗәрә»мне каплыйм.

—Бабай, нигә алай итәбез ул?—дим.

—Кешеләр оят җирләрен бер-берсенә күрсәтергә тиеш түгел, олан! Һәр кешенең үзенең сере бардыр.

—Бабай, син күрмисең бит, нигә миңа бәйләтәсең?—дим.

—Мин күрмәсәм, мунча иясе күрер,—ди бабай.

Ул ах-вах килеп, чабына. Мунча эссе, аягүрә бассаң колак пешә. Кат-кат эссе салып, бабай озак чабына, үзе һаман ләззәтләнеп: «ә-әх, әттә-т—тәтә» дип кычкыра. Аннан соң мине ләүкәгә сузып сала да ике себерке белән алны-артны чабарга тотына. Берничә кат чабынгач, без чайканып, киеп килгән керле киемнәребезне киеп өйгә кайтабыз.

—Рәхмәт мунча хөрмәтенә!—дибез өйдәгеләргә.

Бездән соң әби, әни, Әнисә апа мунчага китә. Бөтенесе дә юынып чыккач, бабай белән без янә мунчага керәбез. Бу юлы чабыну юк, юынабыз гына.

—Зур үскән минем улым, ярдәме тия башлады!—дип бабай мине мактый-мактый сыртын ышкыта.

Аннан соң чиста киемнәребезне киеп янә өйгә кайтабыз.

—Рәхмәт мунча хөрмәтенә!—дибез.

Кабак-чәй эчәбез. Тәмсез булса да, бабай чәйне мактый-мактый, шопыра-шопыра тәмләп эчә. Кабак-чәйдән соң бабай кулына гармун ала. Әби такмаклый-такмаклый бии.

*Кыштыр-кыштыр туныңный,*
*Кыштырдатып киярсең.*
*Бәхетеңә туры килгәч,*
*Күрмәсә дә сөярсең.*

Бабай җавап әйтә:

*Киндер ыштан билдә тормый,*
*Былафкый кадамасаң,*
*Шул ыштанны бүләк итәм,*
*Ятларга карамасаң...*

Гармуннан соң бабай чүкеч, кадак, юка такталар алып ишегалдына чыга. Бисмилла әйтеп, бабай нидер ясарга тотына, мин аңа кирәк-ярак биреп торам.

—Бабакай, син ни ясыйсын ул?—дип сорыйм.

—Очкыч ясыймын, олан, яраплан,—ди бабам.

—Ул очкыч нигә ул, бабай, ә?

—Атаңны эзләргә! Ничә ел бит инде хәбәре юк атаңның...

—Әтине эзләшергә мине да аласыңмы, бабай?

—Алмыйчан! Синнән башка мин ни күрәм? Икәү очарбыз, Алла теләсә...

Әти сугышка китеп, хәбәрсез югалган шул. Шушы такта очкычка утырып, бабай белән әтине эзләп табып, ишегалдына кайтып төшкәннәремне мин әллә ничә тапкыр төшемдә күрдем. Ләкин өн башка, төн башка булган икән шул, очкычыбыз очмады. Бабай яз көне, 1945 елда май аенда үлеп китте. Очкыч дигән нәмәрсәгә, ягъни зур гына фанер тартмага әбием бабайның мич башындагы иске бүрегендәге сап-сары чебиләрне чыгарып салды.

Күп тә узмастан, чебиләр әтәч булып кычкырырга хыялланганда Сукыр Кәлимулланың олы утлы Мохлисулла, ягъни минем әтием исән-сау кайтып төште.

Бабай гына күрә алмады улының әсирлектән исән кайтканын. Мин әтине бабамның каберенә алып бардым.

Сукыр бабам ясаган очкыч еллар буена чеби-бәбкә оясы булып хезмәт итте.

## Әбием дәресләре

Бервакыт мин Исхак агамның йөз данәлек папирус тартмасыннан җидесен алдым. Тәмәке тартырга өйрәнеп йөргән чак. Миңа җиде яшь. Сизгән бит әбием минем бу эшемне.

—Чыгарып сал әле тәмәкеләреңне!—диде әби. Алты папирусны өстәлгә куйдым.

—Берсен тарттыңмыни?—диде әби, мин дәшмим.—Ярар тартсаң. Менә калган бу алтысын да тартып бетер. Ләкин шуннан соң тәмәкегә йогынасы булма.

Әби папиросларны кире бирде. Чыннан да, мин бу папиросларны иптәшләремә тараттым, берсен үзем тартып бетердем. Ләкин шуннан соң гомерем буе мин тәмәке тартмадым.

Тавыклар кытаклаудан туктауга әби мине лапаска, яңа салынган йомыркаларны алып төшәргә менгезеп җибәрә. Маймыл житезлеге белән сәндерәгә менәм, жыпжылы йомыркаларны алам, өч йомырка булса берсен эчәм, эчәм дә, жинаятем тотылмасын дип, салам түбәне тишеп, шул тишектән йомырка кабыгын абзар артына ташлыйм. Биш йомырка булса икесен эчәм. Йомыркаларны әбигә тапшырганда, ул һәрвакыт ризасызлык илә:

—Һе, кая сала икән бу коңгырт тавык йомыркасын! Монда өч йомырка булырга тиеш иде. Саескан аламы, сасы көзәнме ияләнгән лапаска?—дип сукрана.

Жәй урталары узып барган чакта әбием мине чакырып:

—Улым, бар, абзар артында котырып үскән кычытканнарны, әпертиләрне чап!—диде.

Мин чалгы белән кычытканнарны, әрекмәннәрне чаба башладым, әбием читтәрәк карап тора:

—Әйбәт чабасың улым, машалла!—ди.

Берзаман минем чалгы әвен кебек өелгән күкәй кабыкларын ачып ташламасынмы!

Әбиемнең ике күзе шар булды:

—Әһә, менә кем икән ул саескан! Син чөмереп ташлагансың бу күкәйләрне!

Шуннан соң миңа Саескан кушаматы тагылып калды, ярый әле әбием мине Сасы Көзән димәгән!

Мин гомерем буе чи йомырка эчү гадәтемне ташламадым. Хәзер дә эчәм.

## Җылан мөгезе

1946 елның жиденче ноябренә каршы таңда минем энем туды. Язга чыккач, әбием миңа:

—Улым, урманга бар, кара жыланны үтереп, башын кисеп алып кайт!—диде.

—Нигә кирәк ул жылан башы?—дидем.

—Әнисә апаң сабый чагында аның башлыгына жылан мөгезе такмады атаң белән анаң. Әнисә апаңа күз тиде. Ул гарип калды. Әнәс абыеңның башлыгына да мин жибәргән жылан мөгезен такмадылар, Әнәс абыең да чирләп үлде. Синең башлыгыңа мин үзем жылан мөгезе теккән идем, син менә, Аллага шөкер, саусәламәт. Синең мангаеңа таккан ул жылан мөгезен югалттылар. Яңасын алып кайтырга кирәк,—диде әби.

—Әби, жылан мөгезен таккач, ни өчен күз тими?—дим.

—Безнең борынгы бабаларыбыз жыланнарны жиңгән халык, жыланнар бала башлыгында жылан баш сөяген күрсәләр: әһә, бу бала безнең нәселне жиңгән халыкныкы, аңа кагылырга ярамый дип баланы чакмый. Жыланнар Ахырзаманга таба кеше эченә керә барырлар, дигән. Ни өчен кешеләр хәзер гаугалы? Барысының эчендә жылан ята. Эчендә жылан булган кеше башлыгында жылан мөгезе булган

балага бакса, сихере дә, күзе дә тия алмый. Жыланның башын кискәч, гәүдәсен кырмыска оясына ташла. Үзең сәрдә жый, букчаң тулгач, кырмыска оясыннан жылан кабыгын алып кайтырсың.

—Әби, жылан кабыгы нигә ул?

—Кирәк!—кенә диде әби.

Мин, әби өйрәткәнчә урманга менеп, Солтангәрәй жизни биргән сөяк саплы пәкем белән чикләвек куагыннан ике җәпле таяк-сәнәк ясадым. Безнең урманда жыланнар күп, мин жыланнан курыкмыйм. Жылан күрсәм, камчы-камчы, дим, жыланнар миңа тими.

Гомумән, жылан өстенә басмасаң, аны йокысыннан уятмасаң, тора салып жылан кешене чакмый, кешегә ташланмый, алар бик куркак була. Кеше күрсә, жылан качу ягын карый.

—Урман кырында бөгәрләнеп, кояшта кызынып ятучы жыланга чыбык белән сугарга ярамый. Жылан һавага сикерә дә, үзен кыерсытучы кешенең күзенә агуын сиптерә, кеше сукырая,—ди әби.

Әбием, һәр нәрсәне риваять, әкият рәвешенә китереп, сабыйны яман эшләрдән тыйган булган икән.

Кисеп алынган жылан башын әби багана башына—Кояшка куйды. Кошлар алып китмәсен өчен, иске себерке белән каплады. Бер-ике көн шулай эссе кояшта торганнан соң, әби жыланның баш сөяген багана башыннан алды. Жыланның баш тиресе кибеп, чатнап-чатнап ярылган иде. Урман чикләвегенең төше чаклы ап-ак матур баш сөяге генә әбинең учында калды.

—Менә шушы була инде ул жылан мөгезе!—диде әби.

Бу жылан мөгезе ике энекәшемнең дә башлыгында булды. Ике энем дә саусәламәт үстеләр, аларга күз тимәде, шөкер.

---

## ТОМШЫКЛЫ КҮРШЕЛӘРЕБЕЗ

### Мәче башлы ябалак

Илһам урманда йөрергә ярата. Аның күнелен урман шаулавы, кошлар сайравы хуш итә. Агачларның үсүен күзәтергә ярата ул. Һәр урманның, үсемлекләренә һәм агач төрләренә карап, үзенә хас исе бар. Үзенчәлекле җәнлекләр һәм кошлар дөньясы бар.

Шулай бер җәйге урманда йөргәндә Илһамның җилкәсенә кош баласы егылып төште. Аны кулына алгач, бер канаты җәрәхәтле икәнен күрде Илһам. Кошчыкның күзләре түм-түгәрәк, йөзе мәченекенә ошаган. Димәк, бу мәче башлы ябалак була инде. Монда берәр җәнлеккә җим булачак бит инде бу. Малай аны өенә алып кайтты, ашатмакчы булды, су куйды. Ләкин кош җимгә орынмады да, тик күзләрен генә шар кебек итеп ачып бер җирдә утыра бирде. Илһам кошны иптәшләренә дә күрсәтте, киңәш сорады. Тик берсе дә аңык бер сүз әйтә алмады шул. Бу кош турында мәгълүмат эзләргә тотындылар, ләкин җавапны китаплардан да тапмадылар. Сәгать арты сәгать, көн арты көн уза торды, кош инде тәмам хәлсезләнде. Ниһаять, Илһам иске совет энциклопедиясеннән бу төр кошларның тычкан белән тукланганнарын белеп алды. Тозак корып тычкан тотты да, «мәче башлы»ның алдына китереп куйды. Һәм... «Канатлы мәче» шундук ялт иттерде! Инде иптәшләре дә тычкан арты тычкан китереп кенә тора. Кош күзгә күренеп үзгәрде, күзләрендә үзенә генә хас булган төс барлыкка килә, хәрәкәтләре дә житезләнә башлады. Әкренләп канатларын да

каккалап куя әнә. Балалар өчен бу зур куаныч иде. Аның янында дежур торалар. Мәктәптән дә укучылар күпләп килә, мондый кош гел очрап тормый шул. Урманда йөргәндә сирәк-мирәк аның уфылдавын, шомлы тавышын гына ишетеп була. Менә ябалаккай очкалап та карый башлады. Аны ирекка җибәрәсе көн дә килеп җитте. Балалар ябалакны урманга, табылган урынына алып барып очырдылар. Кошның моңа сөенгәне сизелеп тора: үзенә хас аваз чыгара иде ул. Менә канатларын кагып кайчандыр егылып төшкән агач ботагына менеп кунды. Эшләгән эшләренә канәгать булып, укучылар бу кош белән иң якын танышлары белән аерылышкан кебек аерылыштылар. Тагын килербез дип киттеләр. Күңелләрендә янә нинди дә булса игелекле эш эшләү теләге бөреләнде.

## Карга

Илдус бик игътибарлы малай. Тирә-ягында ниләр булганын күрә белә. Шулай бер тапкыр аның күз карашы ишек алдында үскән тирәк ботагындагы каргага төште. Ул аны күзәтә башлады. Менә инде берничә көн карга урынында утыра бирә. Илдус аны ишек алдында йөргәндә дә, өй тәрәзәсеннән дә күрә. Тирә-юньдә агачлар да берничә, каргалар да күп. Иртәләрен шаулашып күтәрелеп басу ягына очып китәләр дә, кичләрен янадан кайталар. Әлеге карга янына да килеп киткәннәре бар. Бу хәл бик күп мәртәбә кабатлана. Илдус аларның теге каргага азык алып килүләрен чамалый. Көннәрдән бер көнне каргалар Илдусның каргасын читләтеп уза башлады. Малай, аптырагач, бик биектә булса да, карга янына үрмәләп менде. Аның каурыйлары таушалган, тәссезләнгән, күзе дә начар күрә кебек. Илдус аңа җим алып менде. Ләкин карга аңа игътибар итми, ничә карама, җиме шунда, тик чыпчыклар гына чүпләргә ияләштеләр.

Беркөнне малай карганы урынында күрмәде. Яхшылабрак караса, карга җиргә егылган икән, җансыз ята бирә. Карганың картлыктан үлгәне аңлашылды. Илдус аны бик кызганды, нык ияләшкән иде шул. Мәчеләр алып китмәсен дип шунда, агач төбенә үк җирләп куйды үзен.

## Үрдәк

Гомер-гомергә үрдәк үстердек. Башта бу эш белән әби шөгыльләнде. Вакыт үтү белән әни белән мина калды. Бу шөгылебезне яшь үрдәктән башладык. Беренче елны 5 кенә йомырка салды. Басып утырып бәбкәләр чыгарды. Икенче елны 10 йомырка, 8 бәбкә булды. Өченче елны күкәй салуны нигәдер соң башлады, апрель аенда гына. 15 күкәй салды, сәке астындагы ояга утырттык, чыгып качмасын дибез. 20 көннән артык утырды инде. Көненә ике-өч мәртәбә тиз-тиз генә ашап куя.

Май урталары иде. Азрак тын алсын дип ишек алдына чыгарабыз, үзе сорый бит ишек янына барып. Бер тапкыр шулай ишек алдыннан керми генә бу. Чыгып карыйм, урамда да юк. Әни мине Олы күлгә җибәрде, шунда гына булыр, алып кайт, ди. Йөгереп барсам, чыннан да шунда йөзеп йөри бу. Әйбәт кенә йөзәргә дә өйрәнгән идем, 10 яшь бит инде. Суга сикерәм, үрдәк янына йөзеп барам күлнең икенче ягына, ә ул, минем белән шаяргандай, еракkарак йөзеп китә. Шулай куыша торгач, хәлем бетә башлады. Үрдәкнең исә ярга чыгарга уенда да юк кебек. Шулай да үҗәтләнеп кууымны беләм. Арыдым, ирексездән су да эчкәләп ала башладым. Ә хәл тәки бетте, инде бер урында гына чәбәләнәм, су астына да төшеп менәм. Күлнең икенче ягында йөзеп йөргән Әмир дигән күрше малай, бу хәлне күреп, безнең өйгә таба йөгергән. Үрдәк турында оныттым инде. Ничек тә булса су төбенә китмәскә—бөтен теләк шул. Шулай бер урында тыпырчына бирәм, тирә-якны да аера алмыйм. Су суык, аякларны көзән җыера башлады инде, кулларым белән генә тартышам. Шунда «Улым!» дип әче тавыш белән кычкырган якка борылам. Күлгә таба әнинең йөгереп килгәнен күрәм. Йөгерми, кош кебек оча, башындагы яулыгы җилдә җилфердәп бара. Күлмәге-ние белән текә ярдан суга сикерде әни һәм тиз-тиз мина таба йөзеп китте. Аның шулай тиз йөгергәнен дә, йөзгәнен дә моңарчы күргәнем юк иде. Миңа да хәл кергәндәй булды, су өстендә тора ала башладым. Әни

йөзеп килеп житте дә, мине тартып кире йөзеп китте. Яр буена инде авылдашлар да җыелып өлгергән, ярдан чыгарга булышалар. Авызга һәм эчкә тулган суны төкерә-төкерә өйгә кайтабыз. Әнинен йөзе ап-ак, йөрәге дөп-дөп типкәне ишетелеп тора. Ләкин күнеле күтәренке, шат иканенен күзләреннән күрәм. Мине күкрәгенә кысып-кысып ала, күшеккән баласына бөтен тән җылысын бирергә тырыша шикелле. Әни кочагында мин бик тиз җылынам, янә шаян авыл малаена әйләнәм.

Өйгә кайтсак, үрдәк оясында утыра! Сәке астыннан пип-пип дигән тавышлар ишетелә. Монысын сонрак анладык: бәбкәләр чыгар алдыннан аларны бераз һава температурасына иләштерергә, суытып алырга кирәк икән ләбаса. Үрдәгебез моны үзе бик шәп белә икән. Бу юлы ул безгә 13 бәбкә чыгарып һәм үстереп бирде.

Ата үрдәк кайда соң, диярсез. Ул каурыйларын ялтыратып үз юлында кәпрәеп йөри бирде. Кирәкле эшебезне күптән эшләдек инде, янәсе!

**Кирам ЮЛДАШ**
*Лаеш районы*

---

# ШАЯН ФИЗИК

Бишенче курста укыганда ук обсерваториядә эшли башлаган идем. Телескопнын да бик кызыклысы насыйп булды, горизонталь телескоп дигәне. Анын бик озын, сигез метрлы торбасы һәрчак горизонталь яссылыкта көньяк юнәлештә була, ә күк йөзенең төрле өлкәләрен күзәтер өчен зур диаметрлы ике ярдәмче көзге кулланалар. Телескоптагы электр җиһазларынын бер өлеше әлеге торбага параллель урнашкан икенче торба эчендә иде. Кайчагында электр схемасын тикшерү өчен шул икенче торба эченә кереп шуышып йөрергә кирәк була. Шундый очракларда мин фәкыйрегез үзен АКШның атаклы физигы Роберт Вудның мәчесе белән чагыштыра иде.

«Вуд мәчесе» хакында мина кемдер сөйләгән идеме, әллә башта ук үзем ниндидер чыганактан укып белгәнмендерме, анысын хәтерләмим дә инде. Галимгә берзаман спектроскоп атамалы җиһазның торбасын анда җыелган чүп-чар, тузан һәм пәрәвез җепләреннән чистартырга кирәк була. Зирәк шәхес шундук бер мәчене тота да, торбага кертеп, анын шул очын ябып куя. Мәче торбаның зәгыйфь кенә яктылык биреп торган икенче очыннан чыгарга мәҗбүр була, юл уңаенда эчтәге чүпне дә үз тиресенә җыеп чыга.

Роберт Вуд хакында шактый күп китаплар һәм мәкаләләр язылган. Аңа «физика Моцарты» дигән кушамат та ябыштырганнар. Озын гомерле, һәрдаим иҗат ялкынында яшәгән галим 250дән артык анарчы билгеле булмаган яңа ысуллар нигезендә гамәли тикшеренүләр башкара һәм нәтиҗәләрен махсус журналларда фән даирәләренә җиткерә. Аны «эксперимент виртуозы», «заман оптикасынын атасы» дип таныйлар.

Р. Вудка Совет галиме Петр Капица кебек тәҗрибәләр өчен көтелмәгән яңа алымнар куллану да хас булган. Мәсәлән, берчак аңа тоз кристаллыннан бик юка пластинка әзерләргә кирәк була. Тоныка пыялада ышкып ярты миллиметр калынлыктагы пластинка булдыргач, галим аны балавыз белән шырпы очына ябыштыра да стакандагы суга тыгып тота. Андый четерекле нечкә эштә пинцет

куллану мөмкин булмый. Тозның бер өлеше суда эрегәннән соң пластинка тиешле дәрәҗәдә югары.

Шунысы кызык, галим көндәлек тормышында да физика һәм химияне һәрдаим кулланып яши. Берчак, тротуардан тротуарга тиклем урамда җәелеп яткан сулык аша чыкканда, үзенә комачаулаган сукбайлар төркемен бик кызык итә ул: кинәт ютәлли башлаган була да су өстенә төкереп куя һәм шул ук мизгелдә, кесәсендәге калай савытыннанн алып, күрсәтмичә генә суга кечкенә шарчык ташлый. Кинәт су өстендә ялкын кабынып китә, чаткылар чәчри, шартлаган тавышлар ишетелә. Вудны иблис дип уйлаган сукбайлар төрлесе төрле якка чабышып таралалар.

Укучыларыбыз андый галим бала чагында нинди булган икән дип уйлыйдыр, мөгаен. Ул кечкенәдән үк гадәти, балалар өчен ясалган уенчыклар белән уйнарга яратмаган. Аның каравы, әтисенең дусты, һава куучы машиналар әзерләүче гигант завод хуҗасы ун яшьлек сабыйга теләсә кайсы цехта йөрергә, җаны теләгән нәрсәне эшләргә рөхсәт биргән. Бала карамагында гидравлик пресслар, төрле станоклар «уенчыклар» ролендә булган! Кыскасы, зирәк олылар баланың тәрәккыяте өчен иң кулай шартлар булдырган.

Студент елларында һич кенә дә үрнәк булмаган студент унтугызынчы белән егерменче гасырлар чигендә Висконсин университетында эшләп, аннан соң кырык елга якын Балтимордагы Дж.Гопкинс университетының профессоры була. Физика өлкәсендәге тәҗрибә остасы химия белән дә дуслыгын җуймый. Кышкы салкын көннәрдә салкын су тутырылган шешәгә күкерт кислотасы кушып, аны кайнау халәтенә тиклем җиткерә. Сөеклесенең салкыннан күшеккән нәфис кулларын җылытырга бик ярап куя бу «химия». Мәхәббәте хакында шул замандагыча хат язып тормаган Роберт, Эдисон уйлап тапкан фонографны кулланып, үзе сөйләгән ялкынлы сүзләре язмасын оннан бушаган калай савытка салган да почта аша юллаган.

Бер шәхестә дус яшәгән физика һәм химиягә мәхәббәт тормышта башка, тискәре төсмерле очракларда да ярдәм иткән. Берчак аның белән бер пансионатта яшәгән күршеләре хуҗабикәдән ул иртәнге аштан калган ит калдыкларын җыя да төшке аш азыкларына кушып яңадан бирә дип шикләнә башлыйлар. Моны ачыклау өчен галим иртәнге аш вакытында сиздермичә генә ит кисәкләренә тозга охшаган, организм өчен зыянсыз хлорлы литий порошогын сибә. Көндезге аштан соң Роберт берничә ит кисәген лабораториягә алып китә һәм спектраль анализ үткәрә. Чыннан да, бу матдәгә хас булган кызыл сызыкча спектрда күзәтелә. Хуҗабикә фаш ителә.


Язмамның исемендә галимнең шуклыгы беренче планга куелган. Моны раслар өчен ике фактны атау да җитәдер. Беренчесе: озынлыгы өч метр чамалы һәм юан очы алтмыш сантиметрлы рупор ярдәмендә кичке урамнарда сирәк йөргән кешеләрне һәм полисменнарны шаккатыра. Ике квартал аша килгән иронияле репликаларын кешеләр күктән ингән тавыш дип аңлаган. Икенчесе: XX гасыр башында Вуд «Кошларны ничек чәчәкләр белән бутамаска» исемле, шаян рәсемнәр белән бизәлгән китап нәшер итә, аның берсен АКШның шул чактагы президенты Теодор Рузвельтка җибәрә. Рузвельт рәхмәтләр әйтеп, авторның башка китапларын да укыйсы килгәнен яза. Галим дәүләт башлыгына үзенең «Физик оптика» исемле китабын җибәрә.

Р. Вудка, армиягә бернинди катнашы булмаган кешегә, аның гамәли тикшеренүләрен АКШ армиясендә киң кулланулары сәбәпле, майор дәрәҗәсе биргәннәр. Кыскасы, галим фән дөньясында гына чикләнеп яшәмәгән, үзен нинди күренеш кызыксындырса, озакка сузмыйча аны тикшергән, тикшерү нәтиҗәсендә файдалы җиһазлар ясаган.

Атаклы галим 1930 елда СССР Фәннәр Академиясенең шәрәфле әгъзасы итеп сайланган. «Буржуаз» галимнәргә мондый хөрмәт ул заманнарда бик сирәк күрсәтелгән.

**Ким ШАКИРОВ**

# ЧАЙНВОРД




1. «Шагыйрь мәхәббәте» операсы авторы, композитор;
2. Г. Ибраһимовның балалар өчен язган хикәясе;
3. Татарстан Гимны авторы исеме, композитор;
4. Һади Такташ поэмасы;
5. (Уртадагы рәсем)
6. Татарстанның халык рәссамы Эрот...;
7. «Күк капусы ачылса» комедиясе авторы, драматург;
8. Казандагы бер театр аның исемен йөртә;
9. Матбугат әсәрләрен бастырып чыгару белән шөгыльләнүче оешма;
10. Җырчы ирләр тавышы;
11. З. Хәбибуллин балеты;
12. Төрле предметларны берләштереп төшерелгән картина;
13. Татарстан театр әһелләре оешмасы рәисе;
14. Шагыйрь, депутат—Разил...;
15. Тынлы музыка коралы;
16. Опера җыры;
17. СССРның халык рәссамы, академик Харис...;
18. Парлы салмак бал биюе;
19. Татарстанның аяк киемнәре җитештерү берләшмәсе;
20. Набордан чыккан текстлардагы хаталарны төзәтүче;
21. Татарстанның халык шагыйре, «Казан утлары» журналының мөхәррире (исеме);
22. Опера әсәре тексты;
23. Күрекле, клавишалы бик зур музыка коралы;
24. Таҗи Гыйззәт пьесасы;
25. Автор кулъязмасы;
26. Кыскартылган сүз (СССР, КПСС).

## ХИКӘЯ ЯЗА АЛАСЫЗМЫ?

Хикәя дип, хикәя үк түгел инде, хикәячек – күләме.. 1800 хәрефтән артмаска тиеш. Язуы да авыр түгел инде: түбәндәге өч вариантның берсен очлап кына куясы. Аның каравы, иң җилле әсәрчек яза алган өч автор мактаулы һәм саллы (саллылыгы ике кило авырлыкта булуда гына түгел!) «Сүнмәс утлар балкышы» дигән китап белән бүләкләнәчәк.

Менә ул башламнар:

1) Йокыдан уянып та җитмәстән Наилнең (Наиләнең) башына шундый бер уй килде...

2) Төн уртасы булгач, шәһәр автобуслары йөрми иде инде. Юл читендә берүзе басып торган Алия янына номерсыз машина килеп туктады...

3) Идел үзенә кирәкмәгән бөтен нәрсәне ярга чыгарып аткан. Камил (Камилә) «Fanta»дан бушаган шешә эчендә түгәрәкләп бөгәрләнгән конвертлы хат күреп өнсез калды...

---

***Журналыбызның узган санында, «Ак җилкән» сәхифәсендә басылган кроссвордның җаваплары.***

**Горизонтальдә:** 3.Алмаз. 6.Балык. 7.Равил. 8.Рабит. 10.Йозак. 12.Марка. 14.Ангар. 16.Монитор.

**Вертикальдә:** 1.Плакат. 2.Каурый. 4.Банан. 5.Китап. 9.Иләк. 11.Озон. 13.Рам. 15.Гер.

---

*«Ак җилкән»гә хат язу өчен адрес:*
*420066, Казан, Декабристлар ур., 2, «Казан утлары», «Ак җилкән».*
*E-mail: kazanutlari@telebit.ru.*

# «ТАТАР КЫЗЫ»—«ХӘЯТ ЮЛЫНДА»

Ниһаять, Гаяз Исхакый әсәрләренең бишенче томы дөнья күрде. Аны бөек әдибебезнең иҗат мирасын барлауда, тормыш юлын өйрәнүдә фидакарьләрчә хезмәт итүче Лена ханым Гайнанова әзерләгән. Бу эштә мөхтәрәм, милләтпәрвәр зат, Чирмешән районы хакимияте башлыгы Минсәгыйть әфәнде Шакиров матди ярдәм күрсәткән. Кереш мәкалә, искәрмә-аңлатмалар да Гайнанованыкы. Китапта Г. Исхакыйның туганнары хакында кызыклы мәгълүматлар, нәсел шәҗәрәсе дә бирелгән. Җыентыкны бик эчтәлекле фотоиллюстратив материаллар да бизәп тора. Китапка әдипнең мөһаҗирлек дәверендә иҗат ителгән әдәби язмалары урнаштырылган. «Өйгә таба», «Көз», «Локман Хәким», «Татар кызы», «Тәүбәгә килгән хатын»—проза әсәрләре; «Дулкын эчендә», «Җан Баевич» «Хәят юлында», «Олуг Мөхәммәд»—драма жанрында. Барлыгы—9 әсәр. Боларның инде төп өлеше XX гасыр ахырында, XXI йөз башларында «Зиндан» китабында, төрле гәҗит-журналларда, җыентыкларда дөнья күргән иде. Әмма хәзергәчә билгеле әсәрләрнең бирелешендә дә камилләшү күзәтелә. Әгәр дә, мәсәлән, «Локман Хәким» (1923) моңа кадәр русча тәрҗемәсе аша гына бирелсә, биредә ул оригинал телендә—татарча—тәкъдим ителә.




Яңа гына дөнья күргән бишенче җилднең аеруча бер кыйммәтле ягы шунда: анда Г. Исхакыйның моңа кадәр хәзерге татар укучысына ирешмәгән ике әсәре урнаштырылган. Аларның беренчесе **«Татар кызы»**, икенчесе «Хәят юлында» дип исемләнгән. Һәр ике ядкяр дә башта ук төрекчә язылган булса кирәк. Бу хакта автор үзе төзегән «библиография»дә дә искәртә *(Г. Исхакый. Зиндан. Сайланма проза һәм сәхнә әсәрләре.—К.: Татар кит. нәшр., 1991.—666-669 б.)*

Әдипнең мөһаҗирлектәге тормышы, эшчәнлеге хакында безнең моңа кадәр дөнья күргән китапларда [ а) Исхакый мөһаҗирлектә.—К., 1999.—84 б.; б) Гаяз Исхакыйның мөһаҗирлектәге иҗаты.—К., 2004.—368 б.] һәм күпсанлы мәкалә-язмаларда шактый гына фикер-күзәтүләр бар. Ә «Татар кызы» һәм «Хәят юлында» әсәрләре турында әлегә фәнни әдәбиятта мәгълүматлар күзгә ташланмады. Шуны истә тотып без биредә бу ике әсәр хакындагы уй-фикерләребезне генә бәян итәргә булдык.

«Татар кызы» (Tatarin kizi) әсәрен Г. Исхакый төрек телендә иҗат итә. Аның ахырында «Бетте, Истанбул, 5 сентябрь 1942» дип язылган. Автор үзе төзегән библиографиядә (1951) әсәрнең иҗат ителү вакыты дип «1943» ел күрсәтелгән һәм шунда ук «басылмаган» дигән искәрмә дә бар (Г. Исхакый Зиндан....., 666-667 б.). Әмма «Татар кызы» Истанбулда нәшер ителүче «Сон почта» исемле «көндәлек сәяси» гәҗитнең 1949 елгы 54 санында дөнья күрә (29 сентябрь—3 октябрь һәм 7 октябрь.—24 ноябрь). Бу хакта автор үзе дә белә: кызы Сәгадәткә 1949 елның 2 октябрендә язган хатында әсәрнең басылуы турында искәрмә бирә (531 б.). «Библиография»дә «Татар кызы»ның нәшер ителмәгән дип күрсәтелүе, мөгаен, аның китап рәвешендә басылмаганлыгын аңлатадыр. Л. Гайнанова искәртүенчә, бу әсәрнең «Сон почта»да дөнья күргән тексты төрек профессоры Исмәгыйль Төрекуглы тарафыннан табыла. (11 б.). Бишенче томга ул Рабит Батулла тәрҗемәсендә бирелгән (159-258 б.).

Мәгълүм ки, һәр әдипнең, кагыйдә буларак, иҗат теле бер була. Шуңа күрә ул башка телдә язган очракта да, төп теленә хас сыйфатларны, образлы фикерләү үзен-

чәлекләрен саклый. Бу канунияҭ татарның чын милли әдибе булган Г. Исхакый өчен аеруча хас. Үзе дә каләм остасы булган, татар һәм төрек телләрен дә яхшы белгән Р. Батулла бөек әдипнең уй-теләкләрен, кылган гамәлләрен, сурәтле фикерләү хосусиятләрен тирәнтен тоеп эш иткән, төрекчә текстны татар телендә мөмкин кадәр авторча, Исхакыйга тугрылык саклап бирергә тырышкан. Әсәрнең тел-стиле, сәнгати корылышы, аһәңе авторның көчле талантын, бай иҗади тәҗрибәсен янә бер мәртәбә раслап тора. «Татар кызы» бер тын белән укыла, мавыктыра. Ул мәгълүмати яктан, танып-белү җәһәтеннән дә игътибарга лаек. Бу китап спектакльләргә, теле һәм кинофильмнарга да соралып тора. Чөнки анда бүгенге кешенең дикъкатен җәлеп итәрлек гыйбрәтле язмышлар, укучыны уйландырырлык вакыйга-хәлләр шактый.

Бишенче жилднен керешендә һәм аңлатмалар өлешендә «Татар кызы»ның жанры, гәрчә авторның «роман» дигән искәрмәсе телгә алынса да, повесть *(бәян.—Х. М.)* дип билгеләнгән (11, 531 б.). Әмма үзенең төзелеше, эчтәлеге, идея-тематикасы белән бу әсәр автор үзе биргән роман атамасына туры килә.

Г. Исхакый үз әсәрләрен еш кына төп геройларына мөнәсәбәттә исемли: «Кәләпүшче кыз», «Бай углы», «Теләнче кызы», «Мөгаллим», «Мулла бабай», «Сөннәтче бабай» һ. б. «Татар кызы» да—шулар исәбеннән. Әмма бирედә әлеге атама кинрәк, кавеми төс ала. Бу аңлашыла да. Чөнки әсәрдәге төп вакыйга-хәлләр, нәкъ «Хәят юлында»гы кебек, XX йөзнең икенче чирегендә, Төркиядә, нигездә, Истанбулда бара. Башка этник мөхит, үзгә иҗтимагый-мәдәни жирлек. Авторның максаты—шушындый шартларда татарның асылын, менталитетын, сакланышын ачыклау, аның кыйммәтен билгеләү, абруен күтәрү. Нәкъ менә шуна күрә дә Г. Исхакый әсәргә шушы исемне бирә, яна гына балигълык яшенә житкән татар кызын үзәккә куя, аның язмышы аркылы үзен һәм укучыларны борчыган күп төрле мәсьәләләргә сәнгать теле белән җавап бирә. Ә бит «татар кызы» дигәне дә этник яктан яртылаш кына үзебезнең кавем кешесе. Әнисе—Мәлахәт ханым—Истанбулда элек-электән яшәгән төрек аксөякләре нәселеннән. Ул Казан якларыннан килеп Төркиядә университетта укыган, аннан бирედә торып калган мөһәндис (инженер) Вахит исемле татар егетенә кияүгә чыга. Эгоистик тәрбия алган бу яшь хатын бик теләмичә генә беренче баласын таба. Аңа Жаһидә исеме бирәләр. Икенче баласын булдырудан ул тәмам баш тарта. Юллар, күперләр, тоннельләр төзетеп йөрүче иренә тиешле игътибар юк. Мәлахәт ханым, аеруча аның әнисе, туганнары өчен Вахит бары тик мал, акча табу чыганагы гына. Ахыр чиктә гаилә таркала. Сабый яшендәге Жаһидә әбисе һәм әнисе тәрбиясендә үсә. Кызны этисе белән һич очраштырмыйлар, гәрчә ул даими рәвештә алимент түләп торса да, ул инде юк, үлде дип тә алдыйлар. Шулай итеп Жаһидә татарга, этисенә тискәре рухта тәрбия ала. Кыз лицейны тәгәлли, аның университетта уку омтылышы зур. Әмма әнисе «аксөякләр токымыннан булган», бай тормышлы Лотфый дигән кешегә кияүгә бирергә тели. Жаһидә «кыска буйлы, черек тешле», «хатыншак» табигатьле бу затны һич тә яратмый. Кызның бик тә кәефсез, күнеле төшенке чаклары. Нәкъ шундый вакытта Жаһидә көймәдә очраклы рәвештә 12-13 яшьләрендәге ике укучыны очрата. Сөем һәм Гөлчәчәк исемле бу кызлар үзләренең татар булуларын горурланып әйтәләр. Татарча «әти», «әни» сүзен дә белмәгән Жаһидәгә бу сүзләрнең мәгънәләрен аңлатып бирәләр. Ике арада шушындый сөйләшү булып ала:

«—Татар дигәнегез ул нәрсә тагын, барыбыз да төрек түгелмени?..—диде (Жаһидә).

Кечерәк кыз:

—Юк, безгә һәр жирдә «татар» диләр ... Без татарлыгыбызны яшермибез дә. Анабыз да, атабыз да татар,—диде.

Бу сабый кызларның самимилеге, ачык сүзле булулары Жаһидәнең хушына китте:

—Татар белән төрек арасында нинди аерма бар? Зинһар, аңлатып бирегезче,—диде Жаһидә.

Кече кыз:

—Татарлар икейөзле түгел. Алар тугры сүзле, тырыш инсаннар,—диде.

Олы кыз:

—Бераз кырыс, әмма бик самими кешеләр,—диде» ( 162-163 б.).

Жаһидә болардан үзе өчен «өр-яңа нәрсәләр» ала (163 б.).

Шунысы гаҗәп: Жаһидә, танышларына кунакка баргач, тәрәзәдән күршедәге бакчада бер гаиләне күреп ала, алар арасында көймәдә очраткан теге ике кыз да була.

Ата-анадан, ике кыз һәм ике малайдан торган бу гаиләнең эш-гамәлләре, сөйләшләре, жыр-биюләре Жаһидәнең күңелен тәмам биләп ала. Шунда ул эчке бер тоем белән үзалдына «Бу мөһәндис минем татар атам булмасын тагы!»—дип куйды. «Тик бу бик культуралы адәм. Минем атам кара татар, тәрбиясез, әхлаксыз бер бәндәдер» (168 б.).

«Минем атам шушы адәм түгелме?» уе кызның бөтен күңелен биләп ала. Шуңа җавап эзләп ул өйдәге иске язулы хатларны укый башлый. Кыз алдында бөтенләй икенче дөнья ачыла. Хатлардан атасының олы җанлы, кайгыртучан, тырыш, катлаулы язмышлы шәхес булуы, әнисенең, әбисенең икейөзлелеге ачыклана. Бу уңай белән автор, персонажга кушылып, болай яза: «Дөрес булмаган тәрбия» аша кергән атасына карата булган нәфрәте олы хөрмәт вә мәхәббәткә әверелде дә куйды, анасына ... олы үпкә пәйда булды...» (183 б.).

Жаһидәнең эчке тоемы алдамый: күрше бакчадагы гаилә башлыгы аның әтисе булып чыга. Ата белән кызның очрашуын автор гаять тәэсирле, күзләрдән яшьләр чыгарлык итеп тасвирлый (187 б.).

Вахит Мәлахәт белән аерылгач, «Искешәһәрдәге бер татар докторының Хәдичә исемле» кызына өйләнә. Төрле урыннарда эшли. Үзе, гаиләсе күп кыенлыклар күрә. Хәзер тормышы көйләнгән. 4 баласы бар. Гаиләдә аңлашу, дустанә мөнәсәбәт, татар рухы.

Әтисенең гаиләсе белән Жаһидә бик тиз уртак тел таба. Аны балалар да, Хәдичә ханым да үз һәм якын итәләр. Әтисенең исә куаныч-шатлыклары тулып ташкан. Мәгълүм ки, Г. Исхакый хатыны белән бик аз вакыт кына яшәп ала. Гомер буе тулы канлы, күп балалы гаиләгә кызыгып яши. Аның мондый халәте бу романында да билгеле бер гәүдәләнеш тапкан. Жаһидәнең ахыр чиктә әтисен табуы, ата белән кызның эчкерсез мөнәсәбәтләре ирексездән Исхакый белән кызы Сәгадәт язмышларын да өлешчә искә төшерә.

Жаһидә атасында, аның гаиләсендә үзен борчыган күп сорауларга җавап таба. Вахит кызына яратмаган кешегә кияүгә чыгуның урынсызлыгын искәртә, университетта укуның кирәклеген, әнисе белән дә табигый мөнәсәбәтләр сакланырга тиешлеген әйтә килә.

Жаһидә әтисенең, аның җәмәгатенең күп кенә танышлары (алар, нигездә, мөһаҗир милләттәшләребез) белән аралаша, алардан төрле мәгълүматлар ала. Шулай итеп, автор татарлыктан бөтенләй читтә торган, кан ягыннан ярты төрек булган кызның эчке үзгәрешен, чын мәгънәсендә татар баласына әверелә баруын төрле сәнгати чаралар ярдәмендә гәүдәләндерүгә ирешкән.

Романдагы күпчелек вакыйга-хәлләр, күренешләр Жаһидә карашы, яшь кызның эчке кичерешләре катнашында бирелә. Мондый алым әсәргә билгеле бер күңел җылылыгы, өлешчә романтик аһәң дә өсти. Билгеле булганча, азык-төлек—милли асылның мөһим бер кыйсеме. Мөгаен, шунадыр Г. Исхакый үз романында ризыклар әзерләүгә, ашау-эчү әйберләрен тасвирлауга зур урын бирә. Коймак, пәрәмәч, пылау, пилмән, балан бәлеше, кыстыбый, сумса һәм башка төр ризыкларны күреп, аларны ашап Жаһидә үз халкына тагын да якыная төшә. Татарның чәй яратуы, аны тәмләп эчүе дә әсәрдә күп мәртәбәләр сурәтләнә.

Яшь кызны татарга якынайтуда, аның рухын миллиләштерүдә аеруча халкыбызның җыр-моңы, әдәбияты зур роль уйный. Вахитләр гаиләсендә «Кара урман», «Туган илкәем», «Әпипә», «Галиябану» җырлары, Тукай, Гафури шигырьләре еш яңгырап тора. Мөһаҗирлектәге милләттәшләребез арасында бигрәк тә С. Рәмиевнең «Сызыла, күңлем» шигыре яратып укыла һәм җырлана. «Бу шигырьнең көе,—диелә әсәрдә,—гасырларча елаган бер халыкның гасырларча кичергән кайгы-хәсрәтенең чагылышы иде» (235 б.). «Шушы бер шигырь шагыйрьнең исемен мәңгеләштерде» (247 б.). Вахитнең балалары өйдә, әниләре җитәкчелегендә, татар телендә «тарих, әдәбият, дин дәресләрен өйрәнә» (190 б.). Өлкәннәр Жаһидәгә, татар телен үзләштерү өчен, «Казан әдәбияты»н укырга киңәш итәләр. «Казан шивәсе»нең, ягъни татар теленең «халыкларның (төркиләрнең.—Х. М.) күбесенә аңлашыла торган бик бай шивә» булуы искәртелә (229 б.).

Г. Исхакыйның бу романы мөһаҗирлектәге, иң беренче чиратта, Төркиядәге милләттәшләребезнең язмышы турындагы әсәр дә. Жаһидәнең бу мәсьәлә белән кызыксынуын күреп, бер мәҗлестә «Доктор бәй» дип йөртелгән милләттәшебез гыйбрәтле генә мәгълүматлар китерә. Аның фикеренчә, «Идел-Урал»дан Төркиягә «берничә йөз укучы» җыела (223 б.).

Аларның максаты—гыйлем алып, һөнәр үзләштереп, илгә кайту, үз халкына хезмәт күрсәтү. Вахит, мөгаллим Салих, «Доктор» һәм башкалар да шулар арасында. Әмма дөнья сугышы, инкыйлаблар башлангач, юллар киселә. Ике ут арасында калган бер төркем татар студентларыннан Төркия полициясе «шпион» дип сораулар да ала. Ахыр чиктә алар бу илдә кала. Ә инде Ватанга кайтканнарның күпчелеге юкка чыгарыла. Төркиядә калган милләттәшләребез, күп төрле кыенлыклар күреп булса да, тырышып эшли, яшәгән иленә файда китерә, кайберләре бу мәмләкәтнең бәйсезлеге өчен көрәштә гомерен дә бирә. Әмма еш кына аларга күп мәртәбәләр артыграк тырышырга туры килә. Бу унай белән «Доктор бәй» болай ди: «Минем мондагы жирле доктор-кәсептәшләрем авыруны бер караганы өчен өч лира алганда, мин бер лира алам... Атаның мөһәндис аркадашлары көнгә ике-өч сәгать эшләгәндә, атаң унике сәгать эшли. Мөгаллим Салих, егерме еллык тәжрибәле әдәбият мөгаллиме, Анадолуның иң ерак почмакларында төрек әдәбияты укыта ... Бәһасез могжизалар булдыра ала торган инсаннар (ягъни татар белгечләре.—Х. М.) ... кечкенә бер ялгыш-хата жибәрәләр икән, аларны урыннарыннан куалар» (226 б.).

Инде берничә дистә ел узуга карамастан, мөһажир милләттәшләребез Идел-Уралга кайту турында хыялланалар. «Без,—ди Хәдичә ханым,—һаман мәмләкәтебезгә кайтып китү уе белән янабыз» (190 б.). Шул ук хатын иренең дуслары хакында: «Монда утыз ел яшиләр инде. Әмма кунакханәдә яшәгән кебек яшиләр»,—ди (217 б.). «Бөтен нәрсә сине хәтерләтә»,—дип жырлыйлар хәзер. Шуның кебек мөһажир милләттәшләребезгә Төркиядәге табигать тә «Ослан» тауларын, «Дим елгасының Агыйделгә кушылган жир»ләрен искә төшерә. Аларны төп Ватан, жирсү хисләре берләштерә.

«Татар кызы» романында Төркиягә караш бер генә төрле түгел. Бер яктан, татарларның бу илгә тугрылыгы, ватанпәрвәрлеге, фидакарьләрчә хезмәт итүләре хуплана. Моның ачык бер мисалы—Жаһидәнең әтисе Вахит ... «Төркиядә,—ди ул,—эшләгән кешегә мәйдан бар. Эшләгәннәр тапсын, яшәсен... Әрәм-тамак булып, типтереп яшәү, дөньяны таныргa, үзеңне белергә комачаулый» (174 б.). Икенче яктан, бу илне тәнкыйтьләү дә бар. Истанбулдагы әхлаксызлык, аеруча аксөякләрнең ярамаган эш-гамәлләре кат-кат телгә алына. Бу шәһәр халкында мәмләкәтнең Анадолу өлешенә түбәнсетеп карау да бар икән. Андагы, аеруча авыллардагы пычраклык, артталык та искәртелә. Бер мәжлестә төрек әдәбияты хакында сүз чыга. Укымышлы гына бер татар кешесе тарафыннан Төркия халкы космополитизмда тәнкыйтьләнә. «Бирердәге театр әсәрләренең барысы да,—ди ул,—французчадан, инглизчәдән, алманчадан тәрҗемә яки күчермәләрдер, аларның һичбер милли төсе, милли тәме юк. Китапчыларга барып карасаң, йөздән туксаны тәрҗемә! Аларның барысы да рухан һәм мәгънәви яктан ят әсәрләрдер» (247 б.). Әлбәттә, бу төр фикерләр бәхәсле. Әмма аларда теге яки бу дәрәҗәдә хаклык та бар.

Мәгълүм ки, төрек һәм татар халкын этник һәм тел якынлыгы, күп кенә рухи кыйммәтләрнең уртаклыгы берләштерә. Төркия аркылы без Шәрык һәм Гарәбнең шактый гына рухи казанышларын үзләштердек. Бу мәмләкәт күп кенә милләттәшләребезгә уку, яшәү өчен мөмкинлекләр бирде. Болар арасында Г. Исхакый үзе дә бар. Шуна күрә романдагы тәнкыйди мотивлар гомумән Төркиягә түгел, ә андагы аерым кимчелекләргә, житешсезлекләргә юнәлтелгән дип кабул ителә. Бу хакта романда да искәртелә: «Безнең тәнкыйть исә чын күңелдән, Төркиягә игелек теләгәнлектән эшләнә» (226 б.).

Госманлы мәмләкәтенең әдәбияты бездә үзебезнең милли ядкярләр кебек укылды. Романда да бу хакта кайбер фикерләр әйтелә. Бер әңгәмә вакытында төрек шагыйре Мөхәммәд Чәләбинең атаклы «Мөхәммәдия»се (1449) хакында сүз чыга. Шунда бер татар зыялысы болай ди: «... Без, безнең бөтен туганнарыбыз, бабаларыбыз, аналарыбыз бу китап өстендә никадәр күз яше түктек. Никадәр татлы мизгелләр уздырдык» (223 б.).

Гомумән, романда татар-төрек мөнәсәбәтләренә кагылышлы шактый гына факт-мәгълүматлар бар. Татарлар беренче дөнья сугышында әсир төшкән «утыз меңнән артык төрекне тәрбия кыла» (248 б.). Олы жанлы Хәлимә ханым төрек балаларына белем-тәрбия бирү белән бергә, бу илнең йөзәрләгән кешесен бушка диярлек дәвалап, үлемнән дә коткарып кала. Юкка гына аны, доктор буларак хөрмәтләп, «Татар апасы» дип йөртмиләр (240-242 б.). Бу

ханымның фидакарьлеге чын мәгънәсендә сокланырлык.

Әйткәнебезчә, әсәрдәге күпчелек вакыйга-хәлләр Җаһидәгә мөнәсәбәттә, аның катнашында бәян ителә, эш-гамәлләр бу яшь кызның карашы аркылы бәяләнә. Шуның нәтиҗәсендә төрле урыннарда һәм елларда барган вакыйга-хәлләр бергә оеша, эчке бер хронологик бөтенлек туа. Хатлар белән танышу, кием сайлау, альбом карау, бизәнү әйберләре алу, тарихи-публицистик чигенешләр әсәрнең төп аһәңе белән яраклашып торалар. Автор үз геройларының, аеруча Җаһидәнең рухи халәтен, күңел тибрәнешләрен гәүдәләндерүгә житди игътибар итә. Әтисе белән әнисе язган хатларны укыгач, кызның күңеле тәмам кузгала, күзенә йокы керми. Иртән ул диңгездә су коена, аның «күңеле тынычлана», «зиһене ачыла» (186 б.). Бу коену Җаһидәнең элеккеге рухи халәтеннән янасына күчү, сыйфади үзгәреш акты, күренеше рәвешендә дә кабул ителә. Әсәр Вахитнең элеккеге хатыны Мәлахәт белән хәзерге җәмәгате Хәдичәнең үзара сөйләше, аңлашуы белән төгәлләнә. Биредә авторның мондый хәлдәге хатын-кызларның психологиясен тоюына, аларның рухи халәтен оста итеп гәүдәләндерүенә сокланырга гына кала.

Г. Исхакыйның башка әсәрләрендәге кебек, бу романында да урынлы һәм оста кулланылган детальләр, сурәтләр, этнографик һәм көнкүреш элементлары шактый еш очрый: пилмәннәрне «ак җәймә капланган бер төпсә өстенә гаскәр кебек рәт-рәт» тезү (168 б.); «Беренче хатны ул (ягъни Җаһидә.—Х. М.), эссе көндә сусаган инсанның су эчкәне кеби, бер тын белән укып чыкты» (170 б.); Безнең тәнкыйть «күз яше белән чыккан әче аһ-зардыр» (226 б.) һ. б. Әсәрдә самавыр кую, чәй эчү еш телгә алына. Сүнә башлаган самавыр башына итек кигезеп, «тимерче алачыгындагы кебек итеп», аны «күреклиләр» (165 б.).

Романның төп каһарманына юкка гына Җаһидә исеме бирелмәгән. Гарәп телендәге бу сүз берничә мәгънәне белдерә: тырыш, эшлекле, хезмәт сөючән, иҗтиһад итүче ... Димәк, шушындый сыйфатларга ия булган хатын-кызларыбыз яшәгәндә милләтебезнең киләчәге бар. Галәттә, хатын-кызларны, аеруча Җаһидә яшендәге кызларны сурәтләгәндә мәхәббәткә зур урын бирелә. Биредә әле төп каһарман андый халәттә тасвирланмаган. Әмма һич шикләнүсез әйтергә мөмкин: Җаһидәгә дә олы, саф мәхәббәт киләчәк; татар җанлы бу кыз да гаилә корып, милләт тарихында үзенең эзен калдырачак! Авторның бу иман-ышанычына без дә кушылабыз.

**«Хәят юлында»**. Автор бу әсәрен 1946 елда тәмамлый. Төрек телендәге әлеге язманың бер битендә авторның мондый искәрмәсе бар: «Бу әсәрем «Яна чак» («Яна заман») мәҗмугасының февраль аеннан башлап кушымта буларак нәшер ителде һәм дә Истанбул шәһәр театрына бирелде. (541 б.). Мәҗмугада әсәр «Модерн хәят юлында» исеме белән басылган. Бишенче томда язма төрек теленнән татарчага Рәшит Кадыйров тәрҗемәсендә бирелгән.

«Хәят юлында»—драма әсәре. Әйткәнебезчә, автор аны Истанбул шәһәр театрына да тәкъдим иткән. Әмма аның сәхнәләштерелүе хакында хәзергә мәгълүматлар юк.

«Хәят юлында»—шактый күләмле (64 бит) пьеса; анда катнашучылар да ике дистәгә якын. Ул биш пәрдәдән гыйбарәт. Жанры белән бу язма әхлакый-социаль эчтәлектәге драмага тартым. Вакыйга-хәлләр узган гасырның икенче чирегендә Истанбулда бара. Мәгълүм ки, бу «мәңгелек шәһәр» Г. Исхакый өчен шактый үз. Мона кадәр дә күп мәртәбәләр булган һәм яшәп алган әлеге калада ул гомеренең ахыргы дистә елдан артыгын уздыра.

Драманың үзәгендә—лицей мөгаллиме 50 яшьләрдәге Сабри Алтынбай һәм аның хатыны Мәлахәт. Урта хәлледән түбәнрәк тормыш алып баручы бу гаиләнең Зөхтү исемле уллары һәм Сабахат атлы кызлары бар. Өченче дистәне ваклап баручы бу кыз белән егетнең һәр икесе дә университетта белем ала. Драмадагы башка персонажлар (Зөхтү белән Сабахатның иптәш студентлары, сөйгән ярлары һ. б.), нигездә, шушы гаиләнең язмышына мөнәсәбәттә гәүдәләндерелә. Пьесада күзгә бәрелеп торган кискен, киеренке вакыйга-хәлләр юк. Төп конфликт бурыч һәм вазыйфа, аталар һәм балалар каршылыгына корылган. Сабри белән Мәлахәт бөтен көчләре, тырышлыклары белән угыл-кызларын тәрбияләп үстергән; алар университет белеме алсын дип җан аталар. Ә Зөхтү белән Сабахат үз мәнфәгатьләрен генә кайгыртыалар, ата-аналарына «сез тиешле», «сезнең ата-аналык бурычыгыз» дигән таләпләрне куеп кына торалар, аларны искелектә, заманны аңламауда гаеплиләр. Боларның «модерн хәят»

кору турындагы теләкләрен иптәшләренең дә бер өлеше хуплый, әмма икенчеләре каршы килә. Бу да әсәрдәге эчке каршылыкны көчәйтә. Ә инде «модерн» карашта торган Зөхтүнең нәкъ шул вакытта Пакизәгә өйләнергә җыенуы, Сабахатның Йосыф Янартауга кияүгә чыгарга карар кылуы вакыйга-хәлләрне тагын да кискенәйтә. Яшьләр вазыйфаларын онытып, һаман да тегесен-бусын таләп итеп кенә торалар. Ә ата-ананың аларның ихтыяҗларын канәгатьләндерергә мөмкинлекләре юк. Егет өйләнеп, кыз кияүгә чыгып, ата-аналары хисабына яшәүләрен дәвам итәләр. Шулай бер ел вакыт узып китә. Куанычка каршы, Зөхтүнең хатыны Пакизә, гаиләдәге авырлыкны күреп, әти-әнисенең хәленә керергә, аларга булышырга тырыша.

Драмада Йосыф Янартау исемле үзенчәлекле бер тип бар. 30 яшьләрдәге бу зат бөек шәхесләрнең (Дарвин, Ленин, Шопенһауэр, Лассаль, Толстой, Виктор Гюго...) сүзләрен китереп сөйләшергә ярата, моңа кадәр урнашкан тормыш кануннарын, яшәү рәвешен, гадәт-йолаларын кире кага; «модерн хәят» төзү—аның төп теләге. Бу кешенең купшы сүзләре, үзен «оригиналь» тотуы Сабахатның да башын әйләндерә. Кыз фикеренчә, егет «Йосыф пәйгамбәр шикелле гүзәл, «янартау кебек тормыш рухы бөркеп тора», ул «гали бер шәхес...»(388 б.). Әмма ахырга таба Йосыф Янартауның «Измир шәһәрендә автобус контролеры» булып эшләгән, ике баласы белән хатынын ташлап киткән алдакчы бер «чегән», автор сүзләре белән әйткәндә, «авантюрист» икәнлеге ачыклана. Драма ахырында Сабахат та үзенең алдануын белеп, «һушы китеп егыла». Шулай итеп, аерым затларның «модерн хәят» кору планнары, тормыш тәҗрибәсен искә алмау, әхлаксызлык, зәминсезлек аркасында, сабын куыгы кебек шартлый.

Сорау туа: ни өчен соң моңа кадәр татар турында язган, аның яшәү рәвешен, теләк-омтылышларын гәүдәләндергән Г. Исхакый бу әсәрендә төрек тематикасына мөрәҗәгать иткән? Ә бит ул нәкъ шушы елларда үзенең атаклы «Олуг Мөхәммәд» драмасын яза. Димәк, автор эволюцион үзгәреш кичермәгән. Бәлкем, матди як әдипне төрек театры өчен пьеса язарга мәҗбүр иткәндер. Бу фаразны да кире кагып булмый. «Хәят юлында» драмасында, күргәнебезчә, чын төрек язмышы гәүдәләндерелә, хәтта исем-атамалар да төрекчә. Әсәрдә татар сүзе дә күзгә ташланмый. Әмма, ныклабрак уйлап караганда, Г. Исхакыйның бу пьесасы да әдипнең гомуми иҗаты белән керешеп китә. Автор төрек материалы нигезендә татар өчен дә мөһим булган мәсьәләләрне хәл итәргә тырыша. Г. Исхакый карашынча, әхлаклылык, әдәп, намус-вөҗдан, иман һәр инсанның, гаиләнең, җәмгыятьнең асылында булырга тиеш; һәртөрле тәрәккыятнең моңа кадәр тупланган инсани, әхлакый тәҗрибәгә нигезләнүе шарт.

Мәгълүм ки, аталар һәм балалар, гаилә, бурыч һәм хокук проблемалары Октябрь инкыйлабына кадәрге татар әдәбиятында, шул исәптән Г. Исхакый иҗатында да мөһим урын биләп торды. 20-40 елларда «искелекне» кире кагу, яңа тормыш, «модерн» җәмгыять төзү күп кенә әдипләрнең иҗатында күзгә ташлана. Нәкъ шушы чорда марксизм-ленинизм тәгълиматы, социалистик идеяләр белән билгеле бер дәрәҗәдә мавыгу төрекләр өчен дә чит түгел (Назыйм Хикмәт иҗаты—шуларның бер үрнәге.). Г. Исхакыйның әдиплек тоемы, бай тормыш һәм әдәби тәҗрибәсе һәм төрек, һәм татар яшәешенә хас булган бу мөһим проблеманы үз әсәрендә үтемле һәм сәнгати югарылыкта яктыртуга этәргән. Тышкы шәкеле, исемнәре, тормыш материалы белән төрекчә булган «Хәят юлында» драмасы шулай итеп, төрек өчен генә түгел, татар ихтыяҗларына да авазлаш бер әсәр булып чыккан.

***

Г. Исхакый язмаларының бишенче томы дөнья күрү, аеруча моңа кадәр Идел-йорт укучыларына таныш булмаган әсәрләренең басылып чыгуы—рухи-мәдәни тормышыбызда зур вакыйга. Алар әдипнең тормышын һәм иҗатын тагын да баета, күнелебезне күп кенә яңа мәгълүмат, мотивлар белән тулыландыра, зиһенебезне кузгата. Шулай ук бу әсәрләрнең танып-белү ягыннан, татар-төрек багланышларын өйрәнү җәһәтеннән дә әһәмиятләре зур.

**Хатыйп МИҢНЕГУЛОВ**

## Тотып ярырлык итмәдек

Китте замана... Әйтик, сез шәһәрдә яшәсәгез йортлар идарәсе түрәсенә, авылда яшәсәгез—район хакиме янына уптым гына барып керә аласызмы? Ай-һай! Ә без теге чакларда кызыл билетны күрсәтеп, партия, Хөкүмәт һәм Югары Совет органнарына бик ансат керә идек.

...Эреләндерелгән Саба районында дүрт битле гәзит чыгару мәсьәләсе кузгатылгач, мине, яшь журналистны, партия өлкә комитетына чакырып китерделәр. Бүлекләрдә кыскача әңгәмә ясадылар. Эшкә билгеләп, кулыма юллама да тоттырдылар. Соңгы үгет-нәсихәт өчен партия өлкә комитетының икенче секретаре Салих Гыйлемхан улы Батыевка (ул идеология эшләренә җаваплы иде) алып керделәр.

—Синмени инде ул Гумеров?—дип гаҗәпсенде түрә.—Артык яшь, минемчә. Ну, ярар. Язганнарыңны укып барам. Тик син, малай, кара аны, кая барганыңны чамала. Сабалар укымышлы, культуралы халык. Тәртипле йөр! Кызларына кагылсаң, үзем тотып ярырмын!..

Менә шулай диде Салих ага. Һич арттырусыз әйтәм. Теләсәң ничек аңла!.. Байлар Сабасында өч ел эшләү дәверендә үземне ничегрәк тотканмындыр—анысы онытылган инде. Узган эшкә салават. Ун елдан соң кабат очраштык Батыев белән. Ул инде ТАССР Югары Советы Президиумы Рәисе иде. «Социалистик Татарстан» гәзитенең 50 еллык юбилеен билгеләп үткән көннәр. Җаваплы редактор (ул чакта шулай аталды) Шәмси Хамматов югарыдагы кайбер җитәкчеләргә гәзитнең юбилей уңаеннан Мактау грамотасын тапшыруны ни өчендер миңа йөкләде. Барып кердем түрә бүлмәсенә. Булдыклы кешеләрчә сәламемне җиткердем. Тагын да батыраеп китеп:

—Салих Гыйлемханович кешеләргә Мактау грамотасын күпләп өләшә. Бүген үзенә дә тапшырып карыйк әле,—дип, түргә үк уздым.

—Кара, син теге Гумеров түгелме соң?—диде бу, танып.

—Әйе, Гумеров, ләкин уртага бөгелә торганы түгел,—дим, үземчә шаяртып.

—Вәт наян! Бөгәрсең сезне. Йә, ничек анда? Саба кызлары елап калмадымы артыңнан?—Теге чактагы сөйләшүен онытмаган икән.

Алга таба язып тормыйм. Дәүләт бинасында иң кәттә түрәләрнең берсе белән бик тә күңелгә ятышлы әңгәмә булды. Юбилей грамотасын үземчә шәп итеп тапшырдым.

—Шулай да чибәр бит Саба кызлары!—диде Салих Гыйлемханович саубуллашканда.

*«Саба кызын сөяр булсаң,*
*Онытырмын диеп уйлама»,—*

дип, мин дә мәгълүм җыр юлларын кабатладым...

## Сәркәтиб кенә димә...

Бауман урамы. Матбугат йорты. Бишенче кат. Язучыларның Г. Тукай исемендәге клубы. Өске каттагы китапханә бүлмәсе. Китаплар белән мәш килеп ятам. Ишектән минем хәтле генә кыска буйлы, чандыр гәүдәле, шомырт кара чәчле, ак йөзле, бик

тә фырт киенеп йөрүче, беркадәр дан-шөһрәт һәм хакимлек яратучы язучы Газиз Иделле (үз фамилиясе Усманов) килеп керде. Утлы күмергә баскандай дерт итеп китте.

—Бу ни бу?!

—Госман ич,—диде китапханә мөдире, балалар язучысы Әминә апа Бикчәнтәева.—Бибколлектордан үзем сорап алып мендем. Китапларны квалификацияли менә.

—Никтер раслатмадың, Әминә,—дип кисәтүне кирәк тапты Язучылар берлегенең партоешма житәкчесе Г. Иделле.

—Ни бит, Газиз, Госман безнең штатта тормый, миңа булыша. Рәхмәт әйтик егеткә!

Хакимлеген күрсәтергә теләде, ахрысы, сәркәтиб. Шулай да шәп кеше иде Газиз Иделле. Кара кәчтүм, ак яка дигәндәй, бик ыспай киенеп, вәкарь белән генә йөрүче язучы яшь авторларга аеруча игътибарлы булды. Тикмәгә генә Язучылар берлегендә фирка сәркәтибе итеп сайламаганнардыр инде үзен. Ә сәркәтибләр кылана белде ул заманда.

## Хәнәви кем дә, майор кем?

Хәзер артистлар бушка жырламый. Ул заманда, уракчыларга концерт бирегез, дип филармония аларны төркем-төркем итеп авылларга чыгара иде. Зөһрә Сәхабиева бригадасы Тәтеш районына туры килгән. Элекке район үзәге Олы Тарханга капкаларга афишалар ябыштырылган. Артистлар килгән, ә каршы алучы юк. Үзләре ач. Инде сәгать төнге уннар тирәсе. Аптыраган болар. Миңа юлыгуларына куандылар. Журналист кеше бит. Колхозның партком секретаре иптәш Ышна (гажәпләнмәгез, ата-бабасыннан килгән фамилиясе шулай) белән хужалык рәисенең өенә киттек. Бөркү кичтә ишекләрен шар ачып, йокларга жыенып йөри. Куптардык тегене тәки. Халыкны жыеп, 2 сәгать буе концерт куйдырдык. Соңыннан мин «Сандугачларны да көнләштерделәр» дигәнрәк баш астында гәзиткә дә язып чыктым.

Сыйлау димим, артистларны ашатмадылар да. Әнә, Зөһрә үзе шаһит. Район үзәгенә алып кайтып, кунакханәгә урнаштырдым, төнге ризык белән сыйладым боларны. Чын дуслыгыбыз шул көннән башланды Хәнәви Шәйдуллин белән. Дуслыкның кадерен белә торган инсан иде, мәрхүм. Дөнья нужасы (бала чагыныкы) бик иртә алып китте үзен.

...Тегенең белән Идел буе районы милициясендә очраштык бер көнне. Төсе качкан. Нидәндер шүрли, ахрысы.

—Нишлисең монда?—дип сорыйм.

—Менә чакырдылар,—ди.—Үз акчама сыра эчим дип, чиратсыз алданрак баскан идем. Тотып китерделәр. Бүген штрафка чакырдылар кабат. 7 яшемнән бирле интектерә шушы кавем.

—Көтеп тор шушында,—дим.

Кереп киттем бер бүлмәгә, майорның үзенә.

—Минлехан энем,—минәйтәм,—тегендә Татарстанның халык артисты Хәнәви Шәйдуллин (ул чакта әле анын мондый исеме юк иде) калтырап тора...

—Беләм,—дип бүлә майор сүземне.

—Алайса, ник тоткарлыйсың?

—Бездә тәртип...

—Ә намус дигәнең кайда?

—Ну-у...

—Хәзер үк чык та гафу үтен үзеннән. Кайтарып жибәр артистны.

Котылды Хәнәви.

—Ну, малай, бар икән үзендә куәт,—дип шаккатты Хәнәви дустым.

Жырчыга майорның безнең авыл малае икәнен әйтеп тормадым.

## Ictimagi-mədəni tormışıbızdan
## Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан

### КАЗАН—УФА. ДУСТАНӘ МӨНӘСӘБӘТЛӘР

Татарстан Президенты Рөстәм Миннеханов республика җитәкчесе вазифасында беренче тапкыр Башкортстан башкаласына эшлекле сәфәр кылды.

Р. Миңнеханов визит барышында иң әүвәл «Биатлон» спорт-сәламәтләндерү үзәген карады. Аннары ике республика җитәкчесе Башкортстан Президенты чыршысында булды. «Бүген сездә бәйрәмдә берьюлы ике Рөстәм, бу—бәхеткә»,—дип шаяртты Татарстан Президенты, чыршы бәйрәмендә катнашучыларга мөрәҗәгать итеп. Ул Уфаның I нче балалар йортына бүләк—«Fiat Ducato» микроавтобусы тапшырды. Кунаклар «Уфа моторлар төзү-җитештерү берләшмәсе» ААҖдә дә булырга өлгерде.

БР Хөкүмәте йортында ике төбәк җитәкчесенең рәсми очрашуы узды. Татарстан белән Башкортстан бергә ике республика арасында транспорт элемтәсен үстерүдә эшләячәк. «Казан белән Уфа арасында автомобиль юлы кирәк»,—дип ассызыклады ТР Президенты. Ике республика арасында товар әйләнеше 30 млрд сумга җитәргә мөмкин. Әнә шундый бурыч куелды ике Президент очрашу вакытында. Очрашу нәтиҗәсе итеп сәүдә-икътисади, фәннитехник, социаль һәм мәдәни хезмәттәшлек турындагы килешүгә һәм ике республика арасында хезмәттәшлекне үстерү буенча чаралар планына кул куелды.

Р. Миннеханов белән Р. Хәмитов очрашу ахырында Этнографик тикшеренүләр институтының археология һәм этнография музеенда, шулай ук «Нур» Уфа Татар дәүләт театрында булдылар.

***

Татарстан һәм Башкортстан закон чыгаручылары парламентара элемтәләрне киңәйтү, ныгытуга йөз тотып эшләячәк. Уфада ике республиканың парламент башлыклары—Фәрит Мөхәммәтшин һәм Константин Толкачев Татарстан Дәүләт Советы белән Башкортстан Дәүләт Җыены—Корылтае арасында алга таба хезмәттәшлек итү турында беркетмәгә имза салды.

Башкортстан парламенты башлыгы Константин Толкачев, Татарстаннан килгән коллегаларын сәламләп, инде күп еллар буе үзенең һәм Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшинның теге яки бу мәсьәләләр буенча карарлар кабул итүдә гамәлләрен бергәләшеп җайга салуын әйтте. «Ике республиканы географик күршелек, халыкларыбызның бердәй мәдәнияте һәм телләре, инде Советлар Союзы чорыннан ук саклanып килүче халык хуҗалыгы комплексы кысаларындагы элемтәләр якынайта»,—дип билгеләп үтте К. Толкачев.

Спикерыбыз Фәрит Мөхәммәтшин, үз чиратында: «Күп мәсьәләләр буенча фикерләребез туры килә. Һәм башка бер генә субъект белән дә мондый тыгыз элемтәләребез юк»,—диде.

Шул ук көнне Башкортстан Президенты Рөстәм Хәмитов Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин белән очрашты. Очрашуда ике республика арасындагы хезмәттәшлекне алга таба киңәйтү-тирәнәйтү мәсьәләләре турында сүз барды.

### КАЗАН МЭРЫ—ПРЕЗИДЕНТТАШ

Россия беренче мәртәбә Берләшкән шәһәрләр һәм җирле хакимиятләрнең бөтендөнья оешмасы президентташы булып сайланды. Оешманың президенты—Истанбул мэры Кадыйр Топбаш, президентташ Казан мэры Илсур Метшин булды. Әлеге оешманың Мехикода узган Бөтендөнья саммитына бөтен дөньядан 3000гә якын муниципалитет җитәкчесе һәм халыкара оешмаларның билгеле эшлеклеләре җыелган иде. Алар җирле хакимиятләрнең актуаль мәсьәләләре буенча фикер алышты. «Мондый саммитта катнашу теләсә кайсы мэр өчен мөһим вакыйга. Россиянең Казан йөзендә әлеге оешманың президентташ булып сайлануы минем өчен мактаулы»,—диде мэр И. Метшин.

### ПОЛЯКЛАРГА РӘХМӘТ СҮЗЕ

Польшада татарлар хөрмәтенә һәйкәл куелу уңаеннан, ТР Дәүләт Советы Польша Президенты Бронислав Коморовскийга, Сенат Маршалы Богдан Борусевичка, Сейм Маршалы Гжегож Юлиуш Схетынега һәм Польша халкына мөрәҗәгать әзерләде.

Мөрәҗәгатьтә татарлар хөрмәтенә һәйкәл куелуның поляк һәм татар халкы арасында күпгасырлык традицияләрнең һәм яхшы элемтәләрнең дәвамы булуы билгеләп үтелә. «Татарларның поляк халкы һәм Польша дәүләте каршындагы тари-

хи казанышлары Польша Республикасы Президенты Бронислав Коморовский тарафыннан югары бәяләнүе өчен Татарстан Республикасы һәм бөтен татар халкы зур рәхмәт белдерә»,—диелә мөрәҗәгатьтә.

Һәйкәл кую уңаеннан оештырылган чараларда Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты рәисе Ринат Закиров, Татарстан Республикасының Санкт-Петербург һәм Ленинград өлкәсендәге даими вәкиле Шамил Әхмәтшин, М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театры һәм Г. Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе солисты Владимир Васильев һәм «Татарстан—Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе журналисты Ләйсән Садретдинова катнашты. Ринат Закиров сүзләренчә, алар Польшага Татар мәдәнияте халык үзәге чакыруы буенча барган. Анда Литвадан, Финляндиядән, Украинадан, Россиядән һәм башка илләрдән татарлар булган. «Польша Президенты татарлар турында бик җылы сүзләр әйтте, татарларның 600 ел эчендә Польшаны яклаучылар арасында булуын билгеләп үтте. Аларның яшь поляклар өчен патриотизм үрнәге булып торуын белдерде»,—диде Р. Закиров.

## ГАЛИМНӘР ЭШЕ БӘЯЛӘНДЕ

Фән һәм техника өлкәсендә 2010 ел өчен Татарстан Республикасы Дәүләт бүләкләрен бирү турында Татарстан Президентының Указы игълан ителде. Табигый, техник һәм гуманитар фәннәрне үстерүгә, яңа технологияләр эшләүгә һәм гамәлгә ашыруга зур өлеш керткәне, фән һәм техника казанышлары нигезендә алынган югары җитештерү нәтиҗәләре өчен 35 галимгә фән һәм техника өлкәсендә Татарстан Республикасы Дәүләт бүләге бирелде.

Алар арасында «Җинаятьчелеккә каршы торуның хәзерге проблемалары һәм аларны хәл итү юллары» дигән хезмәтләр циклы өчен юридик фәннәр докторы, Татарстан Фәннәр академиясе мөхбир әгъзасы, Татарстан Конституция суды судьясы Флер Баһаветдинов һәм «Борынгы чордан алып хәзерге вакытка кадәр дөнья мәдәнияте контекстында татар халкы тарихы» дигән хезмәтләр циклы өчен тарих фәннәре докторы, профессор, Казан дәүләт финанс-икътисад институтының тарих һәм политология кафедрасы мөдире Энгель Таһиров та бар.

## БӨЕК КОМПОЗИТОР ИСТӘЛЕГЕНӘ

Ел ахырында күренекле композитор С. Сәйдәшевнең 110 еллыгы уңаеннан төрле чаралар узды. Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында оештырылган кичә, мөгаен, иң зурысы булгандыр. Бу тантанада композитор көй язган спектакльләрдән өзекләр күрсәтелде. «Казан сөлгесе», «Зәңгәр шәл»не камаллылар күрсәтсә, «Сүнгән йолдызлар»ны тинчуринлылар тәкъдим итте. Зилә Сөнгатуллина, Эмиль Җәләлетдинов, Мингол Галиев, Рөстәм Маликов, Резеда Галимова, Рөстәм Асаев кебек күренекле сәнгать осталары С. Сәйдәшев көйләрен яңгыратты.

С. Сәйдәшев музеенда үткән кичәдә исә композиторның туганнары белән бергә, аны күреп белгән сәнгать әһелләре дә катнашты.

## ПИТЕР ТУКАЙНЫ ЯД ИТТЕ

Татарстан Мәдәният министрлыгы һәм Санкт-Петербургның Татар милли-мәдәни мохтарияте «Ашкынамын... мәңгелеккә» дигән уртак проект тәкъдим итте. Әлеге проект Г. Тукайның 125 еллык юбилее уңаеннан уза торган чараларны ачып җибәрде.

Бәйрәм чаралары Санкт-Петербургның Кронверск проспекты һәм Зверинский урамы кисешкән чатта урнашкан Г. Тукай һәйкәленә чәчәкләр кую белән башланып китте. Аннан соң А. Пушкинның Бөтенроссия музеенда Татарстан Милли музее тупланмаларыннан күргәзмә ачу тантанасы булды. Күргәзмәдә зур урынны Тукайның шәхси әйберләре, исән чагында басылган китаплары алып тора. Анда шагыйрьнең төрле еллардагы фотосурәтләрен һәм аның көндәлек тормышы белән бәйле әйберләрне дә күрергә мөмкин. Алар арасында Тукайның апасы Газизәгә иң беренче гонорарына сатып алган фаянс шкатулка, юл кәрзине, кара хәтфә түбәтәй, «Ан» журналы мөхәррире Әхмәтгәрәй Хәсәнинең шагыйрьгә бүләк иткән көмеш каптырмалары бар.

Күргәзмәдә Татарстан рәссамнары Бакый Урманче, Харис Якупов, Фәйзрахман Әминов, Зөфәр Гыймаев һ. б.ның Тукай һәм аның иҗатына багышланган картиналарын да күрергә мөмкин иде.

Бу көнне Санкт-Петербургның дәүләт академия капелласы бинасында Татарстан сәнгать осталары катнашында концерт та булды. Алар Г. Тукай шигырьләрен, Н. Җиһанов, Ф. Яруллин, Р. Әхиярова һәм башка композиторларның әсәрләрен башкарды.

Тантанада Татарстан Премьер-министры урынбасары—мәдәният министры Зилә Вәлиева катнашты һәм чыгыш ясады.

## КҮКЛӘРГӘ АШКАН ИҖАТ

М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театры бинасында классик шагыйребез Хәсән Туфанның тууына 110 ел тулу уңаеннан «Агыла да болыт агыла...» дип исемләнгән тантаналы кичә үткәрелде. Аны Татарстан Язучылар берлеге рәисе И. Ибраһимов башлап җибәрде.

—Хәсән Туфан әдәбиятка, иҗтимагый хәрәкәткә Г. Тукай, С. Рәмиев, Ф. Әмирхан, М. Гафури, Г. Исхакыйлар кебек бик иртә килә, шагыйрь аларның турыдан-туры дәвамчысы да иде,—диде ул.—Алар кебек

үк, Хәсән Туфан да ил өстенә килгән гарасатның корбаны булды. Ул гарасат төрле елларда Тукайны, Дәрдемәндне, Рәмиевне, Әмирханны, Ибраһимовны, Җәлилне, Кутуйны һәм башкаларны үзенә суырып алды. Тагын 114 татар язучысы һәм шагыйре XX гасырның иң зур афәтләреннән берсе—Ватан сугышы кырларында кан койды. Милләтебез күргән шул фаҗигадән соң:

*Бирде дөнья кирәкне,*
*Еламаска өйрәтте.*
*Кайсыгызның кулы җылы?*
*Бәйлисе бар йөрәкне,—*

дип, ничек язмасын шагыйрь.

—Хәсән Туфан һәрбер татар кешесенең күңелендә яши,—диде үз чыгышында Премьер-министр урынбасары—мәдәният министры З. Вәлиева.—Бу олуг шагыйребез ачы язмышына сабыр гына түзеп яшәде, авыр чакларда да кеше исеменә тап төшермәде, сыгылып төшмәде, тормыштан, халыктан ваз кичмәде, һәммәбезгә дә авырлыкларны җиңәргә көч-куәт бирә торган шәхес булып калды.

Моннан берничә ай элек бер төркем язучылар Хәсән Туфан исеме белән галәмдәге бер планетаны атауны үтенеп, Халыкара астрономия берлеге каршындагы махсус комиссиягә мөрәҗәгать иткән була. Кичәдә катнашкан академик, астрофизик Наил Сәхабетдинов мәдәният министры З.Вәлиевага Кояш системасындагы 48631нче номер белән теркәлгән планетага шагыйрь Хәсән Туфан исеме бирелүен раслаган рәсми документ тапшырды.

Тантаналы кичәдә шагыйрьләр Р. Фәйзуллин, Р. Гаташ, Г. Морат, Р. Зәйдулла, Р. Мөхәммәтшин, Башкортстан шагыйре И. Киньябулатов, җырчылар М. Сөнгатуллин, А. Шаһиморатова, А. Габдинов, Ф. Каһиров, театр артистлары И. Әхмәтҗан, И. Габдрахман, Ә. Хисмәт, Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбле һ. б. катнашты.

## ӘДИПНЕ ИСКӘ АЛДЫЛАР

К. Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театрында язучы һәм шагыйрь Нәби Дәүлине искә алдылар. Әдипнең 100 еллыгына багышланган әлеге чараны Язучылар берлеге оештырды. Аның рәисе Илфак Ибраһимов, профессор Тәлгат Галиуллин Н. Дәүли иҗаты белән таныштырды. Әсәрләрдән өзекләрне К. Тинчурин исемендәге драма һәм комедия театры артистлары һәм театр училищесы студентлары башкарды. Курчак театры Н. Дәүлинең «Җырлап узган җәй» спектакленнән бер күренеш белән таныштырды. Язучы Рәдиф Сәгъди тарафыннан кичәнең сценарие уңышлы эшләнгән. Н. Дәүли шигырьләренә язылган җырларны Мирсәет Сөнгатуллин, Искәндәр Биктаһиров, Рафаэль Сәхабиев башкарды. Әдипнең кызлары Наилә белән Гөлфия ханым әтиләрен искә алулары өчен оештыручыларга рәхмәтләрен ирештерде.

## ШАГЫЙРЬГӘ МЕДАЛЬ ТАПШЫРЫЛДЫ

Танылган шагыйрь Рәниф Шәрипов, Татарстан Президенты Указы нигезендә, «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләнде. Әлеге югары бүләккә ул хәзерге татар әдәбияты үсешенә зур өлеш кертканә, республикабыз хакына күпьеллык нәтиҗәле иҗади эшчәнлеге өчен лаек булды.

Шушы уңайдан аның Казандагы фатирына хөрмәтле кунаклар җыелды. Җөмһүриятебез җитәкчелеге кушуы буенча, Рәниф Шәриповка медальне Татарстан Дәүләт Советы исеменнән Татарстанның халык шагыйре Роберт Миңнуллин тапшырды.

Татарстан Язучылар берлеге рәисе, шагыйрь Илфак Ибраһимов исә Рәниф Шәриповны күпсанлы иҗатчылар исеменнән тәбрикләде, язмыш сынауларын бик муллан кичергән каләмдәшенең күпләр өчен чын мәгънәсендә фидакарьлек үрнәге булуын искәртеп үтте, юбилярга Татарстан Мәдәният министрлыгының чәчәк бәйләмен һәм бүләген тапшырды.

Мәртәбәле медаль иясен котлаучылар арасында Татарстан Әдәбият фонды директоры, язучы Ләбиб Лерон һәм «Мәдәни җомга» газетасының баш мөхәррире, шагыйрь Зиннур Мансуров та бар иде.

## «ТЕАТР БУЛГАН ҖИРДӘ ТАТАР БАР!»

29 ноябрьдә Камал театрында «Идел йорт» X Республика халык театрлары фестиваленә йомгак ясалды. Зур залда җиңүчеләргә бүләкләр тапшырылды.

«Идел йорт» фестивале лауреатларын жюри әгъзасы Әзһәр Шакиров тәбрикләде. «Халык театры булган җирдә татар бар!»—диде ул.

Аннан соң сәхнәгә Татарстанның мәдәният министры Зилә Вәлиева күтәрелде. Ул барлык катнашучыларны, артистларны, тамашачыларны бәйрәм белән тәбрикләде һәм фестивальне оештыручыларга рәхмәт сүзләрен җиткерде.

Аннары сәхнәгә берәм-берәм «Идел йорт» халык театрлары фестиваленең җиңүчеләре аяк басты. Беренче дәрәҗәдәге диплом белән Мамадыш районының мәдәният йорты халык театры бүләкләнде.

Икенче дәрәҗәдәге дипломга Актаныш районы Иске Кормаш авылы мәдәният йортының халык театры лаек булды.

Өченче дәрәҗәдәге диплом Кукмара районының мәдәният йортына тапшырылды.

Җиңүчеләргә дипломнар, чәчәк бәйләмнәре һәм 100әр мең сум акчалата бүләк тапшырылды. Ә менә Гран-при һәм иң төп бүләк—автобус ачкычына Әтнә халык театры лаек булды.

Фестиваль уңаеннан кайбер саннарны да искәртик. Татарстанда 1901 үзешчән театр коллективы бар. Аларның 1786 сы авылда оештырылган. Барлык үзешчән театрларның 300 е—балаларныкы.

«Идел йорт» фестиваленең беренче турында 100дән артык халык театры катнашкан. Сайлап алу этабы Татарстанның төрле район һәм шәһәрләрендә узган. Икенче тур вакытында жюрига барлыгы 44 спектакль карарга туры килгән.

Быелгы фестиваль барышында спектакльләрне барлыгы 21 меңнән артыграк тамашачы караган.

Спектакльләрдә барлыгы 1300 үзешчән артист катнашкан. Алар арасында мәктәп укучылары, эшчеләр, пенсионерлар, укытучылар, сатучылар, медицина хезмәткәрләре һәм башка һөнәр ияләре бар.

### ӘДИБӘ ЮБИЛЕЕ

К. Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театрында Россиянең һәм Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, журналистларның Х. Ямашев исемендәге бүләк иясе, язучы Мәдинә Маликованың иҗат кичәсе узды. Юбилярга Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, Журналистлар берлеге рәисе Римма Ратникова «Фидакарь хезмәтләре өчен» медале тапшырды. Мәдинә ханымны Язучылар берлеге рәисе Илфак Ибраһимов, Сарманнан килгән якташлары тәбрикләде. Казан дәүләт гуманитар-педагогика университеты профессоры Фоат Галимуллин язучыга филология фәннәре кандидаты Лилия Хисмәтова язган «Мәдинә Маликова» дигән монографияне бүләк итте. Камал театры артистлары М. Маликова әсәрләреннән өзекләр укыса, тинчуринлылар аның «Сөембикә» трагедиясеннән күренеш тәкъдим иттеләр.

### АКТЕРГА ХӨРМӘТ

Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында Татарстанның халык, Россиянең атказанган артисты Илдар Хәйруллинга 60 яшь тулу уңаеннан иҗат кичәсе узды. Премьер-министр урынбасары—мәдәният министры Зилә Вәлиева юбилярга «Фидакарь хезмәт өчен» медален тапшырды. И. Хәйруллинны республика театрлары, сәхнәдәшләре, үзенең элекке һәм хәзерге шәкертләре тәбрикләде. Кичәне Татарстанның һәм Россиянең халык артисты Алсу Гайнуллина белән Искәндәр Хәйруллин алып барды.

### КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов, хатыны, Россиянең күренекле шагыйрәсе Белла Әхәт кызы Әхмәдуллинаның вафат булуы сәбәпле, Борис Мессерерга кайгы уртаклашу телеграммасы җибәрде.

«Белла Әхмәдуллина илебез һәм чит илләрдә шигърият сөюче миллионнарча кеше өчен XX гасырда илебез шигъриятенең иң якты символларыннан берсе, Россиянең горурлыгы булды һәм мәңгегә шулай булып калачак. Ул—«легендар алтмышынчы елгылар» сафындагы шәхес, тормыштагы принципларына беркайчан да хыянәт итмәгән кеше буларак абруй яулады. Аның нечкә шигъри күңеле киң колачлы шәхес булуы белән, тирән хисси, ихлас лирикасы ирекле көч-рух, горурлык, намуслылык тулып ашкан гражданлык поэзиясе белән үрелеп барды.

Без Сезнең белән һәм Россиянең бөтен җәмәгатьчелеге белән әлеге югалтуның ачысын сизеп, тирән кайгы тойгылары кичерәбез. Безнең белән аның үлемсез иҗаты һәм якты истәлеге кала»,—диелә республика башлыгы телеграммасында.

### КОТЛЫЙБЫЗ!

Югары квалификацияле белгечләр әзерләүгә зур өлеш керткәне, актив фәнни һәм җәмәгать эшчәнлеге өчен «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары һөнәри белем федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесе профессоры, татар филологиясе һәм тарихы факультеты деканы, татар халкы тарихы һәм мәдәнияте кафедрасы мөдире, тарих фәннәре докторы, Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы **Гыйләҗев Искәндәр Аяз улына** «Татарстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе» дигән мактаулы исем бирелде.

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Беренче биттә:* Польша Республикасында татарга һәйкәл.

*Дүртенче биттә:* язучы **Халисә Ширмән**.

# «Казан утлары» 2011 елда

## РЕДАКЦИЯ ПОРТФЕЛЕНДӘГЕ КУЛЪЯЗМАЛАР

### Г. Тукайның тууына 125 ел

**Р. Батулла.** Тукай. Роман; **Л. Хәмидуллин.** «Китап» ширкәте һәм Тукай; **С. Поварисов.** Тукайның тел тукымалары; **Ф. Дәминова.** Тукай һәм аның Казан төбәгендәге туганнары; **«Печән базары».** Г. Тукай юбилеена багышланган сатирик әсәрләр конкурсы ел азагынача дәвам итә.

### Чәчмә әсәрләр

**Т. Галиуллин.** Китек көзге. Бәян.
**А. Хәлим.** Хунвейбин. Роман-эпопея. Өченче кисәк.
**Р. Мирхәйдәров.** Жәяүле кеше. Бәян.
**М. Әмирхан.** Әлвидаг. Тарихи бәян.
**Р. Кәрами.** Сөеп туймас чакларын. Роман.
**М. Кәбиров.** Бердәнбер һәм кабатланмас. Роман.
**Х. Мөдәррисова.** Соңгы сер. Бәян.
**Т. Нурмөхәммәтов.** Кабан күле әй алкын. Бәян.
**А. Хәсәнов.** Данәгөл. II китап.

### Шигърият

Әйдәп баручы шагыйрьләребезнең яңа поэмалары һәм шигырьләре (**Ә. Баян. Ш. Галиев, Р. Фәйзуллин, Ф. Яруллин, Р. Харис, Р. Миңнуллин, Ф. Гыйззәтуллина, Г. Рәхим, Р. Гаташ, Р. Вәлиев, З. Мансуров, М. Галиев, М. Мирза, Л. Шагыйрьжан, И. Гыйлаҗев, Р. Зәйдулла, Г. Морат, С. Гәрәева** һ. б.).

### Фән

**И. Таһиров.** Татар ничек барлыкка килгән?
**Ә. Хәйри.** Ибне Фазлан сәяхәтнамәсендә хокукый мәсьәләләр.
**Р. Нәбиев.** Урта гасырларда Болгар флоты.
**Х. Миңнегулов.** Татар язмышында Истанбул.
**Р. Галләм, Н. Нәккаш-Исмәгыйль.** Беренче татар басмасы. (1722 елгы «Манифест»)

### Публицистика

**Р. Вәли Карашәмле.** Иң соңгы халык дошманы (Г. Шәрәф)
**Аяз Гыйләҗев**нең Ибраһим Сәлаховка язган хатлары.
**А. Хәмзина.** Атаклы разведчик Ибраһим Аганин.
**Ф. Баттал.** Кадерлеләр һәм кадерсезләр.
**З. Закиров.** Динебез турында уйланулар.

### Әдәби тәнкыйть һәм сәнгать

**Р. Ханнанов.** Төрек татар әдәби бәйләнеше
**Р. Сверигин.** Әдәбият галиме (Ф. Галимуллин)
**И. Низамов.** Әсәр геройлары ничек сөйләшә?
**Ф. Хәсәнова.** Р. Гаташ иҗаты.

**Ә. Шакиров**ның Мөхтәр Мутин һәм Хәлил Әбҗәлилов турындагы мәкаләләре.
**К. Шакиров.** Музыкадан музыкага (көй урлаулар турында).



Халисә Ширмән

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)